АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
ИМЕНИ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Татары Удмуртии*

2-е издание

КАЗАНЬ 2021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

*Удмуртия татарлары*

2 нче басма

КАЗАН 2021

УДК 39(=512.145)(470.51)+930.2+811.512.145+7
ББК 81.2=632.3+82.3(2=632.3)+85.12
М48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

**Редколлегия:**

***К. М. Миңнуллин*** *(рәис),* ***И. И. Шәрипов, М. Х. Вәлиев,***
***М. И. Әхмәтҗанов, И. И. Ямалтдинов, Р.Ф. Сафиуллина***

**Төзүче һәм фәнни мөхәррир**
*филология фәннәре кандидаты* ***М. З. Вәлиева***

**М48** **Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары.** – Казан, 2021. – 2 нче басма. – 400 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).
ISBN 978-5-93091-337-8

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән чираттагы китап Удмуртия Республикасында яшәүче милләттәшләребез, аларның көнкүреше, гореф-гадәтләре, тел үзенчәлекләре турында бай мәгълүмат бирә. Бу җыентыкта борынгы ташбилгеләр, шәҗәрәләр, төбәкнең тарихи шәхесләрен яктырткан язмалар да урын алды. Шулай ук анда төбәкнең халык авыз иҗаты, җыр-моңнары, җирле осталарның кул эшләре, шәмаилләр, мәчетләр белән дә танышырга мөмкин. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең тикшеренү-эзләнүләрен туплаган әлеге басма үз укучыларын табар һәм андагы язмалар һәркемдә зур кызыксыну уятыр дип ышанабыз.

**ISBN 978-5-93091-337-8**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2013, 2021

*Тел – уйлауның коралы, уйның – калыбы...*
*Миллият бинасының нигез ташларыннан*
*иң ныклысы – тел... Телнең эчендә халыкның рухы,*
*моңы, уй һәм тойгысы яшеренгән.*

Галимҗан Ибраһимов

---

*Язык – это инструмент мышления,*
*форма мысли… Самый прочный камень*
*в фундаменте бытия нации – язык… В языке*
*сокрыты душа народа, его мысли и чувства.*

Галимджан Ибрагимов

## КЕРЕШ

Һәр төбәкнең табигать тә, анда яшәүче кешеләр дә, аларның ышанулары һәм дөньяга карашлары да йогынты ясый торган язмышы, йөзе, рухи үзәге-асылы бар. Шушы үзенчәлекне тою-аңлау өчен, әлеге төбәктә яшәү, һич булмаса, андагы тормышны өйрәнү һәм халык белән аралашу кирәк. Болар төбәкнең хәзерге хәл-халәтен күзалларга мөмкинлек бирә.

Үткән-тарих исә күпмедер күләмдә чыганакларда саклана; аларны археологик тикшеренүләр үткәреп тергезәләр; архив документларыннан һәм тарихи һәйкәлләрдән, ташъязмалардан эзлиләр. Археолог-галимнәр борынгы кешеләр турында мәгълүмат сакланган урыннарда разведка уздыра, казу эшләре оештыра һәм, табылдыкларга нигезләнеп, бик ерак тарих хакында төгәл мәгълүматлар китерә. Археологик тикшеренүләр вакытында эралар-чорлар да, шул заманнарда билгеле бер урында яшәгән кешеләрнең кайсы халыкка каравы, көнкүреше, һөнәрләре, нинди технологияләргә ия булуы, ышанулары да, күпмедер күләмдә зәвыгы, мәдәни казанышлары да ачыклана. Алар язма тарихи чыганаклар булмаган ерак заманнарны кабат күзалларга мөмкинлек тудыра, архив материаллары, документлар, эпиграфик һәйкәлләр һ.б. исә безгә якынрак чорлар хакында сөйли.

Алар да күрсәтә алмаган бик күп сәхифәләрне шәҗәрәләр һәм гаилә истәлекләре дә; төбәк кешеләре хәтерендә буыннан-буынга тапшырылып килгән мифлар һәм легендалар, җырлар һәм бәетләр дә; халыкның тел-сөйләм, әдәби фикерләү хасиятләре, көнкүреш һәм мәдәни үзенчәлекләре; матди һәм мәдәни кыйммәтләр дә үзендә саклый. Боларны күрә, аңлый, өйрәнә һәм аңлата белергә генә кирәк. Гаҗәеп күренеш: археологик һәм тарихи чыганакларда сакланмаган мәгълүматлар еш кына кешеләр хәтерендә,

# ВВЕДЕНИЕ

У каждого региона есть свой неповторимый облик, своя судьба, особая духовная составляющая, которые формируются под влиянием местной природы, живущих там людей, их мировоззрения, привычек и верований. Чтобы понять и почувствовать это своеобразие, необходимо здесь пожить или хотя бы понаблюдать местное жизнеустройство и пообщаться с людьми. Только так можно получить представление о современном состоянии региона.

Страницы прошлого в какой-то степени раскрываются в исторических источниках, их восстанавливают посредством археологических исследований, находят в архивных документах и исторических памятниках. Ученые-археологи проводят исследования в местах, сохранивших следы пребывания древних людей, организуют раскопки и, опираясь на сделанные находки, способны представить точную информацию об очень далеких эпохах. Во время археологических изысканий выясняются возраст рассматриваемых объектов, принадлежность населения данной местности к тому или иному народу, особенности их повседневного быта, используемые технологии и ремесла, их верования, эстетические предпочтения и культурные достижения. Археологи дают возможность представить те далекие времена, о которых нет исторических источников.

Исторические источники (архивные материалы, документы, эпиграфические памятники и др.) рассказывают о ближайших к нам эпохах. Многие страницы истории, которые не получили отражение в источниках, сохранились в родословных, семейных преданиях; в передаваемых из поколения в поколение мифах и легендах, песнях и баитах, в специфике разговорной речи и литературного мышления; особенностях повседневной жизни и культуры; в материальных и культурных ценностях населения данного региона. Нужно только

төбәкләрнең тормыш-көнкүрешендә яшәвен дәвам итә! Аларны төрле тармак галимнәре төбәкләргә экспедиция-сәфәрләр уздырып барлый, таба, өйрәнә... Аннары бу материаллар кабат халыкка кайта, шушы урынның, төбәкнең һәм бердәм татар милләтенең тарихи-мәдәни байлыгына әйләнеп яши бирә.

Татарстандагы академик фән, тарихи, археологик тикшеренүләр белән бергә, төбәкләргә чыгып, урыннарда халыкның яшәешен, көнкүрешен, матди һәм мәдәни хәл-халәтен өйрәнү белән һәрвакыт шөгыльләнә. Мондый тикшеренүләр XIX–XX гасыр чикләрендә үк аерым татар зыялылары инициативасы белән уздырыла башлый: бик күп татар җырларын, әкиятләрен, мәкаль-әйтемнәрен, миф-легендаларны язып алырга, татарларның тел-сөйләм үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, К. Насыйри беренчеләрдән булып татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, тарихи-этнографик тикшеренү эшен башлап җибәрә, 1871 елдан үзенең «Казан календаре»нда фольклор үрнәкләре бастыра. Бу эшкә Р.Ф. Фәхреддин, Г.Н. Әхмәрев, Х.Б. Бәдигый, Җ.Җ. Вәлиди һ.б. бик күп фикер ияләре кушыла.

XX гасырның аерым чорларында мондый тикшеренүләрне оештыруда активлык күзәтелә. 1920–1930 елларда – бигрәк тә Гыйльми үзәк эшчәнлеге белән бәйле махсус экспедицияләр фәнни нигездә уздырыла башлый. Н.И. Воробьев, А.С. Башкиров, Ф.И. Терегулов, М.С. Гобәйдуллина, К.С. Гобәйдуллин, С.Г. Вахиди һ.б. тарафыннан Арча, Әлки, Балык Бистәсе, Мамадыш, Минзәлә, Спас, Чаллы, Чистай төбәкләрендә шундый кыр тикшеренүләре үтә; аларда этнография, фольклор, сәнгать, тарихи-мәдәни мираска караган материаллар туплана.

Мондый эшчәнлек хәтта Бөек Ватан сугышы чорында да туктамый. 1940–1980 елларда аерым тармак галимнәренең махсуслаштырылган экспедицияләргә чыгуы киң тарала. Бигрәк тә эпиграфик (Һ.В. Йосыпов), археографик һәйкәлләрне (С.Г. Вахиди, М.И. Әхмәтҗанов, М.Г. Госманов һ.б.), диалектларны (Л.Җ. Җәләй, Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова һ.б.), төрки-татар фольклорын (Х.Х. Ярмөхәммәтов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Мәхмүтов, Л.Ш. Җамалетдинов һ.б.) җыю-барлау максатыннан, Татарстанда һәм аннан читтә яшәүче татар авыллары һәм шәһәрләрендә тикшеренүләр уздырыла. Экспедицияләрдә

увидеть, понять, изучить и правильно интерпретировать эти явления. Удивительно то, что материалы, не сохранившиеся в археологических и исторических источниках, часто продолжают жить в памяти людей, в повседневном жизненном пространстве населения данной местности! Ученые и специалисты в различных областях знаний во время экспедиций в регионы находят, собирают, изучают эти особенности… А затем эти материалы, после комплексного изучения, возвращаются к народу и продолжают жить, став частью общего историко-культурного наследия татарского народа и данного региона.

Академическая наука Татарстана, наряду с историческими и археологическими изысканиями, всегда держала в центре своего внимания изучение жизни, быта, особенностей материального и культурного состояния татарского народа, проживающего в том или ином регионе. Подобные исследования проводились во время экспедиционных выездов по инициативе представителей татарской интеллигенции, на рубеже XIX–XX веков было записано много татарских песен, сказок, пословиц и поговорок, мифов и легенд; зафиксированы местные особенности татарского языка и речи. Например, К. Насыри одним из первых начал собирать материалы по устному творчеству татарского народа и по исторической этнографии; с 1871 года он регулярно публиковал образцы фольклора в своем «Казанском календаре». К этой работе присоединились Р.Ф. Фахретдинов, Г.Н. Ахмеров, Х.Б. Бадиги, Дж.Дж. Валиди и другие представители татарской интеллигенции.

В отдельные периоды XX века наблюдалась особая активность в организации подобных исследований. В 1920–1930-е годы начинают проводиться специальные научные экспедиции, что было связано с деятельностью созданного Академического центра. Подобные полевые исследования осуществляли Н.И. Воробьев, А.С. Башкиров, Ф.И. Терегулов, М.С. Губайдуллина, К.С. Губайдуллин, С.Г. Вахиди и др. в Арском, Алькеевском, Рыбно-Слободском, Мамадышском, Мензелинском, Спасском, Челнинском, Чистопольском районах, собирая при этом материалы по этнографии, фольклору, искусству, историко-культурному наследию данных регионов.

Эта работа не прекращалась даже в годы Великой Отечественной войны. В 1940–1980-е годы широкое распространение получили специализированные экспедиции. В Татарстане и за его

тупланган материал «Татар халык иҗаты» (1951, 1954), «Татар халык әкиятләре», 2 томда (1946, 1956), «Татар халык җырлары» (1965), «Татар халык иҗаты», 12 томда (1976–1988), «Татар халык сөйләшләре», 2 томда (2008), «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (2009), «Татар халык сөйләшләренең атласы», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) кебек фундаменталь хезмәтләр, мәдәният-сәнгать тарихы, милли һөнәрчелек, кулъязма һәм басма китап тарихы һ.б. өлкәләр буенча күпсанлы китаплар нигезендә ята.

XXI гасыр башында, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең системалы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, бу эш яңа баскычка күтәрелә: һәр елны милләттәшләребез яшәгән төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештырыла башлый. Комплекслы рәвештә өйрәнгәндә, тел, әдәбият, фольклор, сәнгать юнәлешенең төбәк хәзинәсендә булган барлык төр байлыгы – буыннан-буынга тапшырыла килгән авыз иҗаты үрнәкләре, бәйрәмнәре, йола-гадәтләре, музыкасы, бәйләү-чигү кебек кул эшләре осталыгы, йорт-каралты бизәкләре, кием-салымы, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе барлана-туплана һәм җентекләп анализлап бәяләнә. Татарстанда Актаныш (2009), Апас (2010), Кукмара (2011), Чүпрәле (2012), Мамадыш (2013), Арча, Әтнә (2016), Минзәлә, Мөслим (2017), Азнакай, Буа (2019) районнарындагы татар авыллары һәм поселокларында шундый кыр тикшеренүләре уза.

Татарстаннан читтә: Түбән Новгород, Курган, Оренбург өлкәләре (2010), Мари Илендәге Бәрәңге районы (2011), Удмуртия Республикасы (2012), Пермь краендагы Барда районы һәм Әстерхан өлкәсе (2013), Омск һәм Самара (2014), Оренбург һәм Томск (2015), Чиләбе өлкәләре, Казакъстан Республикасы (2016), Новосибирск өлкәсе, Башкортстан Республикасының Стәрлебаш районы (2017), Ульяновск (2017, 2018), Иркутск, Киров (2018), Пенза, Төмән өлкәләре, Үзбәкстан Республикасы (2019) җирләрендә булып, анда яшәүче милләттәшләребезнең тел-сөйләш үзенчәлекләрен, тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, сәнгатен, кулъязма һәм ташъязма мирасын барлау, аларны фәнни эшкәртү, тикшерү эше җайгасистемага салына.

Экспедициядә җыйган материалларны тикшерү, өйрәнү, фәнни әйләнешкә кертү белән бергә, шушы вакыттан Татарстан Фәннәр

пределами, в местах компактного проживания татар, проводились исследования по сбору эпиграфических (Х.В. Юсупов), археографических (С.Г. Вахидов, М.И. Ахметзянов, М.Г. Усманов и др.) памятников, изучению диалектов (Л.Дж. Заляй, Л.Т. Махмутова, Н.Б. Бурганова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова и др.), образцов тюрко-татарского фольклора (Х.Х. Ярмухаметов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Махмутов, Л.Ш. Замалетдинов и др.). Собранные в экспедициях материалы легли в основу таких фундаментальных трудов, как «Татарское народное творчество» (1951, 1954), «Татарские народные сказки», в 2-х томах (1946, 1956), «Татарские народные песни» (1965), «Татарское народное творчество», в 12 томах (1976–1988), «Татарские народные говоры», в 2-х томах (2008), «Диалектологический словарь татарского языка» (2009), «Атлас говоров татарского народа», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) и многочисленных книг по истории культуры и искусства, народных ремесел, истории татарской рукописной и печатной книги и др.

В начале XXI века, благодаря системным усилиям Академии наук Республики Татарстан, эта работа вышла на новый уровень: началась организация комплексных экспедиций в регионы проживания представителей татарского народа. В ходе комплексного изучения собираются, тщательно оцениваются и анализируются все богатства духовной сокровищницы региона: язык, литература, фольклор, искусство, то есть все то, что передавалось из поколения в поколение – образцы устного творчества, праздничные традиции, обрядовая культура, музыка, искусство вышивки, убранство домов, одежда, особенности языка, эпиграфическое и археографическое наследие. В Татарстане подобного рода полевые исследования были проведены в деревнях и селах Актанышского (2009), Апастовского (2010), Кукморского (2011), Дрожжановского (2012), Мамадышского (2013), Арского, Атнинского (2016), Мензелинского, Муслюмовского (2017), Азнакаевского, Буинского (2019) районов.

За пределами Татарстана также налажена системная работа по сбору, научной обработке, изучению особенностей говоров, повседневного быта, культуры, искусства, рукописного и эпиграфического наследия татар, проживающих в Нижегородской, Курганской, Оренбургской областях (2010), Параньгинском районе Марий Эл (2011), Удмуртской республике (2012), Бардымском районе Пермского края

академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында 1940–2000 елларда шул ук төбәкләргә, авылларга уздырылган экспедиция материалларын барлау, яңа кайткан мәгълүматлар белән чагыштыру башкарыла. Шул җирлектә фәнни хезмәтләр әзерләнә. Әйтик, бүген инде галимнәребез «Татар халык иҗаты»ның 25 томлыгын төгәлләү алдында.

Элегрәк җыелган һәм яңа гына алып кайтылган материалларны бергә туплау «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә «Милли-мәдәни мирасыбыз» гомуми исеме астында фәнни-популяр китаплар әзерләү эшен башлап җибәрергә этәргеч була. Бу эшнең максаты – халыкның рухи байлыгын үзенә кайтару, аны популярлаштыру, тарихка кертеп калдыру, шушы мәгълүматлар ярдәмендә татар халкының милли үзаңын ныгыту.

Бүген инде бу сериядән 20 китап дөнья күрде, яңаларын әзерләү дәвам итә. Китапларда экспедиция үткән һәр төбәкнең мәдәни тарихы, танылган нәселләр, авыллар-шәһәрләрнең үткәне, гореф-гадәтләре һәм тел үзенчәлекләре төрле яктан яктыртыла. Шулай ук шәҗәрәләр, җирле кул осталарының эш үрнәкләре, кызыклы экспонатлар турында бай мәгълүмат бирелә.

Татар халкының рухи асылын, тарихи-мәдәни сыйфат-билгеләрен бербөтен итеп күзаллау һәм тергезүнең иң нәтиҗәле һәм ышанычлы ысулы булып фәнни экспедицияләр, кыр тикшеренүләре тора. Чөнки бу яшәеш бик борынгыдан килә, татар халкы Евразиянең гаять киң территориясендә формалашкан! Төрле табигый, тарихи, конфессиональ шартларда, төрле этник тирәлектә (төрки халыкларның төрле төркемнәре, фин, угор, славян этнослары янәшәсендә) татарларның этнотерриториаль (Идел-Урал буе, Себер, Әстерхан татарлары), субэтник (Казан, Касыйм татарлары, мишәрләр), субконфессиональ (керәшеннәр, иштәкләр, нагайбәкләр) төркемнәре барлыкка килгән. Бу төркемнәр кая гына яшәвенә карамастан, гомумтатар милли үзаңына ия. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты уздыра торган экспедиция материаллары нәкъ шул хакта сөйли, һәр сәфәр шушы фикерне куәтли.

Әлбәттә, уртак милли үзаңның нигезен татар теле тәшкил итә. Төрки телләрнең кыпчак төркеменә караган татар теле иң борынгы телләрдән санала. Татар теленең төп лексик, фонетик, грамматик

и Астраханской области (2013), Омской и Самарской (2014), Оренбургской и Томской (2015), Челябинской областях и Республике Казахстан (2016), Новосибирской области и Стерлибашевском районе Республики Башкортостан (2017), Ульяновской (2017, 2018), Иркутской и Кировской областях (2018), Пензенской, Тюменской областях и Республике Узбекистан (2019).

Наряду с исследованием, изучением и введением в научный оборот материалов, найденных в экспедициях, ведется работа по сопоставлению новых сведений с материалами, которые были собраны в этих местах ранее – в 1940–2000-х годах и хранятся сейчас в архиве ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. На их основе готовятся серьезные научные труды. К слову, на сегодняшний день завершается работа над фундаментальным 25-томным сводом «Татарское народное творчество».

Проведенные исследования на основе объединения всего комплекса собранных материалов позволили начать работу по подготовке научно-популярных книг под общим названием «Национально-культурное наследие» из серии «Из сокровищницы научных экспедиций». Возвращение народу духовного наследия, популяризация и сохранение его в анналах истории способствует укреплению национального самосознания татарского народа.

На сегодняшний день увидели свет 20 книг из этой серии, продолжается подготовка новых. В книгах представлены обширные сведения по истории региона, прошлом известных татарских родов, деревень и городов, а также об обычаях, традициях и языковых особенностях татар. Вместе с тем в книгах дается богатая информация о родословных, работах местных умельцев и других интересных экспонатах.

Единственно надежным и достоверным способом составления общего представления о духовных основах и историко-культурных особенностях татарского народа является организация научных экспедиций и полевых исследований. Это связано с тем, что образ жизни татар формировался с древних времен и на очень обширной территории Евразии. Различные этнотерриториальные (татары Волго-Уральского региона, сибирские, астраханские татары), субэтнические (казанские, касимовские татары, мишары), субконфессиональные (кряшены, иштяки, нагайбаки) группы татар сформировались в разнообразных природных, исторических, конфессиональных условиях и в сложном этническом окружении

үзенчәлекләре борынгы төрки телдә үк формалаша. Шуңа күрә дә дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче татарларның, төрле сөйләш вәкилләре булсалар да, тел-сөйләмнәре уртак лексик, фонетик, грамматик калыпларга-кануннарга нигезләнә. Шуңа күрә без борынгы рун язулы истәлекләрне укып, эчтәлегенә төшенә алабыз, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан һ.б. төрки телләрне дә аңлыйбыз, татар теленең төрле диалектларында да зур аермалар сизмибез.

Татар милли әдәби теле исә XIX–XX гасырлар чигендә Казанда, Уфада, Оренбургта, Троицкида, Әстерханда һ.б. шәһәрләрдә һәм алар тирәсендәге авылларда гомумхалык теле булып оешып җитә. Тукай теле, Туфан теле, Еники теле – барыбыз өчен дә уртак байлык. Татар әдәби теленең үсеше барышында кайбер традицион хасиятләр һәм формалар югала, әмма алар сөйләшләрдә саклanып кала. Димәк, төрле урыннарда компактлы яшәгән татарларның сөйләшләре борынгы уртак телебезнең үзенчәлекләрен югалтмавы белән дә кадерле. Экспедицияләр материалы безгә шул хакта да сөйли.

Татарларның мәҗүси заман ышанулары ислам дине белән бәйле күзаллаулары белән беррәттән бүген дә халык арасында яши. Бигрәк тә безнең халкыбыз тарихында мең еллык урыны булган ислам диненең һәм матди, һәм мәдәни тормышка йогынтысы халыктан җыелган материалларда аермачык күренә. Каберташ язмалары, борынгы китаплар һәм кульязмалар, шәкерт дәфтәрләре, күчереп язылган текстлар, әдәп-әхлак кагыйдәләре, йола-гадәтләр, ышанулар һәм күзаллаулар, бәйрәмнәр һәм ырымнарда татар халкының барлык этник төркемнәре өчен уртак булган мәдәни мирас чагылыш таба. Ислам мәдәнияте гадәти көнкүреш һәм кеше тормышындагы иң мөһим вакыйгаларга (туу, исем кушу, өйләнү, гаилә, бакыйлыкка күчү) бәйле йолаларда этник мәдәнияткә үрелеп китә. Вакытны күрсәткән азан тавышы, намаз-догалар, җомга көнне бәйрәм дип карау белән бергә, татар халкының мәдәни хәтеренә бәетләр, мөнәҗәтләр, дини-суфичыл текстлар кереп урнаша. Традицион йолалар һәм бәйрәмнәр: Сабан туе, Җыен, Корбан гаете, Ураза гаете, өмәләр, Карга боткалары һәм Яңгыр боткалары – болар да уртак байлыгыбыз һәм татарлыгыбызның аерылгысыз билгеләре.

Комплекслы экспедицияләр вакытында төрле җирлекләрдә кием-салым, һөнәрләр, азык-төлек әзерләү рәвеше, архитектура,

(рядом с разными группами тюркских народов, финно-угорскими, славянскими этносами). Несмотря на то, что данные группы татар проживают на различных территориях, они все объединены общетатарским национальным самосознанием. Каждая экспедиция ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ и собранные материалы неуклонно подтверждают это.

Разумеется, фундаментом общего национального самосознания является язык. Татарский язык, относящийся к кипчакской группе, считается одним из самых древних языков. Основные лексические, фонетические, грамматические особенности татарского языка сформировались уже в древнетюркском языке. Именно поэтому татар, проживающих в разных местах и являющихся представителями разных говоров, объединяет единая основа – общие лексические, фонетические, грамматические закономерности. Благодаря этому мы можем понять самые древние рунические письмена, понимаем казахский, узбекский, азербайджанский и другие языки, не ощущаем большой разницы между диалектами татарского языка.

Становление татарского литературного языка в качестве общенародного происходит на рубеже XIX–XX веков в городах Казань, Уфа, Оренбург, Троицк, Астрахань и др., а также окружающих их селах. Язык Тукая, язык Туфана, язык Еники – это наше общее богатство. В ходе развития татарского литературного языка теряются некоторые его традиционные свойства и формы, но они сохраняются в говорах. Поэтому говоры татар, компактно проживающих на разных территориях, ценны для нас сохранением особенностей нашего древнего общего языка. Материалы экспедиций говорят именно об этом.

В народе и сегодня продолжают сосуществовать древние домусульманские верования татар и представления, связанные с исламом. Материалы экспедиций особенно ярко демонстрируют влияние ислама на материальную и культурную жизнь нашего народа на протяжении его тысячелетней истории. Общее культурное наследие всех этнических групп татар ярко выражены в надгробных памятниках, древних книгах и рукописях, тетрадях шакирдов, списках литературных произведений, нравственно-этических нормах, обрядах и обычаях, представлениях и поверьях, праздниках и верованиях. В моменты самых важных событий человеческой жизни (рождение,

музыка сәнгате буенча да күзәтүләр ясала. Әйтик, төрле җирләрдә яшәүчеләрнең киемнәрендә үзгәлекләр булса да, татарларның традицион гомуммилли өс киеме Казан татарларыныкы йогынтысында формалашкан дигән фикер безнең материаллар белән дә тагын бер тапкыр раслана. Татарлар кайда гына төпләнмәсен – мәчет торгыза. Халкыбызның һәрчак белемгә омтылышы, балалар тәрбияләүгә зур әһәмият бирүе, олыларга аерым бер хөрмәт белән каравы, туган җир һәм нәсел-ыруның һәр кешене саклаучы-яклаучы көч дип санавы, шигърияткә-иҗатка тартылуы да кыр тикшеренү нәтиҗәләрендә чагылыш таба.

Республикабыздагы күтәрелеш татар дөньясының җанлануына, милли үзаң уянуга, татарларның үзләрен бердәм халык итеп тоя башлавына китерде. Хәтта элек-электән туган җирләре, ватаннары бик еракта – әйтик, Польшада яки Литвада, Әстерханда яки Иранда, Уралда яки Себердә, Кытайда яки Финляндиядә булса да, уртак тарих, уртак мәдәният һәм Казан, Татарстан татарларны берләштереп торган үзәк булып кала.

Һәр милләт булып җитешкән бердәмлек төрле мәдәниятләрнең хасиятләрен үзенә туплый. Бу – аксиома. Көчле мәдәният үз тирәсенә башкаларны тарту сәләтенә ия. Алтын Урда чорында ук «татар казаны» күп кабиләләрне кайната, шул исәптән болгарларны да татар политонимына юнәлдерә.

Татар тарихы сикәлтәле, б.э.к. III гасырдан башлап язма истәлекләрдә эз калдыра. Шул ерак гасырлар чоңгылында Бөек кытай диварыннан төньяктарак төрки телле һуннарның империясе төзелә. II гасырда ул хәзерге Казакъстан далаларына күченә. Идел һәм Урал арасында угорлар белән укмаша, IV гасырда Европага юнәлә, халыкларның Бөек күчешен башлап җибәрә. Һуннарның нәсел тамгасы – казан – безнең башкалабыз Казанның да үзәгендә, Казансу буеннан милләттәшләребезне сәламли.

V гасырда Һун империясе таркала – Бөек кытай диварыннан Дунайга кадәр җирләрдә Бөек Төрки каганлык калкып чыга. Аның җимерелүеннән соң исә Болгар цивилизациясе чәчәк ата. Көнчыгышта куәтле татар халкы үзенең дан-шөһрәтен яңгырата. Алтын Урда таркалгач, аның варислары ханлыклар төзи. Бүген алар касыйм, әстерхан, себер татарлары, мишәрләр, керәшеннәр, нагайбәкләр һ.б. атамалар белән исемләндереп йөртелгән

имянаречение, свадьба, семейная жизнь, похороны) традиции исламской культуры тесно переплетаются с обрядами этнической культуры. Наряду со звуками азана, по которым определяли время, с молитвами, с обычаем считать пятницу праздничным днем и т. д. в культурную память татарского народа вошли баиты, мунаджаты, религиозно-суфийские тексты. Наши традиционные обряды и праздники: Сабантуй, Джиен, Курбан байрам, Ураза байрам, коллективные помочи (өмә), обряды вызывания дождя и встречи весны – все это тоже наше общее наследие и то, что делает нас татарами.

Во время комплексных экспедиций в различные места проживания татар изучаются одежда, ремесла, традиции приготовления пищи, архитектура, музыкальное искусство и т. д. Например, наши материалы ещё раз подтвердили мысль о том, что, несмотря на некоторые различия в одежде татар разных регионов, очевидно, что традиционная национальная татарская одежда сформировалась под влиянием казанских татар. Где бы ни селились татары, они воздвигали мечети. Стремление народа к знаниям и просвещению, большое внимание, которое они уделяют воспитанию детей, особое уважение к пожилым, почитание родной земли и своего рода – как оберегающих и защищающих сил, склонность к поэтическому творчеству – все это отражается в материалах полевых исследований.

Разумеется, современная жизнь татар, где бы они ни жили, связана с Татарстаном. Общественный и духовный подъем в нашей республике способствовал оживлению татарского мира, пробуждению национального самосознания, осознанию татарами себя как единого народа. Даже для татар, чьей родиной давно является Польша или Литва, Астрахань или Иран, Урал или Сибирь, Китай или Финляндия, средоточием общей истории, общей культуры и единым связующим звеном остаются Казань и Татарстан.

Каждая общность, достигшая уровня нации, вбирает в себя свойства различных культур. Это – аксиома. Сильная культура обладает способностью консолидировать вокруг себя другие. В эпоху Золотой Орды в «татарском котле» перекипели многие племена, по той же причине название «булгары» стало татарским политонимом.

Перипетии татарской истории нашли отражение в письменных источниках, начиная с III века до нашей эры. В те далекие времена к северу от Великой китайской стены формируется тюркоязычная

төркемнәр буларак билгеле. Аларны бер тел, бер югары мәдәният – Мәрҗани фәһеме, Тукай шигырьләре, Сәйдәш музыкасы, Урманче сурәтләре берләштерә.

Татар асылын, аның рухи үзәген, татарлыкның гомуми һәм үзенчәлекле сыйфатларын аңлау-төшенү өчен, һичшиксез, тарихи барышны гына түгел, бәлки халыкның хәтерендә яшәгән рухи кыйммәтләрне дә барларга, өйрәнергә кирәк. Татарстан Фәннәр академиясе, аның институтлары, шул исәптән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре әлеге юнәлештә эшлиләр. Дөрес, татарлар элек-электән күпләп яшәгән барлык урынчылыклар да өйрәнелгән дияргә иртәрәк әле. Димәк, бу эш дәвам итәргә тиеш.

Фәнни күзлектән караганда, борынгы һәм бай тарихлы, үз әдәби теле, профессиональ әдәбияты һәм сәнгате булган бердәм татар милләте без. XX гасырда татар мәдәнияте, мәгариф һәм фән югары үсеш ала. Бу процесста төрле җирләрдә яшәгән, төрле этнографик төркемнәргә караган татарларның өлеше зур. Безнең көчебез – бердәмлектә!

* * *

Әлеге китап Удмуртия Республикасының Балезино, Глазов, Юкамен районнарында көн күрүче милләттәшләребезнең тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, халык авыз иҗатын, кулъязмаларын барлау-тикшерүгә багышлана. 2010 елгы статистик мәгълүматлар буенча, Удмуртиядә яшәүче татарлар саны 98 831 кеше тәшкил итә.

Тарихчылар күрсәтүенчә, Удмуртиядәге татар-нократ сөйләше вәкилләренең ерак бабалары Болгар дәүләте составында булган, алар төньяктагы халыклар белән мех һәм башка товарлар алышып сәүдә иткәннәр, төньякта үзләренең факторияләрен булдырганнар. Монгол яуларыннан соң Болгар дәүләте халкының тынычсыз көннәре башлана. Халык төньякка, көнбатышка, көнчыгышка күчеп китә башлый. Борынгы удмурт җирләренә дә аларның шулай килеп төпләнүләре ихтимал.

Удмуртиянең кайбер авылларында яшәүче татарлар биредәге удмуртлар һәм бисерманнар белән аралашып көн иткәннәр. Фәнни әдәбиятта бисерманнарне удмурт халкының бик үзенчәлекле бер

империя хуннов. Во II веке они переселяются в степи современного Казахстана. Сплотившись с уграми между Волгой и Уралом, они устремились в Европу, начав процесс Великого переселения народов. Не случайно родовая тамга рода хуннов – казан – сегодня приветствует наших соотечественников на берегу реки Казанки в центре Казани.

В V веке Хуннская империя распадается, и на землях от Великой китайской стены и до Дуная возникает Великий Тюркский каганат. После его распада получает расцвет Булгарская цивилизация. Могучий татарский народ во весь голос заявляет о себе на востоке. После распада Золотой Орды её наследники создают отдельные ханства. Сегодня их потомки живут как касимовские, астраханские, сибирские татары, мишари, кряшены, нагайбаки и другие группы. Их объединяют общий язык, общая высокая культура – интеллект и разум Марджани, поэзия Тукая, музыка Сайдашева, творения Урманче.

Для понимания сути народа, его духовной сущности, общих и специфических особенностей татарства, безусловно, надо изучать не только историю, но и сохранившиеся в памяти народа духовные ценности. Академия наук Татарстана, её институты, в том числе ученые ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, работают в данном направлении. Естественно, ещё не все местности и регионы исторического проживания татар охвачены и изучены. Значит, эта работа должна продолжаться.

Если судить с научных позиций, то мы – единая татарская нация с древней и богатой историей, имеющая свой литературный язык, профессиональную литературу и искусство. В XX веке культура, просвещение и наука татарского народа достигли очень высокого уровня. В этом процессе незаменима роль татар, проживающих в разных регионах и представляющих различные этнографические группы. Ведь наша сила – в нашем единстве!

* * *

В этой книге представлены материалы, относящиеся к культуре, традициям, повседневному быту, устному народному творчеству, рукописному и книжному наследию татар, проживающих в Балезинском, Глазовском, Юкаменском районах Удмуртской Республики. Согласно статистическим данным 2010 года в республике проживало 98 831 человек татарской национальности.

этнографик төркеме итеп карыйлар. Аерым мәгълүматларга караганда, алар, килеп чыгышлары буенча төрки халык булып, тарихи сәбәпләр аркасында удмурт теленең көньяк диалектын үзләштергәннәр, үзләре исә төньяк Удмуртиядә, удмурт теленең төньяк диалектында сөйләшүчеләр арасында утырып калганнар. Удмуртлар белән аралашып яшәүче татарларның гореф-гадәтләре һәм йолаларында уртаклыклар күп.

Болгарлар белән бәйле 1323 елгы кабер ташы, Бигер-Шай каберлекләре кебек тарихи истәлекләр XIV гасыр башында Чыпца буйларында татар авыллары булганлыгы турында сөйлиләр. Гасырлар узган саен әлеге фикерләрне раслый торган фактлар өстәлә бара.

Алда әйтелгән районнарга экспедициягә баруыбыз очраклы түгел. Удмуртия Республикасының бик матур җирендә урнашкан татар авыллары кабатланмас колориты белән үзенчәлекле. Матур аһәңле һәм ифрат бай туган телебез, әби-бабаларыбызның ядкяре булып киләчәк буыннарга тапшырыла килгән моңлы көйләребез, татар йортларының үзенчәлекле бизәлеше, алтын куллы осталарның зәвыклы кул эшләре – болар барысы да биредә күз карасыдай саклана. Күпләрнең өендә әле дә иске кульъязмалар һәм китаплар очратырга мөмкин. Мәсәлән, мәшһүр «Бәдәвам», «Бакырган китабы», «Ахырзаман китабы», «Әхтәри кәбир», «Кисекбаш китабы» һ. б. кебек әдәби җәүһәрләрнең шушы төбәктә дә табылуы – үткән буыннарның укымышлы һәм югары мәдәнияткә ия булуын тагын бер кат дәлилли. Гомумән, милли мәдәниятебезгә ихтирамлы һәм сакчыл караш шушы төбәк халкының һәр гамәлендә чагылыш таба.

Удмуртиянең татарлар яши торган авылларында рухи хәзинәләрне туплау һәм өйрәнү узган гасыр урталарында ук башлана. 1956 елда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты Удмуртия АССРның Юкамен, Глазов, Балезино районнары һәм Киров өлкәсенең Слободской районына фольклор экспедициясе оештыра. Аны Хәмит Ярми җитәкли, хезмәткәрләрдән Халидә Гатина, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Шәех Зәбиров катнаша. Галимнәр, икегә бүленеп, әлеге районнарда булалар. Шул рәвешле, фән өчен кирәкле шактый материал туплыйлар.

Согласно мнению историков, далекие предки нынешних носителей нукратского говора татарского языка когда-то входили в состав Булгарского государства, они торговали с народами, жившими севернее, мехами и другими товарами, создавали на севере свои фактории. После начала монгольского нашествия для населения Булгарского государства наступили тяжелые времена. Люди начали переселяться на север, на запад, на восток. Возможно, именно так часть татар пришла на древние удмуртские земли и обосновалась там.

Татары в повседневной жизни тесно общались с удмуртами и бесермянами. В научной литературе бытует мнение, что бесермяне – это очень своеобразная этнографическая группа в составе удмуртского народа. Согласно некоторым источникам, они, являясь по происхождению тюркским народом, в силу исторических причин освоили южный диалект удмуртского языка, но живут в северной части Удмуртии, среди носителей северного диалекта удмуртского языка. В силу общности территории проживания – у татар и удмуртов много общего в традициях и обрядах.

Такие артефакты, как намогильный камень 1323 года, могила Бигер-Шая, говорят о том, что в начале XIV века по берегам р. Чепца располагались татарские деревни. С течением времени обнаруживается все больше фактов, подтверждающих это мнение.

Экспедиция в упомянутые выше районы была организована не случайно. Татарские деревни, расположенные в удивительно красивых уголках Удмуртии, отличаются неповторимым своеобразием. Благозвучный и лексически богатый татарский язык, задушевные песни, передающиеся от поколения к поколению, особые традиции украшения домов, чудесные произведения местных умельцев – все это здесь ценится и ко всему особое бережное отношение. Во многих семьях до сих пор хранятся старинные рукописные и печатные книги. Например, списки известных литературных жемчужин, таких как «Бәдәвам», «Бакырган китабы», «Ахырзаман китабы», «Әхтәри кәбир», «Кисекбаш китабы», были найдены и в этом регионе, что еще раз подтверждает мысль о том, что жившие здесь издавна татары обладали достаточно высоким уровнем образования и культуры. Уважительное и бережное отношение к национальной культуре вообще свойственно населению этого края и сквозит во всем.

Х. Ярми белән Х. Гатина, Татар Парҗысы, Кистем, Паюра, Әхмәди авылларында булып, барлыгы 1232 кыска җыр, 4 сюжетлы җыр, 27 халык уены, 1 бәет, 16 табышмак һәм мәкальләр теркәп кайталар.

Х. Мәхмүтов белән Ш. Зәбиров Дасис (Засеково), Иманай, Кече Вениш (Малый Вениж), Зур Палагай, Пүчинкә, Тегермән (Татарские Ключи), Татар Парҗысы, Кистем, Паюра авылларыннан барлыгы 2021 кыска җыр, 2 сюжетлы җыр, 61 халык уены, 3 бәет, 148 табышмак һәм мәкаль, 1 әкият, 4 авылның тарихын язып алалар.

1956 елгы экспедиция вакытында фольклор әсәрләрен язып алырга ярдәм иткән бер кеше дә онытылмаган, аларның исем-фамилияләре бүгенге көндә Институтыбызның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана торган кайчандыр үзләре тәкъдим иткән текстлар янәшәсенә теркәлгән.

Шул рәвешчә, Удмуртиядәге беренче сәфәрдән соң ярты гасырдан артык вакыт узганны исәпкә алып, 2012 елның июнь аенда яңадан әлеге республиканың шул ук районнарына комплекслы экспедиция оештырылды, анда катнашучылар биш юнәлештә эш алып бардылар.

Күренекле диалектологлардан Д. Рамазанова һәм Ф. Баязитова белән яшь галимә М. Булатова тел үзенчәлекләрен өйрәнделәр. Алар үзләре алып кайткан диалекталь материалларны, гореф-гадәт һәм йолаларны чагылдырган лексиканы тикшерү-өйрәнү нәтиҗәләрен әлеге җыентыкка кергән мәкаләләрендә шактый тулы яктырталар.

Шушы төбәктә яшәгән атаклы шәхесләрнең нәсел шәҗәрәләре белән бәйле мәгълүматлар Институтыбызның танылган археографы Марсель Әхмәтҗанов хезмәтләрендә урын ала.

Эпиграфик һәм археографик мирасны өйрәнүче яшь галим А. Гайнетдинов экспедициядән йөзләгән кулъязма китап һәм дәфтәр алып кайтты. Удмуртия татарларында сакланып калган кулъязмалар арасында Шәехбаба хакындагы мөнәҗәтләр, имам Газалинең сирәк басмалардан саналган «Әййүһәл-вәләд» дигән әсәре һ. б. хезмәтләрнең булуы бу төбәк тарихының ерак борынгылыкка барып тоташуын раслый.

Халык авыз иҗаты исә И. Закирова һәм И. Ямалтдинов тарафыннан тупланды. Х. Мәхмүтовның 1956 елгы экспедиция көндә-

Сбор и изучение духовного наследия народа в татарских деревнях Удмуртской Республики началось еще в середине прошлого века. В 1956 году Казанский филиал Академии наук СССР – Институт языка, литературы и истории организовал фольклорную экспедицию в Юкаменский, Глазовский, Балезинский районы Удмуртской АССР и Слободской район Кировской области. Экспедицию возглавил Хамит Ярми, в состав группы вошли Халида Гатина, Хузиахмет Махмутов, Шаех Забиров. Так был собран довольно объемный материал.

Х. Ярми и Х. Гатина побывали в селах Татарские Парзи, Кестым, Падера, Ахмади и записали 1232 короткие песни, 4 сюжетные песни, 27 народных игр, 1 баит, 16 загадок и пословиц.

Х. Махмутов и Ш. Забиров в селах Засеково, Иманай, Малый Вениж, Большой Палагай, Починки, Татарские Ключи, Татарские Парзи, Кестым, Падера записали 2021 короткую песню, 2 сюжетные песни, 61 народную игру, 3 баита, 148 загадок и пословиц, 1 сказку, а также истории 4-х деревень.

Не был забыт ни один человек из тех, кто помог членам экспедиции 1956 года записать образцы фольклорных произведений, имена всех информантов зафиксированы рядом с теми текстами, которые были от них записаны, вся информация хранится в Центре письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова.

Поскольку со времени той экспедиции прошло более полувека, было принято решение организовать комплексную экспедицию в те же районы Удмуртии в июне 2012 года. Работа экспедиции шла в пяти направлениях.

Известные диалектологи Д. Рамазанова и Ф. Баязитова, а также молодой ученый М. Булатова изучали особенности языка местных татар. Собранные материалы по диалектологии, а также результаты своих исследований лексики народных традиций и обрядов они достаточно полно представили в статьях, включенных в эту книгу.

Сведения по родословным известных людей, живших в этих краях, содержатся в статьях ученого-археографа Марселя Ахметзянова.

Молодой ученый А. Гайнетдинов, занимающийся исследованием эпиграфического и археографического наследия, привез из экспедиции около ста рукописных книг и тетрадей. Среди рукописей, сохранившихся у татар Удмуртии, оказались мунаджаты

легеннән сәхифәләре дә бүгенге укучылар өчен кызыклы булыр. Л. Җамалетдиновның «Җырлы төбәк» мәкаләсендә исә шул елларда тупланган фольклор хәзинәсенең бер өлеше урын ала.

Халык музыка җәүһәрләрен туплау һәм өйрәнү юнәлешендә Э. Каюмова тикшеренүләр алып барды. Ул үзенең мәкаләсендә гасырлар дәвамында татар халкының аерылгысыз юлдашы булган җыр-көйләрнең Удмуртия Республикасы татарлары тарафыннан әле дә яратып башкарылуын, бәет-мөнәҗәт, дини җыруларның бүген дә киң таралган булуын искәртә.

Гамәли бизәлеш сәнгате һәм матди мәдәният өлкәсендәге тикшеренүләрне Институтның сәнгать белгече Л. Шкляева һәм аспирант И. Фәррахова, Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм сәнгать институты студенты Д. Нуртдинова алып бардылар. Аларның мәкаләләрендә шушы төбәк халкының агачны чокып ясау һәм тимердән бизәкләр коеп эшләү сәнгате һәм башка тасвири, декоратив-гамәли сәнгать төрләре, традицион культурасы яктыртыла, бу төбәктә табылган шәмаилләрнең һәм мәчетләрнең үзенчәлекле бизәлешенә басым ясала.

Йомгаклап әйткәндә, укучыларга тәкъдим ителә торган әлеге басмага шушы төбәктәге татарларның тарихилыкны саклап яшәүләре, җирле осталарның, халык талантларының күңел чишмәләреннән саркып чыккан иҗат җимешләре белән тормыш-көнкүрешләрен матурларга, бизәргә омтылулары хакындагы язмалар кертелде. Удмуртиядә көн күрүче татарларның үткәне һәм бүгенгесе хакында шактый тулы фәнни мәгълүмат бирә торган бу китап шушы төбәк өчен генә түгел, башка милләттәшләребезгә дә кызыклы булыр, дип ышанасы килә.

**_Ким Миңнуллин,_**
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты директоры,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*мөхбир әгъзасы*

о Шаехбаба, редкое печатное издание «Әййүһәл-вәләд» Газали и др. произведения, которые свидетельствуют о том, что история данного региона уходит корнями в очень далекое прошлое.

Образцы устного народного творчества собирали и исследовали фольклористы И. Закирова и И. Ямалтдинов (руководитель экспедиции). Думаем, что читателям будут интересны и записи Х. Махмутова, сделанные им во время экспедиции 1956 года. В статье Л. Замалетдинова «Песенный край» представлена часть фольклорных жемчужин, обнаруженных во время экспедиции полувековой давности.

Сбором и изучением музыкального фольклора занималась Э. Каюмова. В своей статье она пишет о том, что песни и мелодии, которые были неизменными спутниками народа на протяжении веков, и сегодня живут среди татар Удмуртии; баиты и мунаджаты, напевы религиозного содержания широко распространены в настоящее время.

Изучением декоративно-прикладного искусства и материальной культуры татар Удмуртии занимались искусствовед ИЯЛИ Л. Шкляева и аспирант И. Фаррахова, а также студент Института филологии и искусств Казанского федерального университета Д. Нуртдинова. В их статьях освещаются местное искусство резьбы по дереву, фигурная ковка металла, виды декоративно-прикладного искусства, предметы традиционной культуры народа, а также рассматриваются шамаили, найденные в этом регионе, и своеобразное оформление местных мечетей.

Говоря в целом, эта книга – о том, как татары Удмуртии сохраняют свою историю, как народные умельцы, певцы и музыканты стараются расцветить жизнь, наполнить ее национальным содержанием и смыслом. Думаем, что сборник, дающий достаточно полное научное представление о прошлом и сегодняшнем дне татар Удмуртии, будет интересен не только жителям этого региона, но и всем нашим соплеменникам, где бы они ни жили.

***Ким Миннуллин,***
*директор Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова,*
*член-корреспондент Академии наук*
*Республики Татарстан*

# ҺӘР ТӨБӘКНЕҢ ҮЗ СЕРЕ

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы Ким Мөгаллим улы Миңнуллин, чылтыратып, Институт галимнәренең Удмуртия якларына экспедициягә чыгу нияте барлыгын әйткәч, күңелгә җылылык инде, якташларым өчен горурлык хисе уянды. Егерме елдан артык гомерем бу якларда үткәнгә генә туган хисләр түгел ул. Халкыбызга Удмуртия татарлары турында инде күптәннән аваз саласы килә иде.

Һәр төбәктәге татарларның үз хасиятләре, серләре, тарихы бар. Халкыбызның тарихи мәркәзеннән еракта булуга карамастан, милләттәшләребез гасырлар буе рухи кыйблабызны югалтмыйча яшиләр икән, бу – бәян ителергә лаеклы мәгълүмат. Һәм ул киләчәктә дә безнең бербөтен милләт булып сакланып калуыбызның нигез ташларын тәшкил итә.

Удмуртиядә бүген бик күп милләт вәкилләре көн күрә, шуларның 100 меңе чамасы – татарлар. Гадәттә, бүген, күркәм миллилек мохите үрнәге буларак, татар авыллары тормышын күрсәтәләр. Әйе, Чувашия Республикасы, Пермь крае, Ульяновск өлкәсе кебек төбәкләрдә татар авыллары бихисап күп булып, алар хәтта аерым татар районнары булып та оешкан. Бу очракта аларда милли тормышның кайнап торуы аңлашыла да – үз өйләре, үз көйләре. Ә Удмуртия татарлары бу кагыйдәгә туры килеп бетми: биредәге милләттәшләребезнең бары 14 проценты гына авыл җирлегендә яши, ә 86 проценты шау-шулы шәһәр мохитендә, башка милләтләр арасында гомер кичерә. Шуңа да карамастан, Удмуртия татарларының телне, динне, гореф-гадәтләрне кадерләп саклаулары, алардагы миллилек хисе бик күпләргә үрнәк итеп куярлык. Моның сере нидә соң? Бәлки бу серне чыгышлары белән Актаныш, Минзәлә якларыннан булган Камбарка, Сарапул шәһәрләре

# У КАЖДОГО КРАЯ СВОЯ ТАЙНА

Когда директор Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова доктор филологических наук Ким Мугаллимович Миннуллин сообщил по телефону, что ученые Института планируют выехать в экспедицию в Удмуртию, у меня сразу потеплело на душе, пробудилось чувство гордости за земляков. И не только потому, что я двадцать лет прожил в этих краях. Просто давно назрело желание поведать о татарах, живущих в Удмуртии.

Каждая местность имеет свои особенности, тайны, свою историю. Несмотря на отдаленность от исторического центра нашего народа, соплеменники в течение веков живут, не теряя духовных ориентиров. Этот факт достоин внимания и является краеугольным камнем сохранения целостности нашей нации в будущем.

В настоящее время в Удмуртии проживают представители многих национальностей, около 100 тысяч из них татары. Обычно сейчас татарские деревни служат примером истинной национальной жизни. Действительно, в Республике Чувашия, Пермском крае, Ульяновской области татарские деревни, из-за своей многочисленности, составляют целые татарские районы. В этом случае понятна причина бурлящей национальной жизни: свой дом – своя песня. Татары Удмуртии под это правило не подходят: из них только 14 % проживают в деревнях, а 86 % – в шумной городской суете, среди других национальностей. Несмотря на это, бережное сохранение языка, обычаев, национальное чувство татар Удмуртии могут быть примером для многих. В чем же секрет? Его, наверное, знают татары Камбарки, Сарапула – выходцы из Актанышского, Мензелинского районов, или его хранят кукморцы, в большом количестве обосновавшиеся в Можге, или агрызовцы, проживающие в Ижевске со дня основания… Я думаю, что вы, прочитав книгу

татарлары беләдер, йә күпләп Можга шәһәренә килеп урнашкан кукмаралылар саклыйдыр, йә аны Ижау шәһәренә нигез салынуга ук килеп төпләнгән әгерҗеләләр аңлыйдыр... «Милли-мәдәни мирасыбыз» сериясеннән «Удмуртия татарлары» китабын укып чыккач, сез бу серләргә үзегез төшенерсез, дип уйлыйм.

Удмуртия татарларының хөрмәткә лаеклы гамәлләре бихисап. Милли күтәрелеш чорында биредәге һәр шәһәр һәм күпчелек татар авыллары янә мәчетле булды, туган телне өйрәтү-өйрәнү мөмкин булганча җайга салынды, милли оешмалар эшләп килә, республика күләмендә 16 битле «Яңарыш» исемле татар газетасы чыгарыла, телевидениедә берничә татар тапшыруы дөнья күрә, татар гимназиясе, балалар бакчасы һәм китапханә эшли башлады, радиода да инде 25 ел буе татар тапшырулары тынмый.

Җитмеш мең татар яши торган Ижау шәһәре сәхнәсендә татар артистлары гастрольләре еш уза. Шунысы сөенечле: әлеге концертлар Татарстанның зур шәһәр сәхнәләре белән чагыштырырлык, заллар һәрвакыт тулы була. Казаннан елына утызга якын татар концерты килә, җирле үзешчән артистлар да сәхнәгә тузан төшерми. Мәчетләрдә исә гыйбадәт кылу гына түгел, укыту эшләре дә бик төпле итеп жайга салынган, мәчеткә яшьләр күпләп йөри. Үткәнендә генә түгел, бүгенге көнендә дә татар милләте фидакярләрчә хезмәт итә, хәләл ризыгын тырышлык белән таба. Горурланып әйтергә мөмкин: бу эшләрнең күркәм нәтиҗәсе буларак, бүгенге көндә Удмуртиядә сәламәт рухлы татар мохите тудырылды.

Әйе, тиз агымлы, ниндидер бер шашкын заманада кешеләргә, милләтләргә үз йөзләрен саклау җиңел түгел. Кулыгыздагы китап, хөрмәтле укучы, милләт киләчәген кайгыртып, татарны саклап калу нияте белән язылган хезмәт.

***Ирек Шәрипов,***
*Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты директоры,*
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре*

«Национально-культурное наследие: татары Удмуртии», сами раскроете все секреты.

У татар Удмуртии неисчислимое количество дел, заслуживающих уважения. Во времена национального подъема здесь в каждом городе и в большинстве деревень вновь появились мечети, наладилось, по возможности, обучение родному языку, работают национальные организации, в масштабах республики издается шестнадцатистраничная татарская газета «Яңарыш», выпускаются татарские передачи на телевидении, начали работать татарская гимназия, детский сад и библиотека, на радио вот уже 25 лет выходят передачи на татарском языке.

На сценах Ижевска, в котором проживают 70 тысяч татар, часто выступают приезжие татарские артисты. Радует то, что эти концерты по посещаемости можно сравнить с крупными залами Татарстана – всегда аншлаг. Около 30 концертов в год проводят артисты из Казани, не ударяют лицом в грязь и самодеятельные артисты. В мечетях не только молятся, там основательно налажено обучение, очень много молодых посещают мечеть. И сейчас татары самоотверженно трудятся, стараются есть дозволенную пищу. С гордостью можно признать: в результате этих дел в настоящее время в Удмуртии сформировалась здоровая духом татарская среда.

Да, не так легко людям, национальностям в это быстротекущее, бурное время сохранить свое лицо.

Эта книга, уважаемый читатель, написана с беспокойством о будущем татар, с желанием сохранить их национальную целостность.

***Ирек Шарипов,***
*директор Дома дружбы народов Татарстана,*
*заслуженный работник культуры Татарстана*

# ТЕЛ, ГАДӘТ ВӘ ӘХЛАК АЛМАШЫП

***Татар һәм удмурт тарихыннан уртак сәхифәләр***

*Марсель Әхмәтҗанов*

Татар һәм удмурт халыкларының тарихи элемтәләре турындагы мәгълүматлар XIV гасырның соңгы чирегеннән күренә башлый.

Бу вакытларда әле татарлардан төньякта яшәүче удмурт һәм коми халыклары бер-берсеннән аерылган мөстәкыйль халыклар булып саналмаган, урыс халкы аларны зыряннар дип атаган. Зыряннар XIV гасырда Бөек Новгород феодалларына ярым бәйле рәвештә яшәп, аларга кыйммәтле җәнлек тиреләре белән ясак түләгәннәр.

XIV йөздә Бөек Новгородтагы урыс боярлары зыряннарны тәмам үзләренә тулы коллыкка төшерү чарасына керешәләр. Алар моңа мәҗүси зыряннарны көчләп чукындыру аркылы ирешергә булалар. Новгородлылар зыряннарга, пермякларга, югрыларга каршы кораллы көчләр җибәргән. Алар ярдәмендә Стефан Пермьский исемле миссионер Нократ һәм Идел якларында яшәүче зырян-пермякларның изге урыннарын, агачларын, йортларын җимереп, Чердыннан төньяктарак яшәгән җирле халыкларны христиан йолаларын үтәргә мәҗбүр иткән. 1383 елда, аларны ныклап христианлаштыру нияте белән, Пермьдә епархия үзәге оештырыла. Шуңа таянып, Стефан Пермьский зырян, пермяк кавемнәренең борынгы традицион ышануларын җимерү максатында кыргыйларча эш алып бара. Ләкин 1396 елда зырян, пермяк кавемнәре бу христианлык тарату оясын туздырып, епископ Стефанны үтереп ташлыйлар. Аларның баш күтәрүе Бөек Новгородтан җибәрелгән гаскәри көч белән генә бастырыла. Шул вакытта зырян һәм пермякларның бер өлеше, туган җирләрен ташлап, Алтын Урданың Болгар Олысына – татарлар, марилар (чирмешләр) янына килеп утыралар. Бу җирләр, нигездә, Чыпца елгасы буйла-

ры, аларга яңа ватан булып китә. Чыпца елгасының Нократка койган тамагыннан ерак түгел Турна-кала исемле татар авылында 1323 елда куелган, бу җирләрнең Болгар Олысыныкы булуын раслаган язулы ташбилге дә сакланган. Турна-кала соңрак Болгар биләмәсендәге татар авылы булып китә. Бу ташбилгедән бер чакрым чамасы читтә, Нократ авылында, тагын 1504, 1522, 1555 елларда куелган татар-мөселман кабер ташлары сакланган.

Әлбәттә, хәзер Нократ җирләрендә яшәүче Болгар дәүләте кавеменнән булган бисерманнәр яки чувашлар XIV гасыр документларында да искә алыналар. Тик соңыннан чуваш этнонимы кулланылыштан төшеп калып, алар хәзер бисерманнәр яки почырманнар дип аталалар, инде бүгенге көндә, күбесе удмурт кавеме белән кушылып, югала бара торган милли азчылык вәкилләре булып яшиләр. Бисерманнәр арасында Касыймов, Апачев/Абашев кебек Нократтагы атаклы татар фамилияләренә күчеп киткәннәре дә бар. Кыскасы, бисерманнәр нигездә татар белән аралашып яшәгәннәр, татарлар аларны «йотмаганнар». Казан ханлыгы яулап алынган вакытларда йөзләгән татар авыллары яндырылган, җимерелгән, халкы үтерелгән яки әсир ителеп, коллыкка сатылган, чукындырудан баш тартканнарын, төрмәләрдә җәзалап үтергәннәр, нәтиҗәдә Казан тирәсендәге күпчелек авыллар урынында кара күмер генә калган. Исән калып котыла алган татарлар Нугай Урдасы биләмәләре булган Агыйдел, Дим, Сөн, Зәй буйларына качып китеп, шунда төпләнгәннәр.

Казан ханлыгының бушап калган җирләрен монастырьларга, алпавытларга, стрелецларга, урыс хакимиятенә хезмәткә күчкән татар морзаларына бүлеп бирә башлыйлар. Шулай ук Касыйм һәм Төмән татарларын, нугайларны, мордва, чуваш, мари, удмуртларны (арлар дип тә әйтәләр), соңрак әсир полякларны, литвалыларны, кырымлыларны, төрекләрне дә шул җирләрнең хуҗалары итеп утырталар. Ләкин бу халыкларның күбесе (мәсәлән, мордвалар, марилар) үзләренең әүвәлге ватаннарына качып киткән.

Татарстан җирләрендә төпләнеп калган удмуртларның, мариларның күбесе әле хәзер дә татарча яхшы сөйләшә белә. Шул ук вакытта XX йөзнең икенче яртысында бары Татарстанда гына удмурт, мари милли мәктәпләре эшләп килде.

Тарихта XIV гасырның соңгы чирегендә Пермь якларында яшәгән удмуртларның бабалары – зыряннар өчен епископ Стефан

Пермьский, 24 хәрефле алфавит төзеп, зыряннар теленә христиан дине уку әсбапларын тәрҗемә иткән, дигән сүзләр булса да, алардан бер генә үрнәк тә калмаган. Борынгы зырян-пермякларның изге урыннарын җимергән, хурлаган кеше турында җирле халык бер хатирә дә сакламаган.

Киров өлкәсендә һәм Удмуртиядәге XIV, XVI гасыр борынгы болгар һәм татар ташъязмалары сакланган җирләрдән ерак түгел, Глазов төбәгендә борынгы төрки язулар белән бизәлгән көмеш савыт токтасы табылу да төрки мәдәни ареалның чикләренә туры килә.

Удмуртларның татар мәдәнияте белән бәйле иң якты сәхифәләре XIX йөзгә карый. Татарстан Республикасының Мамадыш төбәгендәге Чиялек (Никифиров) авылында туып үскән керәшен татары Борис Гаврилович Гаврилов (1847–1891) тарафыннан беренче удмурт әлифбасы төзеп бастырыла. Аның удмурт этнографиясенә багышланган зур күләмле «Поверья, обряды и обычаи вотяков Мамадышского уезда, Урясь-Учинского прихода» исемле хезмәте кыйммәтле бер фәнни-тарихи чыганак булып санала.

Борис Гаврилов 1873–1874 елларда, Казан һәм Вятка губерналарында яшәүче удмуртларның телләрен өйрәнү өчен, Казан епархиясеннән фатиха алып, удмурт халкының риваятьләре, сөйләкләре һәм йола тасвирларын туплап кайта. Удмурт һәм урыс теленә тәрҗемәләрдә алар 1880 елда нәшер ителә. Христиан китапларының берничәсен ул татарчадан удмурт теленә тәрҗемә итеп бастыра.

Б. Гаврилов шул ук вакытта удмурт авылларында ачылган миссионер мәктәпләрендә укытучы булып та эшләгән. Мәсәлән, аның 1867 елда Ошма дигән удмурт авылына (Казан өязендә) укытучы итеп билгеләнүе мәгълүм. Ләкин бу заманда Татарстан җирендә Ушма (Ошма) дигән удмурт авылы юк, мәгълүматны язучыларда ялгышлык киткәнгә охшый. Б.Гаврилов 1885 елдан, ягъни гомеренең соңгы елларында, Татарстанның хәзерге Алабуга төбәгенә карый торган Үмәк дигән татар-урыс катнаш авылында рухани (поп) булып эшләгән. Ихтимал, бу авылда әлеге гыйлем иясенең кабере дә сакланып калгандыр әле.

## Нократ татарлары тарихыннан

Нократ елгасы буйларында яшәүче татарларның иң борынгы тарихлары Карабәк һәм аның нәселләреннән Касыймовлар,

Дәүләтьяровлар, Мөрсәлимовлар, Байкиевлар, Апачевлар, Янчуриннар, Хуҗасәетовлардан калган борынгы шәҗәрәләр һәм аларга урыс патшалары биргән ярлык-грамоталар аркылы шактый тулы чагыла.

Үкенечкә каршы, аларның нәселләренең XVIII–XX гасырларда бүгенге Удмуртия җөмһүрияте җирләрендәге таралышы, язмышлары турында татарлар үз куллары белән язган чыганаклар, тарихлар фәнни әйләнешкә әлегә кадәр бик сирәк керде. Бу өлкәдә Кистем авылында яшәүче яшь галим Илмир Касыймов төзегән шәҗәрәләр һәм җирле татар авыллары мәдәни тормышына караган язмалар аерым игътибарга лаек.

Ләкин менә тарихчы Габдулла Ушмавиның үткән гасырның 50 нче елларында Казан галимнәренә җибәрелгән күләмле генә язмалары билгесезлектә югалган.

1974 елның март айларында Габдулла ага, минем шәҗәрәләр белән кызыксынуымны ишетеп, үзенең Татар Парҗысы авылы тарихына багышланган кульязмасын биргән иде. Ул чагында бу кульязманы мин үземнең бер фәнни хезмәтемдә искә алып кына үттем, чөнки киң итеп файдалану өчен өстәмә язма чыганаклар җитми иде. Инде хәзер бай гына тарихи материал туплангач Габдулла Ушмави хезмәтенең дә тарихи кыйммәтен бәяләргә мөмкин булды. Кем соң ул Габдулла Ушмави? Ул хәзерге Татарстан җөмһүриятенең Мамадыш төбәгенә керә торган Түбән Ушма авылында 1890 елның 14 июлендә туган, 1988 елда Глазов шәһәрендә үлгән. Атасы Хәмид (1860–?) бине Муса (?–1885) бине Әмир бине Әмин бине Ресмәт әл-Ушмави, әл-Казани, әл-Болгари, шулай ук, Түбән Ушмада гомер иткәннәр. Хәмид Түбән Ушмада Һадиулла бине Әхмәд бине Йанкылыч әл-Ушмави мәдрәсәсендә укыган.

Габдулла Ушмави яхшы дини белем иясе, Уфада Хәсәнгата Габәши тарафыннан имтихан кылынып имам хатип һәм мөдәрrислеккә указ алган.

1916 елда Герман сугышына җибәрелеп, анда яраланып кайта, укытучылар курсына йөреп, укыту эшенә керешә. Ләкин идеология өлкәсендәге буталчыклыктан туеп, урман эшенә күчә, 1948 елда пенсиягә чыга һәм Глазов шәһәренә барып урнаша.

Ул 1914 елдан бирле татар авыллары тарихлары буенча материаллар җыйнап Мамадыш, Ишки һ. б. авылларның (барысы – 14 авылның) тарихын язган. Бу тарихлардан аерым фрагментлар

аның «Түбән Ушма тарихы»на да килеп керә. Андагы мәгълүматлар буенча Идегәй би Түбән Ушма авылы тирәсендә тукталган, анда аның Габделкотдус (Котыш) исемле улы яшәгән. Бу мәгълүматлар тарихыбыз өчен кыйммәтлеләр.

Ә бу хезмәттә Габдулла Ушмавиның Татар Парҗысы авылы турындагы язмалары игътибар үзәгенә алынды.

Әлеге авторның нинди идеологик дәверләрдә яшәп, нинди басымнар кичереп язганы болай да мәгълүм. Мәсәлән, ул борынгы Нократ татарларында зур би булып торган Касыймов шәхесе турында бер сүз дә язмый, фәкать аның XIX гасыр ахырларында 7–8 буынлы шәҗәрәләр төзеп яшәгән нәселләре хакында гына мәгълүмат бирә. Фән өчен болар да бик әһәмиятле.

Габдулла Ушмави XVI–XIX гасырларда Нократ елгасы буйларында татар авылының нинди кыенлыклар кичереп яшәвен, үзенең диненә турылыклы булып калуын, татар-удмурт мөнәсәбәтләрен, мәгърифәт халәтен кызыклы итеп тасвирлый. Совет хөкүмәтенең ислам руханиларына карата аеруча шәфкатьсез мөнәсәбәттә булуын искә алсак, аның руханилар тормышы, мәчетләр эшчәнлеге турында дәшми калуының сәбәпләре бик ачык аңлашыла.

Туплаган кадәрле тарихи мәгълүматлары һәм нократ татарларының XVIII–XIX гасыр шәҗәрәләрен теркәп калдыруы гына да Габдулла Ушмавиның милли тарихыбыз өчен кыйммәтле эш башкаруына дәлил булып тора.

Инде хезмәтнең үзе белән якыннанрак танышыйк. «Башлангыч сүзе»ндә автор менә ниләр яза (мин аның стилен сакларга тырыштым. – **М. Ә.**):

«Дөньяда, ничек кенә булмасын, һәр нәрсәнең башлану тарихы булган шикелле, беткән нәрсәләрнең дә бетү, юкка чыгу тарихлары да буладыр. Тарихи хәлләрнең сүзләр вә эшләрнең дөньяга килеп чыгуына табигый рәвештә адәмнәр сәбәп буладыр. Шуның өчен тарих фәне алдагы көнгә, тормышка кирәк нәрсәләрне белү, өйрәнү өчен бик файдалы фәндер.

Менә безнең бабайлар кайдан килгәннәр икән, ниләр эшләп йөргәннәр икән, ничек торганнар икән, дип, күп гыйбрәт, акыл, белем, аң алырга мөмкинлек бирә торган фәндер.

Дөньяда күп шәһәр һәм авылларның тарихлары мәгълүм булса да, бер дә тарихлары мәгълүм булмаган, бик иске заманда ук була башлаган авыллар да бардыр.

Тарихны, әлбәттә, ясап язып булмыйдыр, фәкать, булса, иске язмалардан карап, яки колакка бабайлардан ишетелеп калган сүзләргә карап, шул язмаларга, ишетелеп калган сүзләргә күршедәге шәһәр һәм авыл тарихларыннан дәлилләр эзләп языладыр, яки иске нәрсәләргә карап языладыр.

Татар Парҗы тарихы да менә шушы рәвештә җыелып, 1958 елда февральдә тәмам итеп, яңа хәреф белән яздым. 53 нче елда кыскарак рәвештә иске хәреф белән язып, Казанга, Академия Наукка җибәргән идем.

Т. Парҗыда торучы язучы Габдулла Хәмит улы Ушмави.
1958 ел, май.

**Бу китапка язылган нәрсәләр**

1. Т. Парҗының утырган урыны хакында
2. Т. Парҗыга беренче килеп утыручылар вә кайдан килүләре хакында
3. Парҗы дип ник аталган
4. Парҗы елгасы
5. Ни өчен күчеп килгәннәр вә кайчан килгәннәр
6. Парҗыга татарлар килүе
7. Татарлар килгәч, удмуртлар ни эшләгәннәр
8. Парҗы татарлары белән удмуртларның аерылышулары
9. Беренче укытучылар, 7 еллык мәктәп салыну
10. Бөтен колхозны электр белән яктырту
11. Укып һөнәр алган кешеләр
12. Нәсел шәҗәрәләре
13. Кече Парҗы тарихы
14. Кече Парҗы дип аталуы
15. Кече Парҗыга ник күчеп килгәннәр
16. Кече Парҗыда укып һөнәр алган кешеләр
17. Кече Парҗының нәсел шәҗәрәсе

Бу тарихны җыеп язучы Габдулла Хәмид углы Ушмавидыр. Төп чыгышым – Татарстанда; Мамадыш районы, Түбән Ушма авылында крестьян гаиләсендәдер тумышым.

Язучылар ел саен язу кагыйдәләрен үзгәртеп барулары сәбәпле, кагыйдәләрне хәтердә тотып бетереп булмыйдыр. Шуңа күрә ялгышларым күп булырга мөмкин. Укучылар гафу итәр, каләмнәре белән төзәтерләр.

Хәмитов Г. 1958 ел, май.

## Тат. Парҗы тарихы

. . . . . . . . . . . . .

1. Т. Парҗы урыны.

Удмурт җөмһүриятендә, Глазов районында ст. Глазовтан 18 километр төшлек тарафында, иске заманда Казанга ат белән йөри торган юл өстендә, Парзи елгасына утыргандыр.

Беренче тапкыр Парҗыга кемнәр вә кайчан килгәннәр?

Парҗы авылына иң элек килүчеләр хакында менә шул хәбәр бар.

Атогородта (Бу авыл Отогурт дип атала. – *Г. Ушмави искәрмәсе*) Мария Николаевна дигән Баженова фамилияле бер карчык бар. Бу карчык 1885 елларда туган булып, шактый гына аңлы да уяу кешедер, күргән-ишеткән нәрсәләре хакында дәмсе белән сөйлидер. Ир кешесе дә укытучы булган икән. «Менә бу карчык болай сөйли», – дип, минем иптәшемнең атасы әйтә иде.

Парҗыга 1-й килеп утыручылар Адәм авылыннан булган, дип. Адәм авылы Чепса (*Чыпца*) елгасының уң ягында, Глазовтан ерак түгел бер авыл икән. Әле бу вакытта, «Адәм» авылыннан 1 нче килгән вакытта удмурт халкы динсезләр булып, фәкать ата-бабадан калган гореф, гадәт, җола, келәүләр белән генә маташалар икән дип карчык сөйләгән иде. Карчык бу сүзләрне 1953–1954 елларда сөйләде. Тагы шул сүзләрне дә әйтте, ул вакытта, ягъни динсез вакытларында – ата-бабадан калган гадәт белән маташкан вакытларында басуларында келәү итә торган агачлыклары булган, җәй көннәрендә шул агачлыкка барып, хайваннар суеп, иске гадәт белән келәү иткәннәр икән, ягъни гыйбадәт кылганнар. Бу басулардагы иске вакытта халыкның келәү итә торган урыннарын «Кирәмәт» дип атап йөрткәннәр. Бу вакытта һәр авылның каберлеге дә үз басуларында булган. Удмурт халкы XVI–XVII гасырларда чукындырылып, христиан диненә кертелә башлагач, үлекләрен кайда чиркәү бар, анда илтеп күмәргә башлаганнар да, иске гадәт тә әкренләп беткән.

Парҗы дип ни өчен аталган? Парҗы авылы буласы урынга иң элек Адәмнәнме, йә башка җирдән булса да башлап килүче Парзи исемле кеше булырга кирәк, башлап килүченең исеме авылга исем булган, соңра авыл исеме белән елга да Парҗы елгасы дип аталып калган.

### Парҗы елгасы

Бу елганы борын заманда Чибашур дип атап йөрткәннәр. Удмурт халкы Чибашур диләр икән, ягъни матур елга дигән сүз

буладыр (чибәр дигән сүз удмурт белән татар арасында уртак сүз булып, әз генә аерма белән татарлар «чибәр», арлар «чибер» диләр. – *Г. У. искәрмәсе*).

Чөнки тарих галимнәренә мәгълүм ки: һәрбер җиргә, суга, күлгә, урманга, шәһәргә, тауларга исем кушылмыйдыр, иң элек шул урыннарда кешеләр йөрмичә. Беренче тапкыр урыннарга кем булса да килеп йөрсә, йә килеп утырса, шул кешенең исеме, яки хайванның исеме исем булып каладыр, яки ул урынга якын шәһәр, яки тау исемнәре булып каладыр. Яки мәшһүррерәк исемнәр табылу сәбәпле, искерәк исемнәр онытылып та каладыр.

Удмуртлар авылларны күбрәк елга исеме белән атап калдырганнар. Хәзерге көндә «Верх. Парзи» дип языла торган авыл бик иске вакытта Чибашур дип йөртелгән. Йәгъни Парзи елгасының борынгы замандагы исеме белән атап йөрткәннәр. Адәм авылыннан Парзи исемле кеше Парҗыга килеп утыргач кына, Парҗы елгасы дип атала башлаган. Чибашур авылын елга башында булганга күрә генә Югары Парҗы дип яза башлаганнар, ягъни, Парҗы авылы утырган елга башындагы авыл, дигән сүз буладыр. Әле дә бу Югары Парҗыны удмуртлар үзләре генә сөйләгәндә Чибашур дип сөйлиләр.

**Адәмнән ни өчен күчеп килгәннәр,**
**вә кайчан килгәннәр**

Адәм авылыннан күчеп килүләренә сәбәп нәрсә икәне ачык мәгълүм булмаса да, бөтенләй билгесез дә түгел.

Чөнки дөньяда бик иске заманнардан ук шәһәрләрнең һәм авылларның күбәюенә сәбәп булган нәрсәләр адәмнәрнең тормышларына кимчелек китерә торган нәрсәләр чыгуыдыр.

Кешеләрнең искедән үк тора торган җирләрендә тормышка беренче зарар китерә торган нәрсә итеп җир искерүе, азаюы һәм урман юклыгы, яки ераклашуы саналган. Аның өчен кешеләр бик иске заманда җир белән урманны тормыш алып бара торган беренче нәрсә итеп санаганнар, хайван асраганнар, шуннан тормышка кирәк бар нәрсәне дә ясаганнар, аларга башка бер нәрсә дә кирәк булмаган. Уку, язу кирәк булмаган, тамгалар белән генә аны-моны санаган вакытларында шома таякларга киртекләр ясап хисаплаганнар. Шәһәрләргә барырга хаҗәт төшмәгән (әле мин кечкенә вакытта да таяк киртләп хисап алу, санау бар иде. Безнең авылда Гәрәй абзый яз көне хайван көтәргә алганда, өч таяк

тотып, йорт саен кереп, ничә хайваның бар, дип сорап, бер таякка сыер, икенче таякка сарык, өченчесенә кәзә (*кәҗә – М.Ә.*) санын алып йөри торган иде. 1900 елларда), чөнки алар бөтен тормышка кирәк нәрсәләрне үзләре ясаганнар. Тырышрак кешеләр бай булганнар. Баеракларга тагын яхшырак урын кирәк булганда Адәм авылыннан күчлерәкләре Парҗыга яхшырак җир эзләп килгәннәр булса кирәк. Менә шулай тыныч кына торганда, ни булса да бер сәбәп белән күчеп китеп, Парҗы авылын дөньяга китереп чыгарганнар...

Парҗы удмуртларының динсез булып, фәкать иске ата-бабаларыннан калган гореф-гадәт, җола, келәүләр белән генә маташканнары мәгълүм. Моның галәмәтләре:

1. Исемнәре ничек туры килсә, аның белән балаларын атаганнар. Мәсәлән: Парза, Ато, Киләп, Ахикбай, Мешкән, Кибә шикелле исемнәр.

2. Христиан диненең исемнәре – Иван, Питр, Симен шикелле исемнәр – чукындырылгач кына кушыла башлаган.

## Парҗыга татарлар килүе

Парҗыга татарлар килүе, кайдан килгәннәр, килүләренә нәрсә сәбәп булган вә кайчан килгәннәр.

Парҗыга татарларның кайдан килүләре хакында Парҗы картларының ата-бабаларыннан калган сүзләре вә хәбәрләренә караганда, Парҗыга беренче тапкыр татарлар килүе Кожя авылыннан икән.

Бу Кожя авылы борынгы Вятка губернасы, Глазов өязе (Удмурт җөмһүриятендә) Балезино станциясеннән ерак түгел Чепса (*Чыпца*) елгасының сул ягында урнашкан. Менә шушы авыл бик иске вакытта татар авылы булган икән. Татарларның бу авылдан күчеп китүләренә сәбәп – XVI гасырның соңгы яртысында Иван Грозный законы белән дингә кысу тынычсызлыгы. Кожядан берничә гаилә татар Парҗы авылына, удмуртлар янына урман арасына поплардан качып килеп утырганнар.

Адәм поселкасындагы удмуртлар килеп, Парҗы авылы ясап, XVI гасыр ахырында Кожядан татарлар килеп, удмурт белән татар катыш авыл булып калган.

Соңыннан бу Парҗыга башка урыннардан да берничә татар семьясы килеп утырган булырга кирәк. Нократтан һәм Әгерҗедән, Татарстаннан килгәнне әйтәләр.

Парҗыга татарлар килгәч, удмуртларның яхшырак тормышлылары, татарларны яратмыйча, башка авылларга күчеп киткәләгәннәр. Мәсәлән, Парҗыдан Ото исемле кеше белән Киләң исемле кеше Оть авылына китеп, Отогорд дигән авылны ясаганнар. Азикбай дигән кеше күчеп, Азикбай авылын ясаган вә башка иске авылларга барып кушылып утырганнар. Удмуртлар үзләре сөйлиләр, фәлән авыл да Парзидан күчеп киткән, төгән авыл да Парзидан күчеп киткән, диләр.

Глазов өязендә ст. Балезиногa ерак түгел Чепса (*Чыпца*) елгасының уң ягында Ужа дигән удмурт авылына 1570–1580 елларда бик зур гына чиркәү салынып, анда дүрт миссионер поп килеп, шул тарафтагы удмуртларны, бер уңайдан, туры килгән мөселман татарларны да чукындыра башлаганнар. Менә шул заманнарда Кожя авылы мөселман татарларына да бу чукындыру афәте килеп баскан. Тормышлары тынычсызланган. Соңра Кожя татарлары бу тынычсызлыктан качып, кайсы кайда киткәннәр. Чөнки Кожя Ужадан ерак түгел. Берничә семья Парҗыга да килгәннәр. Кожядан күчә алмыйча калганнары, чукындырылып, керәшен булганнар да, бисермән дип аталып, удмуртлар белән катышып, бөтенләй йотылганнар, югалганнар да удмурт авылы булып калган.

Удмуртлар XVI гасырның ахырына кадәр язычник, ягъни динсез каүм (*кавем. – М. Ә.*) булганнар. Россия хөкүмәте удмуртларны христиан диненә кертергә башлаганда, беренче эшен менә шушы Ужа авылына чиркәү салдырып башлаган.

Бу хәбәрне Глазов шәһәрендә торучы Михаил исемле поп сөйләде. 1958 елда, июньдә. Хәзер мин 70 яшьтә, ди. Ул болай дип сөйли «Мин село Балезинода школьник вакытымда г. Вяткадан архейри (*архиерей. – М. Ә.*) килеп, шушы Ужа чиркәвенең башлануына 300 ел тулуына моливын (юбилей) ясаган иде. Димәк бу поп ул вакытта 10 яки 15 яшьләрдә булса, чиркәү башлануына 4 гасыр туларга якын буладыр».

Бисермән дигән сүз – удмуртлар мөселман дигән сүзне үзгәртеп *бисермән* дип, кайсылары *бичерман* дип, кайсылары *почырман* дип тә әйтәләр. Ягъни аларча «чукындырылган мөселман» дигән сүз буладыр. Удмуртлар татарларны «бигер» дип, кимсетергә теләгәндә әйтәләр. Болгар дигән сүз була, ягъни Шәһри Болгар кауменнән дигән сүз буладыр. Нитәки удмуртларны кимсетелгән урыннарда «ар» дип, «вотяк» дип тә әйтәләр иде.

Кистем авылына да поплар килеп, дингә кыстап йөри башлаганнар. Кистем авылы зуррак та булып, татарлар поплардан курыкмыйча, дингә көчләүчеләрне кыйнап, кисеп җибәргәләгәннәр икән. Соңра кыйнаучылар базарларда, җыеннарда (ягъни кунак атналарына башка авылларга кунакка барган вакытларында): «Ну соң, иптәш, мин фәлән пупны кистем (ягъни кыйнадым)», – дип мактанганнар икән. Шуннан соң кунак итүче хуҗалар берсенә берсе, сезгә кайсы авыллар килде, бездә «кистем»нәр бар, диләр икән. «Кистем» дип мактанган сүзләре авылга исем булып калган. Һәм авыл исеме елгага да исем булган, – дип Урьякала авылының Талиб Рәхим углы Касыймов дигән карт сөйләгән иде. Бу карт 75 яшендә 1954 елда үлде. Укый-яза белә иде, ата-бабаларыннан ишеткән тарихи вакыйгаларны күп сөйли иде.

Уръякала авылының халкы, яртысы чукындырылып, бисермән булып калганнар. Мөселманнарны чукындыру кыенрак булган, чөнки алар динле, ә удмуртларны чукындыру асат (*ансат. – М. Ә.*) булган, динсез булганнары өчен.

Удм. Парзи авылыннан Герасим Александрович Жуйков дигән карт 1957 ел җәй көнендә үземә сөйләде. 1957 елда тимерчедә идек. Ул болай ди: «Безнең Парзяга татарлар килгәч, удмуртларның яхшылары китеп беткәннәр. Парзяда начарлары гына, бурлары (*каракларьг. – М. Ә.*) гына калган», – ди. Шулай дигәч, тимерче Егор бабай: «Үзебезне бигрәк тә бетердең ич», – диде. Егорга ул: «Карт бабайлар шулай әйтәләр иде», – дип җавап бирде.

Нәтиҗә: Парҗыдан күчеп китүләре дөрес икән. Бу карт ул чакта 70 яшьләрдә иде. Янә Григорий Андреевич Владыкин дигән карт сөйләде: «Безнең Филипп бабай Балэзинәдән килгән бабай. Килгәндә Парзыда удмуртлар 5 кенә гаилә булганнар. Әти Андри 1860 елда Парзыда туган». Димәк, удмуртлар XIX гасыр урталарында Парзыдан күчеп китми калганнары 5 семья гына калган икән. Григорий Андреевичка бабасы сөйләп калдырган. Авыл җыелышларында бер дә киңәшкә килми торган, киреләре генә калган икән. Бер дә киңәшкә килмәгәндә, татарлар удмуртларны кыйныйлар икән дә, соңыннан (*киреләр. – М. Ә.*) риза булалар икән. Бу сүзне татар картлары сөйлиләр. «Күп вакытларда килешеп, кунакларга йөрешеп, бәйрәмнәрне бергә ясый торган идек», – дип сөйлиләр.

Патша хөкүмәтенең дә күбрәк әһәмият биргән эше бөтен Россиядә халыкны христиан диненә кертү, чукындыру булган. Бигрәк

тә мөселманнарны чукындырырга тырышкан. XIX гасыр башларында патша хөкүмәте, хөкүмәткә кайбер файда яки зарар якларын күзәтеп, мөселманнарга тыштанрак кына булса да дингә иркенчелек биргән булып, кайсыбер урыннарга мәчетләр салырга рөхсәт итә башлаганнар. Кистем авылына да мәчет салынып, мөселманнар мәхәлләсе ачылгач, бу Парҗыдагы мөселманнар да Кистемгә ияргәннәр. Парҗы удмуртлары, чукынып, чиркәүгә ияргәннәр... Шулай булса да Татарстанда соңгы елларда да чукынмаган удмуртлар күп иде әле. (Алар хәзерге Балтач, Кукмара районнарында сакланганнар.)

XIX гасырда Парҗы авылы да бик наданлыкта көн иткән. XIX гасыр урталарында Җөрек авылыннан (Киров өлкәсе, Малмыж районы авылы) Насыйбулла бине Гыйсмәтулла бине Фәйзулла дигән кеше Парҗыга укытучы булып килгән. Н. Фәйзуллин Парҗы татарларының дини эшләрен эшләгән. Бу вакытта уку-укытуга кирәкле әсбабларның, шартларның булмавы сәбәпле, Н. Фәйзуллин да зур эш эшли алмаган.

Парҗының татарлары да, удмуртлары да: «Безнең авылда ике генә адрес яза белүче кеше булган, башка язу белүче булмаган», – диләр.

1. Фәйзуллин Сафиулла дигән укытучы, Насыйбулланың улы. Бу кеше армиядә әзрәк өйрәнеп кайткан була.

2. Әюб Сәфәр углы Чәчәков дигән кешедер. Бу кеше Глазовта байлар хезмәтендә йөреп, почта хезмәтендә дә йөреп самоучка, бераз гына язу өйрәнгән булган.

XIX гасырда Парҗы халкының хайваннары күп булган. «Җәй көнендә хайваннарны басуга көтүчесез генә җибәрә идек», – дип сөйлиләр картлар. Басу өчкә бүленеп, араларында киртә тотылган. Бу киртәне йорт башыннан бүлеп тотканнар. Парҗы татарлары иген эшләре бетеп торган араларда, удмурт авылларында йөргәләп, алыш-биреш белән канәгатьләнгәннәр. «Удмуртлардан атлар, колыннар алып суеп, гел ит кенә ашап тора идек, – дип сөйлиләр. – Эш юк иде, акча табуы кыен иде, – диләр. – Өске киемнәр начар, алача штан, кыш көннәрендә бик читен була иде», – дип сөйлиләр. Соңгы елларда Парҗыга да Татарстаннан итек басучылар, китап сатучылар, көмешчеләр килеп йөри башлаганнар икән.

Чын бәдәви халык шикелле яшәп кенә торган Парҗы татарларында да мәдәният чаткысы беленә башлады. XX гасыр башларында Парҗыга яхшырак укытучылар килеп укыта башлаганнар.

Татарларга бераз җан керә башлаган, хәрәкәтләнә башлаганнар. Ниһаять, Кистем безгә ерак, үзебезнең Парҗыга мәчет салырга кирәк, дип, патша хөкүмәтеннән рөхсәт сорый башлаганнар, ләкин хөкүмәт рөхсәт бирмәгән. Парҗы удмуртлары ислам диненә керерләр, дип, урыс хөкүмәте курыккан.

## Парҗы татарлары белән удмуртларның аерылышулары

Дөньяда Татар Парҗысы һәм Удмурт Парҗысы дигән авылларның килеп чыгуы. Парҗы мөселманнары һаман да рөхсәт сорауларыннан туктамаганнар. Бу эш 1900–1902 елларда буладыр.

Ахырда 1903 елларда патша хөкүмәте, удмуртларны 1 яки 2 чакрым читкәрәк аерып утырту шарты белән, мәчет салырга рөхсәт бирәдер. Бу вакытта Парҗы удмуртлары 14 семья (174 душ) булганнар икән...

Менә шушы кешеләр Удмурт Парҗы авылын дөньяга китереп чыгарганнар, Парҗы авылындагы татарлардан аерылып.

Парҗыдан бер чакрым түбәнрәк Парҗы елгасы буена, сул ягына утырганнар, 1904–1905 елларда. Шул ук елда Парҗы авылы Татар Парҗысы дип аталып калган.

Миссионерлар өйрәтүе буенча патша хөкүмәте, татарлар удмуртларны күчерә алмаслар да, мәчет сала алмаслар, дип уйлаган. Күчерү расходы татарлар өстеннән булган. Басуларында удмуртлар теләгән яхшы урыннан гына җир кисеп бирү шарты булган. Татарлар һич нәрсәгә карамыйча барча шартларга риза булып, удмуртларны күчерүгә, бер очтан мәчет тә сала башлаганнар. Башы булган һәр нәрсәнең аягы булган шикелле чукындыру мәдәниятенең дә актык көннәре җитә. 1905 ел килеп баса да, Русиядә хисапсыз еллардан бирле тулган чуаннар тишелә башлый. Кайдадыр эшчеләр тавышлана башлыйлар. 1906 елда мәчет салынган.

Хәзер яңа закун буенча удмуртларны күчермичә дә мәчет салырга рөхсәт ителә, диләр. Ләкин инде соң була, күчерелгән булалар. Менә патша хөкүмәте динне ничек саклаган.

1905 елдан соң Русиядә мәгариф (аң, белем, укыту) мәдәнияте башланадыр. Дин белән шөгыльләнү дә бер тәртипкә салынып китә.

Тат. Парҗыда халык 38 гаилә Касыймов фамилиясендә йөриләр, ләкин алар үзләре бер нәсел түгел, барысы сигезләп нәсел булалар.

Бу Касыймов фамилияләре ата-бабадан килсә дә, аларның бер нәсел булулары күрсәтелмидер. Чөнки бу Касыймов фамилиясендә

йөри торган алты авыл халкы языйлалар: 1) Тат. Парҗы, 2) Кече Парҗы, 3) Падера, 4) Биктеш, 5) Кистем, 6) Калибыр (Ахмедеево). Менә бу авылларда Касыймовлардан башка фамилиядәге кешеләр бик аз гынадыр. Тат. Парҗыда Бузиковлар 5 гаилә, Фәйзуллиннар 2 гаилә, Абашев 1 гаилә, Рәхимов 1 гаиләдер (1958 ел).

Бу Касыймов фамилиясендә кайсы авылларда «бисермән»нәр бар, дип ишетеләдер. Минем уйлавымча, бу Касыймов фамилиясендә бу кадәр күп авыллардагы халыкның языйлуы (булуы) шуннан калган булырга кирәк. Бик иске заманда бу кешеләрнең бабалары бер Касыймов фамилияле алпавыт яки «помещик»ның крестьяны булып, бай фамилиясе крестьяннарга да фамилия булган булыр һәм авылларына да исем булган булыр. Шул сәбәп белән төрле нәсел булсалар да бу фамилиядә булып калганнар. Моның шикелле факт (мисал)лар бик күптер, тарихчыларга мәгълүмдер.

Инде бу урында Тат. Парҗыдагы татарларның нәсел шәҗәрәләрен язамын, ләкин ир балалары гына. Ир балалары булмаганнар бетеп калалар».

## Татар Парҗысы авылындагы Касыймовлар нәселләренә мөнәсәбәтле шәҗәрәләр

Удмуртиядәге Глазов районы Татар Парҗысы авылындагы Касыймовлар нәсел шәҗәрәләрен җиде төркемгә берләштереп карарга мөмкин. Габдулла Ушмави аларның атаклы Карабәк нәселе булуларын күрсәтми, төрле очракларга бәйле рәвештә Касыймов фамилиясе алганнар, дип аңлата.

## I төркем Касыймовлар

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Хәсән | |
| | *II буын* | |
| 2. | Хөсәен | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Заһидулла | 2 |
| 4. | Мөхәммәтҗан | 2 |
| | *IV буын* | |
| 5. | Кәлимулла | 3 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 6. | Әхмәтҗан | 4 |
| 7. | Зәйнулла | 4 |
| 8. | Нигъмәтулла | 4 |
| | *V буын* | |
| 9. | Мәгъфүр | 5 |
| 10. | Равил | 5 |
| 11. | Рафиз | 5 |
| 12. | Матигулла | 7 |
| 13. | Летфулла | 7 |
| 14. | Мәнсур | 7 |

## II төркем Касыймовлар

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Йоныс | |
| | *II буын* | |
| 2. | Йосыф | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Гобәйдулла | 2 |
| | *IV буын* | |
| 4. | Шәрәфетдин | 3 |
| 5. | Сәйфулла | 3 |
| | *V буын* | |
| 6. | Идрис | 4 |
| 7. | Касыйм | 4 |
| 8. | Һибәтулла | 5 |
| | *VI буын* | |
| 9. | Габделфәрд | 6 |
| 10. | Габделхак | 6 |
| 11. | Нәҗип | 6 |
| 12. | Хикмәтулла | 6 |
| 13. | Рамазан | 7 |
| 14. | Гыйльфан | 7 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 15. | Фәиз | 8 |
| 16. | Гәрәй | 8 |
| 17. | Гайсә | 8 |
| | *VII буын* | |
| 18. | Фазылҗан | 13 |
| 19. | Шәрифҗан | 13 |
| 20. | Равил | 13 |
| 21. | Кәрим | 14 |
| 22. | Әнгам | 14 |
| 23. | Хәлил | 14 |
| 24. | Сәлим | 14 |
| 25. | Заһир | 14 |
| | *VIII буын* | |
| 26. | Басыйр | 17 |
| 27. | Габделбәр | 17 |
| 28. | Габдулла | 17 |
| 29. | Сөнгатулла | 17 |
| 30. | Гыйниятулла | 17 |

## III төркем Касыймовлар

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Гомәр | |
| | *II буын* | |
| 2. | Шәми | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Госман | 2 |
| 4. | Галиулла | 2 |
| | *IV буын* | |
| 5. | Локман | 3 |
| 6. | Әхмәт | 3 |
| 7. | Фазулла | 3 |
| 8. | Ясәви | 4 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 9. | Әүхәди | 4 |
| | *V буын* | |
| 10. | Зәйнулла | 5 |
| 11. | Габделхәй | 6 |
| 12. | Зариф | 6 |
| 13. | Зәки | 7 |
| 14. | Шәяхмәт | 7 |
| 15. | Габделәхәт | 8 |
| 16. | Гайнулла | 9 |
| 17. | Фәтхулла | 9 |
| | *VI буын* | |
| 18. | Нәкыйп | 10 |
| 19. | Фатыйх | 10 |
| 20. | Равил | 11 |
| 21. | Гайнулла | 12 |
| 22. | Сәмигулла | 12 |
| 23. | Васыйл | 16 |
| 24. | Гыйниятулла | 17 |
| 25. | Шәйхулла | 17 |
| | *VII буын* | |
| 26. | Ринат | 22 |
| 27. | Азат | 22 |

## IV төркем Касыймовлар

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Рәхимулла | |
| | *II буын* | |
| 2. | Һибәтулла | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Гыймадетдин | 2 |
| 4. | Идрис | 2 |
| 5. | Сәйфетдин | 2 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 6. | Бәдретдин | 2 |
| | *IV буын* | |
| 7. | Габделхак | 3 |
| 8. | Зәйнулла | 3 |
| 9. | Ясәви | 4 |
| 10. | Гыйльметдин | 5 |
| 11. | Лотфулла | 6 |
| 12. | Яхъя | 6 |
| | *V буын* | |
| 13. | Габделфәрт | 7 |
| 14. | Лотфулла | 7 |
| 15. | Гайнулла | 8 |
| 16. | Габделкави | 9 |
| 17. | Габделбари | 9 |
| 18. | Нәкыйп | 10 |
| 19. | Нәҗип | 10 |
| 20. | Нурулла | 10 |
| 21. | Мәгъфүр | 11 |
| | *VI буын* | |
| 22. | Габделбәр | 13 |
| 23. | Һади | 16 |
| 24. | Һабил | 16 |
| 25. | Рәшид | 16 |
| 26. | Рәфгат | 17 |
| 27. | Рафикъ | 17 |
| 28. | Равил | 17 |
| 29. | Фатих | 18 |
| 30. | Рашат | 18 |
| 31. | Фәрид | 18 |
| 32. | Якуб | 18 |
| 33. | Рифгат | 19 |
| 34. | Рафикъ | 19 |
| 35. | Мәлик | 20 |
| 36. | Заһир | 20 |
| 37. | Таһир | 20 |

## V төркем Касыймовлар

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Муса | |
| | *II буын* | |
| 2. | Габделхаликъ | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Рамазан | 2 |
| 4. | Мирас | 2 |
| 5. | Мәсгуд | 2 |
| | *IV буын* | |
| 6. | Шәмсетдин | 3 |
| 7. | Ясәви | 3 |
| 8. | Шәрәфетдин | 3 |
| 9. | Шәгъбән | 3 |
| 10. | Галим | 4 |
| | *V буын* | |
| 11. | Галәүтдин | 6 |
| 12. | Миңнулла | 6 |
| 13. | Исмәгыйль | 6 |
| 14. | Садретдин | 7 |
| 15. | Габделхәй | 8 |
| 16. | Бәдретдин | 9 |
| 17. | Хатим | 10 |
| | *VI буын* | |
| 18. | Варис | 11 |
| 19. | Вагыйз | 11 |
| 20. | Зәки | 11 |
| 21. | Рашид | 13 |
| 22. | Фәрид | 13 |
| 23. | Мөдәррис | 14 |
| 24. | Габделхак | 14 |
| 25. | Газимҗан | 14 |
| 26. | Камил | 15 |
| 27. | Нәҗиб | 16 |
| 28. | Радик | 17 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *VII буын* | |
| 29. | Равил | 23 |
| 30. | Рәшид | 23 |

## VI төркем Касыймовлар

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Сәйфулла | |
| | *II буын* | |
| 2. | Фәйзулла | 1 |
| 3. | Гобәйдулла | 1 |
| 4. | Гайшә | 1 |
| | *III буын* | |
| 5. | Мәүлүд | 2 |
| 6. | Габделвахит | 2 |
| 7. | Заһидулла | 3 |
| 8. | Зәйнелбәшәр | 3 |
| 9. | Заһретдин | 4 |
| | *IV буын* | |
| 10. | Фәхретдин | 5 |
| 11. | Габделкадыйр | 6 |
| 12. | Шәмсетдин | 7 |
| 13. | Габделхак | 7 |
| 14. | Габделбәр | 8 |
| | *V буын* | |
| 15. | Галиулла | 10 |
| 16. | Гәрәй | 11 |
| 17. | Зәйнетдин | 11 |
| 18. | Хәмидулла | 11 |
| 19. | Минхан | 12 |
| 20. | Әхәт | 13 |
| 21. | Зиннәтулла | 14 |
| 22. | Мөэмин | 14 |

## VII төркем Касыймовлар

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана иseme тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Габделрәшит | |
| 2. | Әбүбәкер | |
| | *II буын* | |
| 3. | Кәрим | 1 |
| 4. | Сәгыйть | 1 |
| 5. | Мөстәкыйм | 1 |
| 6. | Ибраһим | 1 |
| 7. | Бәдретдин | 2 |
| 8. | Фәхретдин | 2 |
| 9. | Хисаметдин | 2 |
| | *III буын* | |
| 10. | Ризван | 3 |
| 11. | Ногман | 3 |
| 12. | Вильдан | 3 |
| 13. | Гыйльман | 3 |
| 14. | Гыйльфан | 3 |
| 15. | Фазлыйәхмәт | 4 |
| 16. | Шәфгытдин | 4 |
| 17. | Нәҗметдин | 4 |
| 18. | Гали | 4 |
| 19. | Галим | 5 |
| 20. | Нәҗметдин | 6 |
| 21. | Шәрәфетдин | 6 |
| 22. | Исмәгыйль | 8 |
| 23. | Әсхәтулла | 9 |
| 24. | Вәлиулла | 9 |
| | *IV буын* | |
| 25. | Гайнан | 10 |
| 26. | Ф.-Гайан | 10 |
| 27. | Һади | 12 |
| 28. | Ахунҗан | 13 |
| 29. | Сәлимҗан | 13 |
| 30. | Зәкиҗан | 13 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 31. | Сафа | 14 |
| 32. | Хаҗиәхмәд | 15 |
| 33. | Әсгадулла | 15 |
| 34. | Идрис | 16 |
| 35. | Әхәт | 16 |
| 36. | Зиннәтулла | 17 |
| 37. | Харис | 17 |
| 38. | Гыйлаҗ | 18 |
| 39. | Шәриф | 18 |
| 40. | Сафьян | 18 |
| 41. | Нәгыйм | 19 |
| 42. | Хәлим | 19 |
| 43. | Гаязетдин | 20 |
| 44. | Ахунҗан | 20 |
| 45. | Шәмсетдин | 21 |
| 46. | Харис | 22 |
| 47. | Варис | 22 |
| 48. | Вагыйз | 22 |
| | *V буын* | |
| 49. | Нурислам | 25 |
| 50. | Динислам | 25 |
| 51. | Хәлил | 25 |
| 52. | Рамил | 26 |
| 53. | Зәки | 31 |
| 54. | Рифгат | 31 |
| 55. | Яхъя | 32 |
| 56. | Габделхәй | 32 |
| 57. | Равил | 32 |
| 58. | Әкрам | 34 |
| 59. | Мөбарәк | 34 |
| 60. | Лотфулла | 36 |
| 61. | Нафил | 36 |
| 62. | Мансур | 36 |
| 63. | Фәрид | 38 |
| 64. | Әгъзам | 41 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 65. | Равил | 41 |
| 66. | Ринат | 41 |
| 67. | Хәмил | 42 |
| 68. | Наил | 42 |
| | *VI буын* | |
| 69 | Вил | 60 |

## Татар Парҗысы авылындагы Бузиковлар нәселе шәҗәрәсе

Бу фамилиянең башында торучы баба, Татарстан Республикасының Әтнә төбәгендә Иске Мәңгәр авылы янындагы XVI гасырның беренче яртысында куелган каберташка нигезләнеп, Бүзнак солтанга барып тоташа, дип фараз ителә. Бүзнак солтан Тугаш углы 1543 елда вафат булган. Касыймовлар шәҗәрәсе борынгыдан килгәнлеккә шөбһә булмагач, бу фамилиянең дә бабасы шулай борынгы абруйлы зат булырга тиеш.

### I төркем

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Габид | |
| 2. | Мостафа | |
| | *II буын* | |
| 3. | Әхмәр | 1 |
| 4. | Биктимер | 2 |
| | *III буын* | |
| 5. | Сабит | 3 |
| 6. | Исхак | 4 |
| 7. | Йоныс | 4 |
| 8. | Мәүлүд | 4 |
| | *IV буын* | |
| 9. | Садыйк | 5 |
| 10. | Хатим | 6 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 11. | Камалетдин | 7 |
| | *V буын* | |
| 12. | Хафиз | 9 |
| 13. | Габделбәр | 9 |
| 14. | Мөх.-гали | 9 |
| 15. | Фәтхулла | 9 |
| 16. | Әхәт | 9 |
| 17. | Лотфулла | 9 |
| 18. | Габдулла | 9 |
| 19. | Габдулла | 10 |
| 20. | Габделхак | 10 |
| 21. | Гыймадетдин | 11 |
| | *VI буын* | |
| 22. | Хикмәт | 19 |
| 23. | Нурислам | 20 |
| 24. | Әмир | 21 |
| 25. | Мирза | 21 |

## II төркем

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Габдулла | |
| | *II буын* | |
| 2. | Фәтхулла | 2 |
| | *III буын* | |
| 3. | Габид | 2 |
| | *IV буын* | |
| 4. | Камалетдин | 3 |
| 5. | Шакир | 3 |
| | *V буын* | |
| 6. | Сәлахетдин | 5 |
| | *VI буын* | |
| 7. | Сәгыйть | 6 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 8. | Лотфулла | 6 |
| 9. | Равил | 6 |
| | *VII буын* | |
| 10. | Равил | 8 |

Татар Парҗысы авылына якын күрше булган Кече Парҗы авылы татарларының нәсел шәҗәрәләре Габдулла Ушмави кульязмасында урын алган.

**Нәзир Мөэмин улының шәҗәрәсе**

**I нәсел**

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Мөэмин | |
| | *II буын* | |
| 2. | Нәзир | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Бәшир | 2 |
| 4. | Фәтхетдин | 2 |
| 5. | Галиулла | 2 |
| 6. | Әзһәр | 2 |
| 7. | Әхтәм | 2 |
| | *VI буын* | |
| 8. | Мөхәммәди | 3 |
| 9. | Исмәгыйль | 3 |
| 10. | Ибраһим | 3 |
| 11. | Гыйльман | 4 |
| 12. | Госман | 4 |
| 13. | Шәфгытдин | 5 |
| 14. | Габделҗәббар | 5 |
| 15. | Мәкәй | 6 |
| 16. | Рамазан | 7 |
| 17. | Исмәгыйль | 7 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *V буын* | |
| 18. | Халид | 8 |
| 19. | Фәхретдин | 8 |
| 20. | Әүхәд | 8 |
| 21. | Камалетдин | 9 |
| 22. | Заһретдин | 9 |
| 23. | Бәдретдин | 9 |
| 24. | Шәмәрдән | 10 |
| 25. | Шаһиәхмәт | 10 |
| 26. | Йосыф | 11 |
| 27. | Ягъкуб | 11 |
| 28. | Солтан | 12 |
| 29. | Фәхретдин | 13 |
| 30. | Һашим | 14 |
| 31. | Габделхәй | 14 |
| 32. | Мөэмин | 15 |
| 33. | Сафа | 16 |
| 34. | Габдрахман | 16 |
| 35. | Әбрар | 17 |
| | *VI буын* | |
| 36. | Габделфәрд | 18 |
| 37. | Равил | 20 |
| 38. | Рафиз | 20 |
| 39. | Рафаил | 20 |
| 40. | Әсгатулла | 21 |
| 41. | Зәки | 21 |
| 42. | Гайсә | 22 |
| 43. | Нурислам | 23 |
| 44. | Шәйхелислам | 23 |
| 45. | Нургаян | 23 |
| 46. | Әхәт | 25 |
| 47. | Варис | 26 |
| 48. | Исмәгыйль | 26 |
| 49. | Һади | 27 |
| 50. | Габделхак | 28 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 51. | Наил | 28 |
| 52. | Гайса | 29 |
| 53. | Минхан | 29 |
| 54. | Мөдәррис | 29 |
| 55. | Рәхимҗан | 30 |
| 56. | Шәрифҗан | 30 |
| 57. | Таһир | 30 |
| 58. | Газимҗан | 30 |
| 59. | Нәҗип | 31 |
| 60. | Рафикъ | 31 |
| 61. | Риза | 33 |
| 62. | Равил | 34 |
| 63. | Яхъя | 35 |
| | *VII буын* | |
| 64. | Касыйм | 36 |
| 65. | Камил | 40 |
| 66. | Һади | 40 |
| 67. | Нәкыйп | 40 |
| 68. | Азат | 40 |
| 69. | Рәшит | 40 |
| 70. | Таһир | 42 |
| 71. | Рафил | 52 |
| 72. | Рәшит | 59 |

## II нәсел

Рәхим белән Мәмеш – бертуганнар, диләр

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | ? | |
| | *II буын* | |
| 2. | Рәхим | 1 |
| 3. | Шәмсетдин | 1 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *III буын* | |
| 4. | Фәтхулла | 2 |
| 5. | Һибәтулла | 2 |
| 6. | Хисмәтулла | 3 |
| 7. | Сәйфулла | 3 |
| 8. | Мөхәммәтҗан | 3 |
| | *IV буын* | |
| 9. | Гобәйдулла | 4 |
| 10. | Шәрәфетдин | 4 |
| 11. | Сабит | 4 |
| 12. | Әхмәдулла | 5 |
| 13. | Сәгыйть | 6 |
| 14. | Сабит | 6 |
| 15. | Фәтхулла | 7 |
| 16. | Әхмәтҗан | 8 |
| | *V буын* | |
| 17. | Сәгыйть | 9 |
| 18. | Идрис | 10 |
| 19. | Галиулла | 10 |
| 20. | Габделкаюм | 11 |
| 21. | Төхфәтулла | 12 |
| 22. | Гобәйдулла | 12 |
| 23. | Мөхәммәд | 13 |
| 24. | Рәфгат | 13 |
| 25. | Фатыйх | 14 |
| 26. | Садыйк | 14 |
| 27. | Хәниф | 14 |
| 28. | Мансур | 15 |
| 29. | Самигулла | 16 |
| | *VI буын* | |
| 30. | Нәҗип | 18 |
| 31. | Һади | 18 |
| 32. | Нәкыйп | 18 |
| 33. | Гайнулла | 19 |
| 34. | Гыйниятулла | 19 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 35. | Нигъмәтулла | 19 |
| 36. | Миннеш | 20 |
| 37. | Хәбибулла | 21 |
| 38. | Сәлахетдин | 21 |
| 39. | Газимҗан | 21 |
| 40. | Габделбәр | 21 |
| | *VII буын* | |
| 41. | Рафаил | 30 |
| 42. | Риза | 30 |
| 43. | Нурислам | 31 |
| 44. | Равил | 32 |
| 45. | Нәҗип | 33 |
| 46. | Хаҗиәхмәт | 33 |
| 47. | Әхәт | 33 |
| 48. | Рафис | 36 |
| 49. | Васил | 36 |
| 50. | Муллаҗан | 37 |
| 51. | Нәҗип | 37 |
| 52. | Фәттах | 38 |
| 53. | Габделхәй | 38 |
| 54. | Имин | 38 |
| 55. | Шәкерт | 38 |
| 56. | Нигъмәт | 38 |
| 57. | Рәфгат | 39 |
| 58. | Рәхимҗан | 39 |
| 59. | Рәшит | 39 |
| | *VIII буын* | |
| 60. | Кәрим | 52 |
| 61. | Сәлим | 52 |
| 62. | Кәбир | 53 |
| 63. | Хәлил | 54 |

**III нәсел**

Хисмәтулла хатыны Камиләгә ияреп килгән бала Гобәйдулла.

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана иseме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Гобәйдулла | |
| 2. | Габҗәлил | |
| | *II буын* | |
| 3. | Сөнгатулла | 1 |
| 4. | Әсгатулла | 1 |
| 5. | Рәхимҗан | 1 |

Хисмәтулладан туганнар – Сәгыйть, Сабит; Сәгыйтьтән туган – Мөхәммәт һәм Рифгат.

**IV нәсел**

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Габделхани | |
| | *II буын* | |
| 2. | Төхфәтулла | 1 |
| 3. | Гобәйдулла | 1 |
| 4. | Вәлиулла | 1 |
| | *III буын* | |
| 5. | Әлтаф | 2 |
| 6. | Лотфулла | 2 |
| 7. | Гыйльмулла | 2 |
| 8. | Заһидулла | 3 |
| 9. | Насыйбулла | 3 |
| 10. | Кәлимулла | 3 |
| 11. | Сафиулла | 4 |
| 12. | Бәдретдин | 4 |
| 13. | Ибраһим | 4 |
| | *IV буын* | |
| 14. | Мансур | 5 |
| 15. | Хикмәтулла | 6 |
| 16. | Фәйзулла | 6 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 17. | Нурулла | 8 |
| 18. | Сөнгатулла | 9 |
| 19. | Әсгатулла | 9 |
| 20. | Ихсан | 10 |
| 21. | Ибраһим | 10 |
| 22. | Фатыйх | 10 |
| 23. | Зиннәтулла | 11 |
| 24. | Закир | 11 |
| 25. | Гайнетдин | 11 |
| 26. | Зәйнетдин | 11 |
| 27. | Муллаҗан | 13 |
| | *V буын* | |
| 28. | Һади | 17 |
| 29. | Рәфикъ | 17 |
| 30. | Мансур | 18 |
| 31. | Яхъя | 18 |
| 32. | Габделхәй | 18 |
| 33. | Равил | 19 |
| 34. | Әхәт | 19 |

## V нәсел

Фәйзулла бине Шәмсетдин бине Габсәлам

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Габсәлам | |
| | *II буын* | |
| 2. | Шәмсетдин | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Фәйзулла | 2 |
| | *IV буын* | |
| 4. | Вәлиулла | 3 |
| 5. | Муса | |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *V буын* | |
| 6. | Галиулла | 4 |
| 7. | Хисмәтулла | 5 |
| | *VI буын* | |
| 8. | Камалетдин | 6 |
| 9. | Рамазан | 6 |
| 10. | Сибгатулла | 7 |
| 11. | Лотфулла | 7 |
| 12. | Һидиятулла | 7 |
| 13. | Сәмигулла | 7 |
| | *VII буын* | |
| 14. | Сәет | 8 |
| 15. | Васил | 8 |
| 16. | Габделхак | 8 |
| 17. | Шамил | 8 |
| 18. | Харис | 8 |
| 19. | Бари | 8 |
| 20. | Ясәви | 9 |
| 21. | Нәҗип | 9 |
| 22. | Гыйбади | 9 |
| 23. | Рәшид | 9 |
| 24. | Габделхәви | 10 |
| 25. | Габделхәй | 10 |
| | *VIII буын* | |
| 26. | Варис | 20 |
| 27. | Харис | 20 |
| 28. | Равил | 24 |
| 29. | Рафаил | 24 |

## VI нәсел

Кече Парҗыда 6 нчы нәсел – Чистай өязеннән Чаллыбаш авылыннан килгән нәселдер. Бу нәсел Кече Парҗыга килгәч, фамилияләрен дә Касыймов, – дип яза башлаганнар. Үзләренең фамилияләре Шәмсетдинов икән. Газимҗанның анасы Мәликә, Дәүләтшадан аерылып, Татар Парҗысына килеп, Камалетдин

Бузиковка никахланган, фамилиясен Бузиков дип яза башлаганнар. Шәмсетдинов Дәүләтшаның Яхъя дигән улы Касыймов булып, Газимҗан дигән улы Татар Парҗысында Бузиков булып йөриләр.

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Шәмсетдин | |
| | *II буын* | |
| 2. | Дәүләтша | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Яхъя | 2 |
| 4. | Газимҗан | 2 |
| | *IV буын* | |
| 5. | Нургаян | 3 |
| 6. | Һади | 4 |
| 7. | Ягъкуб | 4 |

*Искәрмә*

Габдулла Ушмави китабына кергән татар шәҗәрәләре, Татарстаннан читтә, Киров өлкәсендә һәм Удмуртиядә яшәгән татар халкы вәкилләренең гомуммилли мәдәният кысалары эчендә әле XX гасырда да борынгы традицияләрне саклаганлыкларын күрсәтәләр. Аларның нәсел таблицаларында руслашу билгеләре Татарстандагы халык дәрәҗәсендә үк күзгә ташланмый. Аларда православие, католицизм тәэсирләре бик аз сизелә.

Габдулла Ушмави язмалары Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мира сүзәгендә 99 коллекциядә, 1 тасвир, 176 сан берәмлеге булып саклана.

Аерым сәбәпләр аркасында Габдулла Ушмави Касыймовлар нәселенең борынгы тарихларын күрсәтмәгән. Шәҗәрә текстының кайбер версияләре минем кайбер хезмәтләремдә дөнья күрделәр инде.

Бу вариант Касыймовларның 600 ел дәвамында яшәгән урыннарында нәселләре дәвам итүен күрсәтә һәм, Габдулла Ушмави

китабы белән берлектә, татар этник тарихы буенча кыйммәтле чыганак булып санала.

**Карабәк нәселенең**
Ильмир Касыймов тарафыннан эшләнгән шәҗәрәсе
(текст оригинал телендә бирелә)

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I поколение* | |
| 1. | Гази Мансур | |
| | *II поколение* | |
| 2. | Шаги Мансур | 1 |
| | *III поколение* | |
| 3. | Газым бий (Казый) | 2 |
| | *IV поколение* | |
| 4. | Касыйм (упомин. в 1551 г.) | 3 |
| 5. | Ишамайка (умер бездетным) | 3 |
| | *V поколение* | |
| 6. | Бажен бий | 4 |
| | *VI поколение* | |
| 7. | Третьяк | 6 |
| | *VII поколение* | |
| 8. | Шагум | 7 |
| 9. | Семен | 7 |
| | *VIII поколение* | |
| 10. | Маметали | 8 |
| 11. | Маматкул (Из Карино переехал в Кестым) | 8 |
| 12. | Байрамали | 8 |
| 13. | Малик | 9 |
| 14. | Нияз | 9 |
| 15. | Юнус | 9 |
| 16. | Зянбулат | 9 |
| 17. | Валей | 9 |
| 18. | Юсуп | 9 |
| | *IX поколение* | |
| 19. | Мирас | 10 |
| 20. | Мавлямберды (из Карино переехал в Кестым) | 10 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 21. | Алмамет | 10 |
| 22. | Саиткул | 11 |
| 23. | Максют | 13 |
| 24. | Ибрашь | 14 |
| 25. | Назар | 14 |
| 26. | Якуп (Ибрашь, Назар, Якуп из Карино выехали в д. Шашинскую Алатской дороги Казанского наместничества) | 14 |
| 27. | Ишман (Из Карино переехал в д. Аднагулово Уфимского наместничества) | 17 |
| 28. | Талмет | 18 |
| | *X поколение* | |
| 29. | Багыш (Бавлюш, Мавлюш) | 22 |
| 30. | Курбанай | 22 |
| 31. | Исмай (из Карино переехал в Кестым) | 23 |
| 32. | Исмаил | 28 |
| 33. | Ефар | 28 |
| 34. | Миней | 28 |
| 35. | Муртаза | 28 |
| | (Все они выехали в Оренбург в 1749 году) | |
| | *XI поколение* | |
| 36. | Филимон | 29 |
| 37. | Ягуда | 29 |
| 38. | Мусалям | 29 |
| 39. | Рамазан (1730–1792) | 29 |
| 40. | Ибрагим | 30 |
| 41. | Мавлюкай | 30 |
| | *XII поколение* | |
| 42. | Салих | 38 |
| 43. | Зягфар | 38 |
| 44. | Саит | 39 |
| 45. | Сагит | 39 |
| 46. | Салих | 39 |
| 47. | Мустаким | 39 |
| 48. | Мухаммат (род. в 1753 г.) | 40 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 49. | Губайдулла | 42 |
| 50. | Файзулла | 42 |
| 51. | Гали | 42 |
| | *XIII поколение* | |
| 52. | Сабит | 45 |
| 53. | Габидулла | 46 |
| 54. | Ахмадулла | 46 |
| 55. | Хамит | 47 |
| 56. | Сабит | 47 |
| 57. | Губайдулла | 49 |
| 58. | Назыр | 49 |
| 59. | Амир | 49 |
| 60. | Баязид | 49 |
| | *XIV поколение* | |
| 61. | Абдрахим | 53 |
| 62. | Абзялиль | 58 |
| 63. | Сайфулла | 58 |
| 64. | Хамидулла | 60 |
| 65. | Гибадулла | 60 |
| 66. | Тагир | 60 |
| 67. | Насыр | 62 |
| 68. | Забир | 62 |
| 69. | Назир | 62 |
| 70. | Губайдулла | 62 |
| | *XV поколение* | |
| 71. | Бахаутдин | 72 |
| 72. | Тахаутдин | 72 |
| 73. | Сабир | 73 |
| 74. | Кабир | 73 |
| 75. | Курбангали | 74 |
| 76. | Ваккас | 74 |
| 77. | Халит | 74 |
| 78. | Габбас | 74 |
| | *XVI поколение* | |
| 79. | Шакир | 76 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 80. | Габдулла | 76 |
| 81. | Галим | 78 |
| 82. | Шамсутдин | 78 |
| 83. | Шарафутдин | 78 |
| 84. | Валиулла | 79 |
| 85. | Габдулхак | 79 |
| 86. | Газизулла | 79 |
| 87. | Юсуп | 79 |
| 88. | Набиулла | 79 |
| 89. | Галиулла | 79 |
| 90. | Губайдулла | 79 |
| 91. | Исмагил | 80 |
| 92. | Зайдулла | 80 |
| 93. | Сафиулла | 80 |
| 94. | Сайфулла | 81 |
| 95. | Идаят | 81 |
| 96. | Габдулла | 81 |
| 97. | Хафиз | 83 |
| 98. | Фатих | 83 |
| 99. | Гариф | 83 |
| | *XVII поколение* | |
| 100. | Кадыр | 84 |
| 101. | Исмагил | 86 |
| 102. | Мухаммедзян | 86 |
| 103. | Мукмин | 86 |
| 104. | Ахмедзян | 86 |
| 105. | Лутфулла | 87 |
| 106. | Самигулла | 90 |
| 107. | Газизулла | 90 |
| 108. | Муса | 90 |
| 109. | Мустафа | 90 |
| 110. | Габдулла | 90 |
| 111. | Валиулла | 93 |
| 112. | Файзулла | 95 |
| 113. | Лутфулла | 95 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 114. | Ибрагим | 96 |
| 115. | Мукмин | 96 |
| 116. | Шайхинур | 96 |
| 117. | Гайнулла | 97 |
| 118. | Зиннат | 97 |
| 119. | Мухамедзян | 98 |
| 120. | Камалтдин | 98 |
| 121. | Гусман | 98 |
| 122. | Мурас | 98 |
| 123. | Валиулла | 98 |
| 124. | Валиулла | 100 |
| 125. | Ахмед | 102 |
| 126. | Шаяхмет | 103 |
| 127. | Габдулхак | 103 |
| 128. | Ясави | 103 |
| | *XVIII поколение* | |
| 129. | Закир | 105 |
| 130. | Шамиль | 106 |
| 131. | Равиль | 106 |
| 132. | Салим | 111 |
| 133. | Шамиль | 111 |
| 134. | Тахир | 111 |
| 135. | Минсара | 114 |
| 136. | Мастюра | 114 |
| 137. | Зухра | 114 |
| 138. | Ринат | 114 |
| 139. | Муса | 114 |
| 140. | Тахир | 114 |
| 141. | Лутфулла | 115 |
| 142. | Мансур | 115 |
| 143. | Эрнест | 117 |
| 144. | Радик | 117 |
| 145. | Рафаил | 117 |
| 146. | Рафис | 117 |
| 147. | Эдди | 118 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 148. | Рута | 118 |
| 149. | Гесс | 118 |
| 150. | Гим | 118 |
| 151. | Мелс | 118 |
| 152. | Габдулла | 118 |
| 153. | Чикис | 118 |
| 154. | Фатхулла | 118 |
| 155. | Раиса | 118 |
| 156. | Раида | 118 |
| 157. | Тахир | 121 |
| 158. | Ильмир | 121 |
| 159. | Насия | 121 |
| 160. | Гульзямал | 122 |
| 161. | Тавис | 122 |
| 162. | Мансур | 122 |
| 163. | Ильдар | 123 |
| 164. | Марат | 123 |
| 165. | Фатхулла | 126 |
| 166. | Габдулла | 127 |
| 167. | Мухамедзян | 127 |
| 168. | Муса | 127 |
| 169. | Нурислям | 128 |
| 170. | Нургали | 128 |
| 171. | Зиннатулла | 129 |
| 172. | Хазиахмед | 131 |
| 173. | Хузяахмед | 131 |
| 174. | Зиннатулла | 131 |
| | *XIX поколение* | |
| 175. | Тахир | 134 |
| 176. | Анвар | 138 |
| 177. | Эльза | 140 |
| 178. | Ильмир | 140 |
| 179. | Гульнара | 142 |
| 180. | Гулия | 143 |
| 181. | Раиль | 143 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 182. | Лилия | 144 |
| 183. | Алсу | 144 |
| 184. | Руслан | 145 |
| 185. | Ильяс | 145 |
| 186. | Ильнур | 148 |
| 187. | Альберт | 150 |
| 188. | Рустам | 151 |
| 189. | Реваль | 157 |
| 190. | Ринат | 157 |
| 191. | Рашит | 157 |
| 192. | Рамис | 158 |
| 193. | Фанис | 158 |
| 194. | Раис | 158 |
| 195. | Ильяс | 158 |
| 196. | Маннур | 163 |
| 197. | Айнур | 163 |
| 198. | Альберт | 165 |
| 199. | Диля | 166 |
| 200. | Руслан | 167 |
| 201. | Гусман | 174 |
| 202. | Нурулла | 174 |
| | *XX поколение* | |
| 203. | Рустам | 192 |
| 204. | Руслан | 194 |
| 205. | Васил | 194 |
| 206. | Сария | 195 |
| 207. | Мирия | 195 |
| 208. | Рамиль | 196 |
| 209. | Айнур | 205 |
| 210. | Марат | 205 |
| 211. | Ильнур | 205 |
| 212. | Зиннур | 205 |

*Искәрмә*

Шәҗәрә текстының бу версиясе Кистем авылында яшәүче Ильмир Касыймов тарафыннан Киров шәһәрендәге архив материаллары нигезендә 2006–2007 елларда төзелгән.

Ильмир Касыймов бу шәҗәрәне «Родословная потомков арских князей – Касыймовых из рода Баяз, живущих в д. Кестым Балезинского района Удмуртской Республики» дип атаган. Аннан алынган күчермә компьютерда җыеп бастырылган һәм ул Казандагы Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә 99 колл., 1 тасвир. 406 санлы эш берәмлеге буларак саклана.

Бу текст Удмуртиядә яшәүче Гыйльман Касыймов төзегән шәҗәрәгә якын, ләкин аермалары да шактый.

Аларда Нократ татарларының Татарстанның хәзерге Әтнә төбәге Шашы һәм Оренбург ягындагы Каргалы, Тәтер-Арслан, Яшерган авылларына да килеп утырулары теркәлгән.

* * *

Карабәк нәселләре хәзерге Удмуртиянең төньяк-көнбатыш җирләренә XIV гасырның ахырында килеп утырган. Бу җирләр әле Алтын Урданың Болгар олысы биләмәләре булып, удмуртларның бабалары да ул вакытларда коми халыклары белән янәшә, төньякта яшәгәннәр. Карабәк яшәгән төп регионда марилар да килеп урнашканнар. Хәзерге вакытта Карабәк нәселләре Балезино, Глазов районнарындагы татар авылларында яшиләр.

Шулай ук Карабәк нәселеннән булган затлар Татарстанның Әгерҗе, Арча, Актаныш, Менделеев, Алабуга якларыннан Ижау шәһәренә дә күпләп килеп, төпләнеп калганнар.

*Ризаэддин Фәхретдин архивыннан*

**Кара бик шәҗәрәсе**

Ул олуг Сократ хәким нәселе. Әүвәл Сократ хәким, Искәндәр шаһ берлә мәңү суы эстәгәндә бергә ирмеш. Олуг бабамыз Гыйффәт Солтан, аның углы Габделгазиз солтан, аның углы Әлвар солтан, аның углы Бирде солтан, аның углы Габдерахман солтан, аның углы Бажтан солтан Рум вилайәтеннән килеп, Йаекга, Сакмар тамагында күп рузгар иткәннәр. Бажтан солтанның углы Балым бик, аның углы Калдар бик, аның углы Күкчә тархан, икенче Ханбар биктер, Ак Идел буенда Нәксадә рузгар иткәннәр. Кара бикнең углы Ханбар бик. Аның өч углы бар ирде: бере Нар бик, икенче Ишем солтан, өченче Кара бик. Килеп Өчпүләдә йорт иткәннәр. Ул Кара бик агаларына үңгесе тартып китеп, Калталы Иван – карт Иванга, сар

Иван Вачилийгә килеп, баш салып, андин соң ул олуг бабамыз Кара биккә падишаһымыз Калталы Иван Вачилий йарлыкаган Нократ йирен биргән. Ул Нократта һич мөселман юк ирмеш иде. Ул йирнең исеме шәрифе Нократ улсын дийү ат биргәннәр. Сократ хәкимнең ыруг-нәселләре ул йирдә мәкам идеке өчен падишаһдан биклек үтенеп йарлыкаш бабамыз Кара бикне падишаһ Калталы Иван йарлыкап Чүпче дигән суы буен башындин тамагына тигрү ары вә урысы берлән, татары вә чирмеше берлән крәстийәнгә биргән, ике яга йылгасы, торуг агачы берлә, ятыр кискәсе берлә, йөгерек камасы берлә, кондозы вә сусары, тиене берлә, киеге-кошы берлә, аю-бүресе берлә, балыгы-чабагы берлә бирептер. Ул йарлыкап биргән йарлыкашны бабамыз Бичура биккә тигрү вә ашаганлар... Кара бикнең фәриглары.

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана иселе тәртибе |
|---|---|---|
| | *XI буын* | |
| 1. | Кара бик | |
| | *XII буын* | |
| 2. | Пакачир морза | 1 |
| 3. | Мөхәммәт бик | 1 |
| 4. | Гали бик | 1 |
| | *XIII буын* | |
| 5. | Алиш (баш) бик | 4 |
| 6. | Әлсуфый бик | 4 |
| | *XIV буын* | |
| 7. | Чуваш бик | 6 |
| 8. | Суфый солтан | 6 |
| 9. | Банша суфыйан | 6 |
| 10. | Сәйтәк бик | 6 |
| | *XV буын* | |
| 11. | Бики бик | 7 |
| 12. | Урак морза | 8 |
| 13. | Йосыф бик | 10 |
| 14. | Шыгайыб бик | 10 |
| 15. | Җансәет | 10 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *XVI буын* | |
| 16. | Пәйке морза | 11 |
| 17. | Дәүләтъяр морза | 12 |
| 18. | Айбулат морза | 12 |
| 19. | Айкилде морза | 12 |
| 20. | Йанкай бик | 13 |
| 21. | Азамат бик | 14 |
| 22. | Гали бик | 14 |
| 23. | Байсәет | 15 |
| | *XVII буын* | |
| 24. | Дусмөхәммәт морза | 16 |
| 25. | Ишмөхәммәт морза | 16 |
| 26. | Йанкилде морза | 19 |
| 27. | Мәкәй бик | 20 |
| 28. | Җәнә(й)? бик | 21 |
| 29. | Айдар хафиз | 21 |
| 30. | Хуҗа бик | 21 |
| 31. | Хуҗасәед | 23 |
| | *XVIII буын* | |
| 32. | Азлы морза | 24 |
| 33. | Ает морза | 24 |
| 34. | Йәрмәк морза | 24 |
| 35. | Илмәк морза | 25 |
| 36. | Килмәк морза | 25 |
| 37. | Салих морза | 26 |
| 38. | Ишмәт бик | 27 |
| 39. | Туймәт бик | 27 |
| 40. | Котлыш бик | 28 |
| 41. | Кишет бик | 29 |
| 42. | Туймәт | 29 |
| 43. | Корбан би | 30 |
| 44. | Коташ би | 30 |
| 45. | Килдийар би | 31 |
| 46. | Җан морза | 31 |
| 47. | Котлы би | 31 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| 48. | Байкилде би | 31 |
| 49. | Кодаяр би | 31 |
| | *XIX буын* | |
| 50. | Сәет морза | 32 |
| 51. | Габдерахман морза | 32 |
| 52. | Мокай морза | 33 |
| 53. | Ибраһим морза | 34 |
| 54. | Исмәгыйль морза | 34 |
| 55. | Әҗкә морза | 35 |
| 56. | Ырыс морза | 36 |
| 57. | Колмак морза | 36 |
| 58. | Таһир морза | 37 |
| 59. | Туймәт морза | 37 |
| 60. | Дәүләтъяр морза | 37 |
| 61. | Рахманкол морза | 37 |
| 62. | Ибәле бик | 39 |
| 63. | Чирүви бик | 39 |
| 64. | Бикмәт бик | 39 |
| 65. | Мишүй бик | 39 |
| 66. | Баймәт | 42 |
| 67. | Бикчәнтәй бик | 42 |
| 68. | Дүскәй бик | 42 |
| 69. | Өркәч мулла | 43 |
| 70. | Бәйрәш | 43 |
| 71. | Биккенә | 44 |
| 72. | Табынчы бик | 44 |
| 73. | Мисин бик | 44 |
| 74. | Биктимер хафиз | 45 |
| 75. | Хәсән бик | 45 |
| 76. | Хөсәен бик | 45 |
| 77. | Котлы бик | 46 |
| 78. | Уразай | 46 |
| 79. | Бикмәт бик | 46 |
| 80. | Йөрмәк морза | 49 |
| 81. | Илмәк | 49 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *XX буын* | |
| 82. | Мөэмин морза | 50 |
| 83. | Сөбханкол морза | 51 |
| 84. | Хәсән морза | 52 |
| 85. | Морат морза | 53 |
| 86. | Гали | 54 |
| 87. | Солтан | 55 |
| 88. | Давыт морза | 56 |
| 89. | Илимин морза | 60 |
| 90. | Габдерахман морза | 61 |
| 91. | Уразай би | 66 |
| 92. | Котлы би | 66 |
| 93. | Үрмәк морза | 81 |
| 94. | Мамай морза | 81 |
| | *XXI буын* | |
| 95. | Нигъмәтулла | 82 |
| 96. | Туйкилде | 82 |
| 97. | Сөләйман морза | 84 |
| 98. | Рахманкол морза | 85 |
| 99. | Мостафа | 86 |
| 100. | Монасиб | 86 |
| 101. | Мостай морза | 87 |
| 102. | Исхак морза | 88 |
| 103. | Сөләйман морза | 88 |
| | *XXII буын* | |
| 104. | Гобәйдулла | 95 |
| 105. | Рәхмәтулла | 96 |
| 106. | Муса | 96 |
| 107. | Габдессәләм | 98 |
| 108. | Хәнәфийә | 98 |
| 109. | Бакый | 98 |
| 110. | Мортаза | 98 |
| 111. | Корбангали | 102 |
| 112. | Баязит | 102 |
| 113. | Әбли морза | 103 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *XXIII буын* | |
| 114. | Зәйнулла | 104 |
| 115. | Йосыф | 105 |
| 116. | Йагкуб | 105 |
| 117. | Мөхәммәтҗан | 105 |
| 118. | Ислам | 105 |
| 119. | Исхак | 105 |
| 120. | Мостафа | 106 |
| 121. | Рәфыйк | 106 |
| 122. | Мөхәммәтгата | 111 |
| 123. | Габделкәрим | 111 |
| 124. | Габденасыйр | 111 |
| 125. | Әмир морза | 111 |
| 126. | Гыйбадулла | 112 |
| 127. | Ваһап | 112 |
| 128. | Нигъмәтулла | 112 |
| 129. | Гафур | 113 |
| 130. | Хаммат | 113 |
| 131. | Хәбибулла | 113 |
| | *XXIV буын* | |
| 132. | Хужа Әхмәт | 120 |
| 133. | Әхмәтҗан | 120 |
| 134. | Мөхәммәтҗан | 120 |
| 135. | Шаһиәхмәт | 120 |
| 136. | Мөхәммәтсадыйк | 120 |
| 137. | Зиннәтулла | 121 |
| 138. | Искәндәр | 121 |
| 139. | Мөхәммәтзариф | 124 |
| 140. | Әхмәр морза | 125 |
| 141. | Дийар | 129 |
| 142. | Мозаффар | 129 |
| 143. | Әхмәт | 129 |
| 144. | Мохтәр | 129 |
| 145. | Вәли | 131 |
| 146. | Шаһи | 131 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *XXV буын* | |
| 147. | Гобәйдулла | 133 |
| 148. | Кәлимулла (туган 1871 нче мәсихияттән (Миладиел исәбе буенча. – ***М. Ә.***), Ижевск завутта) | 133 |
| 149. | Вәлиулла (туган 1873 нче елында, Сарапул өйәзе Вәткә губирнасы) | 133 |
| 150. | Габделбәшир морза | 140 |
| 151. | Мостафа | 142 |
| 152. | Мәхмүт | 143 |
| 153. | Мәдийар | 143 |
| 154. | Галиәкбәр | 144 |
| | *XXVI буын* | |
| 155. | Гали | 150 |
| 156. | Гайнулла | 150 |
| 157. | Габделхалик | 150 |
| 158. | Габделлатыйп | 150 |
| | *XXVII буын* | |
| 159. | Нәҗметдин | 155 |
| 160. | Камалетдин | 155 |
| 161. | Хөснетдин | 155 |
| 162. | Җамалетдин | 155 |
| 163. | Таҗетдин | 155 |
| 164. | Илйас | 157 |
| 165. | Муса | 157 |
| 166. | Каһарман | 157 |
| 167. | Лотфи | 158 |
| | *XXVIII буын* | |
| 168 | Таҗетдин | 161 |

Асылдан күчереп алдыкы 1895 нче мәсихийәттә нуйәбер 28 нче көнендә.

*Искәрмәләр*

Кара бик (*Карабәк – М. Ә.*) шәҗәрәсе татар халкының тарихында зур кыйммәткә ия документ. Аның ике дистәдән артык варианты бар.

Кара бик шәҗәрәсе татар кабиләләренең (угыз-кыпчакларның) XIV гасыр ахырында Кырым һәм Кавказ якларыннан Алтын Урданың Болгар олысына килеп утыру тарихын тасвирлый.

Болгар олысына урыс ушкуйниклары походлары бер-бер артлы кабатланып торып, Олысны хуҗалык ягыннан тәмам аяктан егалар. Болгар шәһәре халкы Сарай шәһәренә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Шул сәбәпле күпсанлы татар кабиләләре Урта Идел һәм Урал буйларына ярдәмгә килеп, анда яшәп калалар. Алар җирле татарлар, болгарлар һәм аз санлы иштәкләр белән тәмам кушылып бетәләр. Бу процесс Көньяк Уралдан алып хәзерге Нократ һәм Идел буйларын колачлый. Урал һәм Идел буе татарлары этник тарихында бу иң әһәмиятле вакыйга була. Татар халкында бу дәвердән дистәләгән нәсел тарихлары сакланган.

Алтын Урда таркалган дәвердә Нократ буендагы татар бәкләре, Мәскәү кенәзлеге йогынтысына эләгеп, урыс хезмәтенә күчәләр.

Р. Фәхреддиннең Кара бик (Карабәк) шәҗәрәсе текстында әйтелгән «Сократ хәким нәселе» дигән тәгъбир Алтын Урдада таралган бер тарихи концепциянең эзе булып тора. Алтын Урда идарәчеләре арасында дәүләтнең башлангычын антик цивилизация белән бәйләү тенденциясе таралган. Анда хәтта Чыңгыз хан нәселен дә мөселман пәйгамбәрләре һәм Александр Македонский (Искәндәр Зөлкарнәйин) нәселенә илтеп ялгаганнар.

Шәҗәрәдә искә алынган топонимик һәм гидронимик атамалар (Сакмар, Нократ, Йаек (Урал), Ак Идел; Өчпүлә – Башкортстанда Дүртөйле районына караган Эчбүлә авылына туры килә) әлегә хәтле сакланалар.

Шәҗәрә тексты атаклы галим Ризаэддин бине Фәхретдин архивында сакланган (С.-Петербург шәһәрендәге Көнчыгышны өйрәнү институты архивы, 131 фонд, 1 тасвир, 5 эш берәмлеге). Әлеге текст беренче мәртәбә тарих фәннәре докторы Миркасыйм Госманов тарафыннан табылып, аңа тарихи анализ ясалган (Усманов М. А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. – Казань, 1972. – Б. 181–187).

Текст архивтагы нөсхәдән алынды.

# ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНЕҢ РАУШАН КӨЗГЕСЕ

*Айдар Гайнетдинов*

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Удмуртия Республикасының татарлар яшәгән төбәкләрендә тупланган күп кенә фольклор, музыкаль, археографик, сәнгатькә караган материаллар саклана. Алар, нигездә, төрле елларда оештырылган фәнни экспедицияләр вакытында җыелганнар.

Удмуртиянең татар районнарына Институтның иң беренче фольклор экспедициясе 1956 елның июль-август айларында оештырыла. Аны Хәмит Ярми җитәкли, хезмәткәрләрдән Халидә Гатина, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Шәех Зәбиров катнаша.

Галимнәр, ике төркемгә бүленеп, Глазов, Юкамен, Балезино районнарында булалар. Шул рәвешле, фән өчен кирәкле күп кенә материал туплыйлар.

Х. Ярми белән Х. Гатина Татар Парҗысы, Кистем, Паюра, Әхмәди авылларында булып, барлыгы 1232 кыска җыр, 4 сюжетлы җыр, 27 халык уены, 1 бәет, 16 табышмак һәм мәкаль язып алып кайталар.

Х. Мәхмүтов белән Ш. Зәбиров Дасис (Засеково), Иманай, Кече Вениш (Малый Вениж), Олы Палагай, Пүчинкә, Тегермән (Татарские Ключи), Татар Парҗысы, Кистем, Паюра авылларыннан барлыгы 2021 кыска җыр, 2 сюжетлы җыр, 61 халык уены, 3 бәет, 148 табышмак һәм мәкаль, 1 әкият, 4 авылның тарихын язып алалар.

1956 ел экспедициясе вакытында фольклор әсәрләрен барлап, язып алырга ярдәм иткән бер кеше дә онытылмаган, исем-фамилияләре үзләре тәкъдим иткән текстлар янәшәсенә теркәлеп куелган, һәм алар Институтыбызның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана.

Удмуртиягә халык авыз иҗатын гына түгел, диалектологик материаллар җыю, ягъни бу төбәктә яшәүче татарларның сөйләш үзенчәлекләрен өйрәнү өчен телче галимәләребездән Ф. Баязитова, Д. Рамазанова, Т. Хәйретдинова да берничә тапкыр фәнни экспедициягә чыгалар.

Әмма 1956 елдан бирле фольклор материаллары һәм 2001 елдан бирле диалектологик материал җыю өчен Институтыбыздан Удмуртиягә баручы булмаган. Бу төбәктә археографик материал, ягъни борынгы кулъязма һәм сирәк китаплар җыю, гомумән, башкарылмаган. Анда бару да хәзер безнең өстебездә фарыз гамәл кебек тора иде. Шуны да әйтергә кирәк: Институтка директор итеп К. М. Миңнуллин билгеләнгәннән соң, фәнни экспедицияләргә аеруча нык игътибар бирелә башлады. Шул сәбәпле, халкыбызның рухи хәзинәсеннән яңа энҗеләр туплана бара.

Сәфәребезнең башы булган Балезино районы хакимияте безгә вакытлыча яшәү һәм эшләү өчен бөтен уңайлыкларны тудырды. Шуңа күрә җирле җитәкчелеккә зур рәхмәтләребезне белдерәбез.

Вакытны әрәм итмичә, без шул ук көнне Балезино авылында районның татар активистлары белән очрашып, алар белән бергәләп уйлашып, киңәшләшеп, йөрү маршрутларын билгеләдек. Активистлар арасыннан Кистем авылында яшәүче Илмир Касыймов белән Мирия Касыймова татар халкы өчен аеруча янып торучы, акыллы, белемле, ярдәмчел, кунакчыл яшьләр булып чыкты. И. Касыймов Кистем авылында имам-хатыйп икән, шул ук вакытта ул мәктәп музеен да җитәкли. Ул Казанда Татар дәүләт гуманитар институтын, шулай ук Мөхәммәдия мәдрәсәсен тәмамлаган. Казанда бераз эшләгәч, үз төбәгендәге милләттәшләренә хезмәт итәр өчен, туган ягына кайта. Мирия Касыймова исә әлегә Глазов шәһәренең педагогика институтында укуын дәвам итә. Киләчәктә ул да, авылдашы Илмир Касыймов кебек, тарихчы булырга әзерләнә.

Икенче көнне районның Кистем авылына юл тоттык. Биредә Илмир Касыймов үзе җыйган археографик материаллар белән таныштырды, кайбер борынгы кулъязмаларны Институт архивына тапшырырга да ризалашты. Алар арасында догалыклар, багышлаулар, Коръән аятьләре, мөнәҗәтләр, дини риваять текстлары, хатлар һ. б. бар. Мөнәҗәтләргә килгәндә, бу төбәктә хәзер дә бик популяр булган Шәехбаба хакындагысы аеруча кызыклы. Шәехбаба турында мәгълүмат 2009 елда «Мәдинә» нәшрият йортында

чыккан «Ислам на Урале» дип аталган ислам энциклопедиясенә дә кертелгән.

Шәехбаба Дербент янындагы Маграка авылында туган. Аның бабасы Шәехкорбан милләте буенча төрек булган. Рус-төрек сугышыннан соң ятим калгач, Шәехкорбанны Шәехмәхмүд исемле бер кавказ кешесе үзенә уллыкка алган. Шәехбабаның ни рәвешле Дагыстан җирләреннән Удмуртия якларына килеп чыкканлыгы бик гади аңлатыла. Ул имам Шамил белән бергә рус гаскәренә каршы көрәшкән. Дербенттагы баш күтәрүдә катнашканы өчен аны кулга алалар һәм Пермь шәһәренә сөргенгә җибәрәләр. Соңыннан, Шәехбаба Казан губернасы, Свияжск өязе, Мулла иле авылына озатыла. Биредә ул, ишан Вәлиднең кызы Фатыймага өйләнеп, тормыш кора. Хатынының туганнары Кистем авылында яшәгәнлектән, бу авылга ул еш кунакка килгән. Шунда һәм якын-тирә авылларда ул ислам динен, төгәлрәк әйткәндә, суфыйчылык тәгълиматын тарату белән шөгыльләнгән. Шул сәбәпле, халык күңелендә Шәехбаба изге-әүлия кеше буларак истә калган. Ул үзе суфый булганлыктан, Кистем авылына суфыйчылык элементларын алып килгән. Авыл имамы сөйләвенчә, кайбер өлкән яшьтәге картлар, азан әйтелгәннән соң, баш бармакларын үбеп, мыекларын һәм кашларын сыпыралар. Янәсе, йөз нурлансын өчен. Кайбер мәҗлесләрдә әбиләр «Аллаһ» дип аяк тибеп утыралар. Бу рәвешле алар ишанга тапшырылалар икән. Шулай ук карчыклар түгәрәкләшеп утыралар, аннары, «уф» дип, аркаларына авалар, ягъни бу да ишанга тапшырылу була.

Шәехбабаның могҗизалары хакында авылда төрле риваятьләр йөри. Аларны безгә И.Касыймов сөйләде. Мәсәлән, бу әүлия тәһарәт алырга чыккач, юкка чыга торган булган. Җир сөргәндә, башка кешеләр кебек, ул да бер үгез белән чыккан. Басу янындагы агачлар арасыннан икенче үгез килеп чыгып, шул икесе белән җир эшкәрткән. Имам Шамил гаскәрендә сугышып йөргәндә, әсирлеккә төшкәч, «Аллаһ» дип өрә торган булган, шунда ук богаулары өзелгән имеш.

Шәехбаба өч яклы өй төзеп калдыра һәм әйтә: «Килер бер көн, монда минем өченче балам килер». Аның Фатыймадан ике улы гына булган. Чыннан да, Кавказ якларында аның өченче баласы табылып, бирегә килеп чыга. Көннәрнең берендә халыкны дингә чакырырга дип сәфәргә чыкканда: «Мин бүтән кайтмам, Пермь шәһәрендә үләрмен, минем җәсәдемне зиратка алып кергәч, күгәрчен

кайда кунар, шунда күмәрсез», дип әйтеп чыгып киткән. Шул рәвешле туганнары аны җирлиләр дә имеш.

Шәехбаба мөнәҗәте шактый күләмле әсәр булганлыктан, монда бер өзеген генә тәкъдим итәм:

«...Кечеклегдин бәне сәүдең,
Олуг булгач, җәза кыйлдың,
Кә безләргә сабак бирдең,
Шәриф кәгъбәм – Шәехбабам.
Бу дөньяның мәгашендин
Кыйлалмадым сиңа хезмәт.
Кә безләрдин бәхил булсаң,
Сиңа җәннәт, Шәехбабам.
Кә безләрдин бәхил булсаң,
Хәер-догаңны һәм кыйлсаң,
Ходаем һәм гата кыйлсун
Сиңа җәннәт, Шәехбабам.
Шәехбабам, синең йөзең
Күрә алмады бәнем күзем,
Синең булды гомерең озын,
Шәриф кәгъбәм – Шәехбабам.
Кә безләрдин тәмам улды,
Кә Газраил җанын алды.
Кә безләрне күрә алмады,
Бәхил булгыл, Шәехбабам...»

Мөнәҗәт ахырында «Язгучы Габдулла Кәчимов» дип язылган. Бу – күчереп язучының исеме булса кирәк.

Материаллар арасында гарәп графикасында язылган 7 хат та бар. Аларның берсе бик кызыклы, чөнки ул юморга бай кеше тарафыннан язылган. Хат авторы бер таныш абыстаена «Мәүлет» исемле китапны укырга биреп торуын сорап: «Шул үтенечемне кабул итсәң – бак, кабул итмәсәң – ерт, утка як», – дип яза. Хат ахырында түбәндәге шигъри юлларны да өсти:

«Хатлар яздым арганчы,
Бармакларум талганчы,
Йокыларым кермәс инде,
Синдәен китаб алганчы.
Хатлар яздым исәбләб,
Почмакларун пичәтләп,
Йокыларум кермәс инде,

Бирүр микән, диб исәбләб.
Мәрхәмәтеңнән булыр иде, бирсәң».

Кистемдәге эзләнүебезне дәвам иткәннән соң, тагын ике хат табылды. Аның берсе латин графикасында Кызыл Армия сафларында хезмәт итүче Мәүлет исемле егет тарафыннан язылган. Яшь булуына карамастан, ул үзенең сагыну хисләрен төрле чагыштырулар кулланып, бик матур итеп тасвирлап яза белгән:

«...бу җәйге җәмле кенләрдә яшь кенә күңелем терлесен уйлап, ялгыз башым терлесен уйлап тырганда, сайри кышлар, былбыллар, иртә тау җилләре искәндә, туганларым, мыңлы су өстендә Финзалив дигән күлләрдә параходлар шулхәтле мыңлы кычкыралар, мин сакта тырганда, таң җилләре искәндә шул мыңлы таушларны тыңлим. Шул мыңлы гына таушларга яшь күңелем бик мыңайды да, алдым каләм, яздым сәлам дигәндәй...»

Хәзерге көндә шул рәвешле хисләргә бирелеп, армиядән хат язучы егетләр калмагандыр инде мөгаен.

Шулай ук Кистем авылы материаллары арасында кирилл хәрефләре белән язылган бер бәет тә килеп чыкты. Ул да, ярты гасыр элек үк язылганлыктан, игътибарга лаек. Текстыннан аңлашылганча, бер ир су коенырга киткән җиреннән фаҗигале рәвештә (суга батып) вафат була:

«Ходай кушкандыр шунда барырга,
Горный суында җанын алырга.
Суларга карыйм тәрәзә ачып,
Ходай кушкачын булмайдер качып».

Кистем электән үк бик дини авыл булганлыктан, биредә бик күп догалар табылды. Алар арасында ниндиләре генә юк: авырганда укыла торганнары, бөти кебек язылганнары, багышлаулар, сихер кайтару догалары һ. б. Шулардан бер дога эче буш калдырылып киселгән зур бер квадрат кәгазьдә язылган. Шуны чирләгән кешенең башыннан кидереп, бөтен тәне буйлап төшереп, аягыннан салдырсаң, шуннан соң кеше сихәтләнә, дип ышанганнар. Шулай ук мөһергә охшаш рәсем эченә язылган дога да кызыклы. Ул Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлек мөһере ясалган бер кәгазь кисәгеннән гыйбарәт. Әгәр аңа иртәнге тәһарәт белән карасаң – Аллаһы Тәгалә кичкә кадәр бәла-казалардан саклар, кичке тәһарәт белән карасаң – иртәгә хәтле саклар, шунда үлеп китсәң – шәһидләрдән булыр, иман белән күчәр имеш.

Бу авылда гарәп телендә язылган ике борынгы кулъязма китап табылды. Аның берсе ата-анага яхшы мөгамәлә, икенчесе кәсеп итү хакында.

Монда басма китаплар да шактый очрады. Әмма аларның күбесе тулы түгел иде: йә башы юк, йә ахыры юк. Шуңа күрә андый китапларны без күп җыймадык. Беренчедән, аларда басылган әсәрләрнең тулы вариантлары Институт архивында шактый күп инде. Икенчедән, кешеләр үзләре ул китапларны өйләрендә кадерләп тотса, әби-бабалардан калган, татар халкы мирасына караган истәлекләргә карата мәхәббәт, хөрмәт, сакчыл караш уята, димәк, бу менә дигән тәрбия чарасы булып та хезмәт итәргә мөмкин. Шул сәбәпле, борынгы басма Коръән китабын да хуҗаларында калдырдык. Бу изге китап һәр мөселман йортында сакланырга тиеш. Дасис авылындагы бер йортка кергәч, хуҗалары XX гасыр башында басылган Коръәнне алып китүләрен бик үтенгәч кенә, Институт архивына куярга ризалашып алырга туры килде.

Тагын бер басма китапны, ахыргы битләре булмаса да, архивыбызга алып китәргә булдык. Чөнки ул гарәп дин эшлеклесе һәм фәлсәфәчесе Имам Газалинең сирәк басмалардан саналган «Әййүһәл-вәләд» («Әй, сабый») хезмәтенең 1883 елда басылган татарчага тәрҗемәсе. Безнең әби-бабаларыбыз шундый китаплардан үгет-нәсыйхәтләр укып тәрбияләнгәннәр бит.

Бер Коръән китабының ахыргы ике битенә тап булдык. Анда китап иясе Закир (Мөхәммәдзакир), үз-үзенә нәсыйхәт биреп, түбәндәге тәрбияви сүзләр язып куйган:

«Әй, Закир, бигрәк әдәбсез син, элек инсаф ал, соңра гыйлемлек ал! Әдәбсез галим наданлардан ямандур. Әүвәл әдәб-инсафлы булурга үгрән, соңра гыйлемлек ал! Әдәбсез галим наданлардан ямандур».

Ике көн буе Кистем авылында эшләгәннән соң, Паюра авылына юл тоттык. Иң әүвәл авылның карт имамы, аксакалы Риза хәзрәт Интинтеев янына бардык, ул безгә әнисеннән калган догалар, Коръән сүрәләре язылган дәфтәр, миһер-шәриф, аятьләр язылган кулъязма битләр тапшырды. Авыл мәчетеннән дә бераз табышларыбыз булды. Алар арасында бер шәкерт дәфтәре аеруча кызыклы. Анда мәдрәсәдә укытылган төрле дини әсәрләр урын алган. Шулай да, шәкертләр арасында телдән-телгә сөйләнелеп йөри торган түбәндәге шаян шигъри юллар да язылып куелган, бәлки, аларны дәфтәр иясе үзе үк иҗат иткәндер:

«Бу китаб иясе
Кызыл чапан киясе,
Бик зур мулла буласы,
Хур кызларын кочасы».

Дәфтәрдәге язмалардан аңлашылганча, аны Шәмсетдин Шәрәфетдин улы 1898 елда Паюра мәдрәсәсендә укыганда язган. Башка битләрдә 1906, 1907 ел даталары тора. Бәлки, шәкерт бу еллар дәверендә мәдрәсәдә укыган булгандыр.

Тагын бер кыйммәтле табыш булып Габделбәр Ситдыйк улы Кәчимовның 1910 елда үз кулы белән язган дәфтәре саналырга хаклы. Анда догалар, дини әсәрләрдән тыш, бик күп мөнәҗәтләр, шигырьләр урын алган. Шигырьләре Касыйм бине мулла Җәмалетдин Бикколовның балалар өчен язылган «Нәмунәи тәрәккый» китабыннан күчерелгән булса кирәк. Шулар арасында «Сука, йир, мужик» исемле шигырь бик үзенчәлекле:

«Сука йорт-йир салдырыр,
Яшь киленләр алдырыр,
Анбарларны тултырыр,
Кышка кибән калдырыр.
Сука илә йир казырмыз,
Йирдән алтун алурмыз,
Йирегезне сатмагыз,
Игүн сачмай калурмыз.
Йирдер безнең анамыз,
Куйнында аның торырмыз,
Анамызны саткан соң,
Ничүк адәм улырмыз.
Безнең барча атайлар,
Йир үстендә яшәгән,
Гакыллы адәм улурму
Анасун сатуб ашаган?
Йирдән чыгар ашымыз
Йирдә торур башымыз».

Бу шигырендә автор җирнең кадерен белергә, һичкайчан аны сатмаска, сука белән җирне эшкәртеп иген үстерергә, кыскасы, авыл хуҗалыгына карата игътибарны арттырырга өнди. Шулай ук бу юлларны авылдагы йортларын, җирләрен сатып, шәһәргә күченеп китүчеләргә карата әйтелгән сүзләр дип тә аңларга була. Бүгенге көн өчен дә алар бик актуаль булып кала, әйтерсең боларны язучы безнең заманга атап язган.

Габделбәр Ситдыйк улы Кәчимовның авыл хуҗалыгы темасына караган шигырьләре байтак. Мәсәлән, сыер, ат, балык, арыш турында. Фәндә аларның күбесен бәетләргә кертеп карыйлар.

«Арыш бәете»ннән өзек:

«Әй, арышым, арышым!
Синдә бәнем табышым,
Синдән башка юкдыр бәнем
Бу дөньяда тормышым.
...Көмеш башак, җәүһәр бөртек,
Ука кеби саламың.
Бөтен дөньяны туйдырдың,
Сиңа булсун сәламем!»

Бу бәет «Татар халкы иҗаты» күптомлыгының «Бәетләр» томында да бирелгән, ләкин без язып алган вариант китаптагыдан бераз аерыла.

Рус-япон сугышы хәлләрен, анда катнашучыларның уй-кичерешләрен тасвирлаган «Сугыш бәете» дә әлеге дәфтәрдә язылган. Аны Габделбәр Кәчимов үзе иҗат иткәнме, юкмы – монысы билгесез. Әмма бу әсәр татар халкы иҗатын тагын бер бәеткә баетты, чөнки моңа кадәр билгеле булган сугыш бәетләре арасында андый вариант юк. Бу – Удмуртиядә яшәүче татарлар күзлегеннән чыгып иҗат ителгән әсәр. Аны фәнни әйләнешкә кертү зарур.

Габделбәр Кәчимов дәфтәрендә мөнәҗәтләр дә шактый. Мәсәлән, кунак килгәндә, имтихан мәҗлесендә укыла торганнары, ахирәт хәлләрен тасвирлаганнары һ. б. бар.

Палеографик билгеләре буенча XVIII гасырга караган кульязма китап та табышларның кыйммәтлесе булды. Анда иман нигезләре, исламда мәҗбүри үтәлергә тиеш булган фарызлар хакында сөйләнелә.

Паюра авылында табылган кульязмалар арасыннан бик күп халык авыз иҗаты әсәрләре чыкты: мөнәҗәтләр, бәетләр, җырлар һ. б.

Туган як темасы, һәрвакыт диярлек, татар халкы иҗатында зур урын билəгән. Нинди генә жанрны алсаң да, анда шул тема чагылыш таба. Төрле сәбәпләр аркасында туган ягын калдырып, чит җирләргә китәргә мәҗбүр булган кешеләрнең йөрәкләреннән күз яшьләре белән чыккан моңсу җырлары берәүне дә битараф калдырмый:

«Күгем (*күңлем*) үсмәде, кулым бармады,
Хәрсрәтле (*хәсрәтле*) уйлар мидәен (*миннән*) калмады,

Туган илләрем күреб туймадым,
Чит илгә яз (*язылган*) минем туфрагым».

Якты дөнья белән хушлашу, балалар һәм туганнар белән бәхилләшү рухында язылган бик кызганыч бәетләр табылды:

«...Өйдән чыкганда ашыктырмагыз,
Бик җылашмагыз, зинһар, чыдагыз!
Каберләремне киңрәк казыгыз,
Ак таш утыртыб исемем языгыз,
Чардуган корыб нурландырыгыз,
Агач утыртыб куандырыгыз!
Яфраклар ярса, кошлар сайраса,
Рухым шатланыр, догалар барса...»

Моңа охшаш тагын бер бәет табылды, ул кечкенә бер кызның үлем түшәгендә ятканда үзе тарафыннан сөйләнелә:

«Зифа буйларым үлчәб алырсыз,
Җуыб пакьлагач, кәфен салырсыз,
Хушландырырсыз зифа буйларым,
Якты дөньяда актык туйларым.
Тәнем юганда өстем ачмагыз,
Кәфенгә салгач, хушландырыгыз,
Тәнем киселгән, хаты (*каты*) тотмагыз,
Кире кайталмам, ашыктырмагыз!»

Удмуртиядә яшәүче татарлар электән үк дини булганлыктан, әлеге авылда бик күп мөнәҗәт дәфтәрләренә тап булдык. Аларда, нигездә, Мөхәммәд пәйгамбәр, ахирәт тормышы, изге гамәлләр кылырга өндәү хакында сөйләнелә.

Паюра авылында шулай ук 1906 елгы көндәлек дәфтәре табылды. Аның иясе үзе өчен мөһим булган вакыйгаларны теркәп барган. Кызганыч, ул  үз исемен генә бер җирдә дә әйтеп узмаган, шуңа күрә бу дәфтәрдәге язмалар кемнеке булганлыгы ачыкланмыйча калды.

Авылда Коръән китабына зур игътибар биргәннәр. Аны XX гасыр урталарыннан соң да күчереп язганнар. Шул рәвешле күбәйткәннәр, һәр кеше үзендә булдырырга теләгән, хәтта совет хөкүмәте динне тыйган заманда да моны эшләргә курыкмаганнар.

Кульязма китаплардан тыш, фотога алу юлы белән ясалган китаплар да табылды. Алар инде, билгеле, борынгы түгел. Ләкин бу күренеш татар халкының төрле юллар белән үз китапларын саклап калырга тырышулары хакында сөйли.

«Васыятьнамә», «Сабырлык хаты» исеме астында төрле мөрәҗәгатьләр, дини өндәмәләр язылган кәгазь битләре күп очрады.

Җирле халык, дингә ышанган кебек үк, төрле ырымнарга да ышанган, аларны дин белән, ягъни төрле догалар белән катыштырып укыган, чөнки ырымнар электән үк татарлар тормышында мөһим урын тоткан. Табылган ырымнардан бер өзек китерәсе килә:

«...Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Иртә тордым илән белән, йөземне юдым бал белән, иртә тордым, казан астым, үдвә тәмле акрын яныны казан кайнады. Ул фәләнне күрмәсә, шулай кайнасун, янсун! Язгы кыяшы эсселеге һәр баушым булса, кичүгә кәбдрә. Ул фәләнне күрмәсә, шулай кибсүн, корысын!

...Айлар айга әйләнсүн, көнләр көнгә әйләнсүн, баш-күзе миңа әйләнсүн, теле-сүзе миңа үтмәсүн, әйтер сүзе этә алмасун, бирахмәтикә йә әрхәмәр-рахимин...»

Бу авылда «Нәсаих нафига», «Намаз хуҗасы», «Гыйбадәте ислямия», «Әл-мөртәаб», «Хисаб кагыйдәләре», «Хисаб мәсьәләләре» исемле басма китаплар да табылды.

Археографик материал эзләү өчен, алга таба Татар Паржысын сайладык. Исеменнән аңлашылганча, биредә татарлар яши, борынгы кулъязмалар да күптер, дип уйлаган идек. Һәм ялгышмаганбыз. Чыннан да, материал җитәрлек җыелды. Мәсәлән, XX йөз башына караган шәкерт дәфтәренә, иман нигезләренә өйрәткән сөаль-җавап китабына, төрле догаларга һ. б. га тап булдык.

Шулай ук анда кулга кергән табышлардан Палагай авылы кешеләренең тормыш-көнкүрешен яктырткан елъязма да кыйммәтле санала. Ул 1903–1904 елларны үз эченә алган. Елъязма да авыл кешеләренең кайчан чәчүгә яки уракка чыкканнары, ул эшләренең кайчан төгәлләнгәне, ни кадәр уңыш җыелганы, шулай ук кайчан сабантуй уздырганнары, һава торышы нинди булганы һ. б. хакында тәфсилләп теркәлгән. Андагы язмалар күрсәткәнчә, элек сабантуйларны яз көне, апрель аенда уздырганнар. Мәсәлән, 1904 елда Тегермән, Тутай, авылларында 19 апрельдә дүшәмбе көн, Палагай авылында 21 апрельдә чәршәмбе көн, Кечкенә Палагай авылында 22 апрельдә кече атна көн (пәнҗешәмбе) үткәрелгән. 23 апрельдә инде сабан чәчәргә чыкканнар.

Татар Паржысы авылында зиратка бару, мәет күмү мәсьәләләре хакында хәдисләр, мөселман галимнәре сүзләре китерелгән бер кулъязма бит табылды. Ул нинди дә булса берәр фикыһ буенча

китапның бер фрагменты булса кирәк. Кәгазе һәм су билгеләре буенча XIX гасырга карый.

Авылда бик күп халык авыз иҗаты әсәрләре табылды: мөнәҗәтләр, бәетләр, җырлар. Алар борынгы түгел, XX гасыр урталарыннан соң язылган, күбесе кирилл имлясында, тик шулай да фольклористика фәне өчен аларның әһәмияте бик зур. Хәзерге заманда татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю кыенлашканнан-кыенлаша бара. Шуңа күрә фольклор әсәрләрен язма чыганаклардан гына эзләргә кала. Табылган дәфтәрләрдә Татар Парҗысы авылы турындагы җырлар да очрый:

«Парҗы авылы урнашкан
Корзинка елгасында,
Рәхәтләнеп чәйләр эчик
Бу фани дөньясында.
Парҗы урамы бик ямьле,
Мәчете бик күңелле,
Кире кайтарып булмый бит
Үтеп киткән гомерне».

Шулай ук сыер савучылар хакында җырлар да кызыклы:

«Яшьлек елларыбыз үтте
Ферма юллары таптап,
Тыныч екы екламадык
Сәгать-минутын саклап.
Трактор да булдык без,
Машина да булдык без,
Ат урнына да җигелдек,
Барсына да түздек без.
Сыерларны сауган чакта
Тала иде беләкләр,
Тибеп ычкындыралар дип,
Тибә иде йөрәкләр».

Бәетләрдән «Әнинең бәете», «Җәмилә бәете», «Миңсылу бәете», «Гыйнәят бәете», «Миңшәкерт бәете», «Рәймә бәете», «Зәйнәп тәтәй бәете» һәм тагы дистәдән артык мөнәҗәт табылды. Боларны һәм югарыда телгә алынган җырларны Татар Парҗысы авылында яшәүче Бузикова Кәшифә Гайнан кызы иҗат иткән. Бу авторның китабын да бастырып чыгарганнар.

Басма китаплардан күренекле галим Җамал Вәлидинең 1918 елда басылган «Татар теленең кагыйдәләре» исемле китабын

табып алып кайттык. Шулай ук 1858 елда чыккан атаклы «Мөхәммәдия» китабын, ахыргы битләре җуелса да, анда китап ияләре язган язмалар күп булганга, әһәмиятле табышлардан саналырга мөмкин. Ул китапны укыган һәр кеше үзе турында мәгълүмат калдырган.

Шуннан соң Уръякала (Гордино) авылында булдык. Монда, мөселман татарларыннан тыш, керәшен татарлары, удмуртлар, бисермәннәр дә яшәгән. Бүгенге көндә авыл буш диярлек инде, бик күп тузган тораклар, ташландык йортлар күзгә ташланып тора. Авылда мәктәп тә, мәчет тә, клуб та юк, фәкать бер кибет кенә бар, анысы да җимерек хәлдә диярлек. Авылның үзәк урамына бетон плитәләрдән юл җәелгән. Ул моннан ярты гасыр элек салынган булган, авыл халкы пычрак юллардан интекми.

9 июнь көнне Әхмәди авылында татар халкының иң яраткан бәйрәме – Сабантуй үткәрелде. Бәйрәмнән алган тәэсирләребез белән икенче көнне дә бу авылда эшләргә булдык. Биредә палеографик һәм су билгеләре буенча XVIII гасырга караган өч борынгы кулъязма китап табылды.

XX йөз башына караган ике кулъязма китап та бар. Аның берсе тарих һәм география буенча, икенчесе «Кырык хәдис» әсәре һәм ир-хатын мәсьәләләренә багышланган язмалардан гыйбарәт.

Болардан тыш, төрле догалар, багышлаулар табылды. Бу инде авыл халкының электән үк дини булганлыгын күрсәтә.

Шулай ук дәфтәргә күчерелгән Йәсин сүрәсе табылды. Ул үзе борынгы булмаса да, күчерелү рәвеше үзенчәлекле: гарәп сүзләре анда гарәпләрдә кабул ителгән формада түгел, бәлки ничек ишетелә, шул рәвешле язылганнар.

Ике китап тышлыгы табылды. Аның берсендә түбәндәге сүзләр язылган:

«Кешенең гаебе булса, көлмә, зинһар! ...Кешедән көлгән адәмнең улындаен һич эш килмәз».

«Гаҗәб хикмәт, гаҗәб халәт, назыр кыйлсаң бу дөньяга
Фәкыйрә игътибар юкдыр, әйләрләр гыйззәт байга.
Язгучы Хәлимә Хәмзина».

Әхмәди авылында түбәндәге басма китаплар табылды: «Рәһбәрел-ислам», «Мөгаллимел-гыйбадәт», «Мохтасар тарих мөкаддәс», «Нәмунәи тәрәккый», «Гыйльме хәл» (намаз кыйсеме), Ризаэддин Фәхретдиннең «Әдәбе тәгълим», Зыя Камалиның «Фәлсәфәи гыйбадәт» хезмәтләре.

Шунысын да әйтергә кирәк, бу авылда табылган борынгы кульязма һәм сирәк китапларның күбесе, заманында, Габделхак Мәсгуд Юкиновныкы булган.

Әхмәдидән Иманай авылына юнәлдек. Бу авыл да яртылаш бушап калган инде, аны да бетү ягында дияргә мөмкин. Биредә археографик материал күп табылмаса да, шактый борынгы һәм кыйммәтле китаплар кулыбызга килеп керде. Мәсәлән, палеографик билгеләре буенча XVIII гасырга караган кульязма Коръән җыентыгы. Шулай ук кульязмалардан XIX йөзгә караган шәкерт дәфтәре, хәдисләр китабы, гакыйдә мәсьәләләренә багышланган китап табу бәхетенә ирештек.

Иманай авылыннан чыгып киткәндә шундый хәбәр ишеттек: бу авылда яшәүче берәүнең борынгы кульязмалары күп булган, ул аларны кая куярга белмәгәч, тартмасы белән зиратка илтеп күмгән. Шулай итеп, никадәр хәзинә, ягъни халкыбызның зур мирасы юкка чыккан. Әйтәсе килгән сүз: борынгы кульязмаларны, иске китапларны зиратка күмү – ул бик начар гадәт, болай эшләргә һич тә ярамый. Һичьюгы мәчетләргә, музейларга тапшырырга кирәк. Чөнки без экспедицияләрдә йөргәндә, борынгы кульязмалар, иске китаплар эзләп мәчетләргә кермичә калмыйбыз. Муллалар, гадәттә, безгә якты йөз күрсәтеп, аларны мирасханәбезгә бүләк итеп җибәрәләр.

Эшебезне дәвам итеп, Дасис авылына барып чыктык. Биредә борынгы язмаларны бик озак эзләргә туры килсә дә, тырышкан тапкан, ташка кадак каккан дигәндәй, берникадәр материал табу бәхетенә ирештек. Мисалга, гарәп телендә язылган борынгы касыйдәне китерергә мөмкин. Ул әле җентекләп өйрәнүне сорый.

Шулай ук бу авылда кызыклы гына ике хат табылуны да исә алып узарга кирәк. Аның берсен гражданнар сугышында катнашучы язган булса кирәк. Хатны Гайнеша исемле кеше 1917 елның 27 июлендә Киев шәһәрендә язган. Кызгыныч, хат бик начар сакланган, дымнан артык зыян күргән, шуңа күрә кайбер җөмләләрне генә укып була. Ул: «Бик зур сугышлар булды, Ходайның... белән сау-сәламәт калдым» дигән сүзләр яза.

Икенче хатны армия сафларында хезмәт итүче бер ир үзенең гаиләсенә атап язган. Хат болай башланып китә: «Сезгә гыйззәтлү, бөкрәйүб, кәкрәйүб, кан-күз белән йулаб, зарланыб калган карчыгыма бик сагыныб, алкынлы-ялкынлы сәламләремне язам. ...Без кә

Урал итәгендә Кама буен уралган таш-таулары арасында әче сукларга чудаб хезмәт итүче карт әткәгездән бик сагынуб вә бик саргайуб алкынлы-ялкынлы сәламләремне язам». Хатның икенче яртысы ертылып югалган, шуңа күрә хат авторының исемен, фамилиясен белеп булмый.

Басма китаплардан 1907 елда нәшер ителгән, ике томнан торган Коръән китабы табылды. Хуҗалары аны бик кадерләп саклаганнар. Шулай ук билгесез авторның шигырьләре һәм җырлары тупланган басма җыентыкка да юлыктык. Анда Г. Тукайга багышланган шигырьләр дә урын алган. Кызганыч, җыентыкның шактый күп битләре югалган. Шулай булса да, аның һәр бите тарих өчен әһәмиятле.

Ниһаять, Палагай авылына да килеп җиттек. Бу авыл ике өлештән тора: Зур Палагай һәм Кечкенә Палагай. 70 нче елларда аларны бергә кушалар һәм зур бер авыл хасил була. Бу авылда палеографик һәм су билгеләре буенча XVIII гасырда, шулай ук XX йөзнең 80 нче елларында күчерелгән кульязма Коръән таптык. Димәк, бу якларда Коръән күчерү традициясе әле XX гасыр ахырына хәтле дәвам иткән.

XIX йөз ахырына караган, берничә хезмәттән торган шәкерт дәфтәре дә табылды. Иман мәсьәләләрен үз эченә алган кульязма китап та кыйммәтле табышлардан булды. Аны заманында Нурулла Гариф улы Абашев күчереп язган булган. Шулай ук кулдан язылган мәшһүр «Бәдәвам» китабы игътибарга лаек. Аны Мифтахетдин Абашев әл-Палагави күчереп язган.

Төрле авырулардан шифа табу өчен укыла торган догалар дәфтәре 1920 елда Шаһисолтан Гариф улы Абашев тарафыннан күчереп язылган. Шушы ук елда күчерелгән, шигъри юллар белән язылган «Мәгъшукнамә» әсәрен дә алып кайттык.

Догалар, багышлаулар язылган кәгазьләр бик күп булды.

Фольклор әсәрләреннән бер җыр дәфтәрен китерергә була. Анда шундый өзек бар:

«Кулымдагы балдагымның исемләре Сәлимә,
Васыять сүзе итеп әйтәм, миндән башка җар сеймә.
Кулымдагы балдагымның исеме Гөлсем, дисең,
Янсын дисең, кипсең дисең, саргаеп үлсен, дисең.
Агыйделнең аръягында лимон тора каб белән,
Эх, дускаем, калдык инде сейләшергә хат белән».

Бу дәфтәрдәге бөтен кыска җырларның үзенчәлеге шунда – алар барысы да сагыну хакында.

Табылган материаллар арасында Таифә Абашева (Лотфулла мулла кызы) язган мөнәҗәтләр, догалар шактый. Ул, үзе үлгәч, дәфтәрендәге догаларны укып, үзе рухына багышлавын үтенеп, түбәндәге сүзләр язып калдырган:

«Бу дөньяда мәңге йөрмәс минем җисемем,
Һәм телләрдә мәңге йөрмәс минем исемем,
Әмма ләкин сез туганлар дәфтәренә
Язылуб калсун минем исемем.
Таифә Абашева».

Икенче бер җирдә Таифә Абашева 1979 елның 17 февралендә гарәп графикасында бик матур шигъри юллар язган (күчереп алган булуы да ихтимал):

«Яшәр идем тып-тыныч дөньяда михнәт булмаса,
Саф күңелемнең саф йиринә кайгы-хәсрәт тулмаса.
Дөньяны да сөяр идем, вафасызлык кылмаса,
Бизмәс идем дөньясындан кайгы-хәсрәт булмаса.
Һич уйламай яшәр идем, ай-вай, курку булмаса,
Үләр идем үлгәндә дә шад, үлгәч газаб булмаса».

Аның язмаларында, әйткәнебезчә, бик күп мөнәҗәтләр урын алган, аларда иман, ахирәт, үлем темасы бик калку бирелгән. Әсәрләрнең күбесен Таифә Абашева үзе иҗат иткән булуы да мөмкин.

Мөршидә Абашева тапшырган материаллар арасында тагын бер мөнәҗәтләр дәфтәре бар иде. Анда да шул ук ахирәт көненә әзерләнү, яхшы гамәлләр кылуга чакыру темалары урын алган. Мисал:

«Сәдәка бир ятимләргә,
Икенче бир фәкыйрьләргә,
Өченче бир галимләргә –
Ходаның сейгән колларыйна.
Сәдәканы бирегез
Үзегезнең сейгән малдан,
Кыямәт көн җәннәтләргә
Юмартлар керүр алдан».

Бу дәфтәрдә 41 ясинны багышлау догасы да китерелгән. Ул да бик кызыклы һәм үзенчәлекле. Һәр укыган ясинны берәр дини шәхескә, яки төркемгә багышлыйсы икән, ә иң соңгы ясинны, ягъни 41 нчесен, укыган кеше үзенең вафат булган туганнарына

багышлый. 39 нчы ясинны барча газизләргә, изгеләргә һәм «66 гаиб ирәнләргә, 72 пәһлеван-шәһидләргә» дип язылган. Мондый гыйбарәләрне башка багышлауларда очраткан юк иде әле.

Борынгы басма китаплар Палагай авылында шактый күп булып чыкты. Биредә яшәүче Абашева Мөршидә ике зур капчык борынгы китаплар тапшырды. Анда кырыктан артык берәмлек борынгы кулъязма битләр, кулъязма һәм басма китаплар булуы ачыкланды.

Әйе, басма китаплар күп табылды, дип әйтергә мөмкин, шулардан татар телендә язылганнары: «Бакырган китабы», «Ахырзаман китабы», «Әхтәри кәбир», «Кисекбаш китабы», «Фәрехнамә», «Рәхәти дел», «Йәнки тәфсир һәфтияккә тәфсир бәян», «Әл-иткан фи тәрҗемәти Коръән», «Кыйссасел-әнбия» һ. б.; гарәп телендә: «Фикыһ Кәйдани», «Бинаъ әл-ислам», «Мохтасар Кудури», «Тәнбиһ әл-гафилин», «Шәрхе гайнел-гыйлем», «Җамигъ әр-румуз» һ. б.; фарсы телендә: «Фарыз гайн», «Хәмде бихәд».

Басма газета-журналлар да шактый җыелды. Мәсәлән, «Дин вә мәгыйшәт» газетасының 1914 елгы саны, «Ислам мәҗәлләсе» журналының 1926 елгы бер саны һ. б.

Палагай авылында барлыгы 7 кулъязма китап, 59 кулъязма бит, 8 кулъязма дәфтәр, 40 басма китап, 3 газета-журналга тап булдык. Бу бик зур күрсәткеч, әлбәттә.

Безгә Пүчинкә авылына да барырга киңәш иттеләр. Анда, янәсе, бик күп борынгы кулъязмалар саклана икән. Инде көн кичкә таба авышса да, башка экспедиция әгъзаларыннан аерылып, мин шул авылга юл тоттым. Авылга килеп керүгә мәчете игътибарны җәлеп итте. Авыл имамы Надир хәзрәт Бузанаков, безне якты йөз белән каршы алып, мәчеттә саклanучы борынгы кулъязмалар һәм сирәк китаплар белән таныштырды. Имам аларның бер өлешен Институт архивына тапшырырга ризалашты. Үзенең дә мәчеттә бу материаллар белән китап музее оештырырга нияте булган икән. Казанда Институт архивында алар күбрәк файда китерер, дип уйлап бер дә ялгышмады хәзрәт, чөнки анда аларны Казан галимнәре тикшереп, өйрәнеп, шулар нигезендә күпме фәнни хезмәтләр язачаклар әле.

Пүчинкә авылында татарның традицион культурасына караган һәм безнең өчен әһәмияте зур булган кулъязма китаплар, текстлар барлыгы ачыкланды. Шуларның иң борынгысы һәм кадерлесе дип «Кыйссаи Йосыф» поэмасы язылган кулъязма китапны атарга мөмкин. Палеографик һәм су билгеләре буенча ул XIX йөз башына карый.

Шулай ук биш хат табылды, шуларның берсе 1939 елда Кызыл армия сафларында хезмәт итүче Ш. Бузиков тарафыннан язылган.

Кыска җырлар да табылды. Менә шуларның берсе:

«Мөселманнар, ал яхшы,
Алдин кызыл гөл яхшы,
Алтун-көмеш чыкган җирдән
Туган-үскән йир яхшы».

Палеографик һәм су билгеләре буенча XIX гасырның икенче яртысына караган борынгы кулъязма китаплардан фал ачу хакында ике хезмәт табылды. Алардагы юрау системасы да бик кызыклы һәм үзенчәлекле. Беренче фал хәрефләргә бәйле, ягъни кеше берәр хәрефнең нинди чыгуга карап, фал ачыла. Мәсәлән, әгәр «б» хәрефе булса, нәтиҗә түбәндәгечә була:

«“Б” килсә, әй, фал иясе, белгел вә әгәһ улгыл, бу ният кем кылуб сән бу фалның яхшы килде, файда күргәй сән, һәр нә морадың булса, хасыл булгай. Падишаһ вә бикләрдин гыйнаять күргәй сән вә кинәлек кешиләрдин мәнфәгать күргәй сән. Әгәр сәфәрдин булса, юлда бераз хәвеф хәтәр бар, әмма соңы хәер булгай...»

Мәсәлән, «җ» хәрефе туры килсә, начар булырга тиеш икән: «“Җ” килсә, әй, фал иясе, белгел вә әгәһ улгыл, бу ният кем кылыб сән хәвеф эчендә улгай сән. Әгәр сәфәрдин булса, яман торур. Сабыр кыйлмак кирәк. Падишаһ вә бикләр кашыйга бармак хуш улмаз, күб зәхмәтләр күргәй...»

Икенчесе исә көн һәм сәгатьләр үзенчәлекләрен исәпкә алып ачыла торган фал. Әле ул җентекләп өйрәнүне сорый, чөнки бүгенге көнгә кадәр фалның мондый төрләре татар галимнәре тарафыннан һаман өйрәнелмәгән. Югарыда әйтелгән фал ачу китабын 1903 елның 19 октябрендә Мөхәммәдхәррас бине Әхмәдвәли язган. Китап ахырында ул үзенең һәм атасының исемен язып куйган. Шулай ук үзенә хәер-дога кылуларын сораган:

«Без фәкыйрьне, зинһар, хәер-догаңыздан мәхрүм итмәңез, һәр ничек булса да “догаил-гаиб лигаиб мөстәҗабә” дигән. Мин бәгъде Хак Сөбханә вә Тәгалә һәр каюмызга хәсән хатимә мияссәр әйләсүн! Әмин! Йә, мөҗибес-саилин! Дәхи, тарафәйндан мәхәббәт берлә бер матур кызга фатиха кыйлыгыз, зинһар, без фәкыйрьгә!»

Пүчинкә авылында бихисап күп халык авыз иҗаты әсәрләре: җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, хикәятләр табылды.

Җырлардан түбәндәгеләрен бу китапны укучыларга да тәкъдим итәм:

«Әй, туганлар, туганлар,
Алар бездин туйганлар.
Алар бездин туймас иде,
Ашлы-сулы булганлар.
Алар бездин туймас иде,
Зур корсаклы булганлар».

Кайбер җырларда Казан шәһәре дә телгә алына:

«Казан каласын, таш, диләр,
Баруб күргән юк әле,
Анадан тугандан бирле
Рәхәт күргән юк әле.
Алмачылар алма сата
Казан калаларында,
Хатын алмый акыл керми
Ата балаларында».

Кызыклы материаллардан тагын «Бибигайшә бәете»н әйтеп узарга мөмкин. Ул «Татар халкы авыз иҗаты» күптомлыгының «Бәетләр» томына кертелгән «Бибигайшә бәете»ннән аерылмый гына түгел, хәтта бөтенләй охшамаган. Бу бәет Пүчинкә авылында яшәгән Бибигайшә Борһанетдин кызы турында:

«Борһанетдин әткәйне чакырсаңчы тиз барып,
Бу Газраил күб йеридер бар кешедән җан алыб.
Аккош оча талпынуб, очуб бара җилкенүб,
Бибигайшә үлеб китде «әткәем» дип тилмерүб.
Пүчинкәдүр илләрем, калды йөргән йирләрем,
Әй, әнкәем, хәлүм начар, бик каты бит тирләдүм».

Тексттан аңлашылганча бу кызны ирексезләп бер карт муллага кияүгә бирәләр, соңыннан ул фаҗигале рәвештә үлеп китә.

«Бибигайшә бәете» язылган китапта Нократ хакында озын бер шигырь дә урын алган. Ул XX гасыр башында язылган. Аның кыскача эчтәлеге болай: Глазов өязеннән бер фәкыйрь кеше Нократ шәһәренә сәфәргә чыга, шунда ул Һади муллага керергә була. Мулла өйдә булмаса да, абыстае аны бик хөрмәтләп кунак итә. Аннан соң башка муллалар да бер-бер артлы бу кешене кунак итә башлыйлар. Муллалардан Һади, Сәлах, Таһир, Нәҗип, Әхмәдсиддыйк, Зариф, Гариф хәзрәтләрнең исемнәре телгә алына, аларга бераз

характеристика бирелә. Мөсафир нинди генә ризыклардан авыз итми, хәтта киткәндә үзенә бик күп итеп сәдака, бүләкләр биреп җибәрәләр. Үзенең күргәннәрен бу фәкыйрь кеше юмор белән һәм төрле сәнгать чаралары ярдәмендә тасвирлап, шигъри юлларга сала.

Динмөхәммәд Нурмөхәммәд улы елъязмаларының табылуы безнең өчен куанычлы булды. Аларга аерым тукталасы килә. Әлеге елъязмаларда төрле хронологик материаллар очрый: һава хәлләре, аерым кешеләрнең туу-үлү даталары, сезонлы хуҗалык эшләренә керешү, бәйрәмнәр һ. б. мәгълүматлар. Боларны язучы 1899 елның 10 февралендә туган. Елъязмаларда, 1940 елдан башлап, 1965 елга кадәрге чордагы вакыйгалар теркәлгән. Алар әле бик җентекләп өйрәнүне сорый. Анда Удмуртия төбәгендә кайсы елны ачлык булган, кайчан чәчүгә яки урып җыю эшләренә чыкканнар, сабантуйларны кайчан үткәргәннәр һ. б. мәгълүматларны белергә мөмкин.

Галим М. Әхмәтҗанов фикеренчә, мондый төр язулар дәүләтчелек сакланганда туган гадәт була. Ул Казан ханлыгы Явыз Иван тарафыннан яулап алынгач та дәвам иткән. Галимнең «Татар кульязма китабы» исемле хезмәтендә язылганча, XVII гасырда татар халкының, дине белән бергә, әдәбияты, фәне, теле, фольклоры да каты кысулар астында үскән. Казан алынганнан бирле туктаусыз милли-колониаль изү шартларында яшәү татарның күп кенә рухи казанышларының югалуына китергән. «Бары XVII гасырның соңгы чирегендә генә татар мәдәни тормышында яңарышка омтылыш билгеләре сизелә башлый. Шуның бер чагылышы булып елъязмалар алып баруга халыкның игътибары үсүе тора. Елъязмаларда XVII гасырга хәтле булган дәвер бик аз чагыла. XVIII гасырда елъязмаларда тар община, табигать һәм гаилә хроникалары күренә башлый. XIX гасырга кергәч, хроникаларда әлеге тема өстенлек ала. XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башында яңадан иҗтимагый тормыш темасы өстенлек ала һәм фәнни ачышлар, сәүдәгә, техникага кагылышлы мәгълүматлар өстәлә», – дип яза Марсель ага.

Күргәнебезчә, елъязма язу традициясе әле XX гасыр урталарыннан соң да дәвам иткән.

Удмуртиядә XIX йөзнең икенче яртысына караган медицина һәм кәлям (фәлсәфә) буенча хезмәтләргә тап булу да, нур өстенә нур өстәде.

Археографик материаллар шактый туплану сәбәпле, барысын да бу мәкалә эчендә генә тасвирлап, сөйләп бетерү мөмкин түгел.

Алар барысы да бик кадерләп саклана. Чөнки, беренчедән, алар татар халкының кыйммәтле мирасын тәшкил итә, икенчедән, бу материалларны җыю өчен институт хезмәткәрләре тарафыннан күп тырышлык куелган. Теләгән кешегә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә бу байлыкны килеп карау, танышу, өйрәнү мөмкинлеге бар.

Җыелган материаллар арасында, сирәк китаплар, борынгы кульязмалардан тыш, әлегә кадәр билгеле булмаган әсәрләр дә шактый. Шулай ук алар аша кайбер борынгы әдипләрнең исемнәре ачыкланды. Димәк, бу экспедицияне, бик уңышлы булды, дип санарга тулы хакыбыз бар.

Безнең арада фольклор, археография, тел, сәнгатькә караган материалларны җыючылар да бар иде. Халык хәтерендә калган фольклор әсәрләрен, йолаларны, көйләрне, әлегәчә сакланган борынгы китапларны, төрле бизәкләр чигелгән тукымаларны һәм, гомумән, татар халкының мирасына караган һәр нәрсәне өйрәнергә тырыштык. Борынгы кабер ташларын табарга ярдәм итүчеләр дә булды.

Кыскасы, юлларыбыз һәрвакыт уңды, яхшы каршы алдылар, ә иң мөһиме, бик күп археографик хәзинә алып кайттык. Әле бу соңгы фәнни экспедиция түгел, бу төбәккә тагын барырбыз, дип өметләнеп калабыз.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә әле тагын төрле кешеләр тарафыннан җибәрелгән фольклор материаллары да саклана. Галимнәр һәрвакыт газеталар, радио аша халыкка мөрәҗәгать итеп, үзләре белгән халык авыз иҗаты үрнәкләрен, борынгы кульязмаларны һәм китапларны Институтка җибәрүләрен үтенәләр. Шул сәбәпле, илнең төрле почмакларыннан, нигездә хатлар аркылы, күп кенә материаллар килә. Алар арасында Удмуртиянең Воткинск шәһәреннән җибәрелгәннәре дә бар. Ә инде безнең белән турыдан-туры элемтәгә керә алмаучылар үзләрендә сакланган рухи хәзинәләрне Институтның Кремль территориясендә урнашкан Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә җибәрә яки китереп бирә ала.

# ТЕЛ – МИЛЛӘТНЕҢ ҖАНЫ

***(Татар теле урта диалектының нократ сөйләше)***

*Дария Рамазанова,*
*Миңнира Булатова*

Татар теленең диалектологик атласын төзү барышында татар диалект теленең үзенчәлекләргә, борынгы күренешләргә бай булуы ачыкланды. «Татар халык сөйләшләре» (ул 2 китаптан тора) тупламасында 56 сөйләш тасвирланды. Тел – тарих көзгесе, дигән гыйбарә халыкның теле белән тарихы аерылгысыз бәйләнгәнне белдерә. Борынгылыкны аеруча яхшы саклаган кайбер сөйләшләр татар халкының теле, аның тарихи формалашуы турында гаять әһәмиятле булган фактларны үзләрендә саклап киләләр. Менә шундыйларның берсе – татар теле урта диалектының нократ сөйләше. Ул Киров өлкәсендә һәм Удмуртиядә Чыпца елгасы бассейнында таралган.

Шунысы әһәмиятле, нократ татарлары Идел буе татар теленә хас үзенчәлекләрне үз иткәннәр һәм теге яки бу күләмдә аларны саклап киләләр.

Болгар дәүләте һәм аның дәвамчысы Алтын Урда чорларындагы төрки тел (В. Хаков, Җ. Вәлиди, Л. Җәләй кебек танылган галимнәр фикеренчә, ул тел хәзерге татар теленә бик якын булган) авазлар составы ягыннан, сузыкларның кулланылышы белән борынгы төрки телдән аз аерылган. Нократ сөйләше вәкилләренең бабалары шушы борынгы чорга хас телне үзләре белән алып китәләр. Башка телләр чолганышында, төп татар халкыннан аерылган хәлдә яшәү нәтиҗәсендә, әлеге борынгы телгә хас авазлар системасы аларның телендә хәзергә кадәр сакланып килә. Идел буе төрки теле исә фонетик яктан шактый зур үзгәрешләр кичерә. Мәсәлән,

Мәкаләләрдә телгә алынган экспонатлар һәм информантларны төсле кушымтадан карагыз.

*а* авазы иренләшү төсмере ала, *о–ө, у–ү* авазлары үзара алмашыну кичерәләр. Борынгы төрки телдәге *о, ө* авазлары урынына *у, ү,* ә *у–ү* урынына *о, ө* әйтелә башлый. Берничә генә генә мисал китерик.

| | |
|---|---|
| борынгы: | хәзерге: |
| *кол* – рука | *кол* – раб |
| *кул* – раб | *кул* – рука |
| *көл* – озеро | *көл* – зола |
| *күл* – зола | *күл* – озеро |

Борынгы төрки телдә хәзерге э авазына охшаш аваз хәзерге татар телендә *ә* яки *и* авазына, ә борынгы *и* авазы хәзерге телдә *е*(э) авазына күчә: *кәлін – килен, бәрі – бире.*

Шунысы игътибарга лаек: авазларның бу рәвешле күчеше Идел–Урал төбәгендәге төрки телләргә, ягъни татар һәм башкорт телләренә генә хас.

Әлбәттә, озак еллар буе барган мондый күчешләр төрле төбәкләрдә төрле дәрәҗәдә була. Мәсәлән, татар телендәге *йүгерү, йүгән, йүткерү* кебек очраклар, пермь сөйләшендәге *оторау* – утрау, *төгөрик* – түгәрәк, *бөрлигән* – бөрлегән, *кәрәк* – кирәк һ. б. Мишәр диалектындагы *орлау* – урлау, *нә* – ни, Урал төбәгендәге татар сөйләшләрендә *кәбән* – әд. кибән, *кәштә* – киштә, *кәм* – ким кебек күренешләр. *О, ө – у, ү* ике яклы күчешнең төрле сөйләшләрдә төрле дәрәҗәдә булуын күрсәтәләр. Сүз уңаеннан күрсәтеп үтик, татар телендә борынгы төрки авазлар системасы шактый тулы хәлдә сакланып калган сөйләшләр дә бар. Мәсәлән, бараба диалектында (Новосибирск өлкәсе), том диалектының калмак сөйләшендә сузык авазларның башка төрки телләрдәге һәм борынгы төрки телдәге кебек кулланылышы сакланып килә.

Менә шушы күренешләрнең чагылышы буенча без өйрәнә торган нократ сөйләше дә үзенчәлекле урын алып тора.

Нократ сөйләшенең үзенчәлекле авазлар системасы татар теленең авазлар системасын тарихи планда өйрәнү өчен бик әһәмиятле. Атаклы тюркологлар (В. В. Радлов, В. А. Богородицкий, Җ. Җ. Вәлиди һ. б.) татар-башкорт сузыклар шкаласына гомумтөрки аспекттагы тикшеренүләрендә игътибар иткәннәр. Сузыклар кичерә торган үзгәрешләр башка төрки телләрдә дә күзәтелә. Мәсәлән, үзбәк телендә беренче иҗектәге *а* авазының көчле иренләшүе билгеле, бу күренеш хәтта орфографиядә дә чагылыш тапкан: *Фон* < *фан* – фән, азәрбайҗан телендә, татар телендәге кебек, *ә* авазы кулланыла, әмма

ул әлегә язма телдә чагылыш тапмый, уйгур теленең авазлар системасы татар теленекенә бик якын һ. б.

Сүз башындагы *а* авазы урынына *о* сузыгын куллану себер татарларының тубыл-иртыш диалекты тевриз сөйләшендә шактый актив: *ол'апқыч* – алъяпкыч, *от* – ат, *попай* < *пабай* – бабай, *ос* – аз, *обый* – абый, *Ойничамал* – Гайниҗамал, *опарам* < *аппарам* – алып барам һ. б. Мондый күренеш эчкен сөйләшендә дә очрый.

Ләкин нократ сөйләшендә *а* авазы иренләшү төсмере булмаган ачык аваз, ягъни алар Идел буеннан күчеп киткәндә *а* авазы әле иренләшмәгән булган. Шуны да әйтик, борынгы чорда төп татар халкыннан аерымланып, изоляциядә формалашкан касыйм, пермь, керәшен сөйләшләрендә дә *а* авазы борынгы әйтелештә (ачык итеп әйтү) сакланып калган.

*О, ө – у, ү* авазларының ике яклы күчеше мәсьәләсенә килгәндә, бу үзенчәлек татар теленең архаик сөйләшләренең барысында да, нигездә, татар әдәби телендәгечә. Күрәсең, әлеге күчешләр элегрәк башланган. Чөнки борынгы төрки телдә үк бер үк сүзне *о* белән дә, *у* белән дә әйтү очраклары теркәлгән.

Нократ сөйләше *э* ~ *и* ~ *ә* ~ *е* күчешләренең стабильләшмәгәнлеге белән аерылып тора, дияргә мөмкин, тик шулай да әлеге сөйләштә *и, э*(*е*) авазларының кулланылышы, нигездә, борынгы төрки телдәгечә.

Шулай итеп, нократ сөйләше татар диалект системасында үзенчәлекле урын тота торган уникаль сөйләшләрнең берсе. Кызганычка каршы, ул югалуга бара.

Нократ сөйләшен өйрәнүнең бай тарихы бар. Аның турында мәгълүматлар фәндә урта диалект сөйләшләре арасында иң беренче билгеле була.

20 нче еллар азагында күренекле галим Җ. Вәлиди Нократ иленә диалектологик экспедицияләр уздыра һәм нократ сөйләше турында тирән күзәтүләр, әһәмиятле мәгълүматлар язып калдыра. Алар «Труды общества изучения Татарстана» (1930, 135–144 б.) дигән журналда «Наречие каринских и глазовских татар» исемле, бай эчтәлекле мәкалә булып басылып чыга. Л. Җәләйнең «Татар диалектологиясе» дигән китабында да (Казан, 1947) нократ сөйләше турында материаллар, фәнни күзәтүләр китерелә.

Нократ сөйләше бик этрафлы итеп, тиешле фәнни югарылыкта һәм бөтен тулылыгы белән күренекле телче Н. Б. Борһанова

тарафыннан тасвирлана [Говор каринских и глазовских татар (Материалы по татарской диалектологии. Вып. 2. – Казань, 1962)]. Автор әлеге сөйләш турында кандидатлык диссертациясе яза һәм аны уңышлы яклый.

Әлеге сөйләш Ф. Й. Йосыпов, Ф. С. Баязитова, Т. Х. Хәйретдинова, Д. Б. Рамазанова тарафыннан да өйрәнелгән, мәкаләләре басылган. Ф. С. Баязитова нократ якларына аеруча күп экспедицияләр уздыра, сөйләшнең грамматик төзелеше, лексик системасы буенча бай материаллар туплый һәм «Нократ татарлары» дигән китап туплап чыгара. Ф. Й. Йосыпов та әлеге сөйләш турында фән өчен әһәмиятле мәкалә бастыра. «Татар халык сөйләшләре» (Казан, 2008) дип аталган 2 китаптан торган хезмәтнең беренчесендә нократ сөйләше Ф. С. Баязитова тарафыннан тасвирланган. Түбәндә татар теле урта диалекты нократ сөйләшенең фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләре һәм аларның сөйләү үрнәкләрендә (материалларында) чагылышы бирелә.

## Нократ сөйләшенең үзенчәлекләре

Инде әйтеп үтелгәнчә, нократ сөйләшенең сузык авазлар системасы татар теле сузыклары системасының формалашу тарихын өйрәнү өчен дә бик мөһим. Чыннан да, сөйләштә сузыклар кулланылышы катлаулы күренешләр системасын тәшкил итә.

Сузыклардан *а* авазының, телнең реликт (касыйм, керәшен, пермь, подберезье, мордва-каратай) сөйләшләрендәге кебек, иренләшү төсмере булмаган, ачык аваз булып әйтелүе Идел–Урал төрки (татар, башкорт) телләренең тарихын ачыклау өчен әһәмиятле булып тора: *таш* әд. *та*$^{о}$*ш*, язылышта таш, *салма* – әд. *са*$^{о}$*лма*, язылышы салма, *аwыл* – авыл, *қалдыралар* – калдыралар.

*Қ, ғ* авазларыннан соң беренче иҗектә килә торган *а* авазы *ә* авазы булып әйтелә: *ғәлим* – галим, *Ғәлийә* – Галия, *қәйа* – кайа (язылышы – кая), *кара кычыткан* – кычытканның бер төре.

*Ә* авазы, Н. Б. Борһанова билгеләп үткәнчә, ике вариантта күзәтелә. Беренче вариант татар әдәби телендәгечә киң әйтелешле. Ул, нигездә, гарәп-фарсы алынмаларында күзәтелә: *қәбен* – никах, *қәғәз* – кагазь, *сәғәт* – сәгать, *сәләм* – сәлам, *шимбә, Сәлимә, Мәдинә, Нәҗибә, Гөлфирә, Әминә, Нәйлә* – Наилә, *Рәисә, қәйер* – хәер, *чилсәwит* – сельсовет һ. б.

Шулай ук кайбер башка сүзләрдә: *әбку*$^{о}$*й* – әбекәй, *әнку*$^{о}$*й* – әнкәй, *кәзә* – кәҗә һ. б.

Икенче вариант тар әйтелешле *ә* авазын тәшкил итә. Ул яңгырашы белән рус телендәге э авазына якын тора (биредә без дә аны э дип билгелибез), сүздә теләсә кайсы позициядә күзәтелә. Мәсәлән: *бикэ* – бикә, *кэмэ* – көймә, *чэчкэ* – чәчкә, *килэлэр* – киләләр, *эшлэмэгэ* < *эшләмәгә* – эшләргә, *белэ* – белә, *эсти* – истә, *эке* – ике, *тэңкэ, йерилэр* – йөриләр, *билгелэрлэр* – билгеләрләр, *күкэйлэр* – күкәйләр, *исемэ* – исемә, *сүлэшэсең* – сөйләшәсең һ. б.

Тар әйтелешле э авазы татар теленең көнбатыш диалекты сөйләшләрендә әдәби *и* авазы урынында күзәтелә. Мәсәлән: *эртә* – иртә, *кэрәк* – кирәк, *эрләр* – ирләр, *бәйремнэр* – бәйрәмнәр.

Нократ сөйләшендә *ә* авазының тараюы тагын да көчәергә һәм *ә* → *и* тәңгәллегенә әйләнергә мөмкин: *безги* – безгә, *йиткези* – җиткезә, *бәйримги* – бәйрәмгә, *тенни* < *тенли* – төнлә, *ийдин-ийги* – өйдән-өйгә, *тэрэзлэрги* – тәрәзәләргә һ. б. Бу күренеш чыгыш килешендә актив: *бердин* – бердән, *синдин* – синнән.

Материаллар шуны күрсәтә, *ә* авазының тараюы (*ә* > *э, ә* > *и*), нигездә, тар әйтелешле сузыклардан соң күзәтелә. *Ә* авазының тараюы ягыннан да нократ сөйләше пермь, касыйм сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә. Мәсәлән, касыйм сөйләшендә: *'ири'* – кирәк, *'иси* – кисә, *бели* – белә.

Пермь сөйләшендә: *күгерчин* – күгәрчен, *бөрлиген* – бөрлегән, *мелиш* – миләш һ. б.

*Ә* авазының күчешләре нократ сөйләшендә еш кына әдәби әйтелеш белән чиратлаша. Бу, аеруча, Биктеш, Кистем, Уръякала, Паюра, Татар Парҗысы, Әхмәди авылларында (ягъни, Глазов, Балезино районнарында) күзәтелә. Ә Нократ (Карино) авылында борынгы сузыклар системасына якын булу шактый ныклы системалылык саклый. Юкамен районында исә *ә* авазын әдәби телдәгечә куллану Н. Б. Борһанова өйрәнгән вакытта ук, ягъни 60 нчы еллар элек үк булган.

*Ә* авазының күчешләре *и* авазының тәңгәллекләре белән дә туры килә. Билгеле булганча, борынгы төрки телдәге *и* авазына хәзерге татар телендә еш кына *ә* авазы, ә борынгы *э авазына *и* авазы туры килә, шуннан *э* ~ *и* ~ *ә* ~ *э* күчешләре килеп чыккан. Бу язмада әлеге күчешләрдән төрле тәңгәллекләр теркәлгән. Билгеле булганча, сөйләү телендә даими рәвештә теге яки бу үзгәрешләр булып тора. 50–60 ел эчендә дә шактый үзгәрешләр барлыкка килгән булырга мөмкин.

Сөйләштәге *и* авазы күбесенчә әдәби э(*е*) сузыгына тәңгәл килә: *ит* – әд. эт (собака), *из* – эз, *ичэге* – эчәге һ. б.

Н. Б. Борһанова, нократ сөйләшендә э(*е*) авызының киң һәм тар вариантлары бар, дип күрсәткән. Тар э(*е*) авазы әдәби *е* сузыгына туры килә: *бер, эш, эз, беренче, үсеп, әле, иде, йәбеште* – ябышты, *тегесе, кеше, кем, үзебез* һ. б.

Киң әйтелешле *э* (*е*) авазы: күбесенчә тамыр сүзләрдә, әдәби телдәге *и* урынында күзәтелә *бэр* – бир, *кэл* – кил, *кэт* – кит. Күзәтүләрдән мәгълүм булганча, *ә* авазының тар варианты әлеге киң әйтелешле *э* (*е*) авазына тәңгәл килә: *бэр* – 1) бир, 2) бер; *кэрэк* – кирәк, *кэлгэлэгэндә* – килгәләгәндә һ. б.

## Дифтонглар

Сөйләшкә хас иренсезләштерү *өй* дифтонгын куллануда да чагылыш таба. Бу сөйләшкә *өй* урынына *ий* дифтонгын яисә э(*е*) монофтонгын куллану хас: *ий/өй* – өй, *тейәп* < *төйәп* – төяп.

Шул ук вакытта *өй* > *ү* тәңгәллеге дә актив: *сийәк/сүwәк* – сөяк, *кийәндә/күwәндә/күwәндә* – көянтә, *тиймә/түмә* – төймә.

Билгеле булганча, *өй* > *ий* (*сийләшә* – сөйләшә, *ий* – өй, *кийәнтә* – көянтә һ. б.) күренеше урта диалект сөйләшләренә хас. Ул тагын көнбатыш һәм урта диалектлар вәкилләре катнашлыгында формалашкан катнаш сөйләшләрдә дә күзәтелә. Мәсәлән, чистай, стәрлетамак, волгоград сөйләшендә: *ийалды* – өйалды, *үрэнер* – өйрәнер.

Нократ сөйләше урта диалектның фигыль кушымчаларында, күрсәтү алмашлыкларында *-ый/-ий* дифтонгы урынына *-ай/-әй* дифтонгы кулланыла торган сөйләшләрнең (керәшен, минзәлә, касыйм, бөре, златоуст, тепекәй, кормантау һ. б.) берсен тәшкил итә: *йылай* – елый, *бармай* – бармый, *андай* – андый, *мындай* – мондый һ. б.

Дифтонглар өлкәсендә сөйләштә тагын бер уникаль күренеш бар: әдәби телдәге *-ау/-әү* дифтонгы, норлат, пермь сөйләшләрендәге кебек, тар вариантта әйтелә: *шаршу/шаршоу* – чаршау, *бызоу/бызу* – бозау, *чылғоу/чылғу* – чолгау, *йәйәү/йәйү* – җәйәү, язылa җәяү, *йалқулық* – ялкаулык, *ашу* – ашау (*Ашу йаса әле иткэ* – эткә).

Шунысын күрсәтеп үтәргә кирәк, *ау* > *у* варианты чагыштырмача сирәгрәк очрый.

Әдәби *-у/-ү* сузыклары урынына *-ыу/-еү* дифтонглары әйтелү очраклары бар: *кеүренмәй* – күренми, *кеүтәрә* – күтәрә һ. б.

**Сузыклар өлкәсендәге башка үзенчәлекләр**

Нократ сөйләшендә палаталь гармониянең бозылу очраклары еш күзәтелә. Мәсәлән: *элгаре* – элгәре, *экы* – ике, *тәбәгый* – паштет, *эшләды* – эшләде, *йылайсин* – елыйсың, *қазрәт* – хәзрәт, *куркә* – күркә, *алйәпкыч* – алъяпкыч.

Бу күренеш грамматик күрсәткечләр ялганганда еш күзәтелә: *барыбез* – барырбыз, *ашарсин* – ашарсың, *син уқ* – син үк, *салқын генә* – салкын гына, һ. б.; югарыда *әбку*$^{о}$*й* – әбекәй, *әнку*$^{о}$*й* – әникәй, *Шамку*$^{о}$*й* – Шамилкәй кебек очракларны күрсәтеп үткән идек.

Палаталь гармониянең бозылу очраклары алынма сүзләрне үзләштергәндә дә була: *кургит* (удм.) – тавык куначасы, *мажес* (удм.) – тырма, *пубрик* (рус. погреб) – кар базы, *мәтыга* – мотыга, *мәтча* – матча һ. б.

Сузык аваз тәңгәллекләре:

*э ~ и: мэн* – мин, *чэтендә* – читендә, *чэтек/чәтек* – читек, *бэлчән* – билчән, *келим/килем* – әд. киндер;

*ы ~ а: қашыға* – кашага;

*ө ~ ү: көп* – күп;

*и ~* э(*у*)*: чилтәр* – челтәр;

*и ~ ү: тигел* – түгел, *изем* – үзем;

*и ~ у: мича* < *муча* – мунча; *мичақ* < муенчак;

э(*е*) *~ ү: беген/бе*$^{ө}$*ген* – бүген;

*о ~ у: зор* – зур;

*ө ~ а: мотор* – матур;

*у ~ а: мутор* – матур, *қоштон* – диал. қуштан, көяз, *Қузон* – Казан, *зурут* – зурат;

*у ~ ы: йодыруқ* – йодрык;

*ү ~ ә: сүндәрә* – сәндерә;

*и ~ ә: бирни* – бирнә, *сиксин* – сиксән.

Алынмаларда: *ырадийу* – радио, *колош* – галош, *кунсирт* – концерт һ. б.

Сөйләштә арткы рәт сузыклар белән әйтелә торган аерым сүзләр нечкә әйтелергә мөмкин: *йәбешә* < *йабыша* – ябыша, *күнәч* – куныч, *бәчкеч* – баскыч.

Киресенчә, алгы рәт сузыклар белән әйтелә торган сүзләр калын әйтелә. Бу күренеш Дасис (Засеково), Уръякала (Гордино)

һ. б. авылларда, дөресрәге бисермән авылларында, шактый актив күзәтелә. Мәсәлән: *алы* – әле, *сылгы* – сөлге, *аби* – әби, *быз гына* – без генә, *кышы* – кеше, *бызга* – безгә, *ылыкылар* – элеккеләр, *хайырлы сагат булсын, ыранйымагыз. Анийым айтыр иды, уналты кыз тут'у* (*ана чеби*) *бар дип. Чыгындар* – чөгендер һ. б.

Мондый очракларда сингармонизм законы да бозылучан була: *әйбатлап* – әйбәтләп.

Сузыклар төшү:

*Ы: лыс* – ылыс, *чәге* – эчәге һ. б.

Сузыклар өстәлү:

*Аст, өст, арт* бәйлек сүзләрдә *т* авазы саклана: *эстегә* – өскә, *астыға* – аска һ. б. Сүз башында: *энечкэ* – нечкә.

*Э*(*е*) авазының киң варианты әдәби теледәге *и* авазына туры килә: *эт* – ит (мясо), *энде* – инде, *эке* – ике, *семез* – симез, *керпеч* – кирпеч, *эл* – ил, *элек* – иләк, *нечә* – ничә, *этек* – итек, *эски* – иске.

Сөйләшкә иренсезләштерү хас: *тырдық* – тордык, *тырмыш* – тормыш, *келә* – көлә, *ызата* – озата һ. б.

Шуның белән бергә, бер төркем сүзләр, киресенчә, иренләшкән вариантта әйтелә: *қор* – кыр (поле), *қор төп* – басуның ерак башы, *қоз* – кыз, *қозом* – кызым һ. б.

*И ~ ә: пилмин* – пилмән, *тегермин* – тегермән, *пирәмәч* – пәрәмәч һ. б.

*У* авазының әйтелеше һәм кулланышы, нигездә, әдәби телдәгечә, ягъни сүздә – беренче иҗектә, исем фигыль формасында икенче яки соңгы иҗектә дә кулланыла: *тукта, куйа* – куя, *була, салу, калу, бару* һ. б.

Шул ук вакытта, *у* авазын икенче яки өченче иҗектә куллану очраклары да бар: *булумады* – булмады, *тулумады* – тулмады, *йыдыруқ* – йодрык, *кызамук* – кызамык. Нократ сөйләше өчен үзенчәлекле күренешләрнең берсе сүз азагындагы *ы* урынына да *у* авазы куллану. Мәсәлән: *сару* – сары, *кыру* – коры, *тулу* – тулы һ. б.

Сорау кисәкчәсендә дә шул ук үзенчәлек күзәтелә: *кыраyму* – кыраумы, *даламу* – даламы, *қарайму* – карыймы һ. б.

Сүз азагында *у ~ ы* күренеше татар теленең бараба һәм том диалектларында да бар: *тару* – тары, *олу* – олы, *кату* – каты, *табанну* – табанлы һ. б. Бу диалектларда да авазларның борынгы төрки системасының хәзерге татар әдәби системага күчү процессы бара.

Нократ сөйләшендә борынгы дифтонгонид *у*$^{о}$ авазы сакланган. Ул кайбер сүзләрдә, иркәләү-кечерәйтү кушымчасында күзәтелә:

*әбку$^{o}$й* – әбикәй, *әнку$^{o}$й* – әнекәй; *йу$^{o}$wан* < *йуwан* – юан, *йу$^{o}$қ* < *йук* – юк һ. б.

## Тартык авазлар системасы

Нократ сөйләше тартык авазлар һәм аларның артикуляциясе белән татар әдәби теленнән аерылмый. Үзенчәлекләр төрле комбинатор үзгәрешләргә, аваз тәңгәллекләренә кайтып кала.

Сөйләшкә тирән тел арты *қ, ғ* авазларын куллану хас: *тырдық* – тордык, *қычытқан* – кычыткан.

Глазов, Балезино, Юкамен районындагы авылларда тирән тел арты *қ, ғ* авазлары урынына тел арты *к, г* авазлары әйтелү очраклары бар: *кай ки* – диал. кайки – каядыр, *чыгардылар* – чығардылар, (язылышы – чыгардылар).

Тирән тел арты *қ* авазы гарәп-фарсы алынмаларындагы *х* тартык авазы урынына да әйтелә: *қәтлек* – хәтле, *ақыры* – ахры, Қаҗи (Хаҗи) бабай, *Миңнеқан* – Миңнехан, *Қәмдийә* – Хәмдия һ. б.

Кайбер очракларда сүз уртасындагы *қ, ғ* авазлары урынына аттракция әйтелә: *Рә'мәт сезги* (рәхмәт сезгә), *бушлатыгыз йылы булды. Ә'мәр тигермэни* – Әхмәр тегермәне, *күлми'* – күлмәк һ. б.

Нократ сөйләшенә, көнбатыш һәм себер татарлары диалектлары кебек үк, *й*-лаштыру хас: *йәшел* – яшел, *йәйеү/йәйү* – җәяү.

Шуның белән бергә, сүз башындагы *й* тартыгын *җ* элементы белән әйтү очраклары да күзәтелә. Мәсәлән: *й$^{ж}$иралмы* < диал. жиралма – бәрәңге, *$^{ж}$инаклап* – җыйнап.

Мондый күренеш әдәби тел йогынтысы белән аңлатыла булса кирәк.

Алынмалардагы тәңгәллекләр дә, нигездә, урта диалект сөйләшләрендәгечә:

*в > б: йәнбәлит* – инвалид,

*в > м: минек < веник* – себерке (каен),

*в > о: агус* – август һ. б.

Аерым сүзләрдә күзәтелә торган тартык авазлар тәңгәллеге:

*й ~ д: йетдом* – детдом,

*к ~ т: келәү* – теләү, *искалык* – истәлек,

*х ~ к: Орхийә* – Оркыя, *сәдәха* – сәдака,

*з ~ д: эзән* – идән, *қазақ* – кадак,

*ғ, г ~ қ, к: бәргем* – беркем, *бағыт* – вакыт, *бетәгә* – бүтәкә; *сәтәғә* – сәдәка,

*ғ, г ~ h: шәғәр* – шәһәр, *ҡәғәр* – каһәр,

*м ~ н: белем* – белән, *былым* – болын, *тетем* – төтен, *үләм* – үлән.

Саңгырауларны яңгыраулаштыру:

*г ~ к: бәргем* – беркем,

*б ~ п: бешү* – пешү, *бычкы* – пычкы,

*д ~ т: дегел* – түгел, *дастымал* – тастымал, *дағын* – тагын, *дары* – тары, *дабын* – табын.

Касыйм, бәрәңге сөйләшләрендәге кебек, нократ сөйләшендә дә *ң* авазы урынына тел очы *н* тартыгы әйтелү шактый актив күзәтелә. Бу күренеш аеруча иялек килеше кушымчасында очрый: *кэленнен* – киленнең, *анын* – аның, *йылнын* – елның, *әнинен* – әнинең, *арпанын* – арпаның, *ҡаласын* – каласың.

Кайбер сүзләрдә: *аннамай* – аңламый, *мен* – мең, *йанаҡ* – йаңаҡ (язылышы – яңак).

Кире ассимиляция очраклары күзәтелә: *бачкыч/бәчкеч* – баскыч; *белмәгәмбез* – белмәгәнбез, *шыршы* – чыршы, *шаршау* – чаршау; *Шәмшыйамал* – Шәмсеҗамал.

*т, т' ~ ч: т'аршау/т'аршоу* – чаршау, *тишмә* – чишмә, *т'ашка* – чашка һ. б.

*т* һәм *к/г* авазлары урынына бугаз авазы әйтелү очраклары күзәтелә: *у'мурт* – удмурт, *балы'* – балык, *йымша'* – йомшак, *за'лы* – затлы.

Тартыклар өстәлү:

*ҡ/к: ҡәтлек* – хәтле, *чыраҡ* – чыра,

*г: миңға* – миңа, *ангар* – аңа, *сиңға* – сиңа, *җиңгел* – җиңел,

*б: бимә/бемә* – өмә;

Авазлар төшү. Сүз башындагы позициядә *й* сонанты төшә: *има* < *җыйма* – җыярга; *иштырдыҡ* – җыештырдык, *өртү* < йөртү (тагу); *ибәрешкән* < *җибәргән* – ычкынган, *суwәсе* < *су ийәсе* – су анасы.

*н: белә* – белән, *күптә йуҡ* < *күптән йук* – күптән түгел,

*л: у* – ул,

*р: биресенме* – бирерсеңме,

*н: мичак* < *минчак* – муенчак, *мича* – муча, *мичала* – мунчала,

*h:* әр кайсы – һәркайсы.

Тартыкларның редукцияләнүе һәм төшүе:

*г > w: йыwартын* < *йуғартын* – югарыдан,

*г > о: тее* – теге, күрмэмбез < күрмәэмбез < күрмәгәнбез.

Метатеза: *бәрйем* – бәйрәм, *кулып* – клуб, *әрйән* – әйрән, *кырйык* – койрык, *қарйақ* – кайрак.

## Сүз төркемнәре өлкәсендәге үзенчәлекләр

Исемнәр. Нократ сөйләшендә исемнәрнең иркәләү-кечерәйтү формасы *қу°й* кушымчасы белән ясала. *Камку°й* – Камилкәй, *Шамку°й* – Шамилкәй һ. б. Бу кушымча сингармоник законга буйсынмый.

Туганлык атамаларында *-ч* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялгана: *бабач* – этисенең, энисенең бертуган олы ир туганы; *апыч* – абыкай (*Мәүләт апыч анда эшли*).

Тартымлы исемнәрнең юнәлеш килеше *-ға/-гә* кушымчасы белән ясала: *эстегә* (*өстенә*) *бушлат қалдырдылар*, *бабамға* – бабама һ. б.

Өстәмә тартым кушымчалары ялгану: *Икесебез дә арықлар идек* – Икебез дә ябык идек.

Чыгыш килеш кушымчалары тар һәм киң вариантларда әйтелә: *киндердән/киндердин*, *синдән/синдин* һ. б.

Тартышлы исемнәрнең чыгыш килешендә, әдәби телдән аермалы буларак, охшашлану күзәтелми: *атларындан* – әд. атларыннан, *мындан* – моннан, *андан* – аннан һ. б.

I зат тартым кушымчалы исемнәрнең иялек килешендә *н* авазы төшә: *Әтийемең әнисе сийләгәләгән.* – Әтиемнең әнисе сөйли иде.

## Саннар

Кешене белдерә торган сүзләр, саннар белән ачыкланып килгәндә, күплек кушымчасы алалар: *Туғыз балалар* (бала) *эчендә Бер без бәқытсез булдық* (хал. җыры). *Ике киленнәр* (ике килен) *белэ тырдық, берги тырдык. Әнәйесе эки ыланнар* (ике олан) *белә қалды. Әки малайлар анда. – Анда ике малай. Хәмидә аппақның ике туганнары* (туганы) *бар Қазанда*.

Аергыч ролендәге саннарга *-сы/-се* тартым кушымчасы ялгана: *Берсе малайы* (малайларының берсе) *мим* (минем) *белән бер йылнын. Берсе малайым – қалада, берсе қозом – йанымда.*

Моңа охшаш күренеш күрсәтү алмашлыклары өчен дә хас: *Мынсы урамда әтәйләре тыра.* – Бу урамда этиләре тора. *Ул тегесе аwылда тырайде.*

## Алмашлыклар

Зат алмашлыклары: *мин/мэн, син/сэн, ыл/ул/у, без, сез, алар.*

Нократ сөйләшендә I зат **мин** алмашлыгының иялек килеше *минем, минең* формаларында килә.

Иялек килешендә килгән *минем* алмашлыгы, кыскарып, *мим* формасында да әйтелә: *Берсе малайы мим белән бер йылнын.* – Малайларының берсе минем белән бер елгы.

*Мин, син* алмашлыклары юнәлеш килешендә *миңә/мийә, сиңә/сийа* формасында әйтеләләр. *Сиңә утырып йеремәгә насилка инде.* – Сиңа утырып йөрү өчен носилка инде. *Мийа элле йиде.* – Миңа илле җиде (яшь).

*Без* зат алмашлыгы иялек килешендә *безнең/безен* вариантларында кулланыла: *Безен әнки белән туган Хисаметтин бабайга племянница ул.*

Күрсәтү алмашлыклары. Нократ сөйләшендә *шул* һәм аның нигезендә ясалган башка формалар кулланылмый: *ул/у* – 1) ул; 2) шул, *алай* – 1) алай, 2) шулай; *андай* – 1) андый, 2) шундый һ. б. Мәсәлән: *Андай* (шундый) *тырмышта тырдык. Алай дип сүләдек* (шулай дип сөйләдек). *Ул уқ арада без ди килдек.* (Шул арада ук без дә килдек). *Ул уқ чакта арулама йәбештеләр өйне. У йақта уорман булғанда* (Ул якта урман булган). *Менә башы бар. Ана қычытқан, йаман парлай* (чага) *ул.*

*Ана, мынау/мына, теге/тее/те, у/ул, бу* һ. б.: *Монау бармаққа нәрсәдер чықты.*

Алмашлыкларның төрләнеше.

Чыгыш килешендәге күрсәтү алмашлыкларына -*тын* форманты ялгана: *анан тын күренмәй.* – Аннан күренми. *Мынан тын йырақ жу°қ.* – Моннан ерак түгел.

Билгесезлек алмашлыклары.

*Кай ки* – каядыр: *Малларны кай ки салдылар* (куйдылар). *Ни ки, чәй бэрде.* – Ничектер, чәй бирде.

*Кемсә* – кемдер: *Мужет кемсәләрнен чийә бардыр аwылда.*

*Ни кей бетергән булған* – Ниндидер (вуз) бетергән булган.

*Кергәчтен қа ки урнаштық* – Кергәч, каядыр, шунда урнаштык.

Сорау алмашлыклары: *нинди, касы, ни/нә/нәстә, ничә/нэчэ, қайа ки* һ. б. *Нинди йассы* (киң) *суларыбыз.*

## Рәвешләр

Вакыт рәвешләре нократ сөйләшендә дә, нигездә, татар әдәби телендәгечә ясалалар: *йәйен* – җәен, *кезне* – көзен, *кез кене* – көз көне һ. б.

Шуның белән бергә, сөйләштә диалекталь вакыт рәвешләре дә бар.

*Қошқосын* – кышын: *Қошқосын олымда тырам.*

*Кезне йәйү барма булмай.* – Көзен җәяү барып булмый.

*Тенен дә, кенен дә ийемдән сагынам.* – Төнен дә, көнен дә өемне уйлыйм.

*Йәй буйы ийдә тырмады ул.*

## Фигыльләр. Затланышлы формалар

Хәзерге заман хикәя фигыльнең кушымчасы киң вариантта, ягъни *-ай/-әй* дип әйтелә, зат кушымчалары I–II затларда зат алмашлыклары белән тәңгәл килә:

| | |
|---|---|
| мин *йылай-мин* | без *йылай-без* |
| син *йылай-син* | сез *йылай-сез* |
| ул *йылай* | алар *йылай*(*лар*) |

Мәсәлән: *Қычқырып йылаймин* (елыйм). *Сэн бэлэсэн* – син беләсең. *Кәрәксенмәйләр* – кирәксенмиләр. *Ынытамин ич* – онытам бит; *Йаз көне май айында инешкә тешеп ботқа бешереп, кешеләргә айырып* (бүлеп) *ашатабыз*.

Билгеле үткән заман сөйләмдә ике форма белән белдерелә.

1) Традицион форма -*ганда/-гәндә* кушымчасы белән ясала: *Алар кичә кансирт салғанда* (куйдылар). *Татарстаннан килгәндә* (килде) *қунақлар*. *Сания аппақ үлгәндә* (үлде).

2) *-ды/-де* формасы: *Нә китирдэмдер инде, йанйаулықмы.* – Нәрсәдер китердем инде (*бүләккә*), кулъяулыкмы. *Кийеүгә беренче кенне бәләкәй* (мендәр) *алып керетте*.

Нократ сөйләшендә нәтиҗәле үткән заман (-*ганмын, -гансың*), күпчелек төрки телләрдәгечә, -*ып/-еп* кушымчасы белән ясала, *-мин, -син, -без, -сез* кушымчалары белән төрләнә. *Адрисын йазмапмин* (язмаганмын). *Мин кебек қартайыпсин, дип әнәй*. – Минем кебек картайгансың, ди әни.

Бу форманың юклыгы -*мап/-мәп* кушымчасы белән ясала: *Без қурықмапбыз* – без курыкмаганбыз.

Сөйләштә әдәби *-ган* формасы да кулланыла. Бу әдәби тел йогынтысы белән аңлатыла булса кирәк. Мисаллар: *Көп булғансыз ич инде.*

III затта нәтиҗәле үткән заманның әдәби формасы кулланыла: *Абычы* (абыйсы) *белән экү* (икәү) *қалғаннар*.

Күптән үткән заман, әдәби телдәгечә, *-ган иде* формасы белән белдерелә: *Әнәй сүләгән иде* – әни сөйләгән иде.

Шул ук вакытта әлеге мәгънә *-ганда иде* конструкциясе белән дә белдерелә: *Бирелгәндә иде* (бирелгән иде) *зимилны участка. Беренче әбийебез Палагайдан* (ав. ис.) *иде, үлгәндә* (үлгән) *иде инде*.

Дәвамлы үткән заман *-ә иде* формасы белән белдерелә: *Май түгәләр* (сибәләр) *иде, йәй әйбәт булсан, дип, сыйыр май беле ашаталар иде. Ботканы т'ашкаларға салып ашап утыра идек.*

Бу форма, көнбатыш диалектындагы кебек, иң актив форма булып тора.

Кабатлаулы үткән заман, урта диалектның күпчелек сөйләшләренә хас булганча, *-ыр иде* формасы белән белдерелә: *Зур-зур ипи күмәч салыр иде әни. Сарык тиредән ыйық кебек тегәрләр иде.*

Сөйләштә аналитик үткән заман формаларының берсендә булган *-адыр иде* конструкциясен кулланылу очраклары күзәтелә: *Қачма* (качарга) *булдырған чақта туп уйнайдырыйық.*

Билгесез киләчәк заман хикәя фигыль әдәби телдәгечә ясала: *Булышырсин* – Булышырсың. *Былар қалырлар энды, папықайым.* – Болар калырлар инде, әтекәйем. *Мэн иртәгә килермин.* – Мин иртәгә килермен.

Мисаллардан күренгәнчә, зат кушымчалары үзләренең чыганак формаларын саклап киләләр. Шулай итеп, нократ сөйләше материаллары фәндә урнашкан I төр зат кушымчалары зат алмашлыкларыннан килеп чыкканнар, дигән фикернең чынбарлыкка туры килүен исбатлый.

Кабатлаулы үткән заман (әд. *-а торган иде*) нократ сөйләшендә *-гала/-гәлә* кушымчасы белән ясала: *Зур әни дигәләде әнку*°*й.* – Зур әни дип әйтә торган иде әнием. *«Шушма» йыруwын бийатам йырлагалады иде.* – «Шушма» җырын каенатам җырлый торган иде. *Урмандан кергәләмәде ул.* – Урманнан кайтып керми торган иде ул. *Кулхузға йер биргәләделәр.* – Колхозга җир бирә торганнар иде.

Теләк фигыльләр.

Теләк наклонениесе әдәби телдәге *-ыйм* (*әле*), *-ыйк* (*әле*) кушымчасы белән ясала, тик сөйләшкә аның киң варианты хас: *йәбе-*

*шәйем әле* – ябышыйм әле. *Берне йырлайыг әле «Шушма» кийенә.* – «Шушма» көенә берне җырлыйк әле.

Нократ сөйләше эчке теләкне белдерә торган *-асы/-әсе + кил-* формасы белән дә татар әдәби теленнән аерылмый: *Йаман сүләсем килэ.* – Бик сөйләшәсем килә.

Сөйләштә тагын мондый теләк формалары бар:

*-асы+иде: Ақрынырақ қайтасыйы. Сабан туйны күрәсе иде.*

Ният, ниятле теләк *-ма + кели* конструкциясе белән белдерелә: *Мында тырма келәй.* – Монда тормакчы була.

Урта диалект сөйләшләренә хас *-ырга + итә* конструкциясе дә күзәтелә: *Ул кичне қайтмаға ителдек* (кайтмакчы булдык).

Эшнең үтәлү дәрәҗәсе нократ сөйләшендә дә, әдәби телдәге кебек, *-гала/-гәлә, -гыла/-гелә* кушымчалары белән ясала: *Сабан йегермәгә баргаладым.* – Сабантуйда йөгерү ярышына бара торган идем. *Мин уйнағаладым.* – Мин уйнаштырдым. *Кузниста эшләгеләде* (эшләштерде).

Билгеле булганча, әд. *-ыштыр/-ештер* кушымчасы структур яктан икегә бүленә: *-ыш/-еш* һәм *-тыр/-тер.* Хәзер инде бу кушымча катлаулы булып саналмый. Нократ сөйләшендә исә әлеге кушымчаның беренче элементы гына кулланыла: *Қараштым аwылға, кеүренмәде.* – Караштырдым авылга (таба), күренмәде. *Анда йырақ йуқ* (түгел), *ийдәнтын қараштым* (өйдән караштыргаладым). *Минем әби уқыша иде* (укыштыра иде). *Бақчаныму бағышасың килә.* – Бакчаны күрәсең киләме?

Гомумән, нократ сөйләшендә *-ыш/-еш* кушымчасы еш кулланыла. Ләкин кайбер очракларда алар эшнең үтәлү дәрәҗәсен белдерми: *Ибәрешкән* (< җибәрешкән; – ычкынган) *ул, менә башы бар. Тилевизырдан тыңнашам. Тилевизыр бағышам* (карыйм). *Әнәй тегешеп тыра иде.*

Нократ сөйләше – инфинитивның борынгы *-мага/-мәгә* формасын саклап килгән сөйләшләрнең берсе. Мәсәлән: *Соңра эшләмәгә йәбеште Чилсавиттә. Порно йапмаға кэрэк.* – Төтенне ябарга кирәк.

*-ма/-мә* формасы да инфинитив буларак кулланыла: *Ашама йоқ, эшки барабез.* – Ашарга юк, эшкә барабыз. *Ат туwарма булдырамин.* – Ат туарырга булдырам. *Има телибез.* – Җыярга телибез.

Нократ сөйләшендә, урта диалект сөйләшләрендәге кебек, *-асы/ -әсе* формасы төрле мәгънә төсмерләре белдерә.

1) Инфинитив, максат: *Сиңа кулыбқа түләп керәсе* (керергә). *Зур пич йағасы* (йагарга кирәк). *Урасы ич кул белин.* – Кул белән урырга бит.

2) Инфинитив, тиешлек: *Нәзерне әйткәч, бирәсе була. Әгәр дә ки йасасы булса, йасап биребез.*

3) Теләк, эчке теләк: *Горотқа барасым килмәй тырыға.*

## Хәл фигыльләр

*-ып/-еп* формасы: *Бытқаны анда* (шунда) *ук бешереб ашайлар. Нәзер әйтсә, әбиләрне китереп уқыта иде, аwыртуларым бетсен, дип.*

*-ып/-еп* формасының юклыгы *-майчы/-мәйче, -мыйчан/-мичән* кушымчалары белән ясала: *Нәзерне әйткәч бирәсе була, бирмичән ыриза булмай. Кулып ачылмайчы тырды бит.*

*-ганчы/-гәнче* формасы һәм аның вариантлары: *Әбиләре бу кешем туғанчы үлгәндә.* – Әбиләре бу ирем туганчы үлгән иде.

*-ғанчы/-ға қәдәр: Ускәнчегә қәдәр чапмайлар печинне.*

*-гач/-гәч: Нәзерне әйткәч бирәсе була. Кайткач та төш күрдем.*

*-гачтын/-гәчтен: Күмгәчтән йиралмалар үсеп китте.*

*-гачын/-гәчен: Миңнәре булғачын, Гелчирә иде, Миңнежәмал, дип салдылар* (куштылар).

*-ганның соңгра: Кызны китергәннең соңгра мулла алып киләләр кәбин салмага* (никах укытырга).

*-мастан/-мәстән, -мастан элек* (яки алда)/*-мәстән элек* (яки алда): *Суғыш чықмастан алда ийләнгән ул.*

## Теркәгечләр

*Исә* теркәгече модаль сүзләр, сорау алмашлыклары белән килгәндә төрле модаль мәгънәләр белдерә. Мәсәлән: *Алай йересе исә, минең бер дә баш-ақыл йуқ.* – Шулай йөрисе булса, минем бер дә зиһенем юк.

*-ды+исә: Уңайланмадисә, балничага барыбез.* – Төзәлмәсә, хастаханәгә барырбыз.

*Исә* теркәгечен кабатлап куллану очраклары күзәтелә: *Бар исә алып, йуғ исә табып, алай* (шулай) *тырмыш иттек.* – Булса алып, булмаса юнәтеп, шулай тормыш иттек. *Бар исә киде, йуғ исә йуқ.* – Булса киде, булмаса юк.

## Бәйлекләр

Бәйлекләрнең составы һәм функцияләре ягыннан, нократ сөйләше әдәби телдән, нигездә, аерылмый. Шулай да, кайбер үзенчәлекләр табыла.

Мәсәлән, *өчен* бәйлеге, сәбәпне түгел, бәлки максатны белдерә: *Пийала эчен барма чықҗан икән.* – Банкаларга барырга чыккан икән.

*Бели/белә* – белән: *Ат бели кутэрэлэр.* – Бәрәңгене ат белән өяләр.

*Сыңгра* – соңыннан, соң: *Уқып чыққаннан сыңгра эшлэмэ йәбеште.* – Укып чыкканнан соң эшли башлады.

Күләм-чама бәйлекләре: *қәдәр* – кадәр, *тәкле/тэкле: Кичэ тәкле уйнай балалар. Астысына тәкле ағып чыққан суwы.*

Чагыштыру бәйлекләре сөйләштә, әдәби телдәге кебек, иялек килешен түгел, бәлки баш килешне башкаралар: *Мин* (минем) *шикелле малайлар да йергәләделәр* (йөрделәр). *Син кебек бергем дә* (дога) *уқучылар йуқ, диләр. Сез дә без кебег икән, без дә сез кебег икән* (сөйләшү турында). *Без кебеге эйеннән чықмай.* – Безнең кебеге өеннән чыкмый.

Диалекталь бәйлек сүзләр: *сартын* – турында, буенча. Мәсәлән: *Морсәлим сартын сүләп бирер барсағыз. Бик л'ақытлар* (яхшылар), *дин сартыннан да аңлата.*

## Модаль сүзләр

Нократ сөйләшендә *түгел* сүзе урынына *йоқ*(*қ*) лексемасы кулланыла. Мәсәлән: *Қәйер эстәп* (яшәдек), *беркем ишана тырған йоқ* (ышана торган түгел). *Үги йоқ, үзенеке.* – Үги түгел, үзенеке. *Мулла йуғ иде* (түгел иде) *ул, ну уқымышлы кеше иде. Күптә йук* (күптән түгел) *йереп кайталар.*

*Шай/шәй* – ахрысы: *Үләм шәй инде, ди әнки. Белмәгәмбез шәй. Алай шай.* – Шулай ахрысы.

Кисәкчәләр. -*мы/-ме/-му/мү/-мый/-ми* сорау кисәкчәсе җөмләдәге логик басым төшкән сүзгә ялгана: *Ачмы йатма мында келәйсең.* – Монда ач ятмакчы буласыңмы? *Алғамы барабыз, арткамы қалабыз. Туwыпбез инде дэ аларны белмэйми? Үзенәме чақырды?*

*Кирәк* сүзе *кэрэк/кәрәк/кирэк* вариантларында әйтелә һәм фигыль кебек төрләнә. Мәсәлән: *Кэрэксенмәйләр* – кирәксенмиләр.

## Синтаксик үзенчәлекләр

Компонентлары нисбәтлелек мөнәсәбәтендә булган исем-исем сүзтезмәләр грамматик күрсәткечсез формалашалар: *аwыл қалық* – авыл халкы, *әүлийә қәбер* – әүлия кабере, *Қырбан бәйрәм* – Корбан бәйрәме, *алар җанға* (алар янына) *барамин, Чүпче йылға* – Чыпца елгасы. *Тау биттә* – тау битендә, *Чима майлар эчертэлэр.* – Көнбагыш майлары эчертәләр.

Шул ук типтагы сүзтезмәләрдә, киресенчә, икенче тартым кушымчасы ялганып килү очраклары бар: *сет эстесе* – сөт өсте, *бидай ынысы* – бодай оны, *қайын утынысы* – каен утыны һ. б.

Өстәмә тартым кушымчасы *-ныкы/-неке* кушымчалы сүзләргә дә ялгана: *Безнекесе терек* – безнеке исән (песи турында).

Нократ сөйләшендә *-ныкы/-неке* кушымчасының тарихи яктан тулы булган варианты әле дә кулланыла, тик анда иялек килеш кушымчасының *ң* авазы урынына *н* әйтелә: *Безненкесе йоwалды* – безнеке югалды.

*-ныкы/-неке* кушымчасы урынына *-ның/-нең* кушымчалы форма кулланылу: *Йегерме бэшенче йылның мэн.* – Мин 25 нче елныкы (туганмын). *Ғәлийә белә без бер йылның.*

Мисаллардан күренгәнчә, икесе дә нисбәтлелекне белдерә торган формантларны алмаш куллану аеруча туган ел турында сөйләшкәндә күзәтелә.

Ияртүчесе фигыль булган сүзтезмәләрдә кайбер үзенчәлекләр бар, кайбер фигыльләр башка килешләрне башкаралар.

*Сагыну – уйлау* фигыле чыгыш килешен башкара: *Усал ийемнән дә сагынамин.* – Иске, начар өемне дә уйлыйм.

Аналитик төзелешле җөмләләр нократ сөйләшендә шактый актив күзәтелә. Мәсәлән: *Қайа қәтле барамин, анда илтэмэн* (капчыкны) – Кая кадәр бара алам, шунда хәтле (капчыкны да) илтәм. *Қая йебәрделәр, анда* (шунда) *бардым.*

Икеләнү, шөбһәләнүне белдерү өчен *бул* фигылен куллану: *Ни кей бешергән дә булыр.* – Берәр нәрсә пешергәндер. *Күз теште ақыры* (ахыры).

Сөйләштә бу мәгънәне белдерү өчен күбесенчә *-дыр/-дер* кушымчасы кулланыла.

## Нократ сөйләшенең лексик үзенчәлекләре

XX гасыр азагы һәм XXI гасыр башында лексикологик эзләнүләр өлкәсендә зур эшчәнлек күзәтелә. Татар теленең төп сүзлек

фонды формалашуын, татар лексикасын тематик һәм лексик-семантик, семасиологик, тарихи генетик аспектларда өйрәнү буенча шактый зур эш башкарылды. Лексикологик тикшеренүләрнең дә халыкларның килеп чыгышы, аларның матди һәм рухи мәдәниятенең формалашуы мәсьәләләрен өйрәнү өчен бай һәм ышанычлы материал булуы ачыкланды.

Нократ сөйләшенең лексикасын өйрәнү шулай ук бик әһәмиятле. Беренчедән, анда борынгы чорга бәйле сүзләр һәм формалар, Идел буе фин-угор халыклары белән уртак сүзләр яки формалар сакланып килә. Мәсәлән: *зорот* – зурат, *мутор* – матур, *Кузан* – Казан һ. б. Бу сүзләр удмурт һәм чуваш телләрендә дә шулай ук әйтеләләр.

Икенчедән: *бикэм, бикэчэм, җанагай* терминнары сакланып киләләр. *Бикэм* – иренең апасын, *бикэчэм* – иренең сеңлесен белдерәләр. Татар халкында бу ике туганга карата махсус атамалар кулланыла (*тута, апа; каенсеңел*). Күрәсең, нократлыларның бабалары күчеп киткәндә, туганлык атамалары системасы формалашып җитмәгән булса кирәк, ә яңа чолганышта (мәсәлән, удмуртларда) иренең олы һәм кече кыз туганнарын индивидуальләштерүнең башкарак закончалыклары яшәп килгән булырга мөмкин. Нәтиҗәдә, нократ сөйләшендә бу атамаларның формалашуы татар теленең бер сөйләшендә дә булмаган чара – грамматик күрсәткечләр (*-м, -чем* һ. б.) белән башкарылган.

Өченчедән, нократ сөйләшенә удмурт сүзләре үтеп кергән: *нурды/норды* – курпы, *мәжес* – тырма, *машталау* – печәнне өемнәргә салуның бер ысулы (тат. киштәләү), *кучак* – тәрәз төбе, *коркапрум* – өй түе, *пут/пыт* – алабута, *зәлҗә* – сыерчык, *козулы* – парлы, *җөпйукалау* – җыю һ. б.

Дүртенчедән, нократ сөйләшендә кайбер реалияләрне атау өчен җирле сүзләр ясалган: *ачкычбау* – әд. хәситә, *арапа* (гарәфә) *кен* – бәйрәм алды көне; *кизүлэмэгэ* – аш-су тирәсендә, йортта эшләү, *убраз* – тәре, *кучак тэмир* – тәрәзә тоткасы һ. б.

Бишенчедән, бер төркем сүзләрнең мәгънәләре семантик күчеш кичергән: *тастымал* – табын, *саламат* – оннан пешерелгән ботка, *бешем* – пешерелгән ризык, *йабыгу* – сагыну.

Нократ сөйләшенең лексикасы буенча бай материалны Ф. С. Баязитованың хезмәтләреннән һәм «Татар теленең зур диалектологик сүзлеген»нән табарга мөмкин.

Бу язмада сөйләшкә хас лексиканың кайбер тематик төркемнәренә аерым штрихлар гына тәкъдим ителә.

## Туганлык атамалары

Күп гасырлар элек, төп татар халкыннан аерылып, башка телләр чолганышында формалашкан сөйләш буларак, нократ сөйләшендә туганлык атамалары өлкәсендә дә үзенчәлекле күренешләр табыла.

Кан туганлык атамалары: *әнәй* – әни, *әтәй* – әти, *бабач* – бабай (*Галим бабач*), *аппақ* – әти яки әнинең өлкән кыз туганнары (*Камилә аппақ ийдә йоқ, Минсылу аппақ киткәндә*).

*Апа/тәтәй* – олы кыз туган, апа: *Ғәрифәттәй ийдәмү?*

*Әнинен удалаган* (сынаган, төпләнеп үсеп китсә, ирем сугыштан исән кайтыр дип юраган) *ыршысы*.

Әбине туып-үскән авыллары исеме белән аеру гадәткә кергән: Пайура әби, Иманай әби һ. б.

*Әтийемең әнисе арча* (удмурт телендә) *сийләшкәләгәннәр* (сөйләшә торган булганнар).

*абзый/апач* (абыи + -ч) *Сания аппак үлгәндә* (үлгән иде),

*тепчек* (бала),

*энем,*

*майбыр* – яратып эндәшү сүзе.

Гомуми туганлык нократ сөйләшендә түбәндәге сүзләр белән белдерелә:

*туған-қарындаш, туған, йәwер, нәсел-нәсәп* һ. б.: *Туган была* (белән) *туган күрешеп булмай. Нәсел-нәсәпне дә сырамапбез*;

*ағыч* < *ага + -ч* 1) бабайның яшьрәк ир туганы, 2) бабайга яратып эндәшү формасы;

*бертуған төгел, туганның ыланнары.*

Никах туганлыгы атамалары. Билгеле булганча, бу төркем атамалар кан туганлыгы атамалары нигезендә ясала. Тик алар никах туганлыгын гомуми рәвештә белдерә торган *каен* сүзе белән ачыкланып киләләр.

*Каен* компоненты күпчелек төрки телләргә хас, шул исәптән татар теле өчен дә. Әмма татар теленең урта диалектка керә торган күпчелек сөйләшләрендә никах туганлыгын белдерә торган гомуми төшенчә ролендә *би/бий* компоненты кулланыла (*бийанай, бийатай* һ. б.), ә *каен* атамасы соңрак, йомышлы татарлар теле (алар, нигездә, мишәрләрдән торган) һәм әдәби тел йогынтысы белән кергән. Нократ сөйләше дә шушы *бий*-системага караган.

Әлеге система, нигездә, Идел–Урал төбәгендә таралган төркиләр – татар һәм башкорт теленә хас, чуваш телендә исә *би* системага хас кайбер атамалар (мәсәлән, И. Золотницкий сүзлегендә) булган булса кирәк, әмма хәзерге чуваш сүзлекләрендә алар күзәтелми («Чувашча-русча сүзлек»). Күрәсең, туганлык атамаларына хас тотрыклылык сыйфаты кыпчаклар өчен характерлы булган *каен* системасының сакланып калуына китергән.

*Ани/ан’и* – иренең олы ир туганының хатыны.

*Бикэм* – иренең апасы, *бикэч/бикэчэй* – иренең сеңлесе.

*Бийағай* – иренең абыйсы.

*Қайынанай* – хатынының әнисе.

*Кийәү/кийөү* – кияү, *балдыз* – хатынның сеңлесе: *Қатыны үлгәчтен балдыз алган.*

*Ир/эр кеше* – ире; *апа* – иренең апасы.

*Зур җиңги* – берничә җиңги булганда, иң олысына эндәшү сүзе.

*Әби, бабай* – әд. (хатынының әнисе һәм этисе).

Кешене сурәтли/тасвирлый торган сүзләр: *арық* – ябык, *арығайу* – ябыгу, *ноғыт үсү* – зур гәүдәле булып үсү; *башы киту* – акылга зәгыйфьләнү (*уқымышлы кеше иде, саңыннан башы китте*), *нуғай* – акылы җитмәү, томана (*Без кебек нугайларга инде йарай*), *тотык* – зәхмәт һ. б.

Соматизмнар: *айақың ырчығы* – шайтан сөяге. Чагыштыр: шушы ук сүз пермь, норлат сөйләшләре өчен характерлы. Соматизмнарның зур күпчелеге Казан арты сөйләшләре белән бертөсле.

Кешене тасвирлау: *күзсез* – сукыр, *кылакай* – чукрак, *төп күзсез* – тома сукыр. *Төп күзсез иде тумыштан. Пәнбәмөт, айаклары кәкре иде, күзе дә сыңар иде.*

*Қычытқаннау* – бүре уы (кычыткан бизгәге) белән авыру.

Йорт һәм җиһазларны белдерә торган лексика составында, төрки сүзләрдән тыш, рус һәм удмурт алынмалары да күзәтелә.

Татар сүзләре: *сирик* – почмак, *чүмпич* – тимер пич (*чүмпич ийдә йана, йылы*), *йугаргылы-түбәнгеле ий* (чагыштыр: калмак сөйләшендә дә шулай ук), *пәтери* – чорма, *сарай* – өйалды, *чулун* – чолан, *ий утырту* – өй салу, *урын-әйләнә* – урын-җир, *чүмәлә* – гөнҗәлә, *қарлан* – көянтә.

Рус алынмалары: *булат* – сәндерә (Булатқа мендем дә йаттым), *бырыс* – матча, *пут* – мич төбе, *әwен ий* – әвен, *гүлмич* – идән асты.

Удмурт сүзләре: *қучақ* – тәрәзә (*Ғалим бабач әнде, ийе қаранғы, кучагы андый гына*), *пүкән* – урындык, *чидун* – утлык, *мушко* – аркага асып йөри торган, үрелгән әрҗә сыман корзина һ. б.

Рухи мәдәният белән бәйле сүзләр: *ыйалу* – тел яшерү (*Кешегә кеүренмэйбез, ыйалабыз*), *аулак утырма* – аулагыйда җыелып утыру, *аулағаш* – аулагыйда пешерелгән ризык; *Сабанту* – Сабан туе, *сабан чабышы* – Сабан туйда ат чабышы; *қорбан чалу*; *коркапрум* – өй туе һ. б.

Аш-су белән бәйле сүзләр бай гына төркемне тәшкил итәләр. Алар арасында йола ризыклары исемнәрен аерып күрсәтергә мөмкин: *киймак* – майлы табада, уртасын тишек итеп пешерелгән камыр ашы, *чепчиги* – чәкчәк, *тәбәгый* – кексны хәтерләткән, табада пешерелгән камыр ашы; *эч чэрекле қабарчы* – өчпочмаклы формада пешерелгән кош теле.

Көндәлек ашлардан нократ якларында иң беренче *шанги*ны атыйлар, *беккән, пирашкилар* һ. б.; *пилмин тату* – пилмән ясау, *йумалдан* – төчегә; *үрә, пүрә* – ярмалы аш.

Кием-салым атамалары: *казаки йақа/качтум йақа* – костюмныкы рәвешле яка, *чэтек* – читек, *калфақ* – бәйләгән башлык, *изү* – муенга тага, күкрәккә киелә торган, тәңкәле бизәнү әйберсе, *мичақ* – муенса (*Гәрәбә мичақларым эч баш*), *йезек, тәңкәле йезек* – йөзек, *белэзэк* – беләзек; *чулпыны чәчүргечкә салалар, акытны* (ахакны) *салалар* (куялар) *иде мичаққа* (муенсага).

Мифик җан төрләре: *өй әби, абзар әби, мича әби* һ. б. – йорт иясе. *Сүwәсе* – су анасы, *абзар байы* – абзар иясе.

Үсемлекләр. *Чыпчық йапрақ* – бака яфрагы (подорожник), *қычытқан, қучқалақ/кузқылақ/қусқылақ* – кузгалак, *пут/пат* – алабутаның бер төре, *кәзәсақал* – кәҗә сакалы, пастернак (*кәзәсақал ул, тигезмәгез, аwыз чэтегез бызыла*); *әче қақы, йөннө күшә* – йонлы күшә (*йоннө күшә, тебендә андый мол'о* (бәрәңгесе бар); *ак билчән/белчән, қара белчән/билчән; чимә* – көнбагыш, *кадаwыч* – энә (гөлҗимештә), *қушман* – ачы торма (шулай ук норлат сөйләшендә дә); *йиралма* – бәрәңге, *йералма геле* – юкә гөле; *чимә май* – көнбагыш мае; *пешник* < *пестик* – нарат үләне (хвощ полевой) һ. б.

*Боро* – виктория җиләге, *қамыр* – боярышник, *шаған ағач йеләк* – гөлҗимеш (җимеше), *чық су* – таң суы.

Хайваннар дөньясы: *зәлқә* – сыерчык, *қорбет* – урман бете (клещ), *куᵒскук* – озынборын (комар).

## НОКРАТ СӨЙЛӘШЕННӘН МАТЕРИАЛЛАР

### Авыллар тарихыннан

Меᵉрсәлим бабай Каринодан (*ав. ис.*) килеп утырған. Метиковмы булған. Амиров Қазандан килгән. Тайып Абашев Палагадан (*ав. ис.*) диләр иде. Мерсәлим сартын (*турында*) сүләп бирер барсағыз. Сәксән йәш булды, башы китә (*акылы җиңеләя*) диде аның. Мулла йуғ (*түгел*) иде, ну уқымышлы кеше иде.

Иманай, бик карт бабай. Шәфи исемне бабай қой күздән (*кое авызыннан*) тартыб алған. Әтийемең әнисе арча (*удмурт телендә*) сийләшкәләгәннәр (*сөйләшә торган булганнар*). Палагайда башта йалгыз абый тырған. Йыртнын урыннары қалғанда әле. Пал удмурт дигән сүз, ағай – абый. Чишмә күз булганда, нарат чишмәсе, нарат астында чишмә күз. Шымырт, миләш анда күб ускәндә. Хәмидә аппақның ике туғаннары бар Қазанда.

*Сөйләүче: Абашева Рәхилә Идрис кызы, 1927 елгы.*
*Юкамен районы Палагай авылы*

### Кушаматлар

Каку, Шикәр, Парҗы, Кара, Туркет, Пиғамбәр, Чайан, Дуwэт, Эдак, Хазяин, Сәрмән, Чорт, Җәләл Апай, Кусоп, Кәкре һ.б.

*Әйтеп яздыручы: Касыймова Гөлҗамал*
*Фаткулла кызы, 1940 елгы. Балезино районы Паюра авылы*

### Тормыш-көнкүреш

– Үләм шәй (*ахры*) инде, ди әнки.

– Wақытмы йитте инде сиңа?

– Йалғыз каласин.

– Элек чақта кич-иртә дә йырттагы эшкә йарый иде. Андан-мындан ғына эшләсә дә булыша иде. Печәнгә барам, без кебекләргә чалгы инде, кеше йалласан кешеги түләси була ич.

*Сөйләүче: Абашева Рәхилә Идрис кызы, 1927 елгы.*
*Юкамен районы Палагай авылы*

Бэшекти үскэндэ безен малайлар. Дүрт ағачқа кэндэр қуйған да бэшэк булғанда. Балаға сусук (*имезлек*) бэрэдек мәрләгә әпәй салалар. Бер қулда бәбәйненке арқаны (бавы), бер қулда мажиш (*тырма*), пэчин ийарға қор төпкә кэтэбез. Дастышал (*яулык*) да йуғ иде башымға. Бэшеккә йә қайчы, йә пычақ сала идек. Күз тисә,

дастымаллар (*чүпрәкләр, тузган әйберләр*) тетемлән (*яндырып*) тетәсли иделәр. Әм (*им*) булсын, әм булсын, күз тешкән бетсен-китсен, башқа йыламасын, дип.

Арпаны да әмләйләр, арпа бетсен, қыйаш чықсын, әм-әм, арпа булшы чыкмасын, дип.

Мийа күземә йылан қарақ булды, күршедә имни тырған әби бар ийе, әмнәде дә бетте. Аны йә йыланнын қабығы белән өшкерәләр.

Бүсер булса, ақри-пақри, қырық ағачнын тамыры қырый, бетсен-китсен, дип имләйләр.

*Сөйләүче: Касыймова Наилә Лотфулла кызы, 1934 елгы.*
*Балезино районы Кистем авылы*

**Печән җыйганда**

Инағ-инақ (*җыйнак итеп*) эйеп қалдыралар, сыңра астыға тайақ тығып атнын делбэгэсе белэн эләктереп алып баралар. Йукалап (*җыеп*) баралар чүмэлэгэ.

Зурутқа (*зуратка*) печэн биреп беллэрем қалмады. Тушыпбез инде дэ аларны белмэйми? Машталай (*тырмалый*) идек мажиш (*тырма*) белә. Кэпсэ ки (*кипсә*) ала идек. Арқылы ағачқа чүмәлә печин тутырабыз, зурутқа ийәбез печэнни. Нурды (*удм. курпы*) чапмаға барабыз.

*Сөйләүче: Касыймова Әкълимә Гыймран кызы. 1933 елгы.*
*Балезино районы Кистем авылы*

**Өмәләр**

Нэрсэ эше бар, эшлэйлэр, чәамэга пешерәләр ондан, сэгез чирек арақы чыға.

Ий қуйма йәбештеләр, фундамит йасағанда, бырыс (*матча*) китергәндә. Дүрт чирегенә (*почмагына*) уқый уқыма белгән кеше. Бемэ йасайлар иде. Ийгэ кергэндә тибикмэк ашата идек ыланнарға, мандырып, зур табаға май салалар да, дабын (*табын*) ашасын.

Йабу бемә дә бар иде.

*Сөйләүче: Габитова Әдия.*
*Балезино районы Кистем авылы*

**Туйлар**

Қозынны биресенме безен малайға, дип сүләшкәндә. Сүзләре килешкәнчә инде ийдәге әбиләр, бабалары хабар итәләр. Селгеләр, ниләр бүләк итәләр (килешкәч).

Кәбен салгач куймақ, беккән, тәбәғыйлар пешерәләр.

*Сөйләүче: Абашева Рәхилә Идрис кызы, 1927 елгы.*
*Юкамен районы Палагай авылы*

Кийәүгә чыкканда бер кенне кереттеләр, бәләкәй (*мендәр*) салып кереттеләр, чәй қайнатып. Бийатам да, бийемем дә йәшел печинне йәйеп кереттеләр. Тупсаны атлағанда, бачқычны менгәндә сарайға тек печэн, топсасын басасын микән, бәләкәй салалар. Әйдәгез, текле айақларығыз белин, дип әйтә. Бал да, май да қаптыралар. Апкереп қа̄ ки урнаштық. Кэч кәбен салдылар мулланы чақырып. Кизүлеймен дә (*аш-су әзерлим*). Кәбен салғанда пич арада тик тырдым. Эстемгә ал’апқыч та, йаулық та салдым. Әтәй ыриза булмай тырғандыр. Әле кейем китэрэлэр иде туйлар узғач. Қашығалар, тартулар (*бүләкләр*) қарындашыңа айырасың (*бүләсең*) инде селгеләр. Ни ки бирдемдер инде, йанйаулыкмы (*кулъяулыкмы*).

Бийатайдан ыйалып йердек, йегерме йыл тырдым, бийем белән утыз йыл тырдым. Иңгәйнең (*җиңгинең*) бәбәйен бақтым. Ий (*өй*) урын бэреп чығарды бийатам. Шанги (*пәрәмәч*), кабарчы (*кош теле*), беккэн, тәбәкмәк (*табада пешкән затлы камыр ашы*) бешереп, бесмела белән суйған эт бешерделәр. Безди башта чәй эчәләр, анан ары аш қуйалар.

Безди ычысын (*өчесен*), йедесен, қырығын, элле берен, йыл тәүлекне итәләр, хот’ ничэ йыл ит!

*Сөйләүче: Касыймова Зөләйха Хафиз кызы, 1934 елгы.*
*Балезино районы Кистем авылы*

Йаңғызым идем. Шәкерт бийағайлар алмаға тештеләр. Шундан қыда йасадық йақ-йақта (*кызны килешкәч, якын туганнар җыелып ясала торган кечкенә мәҗлес, ике якта да була*). Зоры туй була. Печән йәйеп, байыңа (*иреңә*) тотолоноп керттелэр. Тырыға ийебез йуғ иде. Әби, бабамға қайтып керепбез. Бер сөрэк (*чүпрәк*) бэрделэр. Бийем кеше әйдәгез, әйдәгез, диде, эстил әзер инде. Ул (*шул*) кеннүк (*көнне үк*) кәбен салдырдық (*никах укыттык*).

Башта парлыны кертәбез, аш-су кизүләйлэр. Андан симйәне, хуҗаны чақырабыз. Мулла укый. Балдан чепчиги (*чәкчәк*), қыймақ (*клиндер рәвешле камыр ашы*) майда пешкән, қабарчи (*чәй*

*токмачы*) күкәйләр мелэ була. Шанги упши аш ул, алдан шангины, сыңра беккенне пешерәсин кишырмы белэн.

*Сөйләүче: Касыймова Гөлҗамал Фаткулла кызы, 1942 елгы. Балезино районы Паюра авылы*

**Йолалар**

Исем саласы (*кушасы*) ич малайга (*балага*), Нигматулла булган.

Үлгәч әйбатлап инаклап күмәбез. Хайырлы сагат булсын, ранжымагыз.

Армийга киткәндә ын тыткаларсын инде, исән-сау кайтсын инде, дисен, ынны бырар аби кешегә бирасын, хайыр булсын, дисен.

*Сөйләүче: Балтачева Таһира Нигъмәтҗан кызы, 1933 елгы. Юкамен районы Дасис (Засеково) авылы*

Киленне ишектән кертәләр дә битен йудырталар, суын гелбәчкә түктерәләр.

*Сөйләүче: Абашева Миңсара Камалетдин кызы, 1930 елгы. Юкамен районы Палагай авылы*

Абзар әбиләргә, дип, йыл сыйын йасин уқыта идек.

Эч малай заттық салдатқа. Ынға йабышып (*берәр җиргә киткәндә кулны онга тыгу, исән-сау әйләнеп кайтсын дип*) салдатқа китәргә чыққанда. Исэн бырылып қайтты да йәшләр йукаланалар (*җыелалар; удмурт сүзе*). Эчең әчеткән (*пошкан*) сайын ни ки (*нәрсә дә булса*) йырлайсын ул. Бийешеп, дырлап (*җырлап*) йерүләр бар ийе.

Миңнәре булғачын, Гелчирә иде, Миңнежамал дип салғаннар.

*Сөйләүче: Әхмәтҗанова Мәдинә. Балезино районы Кистем авылы*

**Сабан туе**

Сабан чабу, дибез, ат чабышы. Сабан чабу, сабан йегерү, керәш була, кәнсирт салалар, шистка да менэлэр.

Аулагый булгалады, йырлашалар.

Бизәнү әйберләре, кием-салым.

Чулпы булғанда. Мычақ (*муенса*) муйныбызға салы йердек. Ақыты (*ахагы*) ай (*ай рәвешле*) була, уртасында. Без алты баш (*кеше*) идек, үстек, арттан-арттан (*бер-бер артлы*) үлделәр.

Айагыма кима (*киярга*) бырнарса да йук. Ылыкы чабата булган. Айакка куты (*коты*) кигән, туз айак кийымы ул.

Килем ырлыгыннан байрамда бышырганнар. Килемне талкыда теwәләр, ашаулык, чаршау, чыбылдык, урын әйләгәннәр. Wak-wak ситчыларны теккалайлар мутор (*матур*) булсын дип. Зийаклар тегалар, йефәк былган ул. Киндернеке потнор (*озын кунычлы оекбаш*) кигаладылар, нуски кыбык. Кымнын кочо (*кемнең көче*) ничек йита.

Кашамбир йаулык, зур шал’, йефәк шал’. Кашпу, әл дә аны арлар кигаладылар. Касита кигаладылар алга, танкалар была. Мәрҗәм түмә бусир (*бисер*), кызыл. Маржам (*мәрҗән*) акут (*ахак*) бар, аниемен (*әниемнең*) дә бар иде.

*Сөйләүче: Балтачева Таһира Нигъмәтҗан кызы, 1933 елгы.*
*Юкамен районы Дасис (Засеково) авылы*

Әнием киндер суққалады, күлмәкләр. алйәпкечләр теккәләгәндә. Күлмәк буй (*кыса*) була, итәген йалғап тегәләр. Балайтәкле күлмәкләрем бар, менә элгече. Чабата үрү былған, бабач бар иде, мутор үргәләгәндә (*үрә иде*).

Нуски, бийәләй кигәләделәр, беләзеген мутор бәйләйләр, ыйыкнын күнәче (*кунычы*) мынан тын. Чабата, килемдән суққан ыштыр, айақ башқа чырмай.

Сарық тирене иләрләр иде әчетеп, тиредән ыйық кебек тегәрләр иде.

*Сөйләүче: Абашева Рәхилә Идрис кызы. 1927 елгы.*
*Юкамен районы Палагай авылы*

Йетендән эсте кийем йасайлар иды. Килемне йәйеп киптерәләр, теwәләр, йегерләйләр қабада, ырчық белә экы (*ике*) қатлығ итәбез.

Кәбен салғанда кәбен кийем китэрэлэр.

Чабата кийәбез. Йүкэне йыртып алалар, чиктан (*шөшле*) белә керетеп-керетеп үрәбез. Бичерман чабата була. Ыштыр киндердин чылғыйбыз, арканнары (*киндерәсе*) эшкэн була, табанына печэн саласин. Айаққа дағын ийықбаш, кийез ката, кизитек, киндер ийек (*оек*), чүчинкә, кез кенне кулош кигәндә.

Башқа йаулық бәйләгәндә, мамық шәл, кәшәмир йаулықлар була иды, бәйләгән шарыф салалар.

Балайтәкле күлми’лэр, әнәй тегешеп тыра иде, эчки күлми’лэр, йықлай тырған кулми’лэр.

*Сөйләүче: Касыймова Наилә Лотфулла кызы. 1934 елгы.*
*Балезино районы Кистем авылы*

Чулпы мийә бийем бәрде, бер пара, парасы белән. Сырғам бар парасы белән. Белэзек, йезек бар иде, тәңкәле йезегем. Қәситә булғылаған шай, без ғемердә йуғ иде.

*Сөйләүче: Бузикова Таифа Гайнан кызы, 1929 елгы.*
*Глазов районы Татар Парҗысы авылы*

## Аш-су

Кыймак, күзикмәк була, кабарчы (*кош теле, чәй токмачы*), кыймак wак-wак. Зур-зур ипи күмәч салыр иде әни. Пирәмәч ачы қамырдан була, эстегә йералма бытка йаққалағанда. Табагый анын зур булгалады. Чепчәгине Паюра, Әхмәди аwылларында да әйтәләр. Кот’ (< рус. *хоть*) ней да пышерми (< пешермә – *пешерергә*) була.

Безди дә пилмин тыталар, аш шулпа йасыйлар йарма булса, йармалы аш. Балиш, кул’аш – итле бәрәңге, быккан (әд. *бөккән*), кал’агалы беккән – эченә шалкан тыгып пешергән бөккән.

Безди кушман (*ачы торма*) субырнысы (*төнәтмә*) булган.

*Сөйләүчеләр:*
*Балтачева Зөһрә Гыйлемдар кызы, 1950 елгы;*
*Балтачева Таһира Нигъмәтҗан кызы, 1933 елгы.*
*Юкамен районы Дасис (Засеково) авылы*

Қыймақны табада пич алнында апарадан гына әчетеп пешерәсин.

Изә идек тә, пичне тартқачтын ташка (*кисәү агачы*) белән, тәбәгине пешерә идек қабартып.

Сыра йасағанда чүпрә, песук кирэк, бузаны урыслар, квас, диләр.

Буткаларны пыруса (*тары*) белән бешерәләр. Бездә тәбикмәк пешерәбез, май белн майлап тәмне була. Сыңра белен йасайлар иде, шанги йиралма бели. Беккән ит бели бәрәңгедән, гүләш тә ит бели йиралмадан, бәлеш тә барыбер йиралма белэн, эт белэн.

Бәлеш йапқычын, бәлешненке қабықларын йарата иде әнәйем.

Тәптәне (*черек бәрәңге күмәчен*) дә элке тәмне диб ашағанда (*ашадык*).

*Сөйләүче: Касыймова Наилә Лотфулла кызы, 1934 елгы.*
*Балезино районы Кистем авылы*

## Солдатка озату

Сабий чақта бер теш кұрдем,
Йәшел картуз башымда,
Шул тешләрем раска килде,
Унсигезенче йәшемдә.

Әнки, ашың бешәр булса,
Балаларың җыйылыр;
Бар да булып, мин булмасам,
Күзеңдин йәш қыйылыр.

Элек йырлап зата идек. Эртә затабызлар. Солдатка китүче иптәшләре белән күпергә тешәбез. Чепса аға. Шунда селге муйнысына салалар. Маратка тужы селге салып йебәрдем, ийгә қалдырабыз, кем ақча бири, кем селге бири. Булышалар, сәдәқа утыртабыз эстилгэ, алар учлайлар аны. Бер бабач, алар киткәчен уқыйлар. Йеде йасин да уқытабыз, қайтсын, дип. Тәтәсе (*апасы*) ағач астына қалыб үлде.

Йер хуҗаларына, абзар хуҗаларына дип, тәсбих тартам.

Тешлек салдырып бэрдем, мин үзем ишанамын. Баш кастасы белән үлгэннэр элке.

*Сөйләүче: Касыймова Гөлҗамал Фаткулла кызы, 1940 елгы.*
*Балезино районы Паюра авылы*

## Яңгыр боткасы

Қыйаш чык, қыйаш чық!
Майлы батқа қазанда,
Сетле кәҗә абзарда.

*Әйтеп яздырды: Касыймов Рәиф Хәнәфи улы, 1962 елгы.*
*Балезино районы Әхмәди авылы*

Кырбан чалу була иды йаз кене май айында. Инешкә тешеп, бытка бешереп, кешегә айырыб ашатайбыз. Қорбанны йаз көн, йаңгырлар булсын, дип. Сарығ алалар, ашын пешерәләр. Май түгәләр иде, йәй әйбәт булсын, дип. Сийыр май беле ашаталар иде бытканы. Кем нәзер әйтсә, әбиләрне китереп уқыта инде, аwыртуларым бетсен, дип. Кез кен каз чалалар иде, корга чыгаралар иде. Корбан чалуның урыны бар, шыршы йанда. Анда ук бешереп ашайлар иде, ысписиал’ный. Анда зур нарат үсә әл дә, Түбән аwылда.

*Сөйләүче: Тютина (Бийанова) Әлфия Галимулла кызы.*
*Балезино районы Уръякала авылы*

## Уеннар

Күпергә тешэ идек, кыруғ уйнай идек үтә (*бик*).

Басару, басару
Басар эчен килгән у

Утырышалар иде. Таш йуғатыб уйнайлар. Пилминнэр тыта (*пилмән ясый*) идек, кем эт (*ит*) кэтерэ, кем ын.

Қулымдагы йезегемнен
Исемнәре Гөлтуташ.
Гөл булсақ айырылмас идек
Гөл тамырлары тоташ.

Кем таптаса, шулар йусын,
Кылубның эзәннәрен;
Былбыл қышларға ышасын,
Миндән қалған йәрләрең.

Урманда утын чапқанда,
Балтам йуғалса иде.
Балталарым йуғалғанчы,
Башым йуғалса иде.
Алай да үтә ғомерләр,
Былай да үтә гомерләр.
Қычқырып йырлап җибәрсәң,
Күтэрели кеңелләр.

Қатмалда исемә дә тешмәй ич, үтә йырлаймин.

*Җырлап күрсәтүче: Касыймова Гөлҗамал Фаткулла кызы, 1942 елгы.*
*Балезино районы Паюра авылы*

## Бәеттән өзек

Бәхетле бала
Ийләрдә кала.
Бер бәхетсезе
Китеп йуғала.

Аккошлар очар, мамығы тузар,
Аның мамыгын кем генә җыйар.

## Мифик җан ияләре турында

Анан тын йермәгез, су әбиләре (*су анасы*) қырқытмасыннар, дип әйтәләр иде.

Абзар әби күренмәй ич, ди.

Абзар бай йаратмаған, диләр.

Абзар әби йаратмаса йынын утай. – *Абзар иясе яратмаса* (*терлекнең*) *йонын йолка.*

Сушәсе (*су иясе*) әдәмне дә тарта суға. Чупа бабай (*Чулпан ата*) сарықларның хуҗасы, Селәйман казларның, Зәңки бабай – ынтып мин.

*Сөйләүче: Бузикова Таифә Гайнан кызы, 1929 елгы.*
*Глазов районы Татар Парҗысы авылы*

## Ышанулар

Ылыкылар (*элеккеләр*) белгән, үзенен теле бар ич аларнын, арпанын, бизгәкнен. Анын үзенен теле бар. Кызамук белә чирләде, бер телен белгән абины кэтерделәр дә бик килеште.

*Сөйләүче: Балтачева Таһира Нигъмәтҗан кызы. 1933 елгы.*
*Юкамен районы Дасис (Засеково) авылы*

Абзар әби күренмәй ич ул.

Йаман эрәнҗеп (*авырып*) тырамын, күз белән эрәнҗимен. Өшкергәләделәр. Ылык (*элек*) чакта әнийем йанына килгәләй иделәр, башны үлчәгәләделәр. Алай (*шулай*) йерәсе исә, минең бер дә баш ақыл йуқ (*башым эшләми, зиһенем юк*).

*Сөйләүче: Абашева Рәхилә Идрис кызы, 1927 елгы.*
*Юкамен районы Палагай авылы*

Абзар бай (*иясе*) йаратмаған, диләр. Бала аwыртса, қарт керәшен әбине чакыра идек.

Ипине, пумаланы гелбәчтән алып чығалар, әйдә безнен белә бергә, үпкәләшеп қалма, диләр базар байына.

Мунча әби, мунча бабай була. Кергәндә мунчага сүләшеп керәсе, куркытырсыз, диләр. Сәдәка биргәннәр.

Бала китермә (*тудырырга*) әбиләр килә. Хайwан тудырғанда да мулланы китерәләр иде.

Кемгә баш акылын бирә, кемгә эт акылын бирә.

Йәшеннәп йаңгыр йауганда ак шыршы астына кергәннәр. Бисмилла әйтеп култыг астыгызны сыйпаштырыгыз, дигәндә әбиләр.

Абзар әби, өй әби бар. Сийырыбызны абзар әби йаратмаган. Миллек йасамайык, сатма бардык, алмадылар. Мича әбине дә сийлиләр, бисмилланы әйтеп кер, дип.

*Сөйләүче: Абашева Миңсара Камалетдин кызы, 1930 елгы.*
*Юкамен районы Палагай авылы*

Арпа чыккан күземэ. Әбиләр имнәйләр: им булсын, ийем булсын, ай да қайта, йыл да қайта, ай да қайтсын, йыл да қайтсын, бетсен, китсен, дип.

*Сөйләүче: Бузикова Таифа Гайнан кызы, 1929 елгы.*
*Глазов районы Татар Парҗысы авылы*

### Шушма җыры

Утырдым киймәнең түренә,
Қарадым суның тебенә;
Қарамадым суның йезенә
Суларның йезендә ич қара йуқ,
Алла йазган эшкә чара йуқ.

Ат баралмый йул пычрак булгач,
Чыдап булмый йәш йерәк йангач.

Ақ қайыннар ақ булса да,
Ата йәшел йафырақ.
Башқайларым йәш булғач,
Күрә қайғы хәсерәт.

Сажидәнең ал җаулығы,
Қаш эстендә күләгә;
Җилкә эстендә күләгә.
Мында уйнаған мында калсын,
Ийеңә қайтқач сүләмә.

Сызғыр, йегет, сызғыр, йегет,
Атларым эчә тырсын;
Үзем күреп сүләшкәнче,
Қатларым бара тырсын.

Без әнкәйдин туғыз тудық,
Туғызыбыз да таралдык;
Тугыз балалар эчендә
Бер без бәқытсыз булдық.

Без андай малай түгел,
Без мындай малай түгел;
Кайа барсак та ки сийышабыз,
Күпчәргән (*күгәргән*) калай түгел.

Агыйделгә басма салдым,
Басмагыз, бегелмәсен;
Исегезгә тешермәдем,
Үзәгем эзелмәсен.

*Җырлап күрсәтүче: Касыймова Наилә Лотфулла кызы, 1934 елгы.*
*Балезино районы Кистем авылы*

**Тормыш-көнкүреш.** Гүрйә қалада нуқратлар Туқтамыш қанға бой биргәннәр. Аннан аларға Чипса буйларын биргәннәр.

Әwәле ачқыч бау (*хәситә*) қамыт кебек кийеп, тәңкәләр тағып. Бәрхәт камзул уқалар белән йасағанны, эзүләрен. Қалпақлар терле-терле: кукушкасы түбәтәй кебегрәк, энҗеләр белән чиккән, йассы. Алдылық була, эзү дә диләр. Алдылық дип күкерәкне дә әйткәннәр, алдылықта тәңкәләр дә була, уқа белән чиккән. Терледән-терле доғалар теккән бетү була.

Қарчыға килгән киртәгә,
Қанатларын йәйгән китиргә;
Бер йырлаймин, бер йылаймин,
Ич белмимен нихәл итиргәй.

Аwадан ичқан аққошның
Аwызындин тама балаwыз;
Безнең өчен кемнәр йылар,
Булса иде үз анайыбыз.

Күгәрчен күкәй салмасын,
Бала да чығармасын.
Эризығың чәчелсә дә
Туфрағың алынмасын.

Селге биргәндә акча салалар патнусқа, йегерме сум салалар бер селгегә. Сурама кәлгәндә башқа йелән йабып тырасын. Алдым-

бирдем шушы булсын, wәгъдә бүләк шул булсын, дип бирэ селгене. Баш ақчасын бирэлэр йегет йақтан, қызны саттың була энде. Йыртысла (*йорт сырасы*) утыртып, қабарчы пешереп, бутқа бутап қунақ итэсин. Белемгә йергелэгэннэр йәш йегетлэр, кийөү йегетлэр. Атларға терле селгеләр асып, кулкуллар тағып қызға баралар, затып баручының йыртына белемгэ керэлэр. Тигэн қәрендәшләрең затып бара қызны күмә белин абысталар, йеңгэлэр. Атайлар да тағын элтереп кэтэләр, табикмәкләр кисэлэр. Кэлен кеше қыймақ элтэ, бал, май, кийөү йағындағыларға. Бикэчәлэрем (*каенсеңелләрем*) бар элекке иремнең биг әйбәтләр. Абзыйларыннан қалдық ылан да йуқ, алай да йараталар. Йәштин үк дустымнар идек, дустым булып йәшәдек. Энде қартайдық, зур қартайғас чәчләр дә картайа икэн.

**Туганлык атамалары**. Абыз йеңги, дип, олы киленгә кечерәкләр әйтәләр. Анйам бар иде минем Эләсил (< Ильяс иле – Каригино авылының бер өлеше) дигэн тышта. Анамның абзыйының қатынын анйам дигэлэдем, ә ул абзыйым мина бабача тийә. Әтинең абзыйы – бабача, энесе – абзый, апасы – апай, апасының ире – бабача, әтинең сеңлесе – абыс-тасы дигэн сүз, анынқы эре – йезни. Әнинең абзыйы – бабач, бабачнынқы қатыны – анйа дибез. Эрененке абзыйы мулла бийағай, қатынына абыз йеңги дигэлэдек. Ир кешемненке энесе булса, мулла җанағай, қатыны – кэлен. Ир кешемненке апасы туғаным абыстай, бикэм дилэр (*эндәшкәндә*), ире – мулла бийағай, сеңлесе – туғаным. Қайнананың, бездә бийанай ич, апасы – абыстай, йә абыз бикэ, ир кешесе – мулла бийағай.

*Сөйләүче: Касыймова Тәкмилә. Киров өлкәсе*
*Яңа Слобода районы Нукрат (Карино) авылы. 1979 ел*

## Өмәләр

Қаз биме (*өмә*) йасайлар инде, аны суйып, қазларны йума тешэ идек. Сыңра йегерли идек, аны дағын йума тешэ идек күперлэргэ. Йелле этеп кэптереп киндер суға идек. Қазны йуғачын урам әйләнә идек, ат беле йери идек. Күтәреп дегел, кушуфка булды, чана дегел. Йегетләр дә керә үзеңнең тигэн (*туган*). Тимәгэн кеше килмәй ич ул. Ботқа ашағач бийәйләр, йырлайлар. Қанатын кисеб алабыз. Кәләмен (*каурыен*) сызған кеше сыза, без йандырдық, безне рәнҗетмейләр иде эшлэтэп. Йоны да йетэрлек булды. Алла қазларны күп бирсен дип. Қәләм дибез, қоймақларны майлайбыз. Қанат белен эйдэн себерэбэз. Бу йыл қазларыбыз сийырға (*суярга*)

табылды аз. Йолықма йеңел булсын дип гурласыннан өрәләр дә бәйләп салайдек. Шар инде ул, аны шартлаталар бала-чағалар. Пуйон (*казның койрык астындагы май бизе өстенә үскән мамык*) өреп төрле-төрле буйауларға буйап сала идек, мамықланып матур булып тыра. Қайсы баланың күкрәгенә тегеп қуйа қабартып, буйап. Айақ кийеменә дә қуйабыз.

*Глазов районы Паюра авылы.*
*1990 ел*

## Ырымнар

Қурқылық қойалар. Қурғаш эретәсин, суға саласин. Нәрсәдән қурыққан, шул тэшэ: итме, этәсме. Йөрәк сабырчықлана. Кил қотым, кил қотым, энзе кебек тезелеп, йефәк кебек сузылып, дип әйтәсин. Алла мөсалли ғаләм мөқәммәди йағалә али мөқәммәт. Безнең қарчық анйыбыз бар иде, ул қойа иде. Аның эр кешесе Даут бабач.

Су салучысы, су ташучысы була, ул йуған суны бер ару йергә түгэлир. Аны бүләкләсе була, сат астыларға түгәбез. Ике күwәнтә китерэсин, бетмәй у, қала. Қалғаны мишалами нәрсәгә тотсаң да. Суның эсенә дастымал йабып нэ ки уқышып қайтасин, сүлэшмисин.

Күмгән чақта дусқаға салғач садақа бирэләр, дуска эстегә тастар йабалар, аны дүрт кеше тытып тырасы. Тәлил әйткәч ирләргә акча айыралар (*бүләләр*). Қөр'ән уқыған өчен дә айыралар.

Көзнөң көзө, мине чақыра. Тотыққа (*бозыкка*) ләктеме инде. Тотық дибез, тотылуға ләкте. Читкә кереп симәгез, ул тотық дийә иде әбкуй. Анда ташланған әйберләр була. Ә йулның уртасында бернэ дэ йуқ.

*Балезино районы Кистем авылы. 1993 ел*

Он тотмаға қайттым, дип, әни садақа күтир (*дога кыл*), дип қайтып китэ ул. Йулға чыққанда садақа күтирибез инде без, изге йулларға, дип. Он салабыз инде, ул аны тота энде йулға чыққанда, ул онны бер қарчыққа бирибез.

*Глазов районы Паюра авылы. 1990 ел*

## Туй турында

Башта қыз ий йақта булды туй, сыңра ыл йақта. Орлаған кебек кенә алып киттеләр. Қызым кэткэчен ылым җамағат алды. Қызға ийгә қырмаға, түшик, йурған, мәләкәй (*мендәр*) қәстәрлисең. Ылым тауфиқлы. Әни, җамағат аламин, син дә аwыртасин, диде. Киленне

кертәсин, печәнгә басқалап керә, йеңел айағы белән. Килэнне эшләмә аласин ич аны. Җиңгелеләр (*кыңгыраулар*) белән җырлашып җөрөйләр, беләбез инде, қыз урлағаннар, дип, қарарға чығабыз. Күремчеләр (*шаһит*) була инды қыз йақтан, йегет йақтан да. Имеш, печән кебек йәшәреп торсын, дип, печән сибеп кертәләр татарлар килэнне. Арларны белмәйем, алар мәләкәй салалар шай. Бал ширбәте эчерәләр дустығандан. Қыз ғына эчэ, төпле булсын, дип эчерэлэрдер инде, элекке инде бу, элекке. Намаз уқыталар. Намазлық өстендэ утырасың инде, beләсинме, йуқмы. Йыртқа чығу энде безнекенчә ийеңнән чыққач, бөтэн (*бүтән*) ийгә кергэч йыртқа чығу була. Қыз энде шаршау артында утыра кийәwe белән, сақлаб утыра. Алар почмақта утыралар. Йегетнең әтисе бара әйтергә, йанында бер кеше бара, қызығызны алдық, дип. Йаучы – алдын килеп йөрүче. Қызығызны сырама килдем, алай, алай (*шулай*) бирмисезме? Аталары әйтмә барғач, қызығызны керттег инде, дип, қызның әнисе сөлге бирә. Иртәгесен икенче көнне үк туйға баралар, әзерләнгәнме, йуқмы, эченче көнне йегет йаққа киләләр. Кийемнәрне китергэч, әйберләрне элгәч, ийне кыруғ эләләр иде әйберләр. Эстәлдә ашаулықлары була, қучаққа (*тәрәзәгә*) үзләре читсыдан теккәндә (*теккән*) була иде, үзләренә йоқларға чаршау эләләр. Йегет, йақтан туй беткәч өчөнчө көнне қодаға киләләр қартлар, йәшләрнең туйлары бетте инде, қартлар йерәй, таңда йегет йаққа киләләр. Бирнә дип бөтен туйчыларға әйбер биреп чығалар, этиләре-әниләре бирә қыз йақтан да, ыл йақтан да. Читчымы, йаулықмы, йақыннарына күлмикләр бирәләр. Қыз әнкәсе қодаға килгәндә белем пешереп китерәләр. Кийәүнең әңкәсе бәлиш пешереб илтә қамырға тотқан, кийәү белем дип әйтәбез. Йетез булсын дип кийәүгә белем илтәбез. Кийәү бүлэге алып бара кийү, кемгә бырушка, гырибинка, кемгә мичак (*муенса*) та, карандаш та бала-чағаға. Зурларға эстәл артында айыралар (*тараталар*). Килен (*алып килә*) ике мәләкәй (*мендәр*), зур йастық, йурған, палазы бармы дип сурыйлар иде, җә җәймәсе үзе суққаны. Эстәлгә иң беренче май тутыралар. Май ашағанда ақча саласың, румкылар салмыйлар (*куймыйлар*) эды. Зур таз (*поднос*) тотып килә иде дә, аңа бүләген сала. Киленгә була ул бүләге. Аннан эстәлгә чәй ашауларын тутыралар, пирушки, қабарчы (*кош теле*) зур итеп пешерәсең, сындырғалап ашайсин. Менә сиңа қода (*туй*).

*Сөйләүче: Энтентиева Нәгыймә.*
*Глазов районы Паюра авылы. 1990 ел*

Тырмышқа чықмас элек сеңелесе wафат булған. Мин апа әйттем бикэмне. Җиңги – тырмышқа чығып килгән килен чақлар (*кечкенә*) өчен җиңги, зурлар өчен килен. Уникенче җан булдым. Әтийем, әнкийем, мәрхүмәкәйләр, биг әйбәтләр иде. Әнә әнки ич инде ул бийем. Мулланур абый ир кешемнән (*иремнән*) зур ул. Ул башка тыра иде инде. Ул безгә көн алмаш килә иде. Нәwәл апаның әнисен абыстай әби әйткән мин, қарчығ иде инде, абыстай әби мин эчен. Киленнең кизүләп (*ашарга әзерләп*) җергәнен бик җаратамын, аның хатлек җирдән суын китерә, чиләге тулайым (*туп-тулы*), суы да түгелми. Утырта, тақта да, чүмеч тә тими. Мона мин балаларыма әйтәм, дым-дат (*дөбер-шатыр*) итмәгез, дим. Йаңыдан Зарттин мәрхүм, Гемәребез, җанағайлар (*иремнең энеләре*) былар. Уҗыларым (*иремнең сеңелләре*) Гөлҗиһан, Маһинур, эй аллам, барсы да мәрхүм. Мин Мулланур абый белән сийләшмәдем, ул эр кешемнән ылы кеше ич. Әтки белән дә сийләшмәдем. Үтә (*бер дә*) сүләшмәдем. Минем әнийем әбилек ийе, баланы кабул итә, соңғысын баламны әнийем кабул итте. Балаға чирлисен. Туа. Кендекне кисә, баланы ала да йуа. Чүпрәккә төрә, үземне қарый. Сыңғылығын ала, йуа, иске трапқаға төрә, чабатаға қуйды мәрхүмәкәй. Сыннан инде, бушағач, чабатаны йаңыдан тереп зират буйына, эченә түгел, қайда мәйетләрне күмәбез, күмә. Үземнекесе булмағас, белмим.

*Сөйдәүче: Фәрхениса әби Сабрекова, 1910 елгы.*
*Глазов районы Дасис авылы. 1990 ел*

Қилде ул, бабай, ди, Гөлбикәне сыраға килдем. Утын сапмағ илтәм. Бездә пис йағар инде ул. И ани қозды (*кызды*) ис, йуқ-бар нәрсә аңғар коз бирмә келәгән ди, этине туздыра ғына. Аларнын бернәрсәләре йуқ, бер өйләре генә, ди. Алай иде. Сигез таwықлары бар иде, берсен ниқағ ашқа салдылар. Без бит кич сийләшеп утырдық, бабай бирер, әби бик қызу, бирер микән. Мынын апасы чишмәдә кетеп тыра. Сындан сийләштек, алай ғына булмый ул кешенекен патхутын табасы була, кешенең әле қанатының астына ничек керәсе була. Әйдә, утын сапма дәшерсен. Үземне алып килде. Мында килдек. Әнки ашау алып килде, пирәмәчләр пешергән, беккән салған, чәйләр салған, мына былай чықыр, чәйләр әзер. Сығра, син, ди, килен бөген анда мунса йағарлар микән. Иртәгә без сине кертмәгә келибез. Йағарлар, дийәм. Йақтылар, мунса кердек әниләр, апалар белән. Чәчем йаман кодра (*бөдрә*). Вынучка да

миңға барған (*охшаган*), чәче кодра. Мин мунчадан қайтқан wақытта мында сарай тептә сийләшеб утыралар. Бу кийемен беләнме син барасин. Ыризалашмаға кердем өйгә, әни йоқламаған. Йә, әни, эти, ыриза булығыз, мин китэм, тыныч тырмышларыбыз булсын, дип. Йақшы тырма йазған булсын. Мындағы кебек үк ашау-эсү белән, мал белән тырсын, диб әйтеп теләк теләгез, дип әйтеп сықтым. Апам йылай, ул сирле иде, арқасына гурбун (*бөкре*) сыққанда иде, энем йылай, Мәймүнә килен дә йылай йаман, нисек тырмыш төзәрсен анда, диләр. Булыштылар, өй дә салдық, мунса йеткердек. Ике қозлар тырдылар маллар қарап. Мында килеп кердек, қаршы алдылар. Қомған тытқан, сөлге салған, битне йуwып кертәләр ис, алай безнең ғәдәт. Қапқадан кергән wақытта ун айақны атлап керәсе була. Кийэүдән алдарақ керергә тырышасы була. Анасы чықты алай, икебез дә битләребезне йуабыз, ул су қуйа безгә, сертендек, атлап кердек. Әңки әйтә, килен, килен, алда Ғаптелхақ узсын, син тырыбрақ тыр, ә мийа әйткәннәр иде инде, син алдынырақ кер, дип. Самаwырлар қайнаб утыра. Самуарыбыз өчәү, күмерле. Әле лампа белән сыра йағып утырдық, паласлар суққаладық, әле ике киләбем бар әле, бүрәнәгә затабыз, киндер суға торған ыстан бар. Чәй эчтек. Көн йақты булды. Ғаптелхақ мулла эчен барды. Әниләр менделәр, без пич йағып кизүләштек, ашлар пешергәләдек. Мулла килеп керде, никах салды (*укыды*). Нихак салған wақытта бер-қайда да бәйләгән қалмасын, бар да сүтелеп тыра. Пич йанына барып терәлдем. Чәчләремне сүтеп терәлеп тырам. Пич алды йақта алай тырамын. Ни дийэм, сийә келке, мулла бар ич, дийэм. Хәзер алай йуғ инде, ну никах салалар барыбер. Мулла бабай сырай, эриза булып алдыңмы, Сәлим кызы Гөлбикәне? Алдым. Сәлим қызы Гөлбикә, эриза булып бардыңмы Ғаптелхаққа? Бардым, дидем инде әкерен генә. Әни әрләй мине, эриза булып бардым, диден дип. Қыдағый, ырышма, ырышма алай, чит итмәм, йақшы тытармын, ди әнки. Горобы (*бөкресе*) бар инде анықы, суғышқа йерешмәде ул. Алтын балдақ кебек йегетләрем бар иде, суғышта қалдылар. Әнинен ике быратлары қалды. Безнең әнинен җиденче бала туды. Минем артыннан һаман йөри инде. Қайа син барма келәйсен, ди, әни әйтә, тырактыр эшләдем. Әти затына барсам тағы биш йыл тырасым бар. Алла қайсы йақшы, ансын бирсен. Онно тыталар (*онга кул тидерәләр*). Менә былай ипине селге белән тытқанда була. Ул ипине йә бер исә тешләтәләр, йә бер исә тытынып кереп китәләр. Туйда

да алай, килен белән кийәүгә ипи тешләтәләр. Қайа булса, киткәндә ын тыталар. Туй ике йақлы була. Баштуқ қыз эчен баралар, икенче көнне малайда. Анда туйға килгән кешеләр бар да килә туйға. Қоз йақтан бер иптәше була, дүртәү киләләр. Кем синең җан тартымлы иптәшең, аны алабыз бергә дип. Бийатай, бийем, диб әйттек. Элек мында ар, татар бергә булған, ар керәшеннәр киткән. Килен эчкә хәтле дә йөрөй, ике йыл дә йөрәй, эндәшмәй. Ике-өч йыл тырғач бийатаймы, бийемме алырға қуша. Йаулықны алғанда килennең башындан, йитте инде битенне ач, диләр, булса тәңкә бирә. Зурысы малайны тудырғанчы бер кем белән дә силәшмисен.

## Рухи дөнья, йолалар

Эштән қайттым, аwыртам тесле. Бәрәңгене төйгән, сөт өсте салып сыйықлаған, миңә әйтерләр иде алдан сиздермәгез, аwыр була, дип. Әни әбилек булып йергәләде, бала алып йергәлэде. Берсенеке гел баласы үлеп тырды, саттылар әнигә, әнинең балалары тырғанда, ә бу Мәтлүфәнең балалары үлгәндә. Мәғридә әбү бу баланы сиңгә бирмәгә келимен, ал инде, ал әтә, қоз, ике малай үлгәннәр инде. Алған әни. Хәмидә исеме қушқан, бала әнисе белән тырды.

Менә былай йилпуч була иде, Рәқиләнең баласы йаман йылағ иде, усал (*начар*) иде, начар (*зәгыйфь*) ғына туды ул. Аны йилпүскә салып ипи салған пискә өч қат төртеб алдылар, име-йомы шул булсын, дип, йылағы бетсен, дип, шайтан басқаны бетсен, дип. Мона йықлағанда эндәшмәгә дә булмый, аwыр була, эскә шайтан тешкән әйтәсен.

Аулаг өй дип, қунаққа барғач әниләр, қозлар киләләр, йегетләр дә киләләр, утырдылар сөйләшеп. Қоз йегерләүче була, қайсынын мунсаларда йегерләп йергәләделәр. Куптилка лампа белин күз бетереп утырғалағанбыз. Әле менә күптин йуғ ич.

Салқын чишмәләргә барып
Атлар эчерсәң иде;
Иптәйшкәйем синен белән
Ғөмер кичерсән иде.

## Кием-салым

Қызны биргәндә чулпысы дүрт булса, болар пара торыр, тигез ғөмер итәр, диләр. Алар чылт-чалт, чылт-чалт эндәшерләр иде. Белэзеклэр булыр иде қашлы. Әнийнекен мин йуалттым песән сапқан

сағында, өч бармақ йассылық иде, йаман матыр иде. Кемеш, қашлы қызыл, зәнгәр йә бер исә йәшел, қызыл әбәзәтелни булғалады. Элэктерэ тырған йуғ иде, былай ғына кийэ, сала. Мин Зуринға эч бүрәнә (*тукыган паласны үлчәү берәмлеге*) киндер суқтым, анын эчен дип, әни әрләде. Эч бүрәнә әнә бу паластан ызын була.

Алқам йуқ, менич (*менә ич*) йабылып бетте инде ачықлары (*тишекләре*), қылағ ачықлар йабылды, минең әле алтын алқа да бар қашлы, элгечле. Тәңкә булғанда (*булган*), Шамшинур җиңгинең бар иде тәңкәсе. Шылық-шылық, шөл-шөл итеп барыр иде артта су эчен барғанда. Қош кене бик йерткэлэмэделэр, җәй көне йаланғач барғанда тағып йергеледеләр. Қаситаны (*хәситәне*) бисерман йертэ, үзләре урысча сөйләшә, үзләре урыс дине тыта. Бик йаман пыразник булса, қасита кийэлэр. Илин дин, эйтэлэр, менә аларның паска йитә, қасита кийэлэр. Қайсы айақлы чулпы таға иде, уртасында чулпы, сығра (*соңыннан*) тәңкәләр тезгәндә, айақ диләр. Қайсы эч айақлы була.

Бийатай, бийем диб эйттек, арча сийләшәләр иде. Ар, татар берги булған. Ар керәшеннәр киткэн. Бер йыл эндэшмэдем, бэйләргә йаулық бирэлэр иде, эчкә хәтле дә йерәй, ике йыл да. Бийатай, килен безнеке әллә күзсез, әллә ничек ди дә алалар йаулықны. Болай бэйлэмэгэ ике-эч йыл тырғач бийатаймы, бийемме алырға қуша йаулықны. Сиғбәт бабач (*әтинең олы ир туганы*) белэн бер-ике кен генә сөйләшмәдэм. Килгәндә, ийдән алып килэсин йаулықны, бар булса, бирэлэр. Йаулықны алғанда киленнең башыннан, йитте инде битенне ач, диләр. Йабынмыйчы йерәсең. Зурысы малайны тудырғанчы бер кем белән дә сөйләшмәдем. Күкрэк тегәрләр ийе. Ими элэпкече (*алъяпкычы*) инде аwырлы булғачтын, зурлар алдыннан үткэлэделэр кулны алэпқыч астындан тытып.

*Сөйләүче: Бикмансурова Гөлбикә Сәлах кызы, 1924 елгы.*
*Юкамен районы Пүчинкә авылы. 1992 ел*

Сырамаға бармадылар, урынтын керттеләр, сыңра әйтмәгә барды эр кешемнең атасы, җәмәғате белэн, қызлары бардылар, туғаннары ике пар ат белэн кэлештелэр, күлмәк бирәләр, сөлге. Бийатай йазулар алып килделәр, унҗиденченең мин. Қәбен салдылар (*никах укыттылар*). Китерә дә печән йәйәләр дә кертәләр. Битен йуалар ийе, қомған бели су чығардылар, бэтемне йудылар, сөлге бирде бийем, алай керттеләр. Монда электән кермә йеткәчтен бэтне

йудыралар. Андағы ғадәте бетсен, монда йақшы ғадәтләнсен дип. Керттеләр бэтемне йуып, чаршау артынға утырттылар. Асқа бәләкәй (*бәләкәй*) салдылар, ул бәләкәй үзеңә була. И Алла, йеде йыл ийалдым (*тел яшердем*) әле мин. Қәбен салғанчы иптәш қыз беле утырып тора, чыбылдық эстесе йабу, түгэрэк. Эчэнэ кэрэлэр. Эстил артына кешене чақырасин, мулла уқый. Без бергэ утырдық сәкедә. Қасы эңелчи (*икенче*) ир кертэлэр. Ризы булып аласыңмы? Аламин. Никах керә, чәч сүттеләр иде, йабынып утыра идек челтәр шәл белэн. Қәбен салған чақта гадиналарың (*штан бавың*) йебәргән булсын, ыштан баwын чиштерәләр, никах керсен, керми қалмасын, дип, чәчне дә сүттерәләр иди. Кәбеңгә әйбир бирәләр, бер йаулық, бер шәл, бер күлмик, кәбен әйбир киленгә бирәләр. Бикэчем йаман усал иде, аның батинкасын салалар миңа кәбенгә. Кийәүгә кийәү күлмик бирәләр. Элек читек бирәләр. Киленне қотлап бирәләр. Күрешеп әйбир бирәләр, менә күрешэсин, йаулықны бирэлэр. Әтийемнең нәсел тамыры була, бийатай йағыннан килделәр, бар да бирәләр әйбир. Шэрбэт су эчерделәр эченә тәңкә салып, ақчамы инде бертөрле көмешме салып, Чәйләттеләр, төрле-төрле ашаулар була. Минем бийатай қачтырмады, әтийең булмағач, әти урынына күрәсең, диде, ийалдырмады. Нәқыйп бийағай белән тырдық, ийалдым. Башқаландық та әйтте, килен рәхмәт, инде битеңне ач, дүрт митер читсе бирде, очрашмай, сүләшмәй булмас, диде. Ийалып бер сүз әйтмәйсәң, бергә эшләйсәң. Алапқыч, йиңне озын тектерәләр ийе, беләкне дә күрмәссең. Бийатай әйтеп қайтқач, кәбен салдылар, ул сүләшеп қайтқан туй йасамаға. Қыз йаққа баралар туйға. Арт қода, ал қода була, туйдан сыңра. Ал қода қыз йақта, ал қода кийәүнең булма тийеш. Кийәү белем ашаталар кийәүгә, қызға. Ол йақтан йақшы ыннан тәбәғый элтэлэр. Қызның байы (*өлеше*) бирәсин, қаз, кемнең нийе бар.

* * *

Әнисе бар иды малайныкы. Кен белә белмәймин. Әнкайы сырама килде. Мин қозны сырама килдем. Чәй пешереп, кечкенәрәк никаг ашы йасадылар. Мулла кеше уқыды. Пич алды йағында булдым, сәкегә утырып тордым. Мына былай күлмәк бауларығызны сүтегез диделәр миңа. Азрақ кизүләдек. Тагын анда да чақырдылар. Азрак кичеккәч зур туйлар йасайлар арақылар были, эчешеп йырлайлар. Қода алай ук килә сырарға, бүләк биреп җибәрә, сылгы, диләр. Нинди исә дә йарай, сун айбатыракны биралар, намазлық

та намаз уқымаға. Чыпчаги бал белин ничек булса йасайлар шай. Йасагалаганнар булыр. Мәәр кийем китерәләр, шәлләр, йаулықлар, күлмәкләр, байларның камзул була, билле булғалай иде. Қыйбатлы ситса, бәрхәт камзул булыр иде, җиңсез. Укалы камзул, сатин, атлас, әдрәс тә булған. Алы ғына сутып ташлапмин ич ситсы алапкеч.

*Глазов районы Дасис авылы.*
*1990 ел*

**Бизәнү әйберләре.** Қамзул кийэләр иде эстэгэ. Элек wахытта мындый кийем йуғ иде ич. Әдәп сақладылар, айақларға ойықлар кимәйче кермиләр. Әтийем, башығызға йабығыз, дийер ийе. Шәл йаба, йаулық йаба, йәй кен нечкә шәл. Челтәр була иде, кәшәмир була иде, йефәк тә була. Хәситә кийеп йергэлэгэннэр, тәңкәләр тағып. Бетү йазасин да мун'ыға тағасин, чәч артына. Тәңкә кемештин йасаған, уртасында қаш мутордан (*матур*), йалтырап тора торған. Тәңкә тағып чыққалағаннар қутыртлап (*көязләнеп*). Чәчқап булғанда тәңкәләрдин тезгэн. Күлмәкләрне чеметеп-чеметеп теккәндә, тасма тотқаннар. Қуштан булып йерелде ул азрақ йәш wақытта. Ал'апқыч балайтәклесе була. Кимәле алйапқыч аллы-артлы була, баштин кийеп мондан түмэлип саласин. Эр кешем (*ирем*) қуштан иде, алай да йарата иде мин теккәнне дә.

**Легенда.** Тау битендә чиркәү бар иде, аның артында татар зираты иде. Урайчиновның қатыннары, зираттағы үлекләргә қор'ән уқырға дип, безнең аwылға безгә киләләр иде. Урйа Қалада мулла булып тырды Тайып бабай. Ул Биктэштэге (*ав. ис.*) кийәwенә Зиннатуллаға сүләп қалдырған. Йунданы (*ав. ис.*) нигез салучылар Гурйа Қаладан күчкән кешеләр. Йунданын қыйбыла йағына чығалар, анда йерне баққалайлар. Чишмәсе дә бар, безгә килешә, диләр. Анда йуwынайық, намаз уқыйық, аннан Йунда булып қалған, йуwындық сүзенә бик килешә. Аларның мөсөлманнар икэнен зират та күрсэтэ. Йундада бичерманнар Урйа Қаладан күчкән, анда татарча шүләшүчеләр дә бар иде, үлделәр инде қәзер. Гүрҗи дигән аwыл бар. Урйа Қала артында, тужы бисермән. Туқый мөсөлман аwыл, ул аwыл беткәндә (*беткән*), йуқ ул.

*Сөйләүчеләр:*
*Урайчинов Варсонофий Михаилович,*
*Энтентиев Ахун Әхмәтҗан улы,*
*Глазов районы Паюра авылы.*
*1990 ел*

## Яшь қызлар бәйете

Бисмилаһи үә биляһи, житте қорбан ғайете,
Без уқыйық, сез тыңлағыз йәш қызларның бәйете:
Кистем илен чыққан чақта қарадым қайырылып,
Қарамас идем қайырылып, китәмен ич айырылып.

И, китәбез, китәбез, китәбез дә киләбез.
Озақ торабыз, дип киттек тә ике көннән киләбез.
Столовой аш бирәләр пийала тәбеч белән,
Вагонға, дип қычқыралар ачы тамақлар белән.

Лумполарға барған идем ақлы күлмәкләр кийеп,
Тәмле йықыдан уйаталар, вагон тутырма, дийеп.
Лумполарда йөрер өчен киндер күлмәк тектердем,
Лумполарда вагон тийәп бар көчемне бетердем.

Лумполарда вагон тийәп фуфайкамны туздырдым,
Алты ай қышны, өч ай йазны вагон тутырып уздырдым.
Ақлы ситса күлмәкләрне байлар да кимәс иде,
Вагон тутыру жиңел булса, безгә дә тэймәс иде.

И дусқайлар, йаз көнендә йылғалар матур аға,
Вагонға утын кереткәндә күзләрдән йәшләр аға.
Айағымдағы чабатам урманға бара торған,
Бу қәһәр суққан урманнар үзәккә үтә торған.

Ике числода қайттық без, өйдә торырбыз, дийеп,
Комбой белән жибәрделәр, өч ай эшләгез, дийеп.
Лумполарда йөреп кенә бер йаулықны бетердем.
Алты ай қышқа, өч ай йазға бар көчемне бетердем.

Машинада барған чақта төшеп сөтләр алабыз,
Безгә озақ гомер қайда – бар саулықны салабыз.
Ақлы йаулық ике иде – берсен жилгә алдырдым,
Лумполарда вагон тийәп бар саулықны қалдырдым.

Тәрәздән қарағанда, вагоннар үтеп китәләр,
Ач үзәккә үтәләр.
Пуйысыз лампа йақты йана без торған баракта,
Туган илебез күренми йуғарыға қарап та.

Алйапқычым қыйар-қыйар, шул қыйарны кем жыар
Лумпода йереп үлдем исә минем өчен кем йылар.
Иртә йықлап тору белән чәчне үреп салабыз,
Қалын утын аwыр булса, икәү керетеп салабыз.

Дөнйада рәхәт йәшәргә иде минем уйларым
Рәхәт күреп үсә алмады минем зифа буйларым.
Ташлар аттым йырақтан, ташым китте улақтан,
Йаман җилле көннәр булса, йығылып төшәбез
драпктан (*трап*).

Моңайып җылап калабыз, тезелеп қазлар үткәндә,
Бу бәйетне йазмас идек, йазам үзәккә үткәнгә.
Қулымдағы йөзегэмнең исемнәре Ибрай,
Бер ай ғына түгел инде, тутырабыз туғыз ай.

Ал крушка, гел крушка, күтәреп сал подносқа,
Тағы өч ай эшләгез, дип, кулға бирделәр побеска.
Қулымдағы йөзегемнең исеме шалтай-балтай,
Безгә байлар рәхмәт итми эшләгән идек алты ай.

Беләзекләрем бегелми, беләгем бегелсә дә,
Тағы өч ай эшләсе булды, үзәгем эзелсә дә.
Вагоннарда килгән чақта, кешеләр қарап қала,
Вагоннар кереп җитсә, бешкән ашлар да қала.

Без торасы қара урманда өйләре утыз ике,
Бу бәйетне чығаручы – йәш қызлар без унике.
Тәмле йықы без күрмибез йазғы озын көннәрдә,
Унар вагон тутырабыз қараңғы озын төннәрдә.

Қулымдагы бийәләйем эшләгәндә тишелә,
«Подъём» дийеп қычқырулар бик йамансу ишетелә.
Әнә килә автомобиль, тийәгәннәр ат дағa,
Без вагон тутырған чақта ир-ат та йуқақтығы.

Сәғәт суға сигезне, без чығабыз диңгезне,
Сез онытсагыз да безне, без онытмыйбыз сезне.

Өй алдына ат килә дә китәмен мин утырып,
Туғаннарым қарап қала ике күзен тутырып.
Өй алдында йәшел суган сулар сорый торғандыр,
Бу илләрдән чыққан чақта қаты буран бурыйдер.

Қул йөзегемнең исемнәре Нәфисә,
Шатлық көннәр булыр иде – бу урман қәхәр бетсә.
Уфа тарақлары белән кем чәчләрен тараған,
Нужна күрсеннәр, дип кенә әнкәй безне асыраған.

Йегерләгән йепләрне орчық белән бөтерәм,
Биш йөз грамм ипиләрен қайтқанда ук бетерәм.
Мовлизованный башыбыз, кәбестәле ашыбыз,
Сыйыр тормаған баракта тора ғазиз башыбыз.

Лумподағы қызларның йөзекләре йалтырый,
Унбиш вагон керә, дигәч, йәш йөрәкләр қалтырый.
Лумполардан тарақ алдым чәчләремне тарарға,
Урман бийек, басқычы йуқ туған илне қарарға.

Лумпо дигән урманнарда вагон тутырып йатабыз,
Тәннән жаннар чықса гына бу эзләрдән қотылырбыз.
Штягалар йасый-йасый балтам қылялап бетте,
Вагонға утын ташый-ташый җилкәм уйылып бетте.

И дусқайлар, күрми қалдық, йылғалар матур аға,
Ураққа да китмәссез, дип безне Иван йылата.
Сибелә чәчем, чәчем сибелә, чәчем сибелә саwырға,
Уйланып, сызланып йылыйм вагон тутыру аwырға.

Лумполарда, кабакларда вагон тутырып йатабыз,
Колхоздан оннар килмәсә, ач-ач вагон тутырабаз.
Биш йөз грамм ипиләрне тешли-тешли ашыйбыз,
Колхоздан оннар килмәсә, биш йөз грамм белән эшлибез.

Бу чүбәк үзәгемне тартамын да йылқамын,
Өйгә китеп торыр идем судлардан қурықамын.
Без мескеннәр кеч түгәбез бөтен Кистеме өчен,
Без мескеннәр эшлибез биш йөз грамм ипи өчен.

Алйапқычым челтәрле, бауы қысқа – җитәрме,
Кеше көбек өйгә қайтып торма насыйп итәрмэ?
Көз башлары җитәр-җитмәс тезелеп китәләр қазлар,
Алты ай дип җибәрделәр, тағы өч ай эшләттеләр.

И беләгем-беләгем, сабынладым төнәген,
Элек рәхәт торған өчен әл дә өзелә үзәгем.

Иртә торып тышқа чықсам, матур қызлар су ташый,
Йықларға да тынычлық йуқ – кандалалар бик ашый.
Чәчергечем, чәчергечем чәчемне үрер өчен,
Әллә ниләр бирер идем урманнан қотылыр өчен.

Әллә поезд килә микән – рельеслары селкенә,
Вагонға утын кереткәндә йөрәкләрем селкенә.
Кистем йылғасы буйында кер чайқадым, элегез,
Өй алдында қош сайраса, вагон тутыра, дип белегез.

Үлдем исә қаберемне тирән итеп қазығыз,
Вагон тутырып үлдем исә башбатама йазығыз.
Атларымны бәйләп салдым (*куйдым*) тезләре тимәс җиргә,
Кистемнәр безне озаттылар күзләре күрмәс җиргә.

Кистем буйы, Кистем буйы, Кистем буйы гел нарат,
Өйгә китсәм, йылап киләм туған илемә қарап.
Бәхетле булган кешеләр киләләр дә китәләр,
Безнең кебек бәхетсезләр мәңгелеккә түзәләр.

**Суга батып үлгән Гасанша Ибраим бәете**

Өйдән киткәндә, сау бул, димәде,
Балаларым да қала, димәде.
Мин барам, диде, озак йөрмәм, диде,
Озақ қайтмас дийеп уйлама, диде.

Уйламадым мин, суға батар, дип,
Безләрне шулай йәтим итәр, дип.
Өйдән киткәндә, сау бул, димәдем,
Барма җаныйым, дип, нигә әйтмәдем.

Бешкән ашыбыз қалды өстәлдә,
Тәғәм җыймады өйдән чыққанда.
Өйләрдән китте сәғәт алтыларда,
Суларға батқан сәғәт уннарда.

Көн йақтырғынчы, қайтыр, дип көттем,
Көн йақтырғачын эметемне эздем.
Балалар сорый, эти қайда, дип,
Нигә соң әл дә өйгә қайтмый, дип.

Алар белмиләр суға батқан дип,
Сорыйлар һаман, нигә қайтмый, дип.
Дүртәүләп бергә җылыйбыз бергә,
Түзәйек инде йазған тәхтиргә.

Ходай қушкандыр шунда барырға,
Чорный суында җанын алырға.
Суларға қарыйм тәрәзә ачып,
Ходай қушкачын булмыйдыр қачып.

Чит илләрендә қалдық үзебез,
Адашқан қоштай булдық үзебез.
Суларға қарасам, эзелә үзәк,
Йалғыз башыма төште хәсерәт.

Туғаннарым йуқ хәлне белергә,
Ни хәлегез, дип сорый килергә.
Уйлый-уйлый да қалам қайғыға,
Бу хәсерәттин булдым дивана.

Йықы күрмәдем озын төннәрдә,
Тәгәм жыймадым йакты көннәрдә.
Белмим инде niләр эшләргә,
Қулларым бармый берни эшләргә.

Ун көнгә хәтле су төптә йатты,
Ун көннәрдән соң су өскә қалықты.
Өскә қалыққач, безгә әйтмәделәр,
Судан чығарғач, күрсәтмәделәр.

Балалар сорый аны қарарға,
Тәхәт тоталмый жылый алар да.
Бабайлар килде аны илтергә,
Йуып гәфеннән аны күмәргә.

Бабайлар жылый балалар жылағанға,
Сабыр итегез, дийеп аларға.
Балалар моглы йәтим қалдылар,
Әтийебез, дийеп кемгә қарарлар.
Анын буйлары күз алларымда,
Әйткән сүзләре әл дә хәтердә.

Кигән кийеме қалды чүләрдә,
Әйткән сүзләрен сағынып сөйләргә.
Ничек соң инде әйтийем сезгә,
Сабырын бирсен бер Ходай безгә.

**Юач мулла бәете**

Ничә-ничә шәһәрләрне үттем мин,
Килеп Казан қаласына житепмен.
Жери торгач Паржы илендә тотылдым,
Ахырында вә төрмәдә утырдым.

Монын турында йазим бер хикәйәт
Қабул итеп уқырсыз аны шәят.
Монын кеби хикәйәтләр табылмый,
Беләсез бит сызлауықлы аwылни.

Менә, дуслар, қара бәнем хәлемне,
Юлықты анда бәңә бер шүрәлем.
Ике кулына тоткан кенәгә,
Даhи кәләмнәре бар әллә нигә.

Қайан килдең, кемлегеңне күрсәт,
Қачып килдеңме әллә – турысын әйт.

Вәсият итәм хәлемне барчаларға,
Алып барди ул мине кәнсәләргә.
Кесәләремне қаради қалдырмый,
Даhи иреннәремне дә ақтарди.

Даhи мулла булғансыңдыр – әйт туры,
Түгелдер бит қачып йерүче үзи.
Дидем мин: муллаларны күргәнем йуқ,
Йалынсам да сүземне алмадылар.
Сүземә исә қолақ та салмадылар.

Бәңә hич тә шәфәхәт итмәделәр,
Вә төрмәгә илтеп тә бикләделәр.
Вә төрмәдә биш көн үтептер
Тәмәм итәм хикәйәмне көтеп тор.

Ни сәфәрдин җырақ җирдән килермен,
Әгәр хуш килсәгез, хәлемне силәрмен.
Қайа барсам да дөнйа бер аwырлық.
Қодай қолларина бирсен сабырлық.

Хак исемендә әйләп башлимым кәләмем,
Хак пигәмбәрләргә булсын лә сәләмем.
Кичләрдә йоқым керми йатамын,
Сигез қоллар ғариф күңелен ачамын.
Йәшем йедмеш икегә дә җитептер
Хак бәләгә тәқтир җитептер.

Бән үтептер хөкемәт қулына алди,
Даhи мәгфуз җитеп зинданға салды.
Қамыш тик нечкәреп қалды беләгем,
Итем бетте, қалды минем сийәгем.
Бәнем тик ничәләр мәхфуз алыптыр,
Бу зинданға бәгерләрем кибептер.

Кемси йолар, атам-анам, диеп,
Кемси йолар, қалди балам, диеп.
Кемси йолар қамыш (*калган*) малы өчен,
Кемси йолар, қалди балаларым, диеп.

Кемси аерылды дөнйа малиндин,
Йақын күргән мөхәббәтем йарендин.

Бу ни гәҗәп заhит улди кәләфәт,
Қала яқлар арасында хикәйәт.
Ничә мәглүмнәрнең мали алынды,
Үзе җир өйләп зинданға салынды.

Ничәләрне айырдылар имендин,
Мөхәббәтле узи хәләл яриндин.
Ничәләрне айырдылар йыраққа
Кемне мәгриф, кемне машриф тарафқа.

Сәләм булсын сезгә йәшләргә һәм қартларға,
Безни зекерәйләгез ақ қартларға.
Сезнең белән ничә йыллар йәшәгән,
Бер өстәлдә утырып ашлар ашаған.

Онытмимен сезне иртә үә кичә,
Төшемдә күрәмен, йатсам, һәр кичә.
Қайчан булыр безгә күрешмәк,
Әвәлге тик аралашмақ күрешмәк?

Кичәләрдә укимен йәсин шәрипни
Доғағыздан онытмағыз гәрипни.

Даһи хәсрәтле қалмыш қыз туғаннар,
Мине йақын күргән, қардәш, дип белгәннәр.
Минем өчен қайғырып йөрмә бигрәк,
Ходай қылсын жанығызны сәләмәт.
Бу ни гәҗәп сағынмақны қуйалмыйм,
Ике күзләремнең йәшен тыя алмыйм.

Әгәр йатсам, йокы керми уйанам,
Төшемдә дә сезни күреп қуанам.
Кичә көндез бу хәсрәтне қуялмим,
Сезнең нурлы йөзегезне күрәлмим.

Әгәр хуш, күрсәгез минем сүземне,
Қабул әйлә бәнем әйткән сүземне.
Уки белсәң, бәнем йазған хатымны
Доға қылығыз онытмағыз атымны.

Әгәр күрсәң, бу хатларны алып қуй,
Айақ астына таптама, салып қуй.
Аманатдер укучыға, аманат,
Ходай қылсын жанығызны сәләмәт.

Балаларым, қылақ салығыз сүземә,
Насип қайтсам, күренерсез күземә.
Горурланып бигәят азмағайсыз,
Шаригәтен йул белмәгәйсез.

Әгәр дә без йорақ жирдән узабыз,
Йегетләргә бу дер безнен сүзебез.

Телегезне һич урында сақланығыз,
Олыларға йаман сүз қақмайсыз.

Ходаһ җанығызны бирсен сәләмәт,
Аманатдер-аманатдер – аманат.
Хатын-қызға будыр сүзебез,
Тубал тик булмасын сезнең күзегез.

Олылар алдин атламағайсыз,
Аларға сүз қаршы сез йул тапмағайасыз.
Беләсез бит Кодай сәбәп әдәбен,
Әдәпле бул, әдәпле бул, әдәпле.

*Касыймова Нәсимә Якуп кызыннан (1945 елгы)*
*күчереп алынды.*
*Балезино районы Кистем авылы*

Утырғанда (*утырмада*) шәлләр бәйли идек. Глазға (*шәһ.ис.*) илтеп сата идек, кемгә дә булса заказ була иде. Эшсез торылмады, йәштин үк эшлидек. Ул wақытта колхоз бик начар иде. Балаларға сөйләдем әле: ризығы да йуқ чағы да булды. Соңра колхоз, ашлық уңды, аны тартмаға барасың, мондан дүрт чақрым йәйәү арқаға кийеп тегермэн тартма бардық та, бер дә тарталмадық. Ул wақытларда атлар бар иде колхозда. Бик күп читтэн ат белән тегермэн тартмақ килгэннэр. Безгә бер дә тегермен табылмады ич. Аннантын бардық алты чақрымдағы, тегермэн тарттық. Тегермэн қәдәр болынынан күтереп бардық йэшел үлэн – анис дип әйтэбез. Анисны йыштырып ашадық. Ашлық тарттырып боламақ ашамақ йазсын инде, пэчэн ашап йөрмиг инде, дидек. Аллаһқа доға қылабыз. Шылай йөргэлэдэк.

Бер грамм да айақ басарлык йернэ буш қалдырмайлар иде – урақ урдық. Соңра комбай йуқ иде, трактор берөү бар иде. Ул комбайны сәгәт 3 тә урақ урабыз. Кем күбрәк урақ уралар, шуңа күбрәк – 200 грамм бирәләр. Алай эшлэдэк, ни күрмэдек.

*Сөйләүче: Бузикова Таифә Гайнан кызы. 1929 елгы.*
*Глазов районы Татар Парҗысы авылы*

Минем үзем дә Казан йақтағы тамырым. Менем бабай Қазандан булған: бабайның бабайы – Чистайдан. Монда ике километр аwыл бар ийе. Ул аwылға мулла булып килгэн ийе әтисе. Әтисе Шәмсетдин булған, малайы – Дәүләтша булган. Ул Дәүләтша бабайның

малайы булған минем әти, Галимҗан исемле. Монда тордылар, монда үлде инде. Менә алай булған.

*Сөйләүче: Бузиков Ади Галимҗан улы. 1932 елгы.*
*Глазов районы Татар Парҗысы авылы*

### *Җырлар*

Йалғыз қайын үсми, диләр,
Йалғыз қайын күллэрдэ.
Йалғыз қайыннардан йалғыз
Мин бүгенгэ кэннэрдэ.

Түбән йаққа төшкэн чақта
Таптым қарның кэлләмен.
Кем айырылмый, шулар белми,
Айырылуның хэллэрен.

Әнә килә автомобиль,
Әнә килә қаршыма.
Йулларыңа сачәк булып
Мин үсәрмен, таптама.

Агыйделгә төштең инде,
Төштең инде, йөз инде.
Син минеке түгел инде,
Өметеңне өз инде.

Ап-ақ итеп кер йуған да
Қоймаға элеп қуйғаннар.
Сағынғанда сэйлэшергэ
Йуғ ич безнең туғаннар.

Күрше әби сөйләде. Йегермэ йэдэ кешене суғышқа озатқаннар аwылдан. Чапай (*кушаматы*) Фатқулла йэдэ балалы булған. Аwылдан йырлап чыққаннар. Монау йыруны Фатқулла йырлаған, зыйарат йаныннан машинаға утырып апкитәләр, барысы да. Суғышта беткән Фатқулла. Қатыны йэдэ балаларын үстергэн, кеше иткэн. Фатқулла қулын селкеп шушы йулларны йырлады, ди, йаман қычқырып:

Машинада барған чақта
Төшеп сулар алабыз.
Инде бергә қайту қайда
Әҗәл эзләп барабыз.

Без илләрдән чыққан чақта,
Күтәрелде бураннар.
Йә қайтырбыз, йә қайтмабыз,
Сау булығыз, туғаннар!

*Сөйләүче: Касыймова Әминә Галим кызы. 1925 елгы.*
*Балезино районы Кистем авылы*

Без үстек әнкәйнең биш бала, йеде тапқан, икесе үлгэннэр. Уртача тормышта әни дә, эти дә эшләде. Тормыш йаман аwыр иде.

1936 йылда умбер йәш булдым. Заманнар аwыр: ипи йуқ, урожай булмады. Без умбер йәшлек балалар җыйылып киттек. Уқуларны ташлап, Кировқа йөрдик. Вагоннарға тутырып Балезиноға китереп, сельсоветта, больше барма, диделэр. Ә ашасы килә, Кировта тамақ туйа. Безнең абый, 1923 йылғы, соңра эшлэмэгэ китте.

1941 йыл етте. Уқуларға бер барабыз, бер бармайбыз. Суғыш башланды. Уналты тулмаған балаларны (безне – ун кешене) сельсоветтан чақырталар, бардық ике кыз, сигез малай. Шуннан, военный заводқа озатабыз, диделәр. Грузовой машинаға тутырып Ижевскиға илттеләр, бараққа 74 нче заводқа. Ул бараққа салдылар. 86 нчы цех 74 нче заводта эшләдек. Өч ай эшлэдек, ашама йуқ, йуғаллтық әйберләребезне. Төп тел – арча да, урысча да белмибез, татарча гына беләбез. Өч ай йетте. Монда эшлэү, йәшэү аwыр иде, йабығып беттек. Мондан қачабыз, булдырмыйбыз, дидек <...>

*Сөйләүче: Касыймова Әминә Галим кызы. 1925 елгы.*
*Балезино районы Кистем авылы*

Шулай итеп сөйләү үрнәкләрендә (материалларында) күренгәнчә, Удмуртия Республикасындагы татарлар милләтебезгә хас гореф-гадәт, йолаларны ихтирам итеп, туган телдә аралашып гомер кичерәләр.

Татар диалектологиясендә бу төбәк татарларының сөйләше татар теле урта диалектының нократ сөйләше дип билгеләнә. Сөйләшнең фонетикасы, сүз төркемнәре һәм аларның грамматик категорияләре, лексик составы, нигездә, татар әдәби телендәгечә. Удмуртия җирлегендәге татарлар сөйләшендә борынгы һәм иске татар язма әдәби теленә хас булган үзенчәлекләр ныграк сакланып калган.

## «ЧИШМӘ КҮЗЛӘР КҮП БЕЗДӘ»

***Удмуртия татарлары сөйләше***

*Флера Баязитова*

Удмуртия татарларының сөйләше фәнни әдәбиятта нократ сөйләше төркеменә керә.

Нократ сөйләше вәкилләре барлыгы кырыкка якын авылда – Нократ (Вятка) елгасының бер тармагы булган Чыпца елгасы бассейнында яшиләр. Шуның өчен аларны, кайбер очракта, Чыпца буе татарлары, дип, яки, нократ татарлары, дип тә атап йөртәләр.

Хәзерге административ бүленеш буенча бу территория Киров өлкәсенең Слобода районын, Удмуртия Республикасының Юкамен, Глазов, Балезино районнарын колачлый.

Тарих һәм археология материаллары күрсәткәнчә, Нократ татарлары яши торган җирләр борынгы чорда Болгар дәүләте составына кергән, ягъни татарларның борынгы бабаларының (болгарларның) авыллары монгол яуларына кадәр үк булган. Шуннан соңгы чорда исә болгарларның төньякка, борынгы удмурт җирләренә күчеп утырган булулары мөмкин.

Киров өлкәсенең Слобода районына караган Нократ (Карино) авылы элек бик зур булган, үзе берничә авылны (Олы ил яки Югары авыл, Түбән авыл, Ильясавыл) берләштергән. Югары авыл үзе дә Дәүләтьяр һәм Митюк авылларына, Түбән авыл исә Арслан, Абаш, Касыйм, Юач авылларына бүленгән булган.

Нократ буенда яшәүче татарларның икенче зур төркеме – Чыпца елгасының югары агымында, Удмуртиядәге авылларда яшиләр. Биредәге авыллар арасында иң зурысы – Кистем авылы, ул Балезино районына карый. Тарихи материаллардан күренгәнчә, Кистем авылының халкы, җир аз булу сәбәпле, Киров өлкәсендәге Нократ (Карино) авылыннан аерылып чыгып, әлеге урынга килеп утырган. Бу авылның

сөйләше дә шул ук Нократ авылы сөйләшеннән аерылмый диярлек. Фәндә ул нократ-кистем сөйләше дигән исем астында да билгеле.

Удмуртиянең кайбер авылларында яшәүче татарлар биредәге удмуртлар һәм бисерманнәр белән аралашып көн иткәннәр. Бисерманнәрнең фамилияләре дә төрки-мөселманча: Бекмансуров, Бекмаметов, Балтачев, Касыймов, Абашев, Сабреков һ. б. Шуннан чыгып, элек алар мөселман булганнар, дигән нәтиҗәгә килүчеләр дә бар. XVII–XVIII гасырларда бисерманнәрнең бер өлеше христиан диненә кертелә. Шуннан соң бисерман-христианнар удмуртлар белән, ә бисерман-мөселманнар татарлар белән аралашып, берберсенә кушылып киткән булырга мөмкин.

Удмуртия Республикасында яшәүче татарларның бисерманнәр белән аралашуы аларның теленә дә йогынты ясамый калмаган. Мәсәлән, Удмуртиянең төньягындагы татар авылларыннан тел үзенчәлекләре һәм гореф-гадәтләре, йолалары ягыннан күрше бисерманнәр белән бик күп уртаклыклары булган бер төркем авыллар бүленеп чыга: Тегермән авыл (Тат. Ключ), Дасис (Засеково), Атабай (Богошур), Иманай, Пүчинкә, Биктәш, Уръякала (Гордино), Әхмәди (Ахмадеево), Татар Парҗысы, Палага (Палагай) һ. б.

## Нократ сөйләшенең өйрәнелү тарихы

Нократ татарларының тел үзенчәлекләре фәнни яктан шактый тирән өйрәнелгән. Бу сөйләшне күренекле тел галимнәре Җ. Вәлиди, Л. Җәләй, Н. Борһанова, беренчеләрдән булып, язып, өйрәнеп калдырганнар һәм ул хезмәтләр зур әһәмияткә ия.

Соңгы елларда да әлеге төркем татарларның тел үзенчәлекләрен, аларның бүгенге көндәге торышын һәм сакланышын, халыкның гореф-гадәт һәм йолаларын өйрәнү дәвам иттерелде, алар хакындагы мәкаләләр дөнья күрде, магнитофон тасмасына күп кенә тел байлыгы яздырып алынды

Нократ сөйләше урта диалектның бик кызыклы, борынгылыкны шактый яхшы саклаган бер сөйләше булып санала. Бу сөйләштә тарихның тирән катламнарын ачарга ярдәм итә торган фонетик, морфологик, лексик үзенчәлекләр, йолалар һәм гореф-гадәтләр сакланып калган. Йолаларга, мифологиягә һәм ырымнарга караган сүзләрдә, кием-салым атамаларында, туганлык мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләрдә татар теленең казан арты, пермь татарлары,

керәшеннәр, касыйм татарлары сөйләшләре белән (шулай ук мишәр диалекты сөйләшләре белән дә) уртаклыклар күзәтелә.

Кызганычка каршы, нократ татарларының шундый бай, җирле үзенчәлекләрне нык саклаган һәм тарихи яктан гаять кызыклы сөйләше бүгенге көндә өлкән буын кешеләре сөйләшендә генә сакланган. Чөнки күпчелек татар авылларында туган тел, татар теле укытылмау, яисә аны тиешле югарылыкта алып бармау сәбәпле, балалар, гомумән, яшь буын туган телне аңлаудан һәм җирле телдә сөйләшүдән, аның үзенчәлекләрен тоюдан мәхрүм ителәләр.

Элек-электән казан татарлары белән тыгыз бәйләнештә яшәгән нократ татарлары соңгы чорларда нык ассимиляцияләнү, ягъни бүтән халыклар йогынтысында эреп югалу алдында торалар.

## Нократ сөйләшенең грамматик үзенчәлекләре

### *Фонетик үзенчәлекләр*

**Сузыклар**. Нократ сөйләшендә унике сузык аваз бар. Аларның сигезе (*а, ә, и, ы, е, у, ү, е [э]*) әдәби телдәге авазлар, ә калган дүртесе (*ә̂, у°, у$^{ө}$, о$^{ү}$*) әдәби телдә кулланылмыйлар.

***А*** авазы барлык очракта да, әдәби телдән аермалы буларак, ачык, иренләшмәгән аваз булып әйтелә: *алма, бабач* – әд. абзый, *йанйаулыҡ / йанйаулык* – кулъяулыгы, *башбата* – кабер ташы һ. б.

*А* авазының ачык, иренләшмичә әйтелүе ягыннан нократ сөйләше татар теленең пермь, касыйм татарлары, казан арты – дөбъяз, керәшен татарлары сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә.

***Ә*** авазының нократ сөйләшендә ике варианты бар: әдәби телдәге кебек киң әйтелешле *ә* һәм тар әйтелешле *ә̂*.

Әдәби телдәге кебек киң әйтелешле *ә* түбәндәге очракларда күзәтелә.

Аерым сүзләрдә: *кәзә* – әд. кәҗә, *әнкуй* – әнкәй, *әбкуй* – әбкәй, *әткуй* – әткәй, *кәбен* (*салу*) – никах уку һ. б.

Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән алынма сүзләрдә: *кәғәз* – әд. кәгазь; *ҡәләм* – каләм; *сәғәт* – сәгать; *сәләм* – сәлам; *шимбә, нәкәс* – бик һ. б.

Ялгызлык исемнәрендә: *Эрәшидә, Нәфисә, Бәлхисә, Тәкмийә, Сәлимә, Мәдинә, Галийә, Ғәйшә, Фәрдәнә* һ. б.

Нократ сөйләшендә кулланыла торган тар әйтелешле *ә̂* артикуляцион һәм акустик яктан рус телендәге ачык э (эт дигән сүздәге кебек) авазына якын тора.

Тар әйтелешле *ә̂* авазы сүзләрдә төрле фонетик шартларда килергә мөмкин: *ә̂йбер* – әд. әйбер, *ә̂йтә* – әйтә, *түмә̂* – төймә, *иптә̂шлә̂р* – иптәшләр, *белмә̂деләр* – белмәделәр, *күмә̂* – көймә, *пә̂рә̂вез* – пәрәвез. Мондый үзенчәлеге белән нократ сөйләше татар теленең Рязань өлкәсендә таралган касыйм сөйләшенә якын тора.

Кайбер очракларда *ә̂* авазының тараю дәрәҗәсе бик көчле була һәм ул тар *и* сузыгын хәтерләтә: *хәзер кери* – әд. хәзер керә, *ашама пеши* – ашарга пешә, *килилир* – киләләр.

Шул ук күренеш чыгыш килеш кушымчасында да чагыла: *сәгәттин артыķ* – әд. сәгатьтән артык, *читтин килделәр* – читтән килделәр, *синдин йабыгам* – сине сагынам.

Әдәби телдәге киң *ә* авазы урынына тар *ә̂* авазын әйтеп сөйләү барлык авылларда да бер төсле түгел. Ул, нигездә, нократ урынчылыгында бик актив, ә кистем урынчылыгында әлеге күренеш тотрыклы түгел, ягъни бер үк сүз төрле кеше сөйләшендә ачык *ә* белән дә, тар *ә̂* белән дә әйтелергә мөмкин: *тәрәзә/тә̂рә̂зә̂, нәрсә/нә̂рсә̂, сәләм/сә̂лә̂м* һ. б.

***И*** авазының нократ сөйләшендә ике варианты бар: озынрак әйтелә торган *и* һәм кыскарак әйтелә торган *и*.

Озын *и* сузыгы әдәби телдәге -*өй, -ый* дифтонглары урынында кулланыла торган -*ий* дифтонгында чагылыш таба: *ий* – әд. өй, *сийләде* – сөйләде, *сийәк* – сөйәк (граф. сөяк), *ийләнә* – өйләнә, *ийрән* – өйрән. Кыска *и* сузыгы түбәндәге очракларда кулланыла:

а) зат алмашлыкларында: *мин, син;*

ә) *иде, икән* ярдәмче фигыльләрендә һәм *ич, дип, ки, исә* сүзләрендә;

б) гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләрдә: *Ғиззәт, шимбә, сишәмбе, Бибиҗамал;*

в) рус теленнән кергән сүзләрдә: *Чипча* – Чыпца (елга), *лечебнича* – лечебница, *ударнича* – ударница, *гачинча* – күчтәнәч;

г) чыгыш килеш кушымчаларында һәм фигыльләрнең зат кушымчаларында: *синдин* – әд. синнән, *кешедин* – кешедән, *ķайа барасин* – кая барасың, *суга утырыпмин ич* – суга утырганмын ич;

д) тагын түбәндәге сүзләрдә: *ит* – әд. эт, *ире* – эре, *инә* – энә, *ишаныч* – ышаныч, *ийат* – ойат, *иләк* – җиләк.

*Э* (*е*) авазының нократ сөйләшендә шулай ук ике варианты бар: тар һәм киң әйтелешле очраклары.

Тар әйтелешле э (*е*), гомумтатар сүзләрендәге кебек, тамыр һәм кушымчаларда, сүз башында һәм сүз ахырында килә ала: *эшче, беренче, беттегесе* (әд. барысы да) *эш, элеш* һ. б.

Тар әйтелешле *э* (*е*) әдәби телдәге ирен-ирен *ө* авазы урынына да кулланыла, ягъни күпчелек очракта *ө* – *э* (*е*): *кен* – әд. көн, *тен* – төн, *сет* – сөт, *тетен* – төтен, *серен* – сөрем, *келешә* – көлешә.

Киң әйтелешле *э* (*е*) авазы әдәби телдәге *и* авазы урынына кулланылырга мөмкин: *экмәк* – әд. икмәк, *эт* – ит, *эке* – ике, *бэш* – биш, *кэлгән* – килгән, *эшек* – ишек, *керпеч* – кирпеч, *эзән* – идән һ. б.

Шулай итеп, нократ сөйләшендә сузык *и, э, е* авазларының төрле вариантлары кулланыла һәм бу күренеш татар телендә сузыкларның эволюциясе һәм үсү юллары тарихы белән аңлатыла ала.

*Ы* – иренләшмәгән, арткы рәт, түбән күтәрелештәге кыска сузык. Сөйләштә бу аваз әдәби телдәге *о* авазы урынында да кулланыла: *сыра* – әд. сора, *йымырқа* – йомырка, *ызын* – озын, *ылы* – олы, *йызак*, – йозак, *былын* – болын, *йықы* – йокы.

Кайбер очракларда ирен-ирен *у* авазы да *ы* авазы белән алмаштырыла: *ыл* – ул, *мынча* – мунча.

Нократ сөйләшендә иренсезләшкән *ы* сузыгы урынына көчле иренләшкән *о* авазы әйтеп сөйләү очраклары да бар. Бу үзенчәлек күбесенчә тирән тел арты *қ* һәм тел арты *к* тартыклары булган сүзләр өчен хас: *коз* – әд. кыз, *қош/кош* – кыш, *коз-коркон* – кыз-кыркын, *коп-козол* – кып-кызыл һ. б. Көчле иренләшкән *о* авазы алынма сүзләрдә дә күзәтелә: *л'ого* (удм.) – тигәнәк, *кот'ор* (удм.) – тирә-як, әйләнә, копкозо (удм.) – чабата киндерәсе, *токма* (удм.) – юкка, бушка.

***Ө*** – алгы рәт, югары күтәрелештәге ирен сузыгы, нократ сөйләмендә сирәк кулланыла. Күпчелек очракта ул иренсезләшкән кыска *е* сузыгы белән алмаштырыла: *элеш* – әд. өлеш, *кен-тен* – көн-төн.

***О*** – арткы рәт, түбән күтәрелештәге ирен сузыгы, сөйләштә ул күпчелек очракта иренсезләштерелә: *бызылмай* – әд. бозылмый, *былай* – болай, *кыдача* – кодача, *ызақ/ызак* – озак, *ыйық/ыйык* – оек, *сылы* – солы, *қыры/кыры* – коры.

Кайбер очракларда *о–ы, ө–е* авазлары бер үк кеше сөйләшендә параллель кулланылырга да мөмкин: *он/ын, ол/ыл, соло/ сылы, серен/сөрен* – сөрем, төпле/тепле – бикле, көмөш/кемеш һ. б.

***У*** – арткы рәт, югары күтәрелештәге ирен сузыгы. Нократ сөйләшендә аның тар һәм киң вариантлары бар.

Тар *у* авазы әйтелеше ягыннан әдәби телдәге *у* авазыннан аерылмый. Ләкин, әдәби телдән һәм татар теленең башка сөйләшләреннән аермалы буларак, бу аваз сүзнең беренче иҗегендә генә түгел, алдагы иҗекләрдә дә һәм сүз ахырындагы *ы* сузыгы урынында да кулланылырга мөмкин: *усал* – әд. начар, *дуйын* – күп, *уйнай* – уйный, *җыру кен* – коры көн, *сару* – сары, *бушайму* – бушыймы, *йыру* – җыр, *булумады* – булмады, *тулумады* – тулмады.

*У* авазының киң әйтелешле варианты (*у*°) *у* һәм *о* авазлары урталыгында торган дифтонгоид характердагы аваз *у*° – иркәләүкечерәйтү кушымчасы булган *-ку°й* составында һәм *-йу°* күтәрелеш дифтонгында күзәтелә: *әбку°й* – әд. әбекәй, *әнку°й* – әнкәй, *апку°й* – апакай, *Камку°й* – Камилкәй, *Шамку°й* – Шамилкәй, *Ыразку°й* – Разинкәй, *Мәдку°й* – Мәдинәкәй, *иу°waui* – юаш, *иу°waН* – юан, *йу°к* – юк.

*Ү* – алгы рәт, югары күтәрелештәге ирен сузыгы. Нократ сөйләшендә *ү* сузыгының ике варианты бар: тар һәм киң әйтелешле *ү*.

Тар әйтелешле ү артикуляцион яктан әдәби телдәге ү авазыннан аерылмый: *үчләй* – әд. үлчи, *түнгәк* – түмгәк, *чүпләшмә* – сугу (ашлык сугу), *кизүләмә* – өй эшләрен эшләргә.

*Ү* авазының киң әйтелешле варианты (*ү*°) *ү* һәм *ө* авазлары урталыгында торган дифтонгоид характердагы аваз. Ул сүзләрдә *р* авазы алдыннан килә: *ү*$^{ө}$*рә* – әд. үрә, *ү*$^{ө}$*рмәкүч* – үрмәкүч, *ү*$^{ө}$*рзәк* – үрдәк, *кү*$^{ө}$*рә* – күрә.

Нократ сөйләшендә рус теленнән кергән *э, е* авазлары күзәтелми. Ул авазларга сөйләштә *и* авазы, ә басым астында килгәндә тар *ә* тәңгәл килә: *ниргийе* – энергия, *икран* – экран, *личибнича* – лечебница, *иликтыр* – электр, *Чипча* – Чыпца, *нивиста* – невеста, *канфәт* – конфета һ. б.

Рус теленнән кергән *о* сузыгы нократ сөйләшендә көчле иренләшкән дифтонгоид характердагы аваз – о$^{у}$: *о*$^{у}$*тчо*$^{у}$*т* – отчет, *wo*$^{у}$*т* – вот, *ко*$^{у}$*лхоуз* – колхоз, *ко*$^{у}$*рым* – корм, *по*$^{у}$*ло*$^{у}$*жение* – положение, *мо*$^{у}$*то*$^{у}$*р* – мотор.

Нократ сөйләшендәге мондый күренешне шул төбәктәге рус сөйләшенең йогынтысы дип карарга мөмкин. Чөнки рус теленең нократ сөйләшендә дә басымлы иҗек алдыннан килгән *о* авазы *о*$^{у}$ булып әйтелә: *ко*$^{у}$*рова, хо*$^{у}$*рошо, до*$^{у}$*мой*.

**Дифтонглар.** Нократ сөйләшендә әдәби телдәге *-өй* дифтонгы иренсезләштерелеп *-ий, э*(*е*) булып әйтелә, ә кайбер очракларда

*ү* монофтонгы белән дә тәңгәлләшә: *сийәк/сүwәк* – сөйәк (граф. сөяк), *ий/өй* – өй, *сийлә/сүлә* – сөйлә, *кийәндә/көwәндә/күwәндә* – көйәнтә, *ийрән/эwрән/үрән* – өйрән, *түмә/тиймә* – төймә, *сүкемсез/сикемсез* – сөйкемсез.

Сүз ахырындагы *-ый/-ий* дифтонгларына сөйләштә *-ай/-әй* дифтонглары тәңгәл килә: *андай* – андый, *мындай* – мондый, *йылай* – йылый (граф. елый), *бармай* – бармый, *танымай* – танымый, *чыдай* – чыдый, *сийлай* – сыйлый, *печәй* – песи.

*-у°й* төшерелмә дифтонгы исемнәрдәге иркәләү-кечерәйтү кушымчасында күзәтелә: *әбку°й* – әбекәй, *әнку°й* – әнкәй, *Шамкуй* – Шамилкәй.

Әдәби телдәге *-ау* дифтонгы сөйләштә тар *-оу* дифтонгы белән тәңгәлләшә: *бызоу* – бозау, *қыроу* – кырау, *ашоу* – ашау, *чолгау* – чолгау, *қыңгыроу* – кыңгырау. Мисаллардан күренгәнчә, *-оу* дифтонгы сөйләштә бары тик сүз ахырында гына килә ала.

**Тартыклар.** Нократ сөйләшендәге тартык авазлар, составы һәм артикуляциясе ягыннан, нигездә, әдәби телдәге авазлардан аерылмый. Монда мисал итеп юкамен һәм бисермән-керәшен урынчылыкларында тирән тел арты һәм тел арты тартыкларының параллель кулланылуын күрсәтеп үтәргә мөмкин, ягъни *қ/к, қ/г, қат/кат* – әд. хат, *Ғали/Гали, қамыр/камыр*. Сөйләшкә түбәндәге аваз тәңгәллекләре хас:

***м – н:*** *белем* – әд. белен, *тетем* – төтен, *болом* – болын;

***н – м:*** *серен* – әд. сөрем;

***б – п:*** *бычжҗы* – әд. пычкы, *бетү* – пешү, *бычак* – пычак, *бугрәп* – рус. погреб;

***д – т:*** *дегел* – әд. түгел, *дастымал* – тастымал, *дагын* – тагын, *тары/дары* – тары;

***з – д:*** *эзән* – әд. идән, *қазақ/казак* – кадак, *йаз* (фарсы – йад) *итү* – искә алу, *үрзәк* – үрдәк;

***қ/к, һ – ғ, г:*** *бетәгә* – әд. бүтәкә, *бағыт/багыт* – wакыт (граф. вакыт), *қурғыту* – куркыту, *қәғәр* – каһәр, *шәғәр* – шәһәр;

***г – ң:*** *йағадан/йагадан* – йаңадан (граф. яңадан), *өстөгә/эстегә* – өстеңә: *Эстегә қалат кий.* – Өстеңә халат ки;

***н, м*** тартыкларына беткән сүзләр чыгыш килешендә килгәндә кушымчалардагы *д* тартыгы саклана: *Уйындан* – әд. уйыннан (граф. уеннан), *кийемдән* – кийемнән (граф. киемнән), *синдән* – синнән, *миндән* – миннән, *андан* – аннан, *урмандан* – урманнан, *боломдан* – болыннан.

Нократ сөйләшендә тел уртасы *й* авазы бик актив кулланыла. Ул әдәби телдәге *җ* тартыгы урынына сүз һәм иҗекләрнең башында да, ахырында да килергә мөмкин: *йиңгәй* – әд. җиңги, *йетен* – җитен, *йеде* – җиде, *йәйәү* – җәйәү (граф. җәяү), *мырйа* – моржа, *йул* – җул (граф. юл), *йыру* – җыру, *йетмеш/йе'меш* – җитмеш, *йемеш* – җимеш, *йәйге* – җәйге, *йәймә* – җәймә.

Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән алынма сүзләрдә әдәби телдәге кебек *җ* тартыгы саклана: *җан, җомга/җомга, Җийанша* – Җиһанша, *җомак* – оҗмах, *йемеш* – гөлҗимеш.

Удмурт теленнән кергән сүзләрнең дә кайберләрендә шулай ук *җ* тартыгы күзәтелә: *пугриж* – кыяр, *кыжҗылы* – очкын, *Парҗы* – авыл исеме, *Гурҗушур* – авыл исеме.

Арткы рәт сузыклары белән янәшә килгәндә *л* тартыгының нечкәрүе түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *шал'* – әд. шәл; *Гул'бикә* – Гөлбикә, *гул'бәч* – гөлбәч (әд. идән асты), *ыл'ык* – элек, *ыл'гыл'аганда* – элгән, *ыл'ыш* – өлеш, *Пал'ага* – Палага (ав. исеме.).

Кайбер сүзләрдә әдәби телдәге *ч* тартыгы урынына нечкәртелгән *т'*(*ти*) кулланыла: *тишмә* – әд. чишмә, *т'аршу/т'аршоу* – чаршау, *т'ашка* – чашка, *он т'апена* (удм.) – он боламыгы.

Сүз һәм иҗек ахырында тирән тел арты *қ* тартыкларына аерым очракларда йомык *аваз'* (хәмзә) тәңгәл килү күренеше күзәтелә: *йы'ла* – әд. йокла, *балы'* – балык, *би' йыра'* – бик йырак (граф. ерак), *суwы' тиде* – суык тиде, *чи'ләwе'* – чикләвек. Сирәк очракларда йомык *аваз'* (хәмзә) тел алды *д, т* тартыкларын да алмаштыра: *ира'лар* – әд. ир-атлар, *за'лы* – затлы.

***К – т:*** *искалекка* – әд. истәлеккә, *келә* – телә.

***Д – к:*** *дустәнәч* – әд. кучтәнәч.

**Аваз өстәлү**, *б: бемә/бимә* – өмә; *ы, э: эрәқмәт/эрәхмәт* – рәхмәт, *ылампы* – лампа, *ышкап* – шкаф, *ыстанча* – станция.

**Аваз төшү.** Сөйләштә *г, й, н* тартыкларының төшеп калу очраклары күзәтелә, *г* төшә: *тее* – әд. теге, *теенди* – тегенди, *нии* – нигә.

***Й*** төшә: *қаа барасин?* – кая барасың?

***Н*** төшә: *мича* – мунча, *мичала* – мунчала.

Аерым очракларда сүзләрдә иҗекләр һәм берничә аваз төшеп калырга мөмкин: *қычра* – әд. кычкыра, *қырыша* – кычкырыша, *эшелми* – ишетелми.

**Метатеза.** Метатеза күренеше (ягъни авазларның һәм иҗекләрнең урыннарын алмаштырып сөйләү) түбәндәге бер төркем

сүзләрдә күзәтелә: *әрйән* – әд. әйрән, *қырйық/кырйык* – койрык, *саумар/самырау* – самовар, *қарйақ/карйак* – кайрак, *үчләмә* – үлчәргә, *бәрйәм* – бәйрәм.

Югарыда күрсәтелгән фонетик үзенчәлекләрдән тыш, нократ сөйләшендә тагын кайбер борынгы күренешләрнең саклануын да искәртеп китәргә кирәк. Мәсәлән, түбәндәге сүзләрдә: *артқылы/арткылы* – аркылы, *астылы-эстеле* – аслы-өсле. Биредә *т* тартыгы саклану тарихи яктан борынгылыкның чагылышы дип карала.

Билгеле булганча, татар әдәби телендә *у* сузыгы сүзнең беренче иҗегендә генә кулланыла, ә нократ сөйләшендә кайбер сүзләрдә икенче иҗектә дә килергә мөмкин: *булумады* – булмады, *тулумады* – тулмады.

### *Морфологик үзенчәлекләр*

**Исемнәр.** Нократ сөйләшендә иркәләү кушымчасы әдәби телдәге кебек *-кай/-кәй* итеп түгел, ә *ку°й* формасында әйтелә һәм сүзнең беренче иҗегенә кушыла: *Камкуй* – Камиләкәй, *әтку°й* – әткәй, *әңку°й* – әнкәй, *җанкуй* – җаныкай, *Бибкуй* – Бибкәй.

Исем, алмашлык, сыйфат һәм саннарга өченче затта икешәр зат тартым кушымчасы ялгап сөйләү үзенчәлекле: *арыш ынысы* – арыш оны, *икесегез* – икегез, *барсыбызны* – барыбызны, *берсебез* – беребез, *өчесебез* – өчебез, *сет эстесе* – сөт өсте.

Исем белән исем янәшә килеп ясалган сүзтезмәләр бу сөйләштә күп очракта кушымчасыз гына кулланылалар: *сабан туй/сабан ту* – сабан туе, *печәй бала* – песи баласы, *йиералма баз* – бәрәңге базы, *аwыл калык* – авыл халкы, *ылы йул кайын* – олы юл каены, *Қазан қала* – Казан каласы, *Мазар тау* – Мазар тавы, *тау бит* – тау бите, *әүлийә кабер* – әүлия кабере, *корбан бәйрәм* – корбан бәйрәме, *аwыл йак эниш* – авыл ягы инеше, *Чүпче йылга* – Чыпца елгасы һ. б.; *Сабан ту тау биттә сабан тулар булгалады.* – Сабан туе тау битендә сабан туйлары була иде; *Чүпче йылга арйагында Гурийә-Кала аwылы.* – Чыпца елгасы аръягында Уръякала авылы.

Иялек һәм төшем килешендәге исемнәр һәм алмашлыкларга *-кысы/-кесе* кушымчалары ялгап сөйләүне нократ сөйләшенең төп морфологик үзенчәлекләреннән берсе дип әйтергә мөмкин: *безнекесе бақча* – безнең бакча, *қызымнықысы шал'* – кызымның шәле, *аныңкысы бар* – аныкы бар, *анынқысы йаwлық* – аның яулыгы, *синенкесе сабын* – синең сабының, *безненкесе йиералма* – безнең бәрәңге.

*-ныкы*(*сы*)/*-ныңкы*(*сы*) формасындагы тартым кушымчасы алган исемнәр һәм алмашлыклар, исемнәр алдыннан килгәндә, аергыч ролен үтиләр: *минеңкесе кыз* – әд. минем кыз, *безнекесе аwыл* – безнең авыл, *күршенеке малай* – күрше малае, *аныңқысы йаwлық* – аның яулыгы, *безнеңкесе йералма* – безнең бәрәңге, *Қазанныңы қатын* – Казан хатыны, *аwылныкы қызлар* – авыл кызлары.

Әдәби телдән аермалы буларак, сан һәм исем сүз төркемнәре янәшә килгәндә, исемнәргә күплек кушымчасы *-лар/-ләр* ялгана: *Беш кешеләр тороп китте.* – Биш кеше торып китте; *Ике қазлар бирдем.* – Ике каз бирдем; *Кош көн кызларга кәбен салгаладым.* – Кыш көне өч кызга никах укыдым; *Мин ике ирнең алты балаларын үстергәндә.* – Мин ике ирнең алты баласын үстердем.

**Алмашлыклар.** Нократ сөйләшендә *шул* күрсәтү алмашлыгы кулланылмый, аның урынында *ул, бу, алай, былай, андай* (әд. шул, шушы, шулай, шушылай, шундый) алмашлыклары кулланыла. Мисаллар: *Андай йил* (әд. шундый җил), *бер дә барма булмай. Ул уқ кешеләр* (шул ук кешеләр) *барды бүген дә қалага. Алай йылай абыстам* (шундый елый апам). *Ул уқ йиргә* (шул ук җиргә) *килеп чықтық урманда.*

Нократ сөйләшендә тагын түбәндәге алмашлыклар кулланылуын күрсәтеп китәргә мөмкин: *беттегесе* – әд. бөтенесе; *кемки* – кемдер; *ники* – нидер, нәрсәдер; *қайки/кайки* – кая да булса.

Мисаллар: *Беттегесе безнең йәwер бу тирәдә; Кемкидә бардыр ул йырулар; Ники йазма таптығыз шәт? Кемки әүлийә қабере бар безнең зиратта.*

### *Затланышлы фигыль формалары*

**Фигыльләр. Хикәя фигыльләр.** Нәтиҗәле үткән заман белдерү өчен, *-ып/-еп* формалы фигыльгә зат кушымчалары ялганып ясалган фигыль формалары актив кулланыла. Фигыльләрнең мондый формалары татар теленең мишәр диалектында һәм себер татарлары сөйләшләрендә күзәтелә. Ләкин биредә, башка сөйләшләрдән аермалы буларак, зат кушымчалары булып зат алмашлыгы үзе кабатланып килә. Мисаллар: *Тее китапны мин ынытыпмин ич; Йықлап китеп мин, сез қайтқанны сизмәпмин; Ызак, тырыпсыз икән Нухратта; Арыпсин инде, утыр чәй эчмә; Йаман шәп бешерепсин, ди, бийагай әйтә, йаман тәмле булган, ди. Син торган кеше булдырмапсин дә, ниги йәш килен кеше*

*булдырган, ди; Андай тәмле йыкълап мин; Ничек чыдапбыз йәш килен чакъта.*

Төрләнеш үрнәге: *мин барыпмин* – мин барганмын, *син барыпсын* – син баргансың, ул барган, *без барыпбыз* – без барганбыз, *сез барыпсыз* – сез баргансыз, алар барган(нар).

Мисаллардан күренгәнчә, *-ып* формасы I һәм II затларда гына килә, III зат *-ган* формасы белән белдерелә: *ул алган, алар алганнар.* III затта үткән заманның *-ып* формасы белән ясалуы сирәк очракларда гына күзәтелә: *Метик кенә йымыркъа салыптыр; Соңра күреп микән сон? Алай булып энде.*

Нократ сөйләшендә *-п* формалы фигыльләр юклык кушымчасы да (*-ап/-әп*) алалар: *Самwарны сулы къуймапмин ич; Йәшмәпсез бит мине къунаккъа; Ашамапсин ич къоймакъны.*

Юклык формасының I зат күплеген *бармамбыз* формасында (ике катлы зат кушымчасы белән) ясау да нократ сөйләшендә бик актив күренеш: *Экәү йермәмбез инде сет эчен; Аларда ызак, утырмамбыз; Бик тиз къайтмамбыз, диде; Күп арчымамбыз боранғыны.*

Төрләнеш үрнәге: *мин алмам, син алмассин* – син алмассың, ул алмас; *без алмамбыз* – без алмабыз, *сез алмассез* – сез алмассыз, *алар алмас*(*лар*).

Күптән үткән заман формасы *-ғала/-гәлә, -къала/-кәлә* кушымчалары ярдәмендә белдерелә: *Ул къайткъалады мени йәй кен; Чәчүгә чыкканчы булгалады сабан туй; Уналты йәштән кийәүгә биргәләделәр козларны; Эшчән козлар, къулбашлылар, дип, безгә йаучыга килгәләделәр; Мин үзем Биктәштән, бу авылга тормышка чыккаладым; Мин ул китапны укъыгаладым.*

Хикәя фигыльләрнең кабатлаулы үткән заман формасы сыйфат фигыльнең *-ыр/-ар* формасы һәм *иде, ыйы* ярдәмче фигыле белән ясала. Юклык (*-маq*) кушымчасы фигыль нигезенә, ә зат кушымчалары *иде* ярдәмче фигыленә һәм, күпчелек очракта, төп фигыльгә дә ялгана ала. Мисаллар: *Кистемгә утырмага барыр идек түwенчекләр белән; Йыгырлагач киндырны сугарсын иды, тукмакларсын иды, талкырсын иды тузан ычында; Сонгра куршыларынны чакъырырсын иды; Сылгы бирырсын иды бул'акка; Чепчәгине майга салып пешерерсен иде.*

Кабатлаулы үткән заманның *-ыр/-р + -ыйы/иде* формасын куллану ягыннан нократ сөйләше урта диалектның казан арты, бәрәңге, керәшен, минзәлә сөйләшләренә якын тора.

Хикәя фигыльләр өлкәсендәге диалекталь үзенчәлекләр зат кушымчаларының формалашуында да чагыла. Мәсәлән, I һәм II затларда хәзерге заман формалары: *-мин, -без; -син, -сез: Қазанча сүләшмә булдырмыймын; Бармаймин, утқа салсагыз да қайтмаймин ди абыстам; Мича йагучыга селге саласин; Қайтқач әйтә мин, абыстай, кийәwеңне күрдем, қулына тайақ тотқан, димин; Баwыр турайсин, ит турайсин; Чәчүгә чыкканда чәчү йомыркасы пешерәмин, оланнарны ашатамин. Кучактан* (тәрәзәдән) *чыгамин да китәмин* (чыгам да китәм). *Сыйыр асыраймин* (асырыйм).

Төрләнеш үрнәге: *мин бармаймин* – мин бармыйм, *син бармайсин* – син бармыйсың, *ул бармай* – ул бармый; *без бармайбез* – без бармыйбыз, *сез бармайсез* – сез бармыйсыз, *алар бармайлар* – алар бармыйлар.

### *Затланышсыз фигыль формалары*

**Инфинитив.** Нократ сөйләшендә инфинитивның түбәндәге формалары бар.

*-ма/-мә* кушымчасы белән ясалган инфинитив. Ул форма сөйләштә актив кулланыла һәм үзенең мәгънәләре, функцияләре буенча әдәби телдәге төрле сүз төркемнәре урынында килә:

а) әдәби телдәге *-ырга/-ергә* формалы инфинитив: *Мин сийләшми йаратам; Алдашма биг оста; Туй багышма йердем; Чәй эчмә утыр; Чөгендер алма чыктым; Бийем тәбгый бешермә чыкты.*

б) *-ма/-мә + тели* формасы әдәби телдәге *-ырга/-ергә + тели* яки *-макчы/-мәкче + булу* формасына туры килә: *Кемгә қат йазма телисин? Қалага барма телим; Йегер йегерләмә телим.*

в) *-ма/-мә* формасы *йабышу* (әд. башлау), *булдыру, белү* фигыльләре белән килгәндә *-а, -ә/-ый, -и* формалы хәл фигыль мәгънәсендә кулланыла: *Абыстай йылама йабышты; Әйтмә булдырасинмы арча; Былыт келмә йабышты; Йуwышма йабышқан, суwы аз гына; Гурийә-Кала аwылына барып қайтма йулны белерсинме.*

*-ма/-мә* формалары белән җөмләдә ия, тәмамлык һәм аергыч мәгънәләре дә белдерелергә мөмкин: *Безгә уқыма* (уку) *булмады энде. Бырын астыбызга йеткән печән чапма* (печән чабу). *Ашама* (ашарга) *йетте қәзер, чыгып китмә қызым. Алар анда йыру әйтмә* (җырлаганны) *тыңнашып тыралар. Бер тапқыр қырт чақты, суга сикермә* (сикерергә) *булдым. Безгә кумма* (кунарга) *керделәр.*

*-ма/-мә* кушымчасы белән ясалган инфинитив урта диалектның тау ягы норлат һәм тау ягы керәшен сөйләшләре өчен характерлы.

*-мага/-мәгә* кушымчалы инфинитив әдәби телдәге төрле фигыль мәгънәләрендә кулланылырга мөмкин:

а) *-ырга/-ергә* формалы инфинитив мәгънәсендә: *Урманга китте утын чапмага; Бармага-кайтмага йаҡын; Ҡызым ҡалага уҡымага барды; Әткуй урманга шымырт агач кетермәгә барды; Мин чирләмәгә йабыштым.* – Мин чирли башладым; *Ашама-эчмәгә чимийәгә йасадым*;

б) *-а/-ә, -ый/-и* формалы хәл фигыль мәгънәсендә: *Йаңгыр йаwмага йабышты; Мин рәсем йасамага белмәйем; Печән чапмага булдырасынмы; Болом саламат* (болында боламык) *пешермәгә булдырмаймин хәзер;*

в) *-ып/-еп* формалы хәл фигыль мәгънәсендә: *Бу кучакны тәрәзәне ачмага булмай; Мында качилка белән чапмага булмай былымны.*

*-мага/-мәгә* (бармага) кушымчалы инфинитив урта диалектның характерлы морфологик үзенчәлеге санала. Бу форма урта диалектның касыйм, гәйнә, бәрәңге, казан арты-балтач сөйләшләрендә дә актив кулланыла. Мамадыш һәм минзәлә сөйләшләрендә бу форма *алмага* фигыле белән генә очрый.

*-асы/-әсе* формалы инфинитив әдәби телдәге *-ырга/-ергә* формасы белән туры килә: *Әллә сезне тыннашасы, әллә чыгып кизүләсе; Уттан бик таза сакланасы; Аш казанга су саласы; Миңа ҡәзер калага китәсе; Килынны кийашка каршы яктан кыртасы дип силәрләр иде; Алмаш кизү кизүләсе киленнәргә. Икмиген бешерәсе, шангийын бешерәсе, табикмәк бешерәсе.*

*Кунакка муча йагасы, пич каршында тәбик* (тәбикмәк) *пешерәсе. Чишмәкүзгә* (чишмәгә) *таудан гына төшәсе. Баланы тугач заҡ тотасы дегел, әби* (йорт анасы) *алыштыра аны. Ат саласы* (исем кушасы) *тиҗерәк. Эч кендән артыҡ тотасы дегел. Ҡолагына ҡычҡырасы эч тапҡыр атап. Кырдан кайтасы, тәкә суйасы, пуминкага барасы дип сөйләшәләр бичырманнар. Йегерләсе куб ийе элек. Ҡазботҡа пешерәсе ҡаз утаучыларга* (каз йолкучыларга).

*-асы/-әсе* формасы *иде* һәм теләү сүзләре белән килгәндә көчле теләк мәгънәсе белдерелә: *Уҡысы иде безгә ул китапны.* – Укырга иде безгә ул китапны; *Ыстанчага китәсе телим.* – Станциягә китәргә телим.

*-асы/-әсе* формалы фигыльләр урта диалект сөйләшләренең барысында да диярлек табыла һәм бу үзенчәлек урта диалектның төп билгеләреннән берсе булып санала.

Сыйфат фигыль формалары, әдәби телдәге кебек үк, берничә төрле.

а) *-ган/-гән, -қан/-кән* формасы: *Үрәнмәгән эш.* – Өйрәнмәгән эш; *Қалган ашлыкны суwыртма йабыштық.* – Калган ашлыкны суырта башладык; *Быйыл уқыган бик кәрәк.* – Хәзер укыганнар бик кирәк.

б) Сөйләштә сыйфат фигыльләрнең *-асы/-әсе* формасы актив кулланыла. Ул биредә әдәби телдәге *-ачак/-әчәк* формасын да алыштырып килә: *Дүшәмбе кен туй буласы. Тәтә қаладан беген қайтасы. Эштән қайтасы кешем бар.*

в) *-ыр/-ер/-р* формалы сыйфат фигыль, нигездә, ике яшәр бала кебек сүзтезмәләр эчендә генә кулланыла: *Эке йәшәр тай йегеп калага йердем. Алтмыш йәшәр қарт инде мин.*

*-ыр/-ер* формалы сыйфат фигыльләр борынгы чорда актив кулланылган булырга тиеш. Мәсәлән, XIV йөз әсәре «Кыйссаи Йосыф» поэмасында түбәндәге юллар бар: *Газиз Йосыф унбер йәшәр иде.* Шушы ук форма әйтемдә: *Алты йәшәр йулдан қайтса, алтмыш йәшәр хәл белә килер.*

г) *-учы/-үче* формалы сыйфат фигыль нократ сөйләшендә шактый актив кулланыла. Ул әдәби телдәге формадан аерылмый, ләкин аерым очракларда мәгънәләре ягыннан кайбер үзенчәлекләр күзәтелә. Мисаллар: *Иргә баручы кызның* (бара торган кызның) *арабасы wатылгалаган. Ипи куwас белән өйгә керүче* (өйгә керә), *диләр ийе өй әбине. Син қайчан қайтучы булырсин? Йаман сөйләшүче* (сөйләшә торган) *ийем мин. Чигешүче* (чигүче) *ийек бийемем дә, үзем дә. Өй саклаучы қала бит, гүчтинәч алып қайтасы.*

Нократ сөйләшендә татар теленең башка диалектларында табылмаган -*ганда* формалы фигыльләр дә кулланыла: *Ике улы сугышта йугалганда; Мында балалар кечкенәдәнтен арча* (удмуртча) *ирәйгәндә; Син аwыл кейләрен йырлаганда; Атны бик матурлаганда була туйга барганда; Минем әле чалгы да саплаганда йуқ; Учителләр идә йуқ кеткәндә; Мырйа ачық торганда; Шақмақлап суққанда була йулашаулык; Киленнең әйләнәсе тулганда* (Килен юанайган, ягъни бала көтә).

-*ган/-гән* формалы фигыльләр урынына *-ганда/-гәндә* формаларын куллану нократ сөйләшенең төп үзенчәлекләреннән берсе булып тора.

**Хәл фигыльләр.** Аларның актив кулланыла торган формалары түбәндәгеләр:

*-гачын/-гәчен: Қода узгачын қыз белән кийәүне қунаққа чакыралар; Туй йегетләр, туй қызлар қызны йәрәшкәчен, селге биргәчен дә туйны хәстәрләмә йабышалар; Кыз йақ селге биргәчен, ол йак, башакча биргәләгән; Қар беткәчен дә сабан туйы булгалады; Рошпо* (рождество) *йеткәнен чана шугаладык; Қаз бутқаларны ашап бетергәчен уйнагаладылар.*

*-ганның сонгра, соңра, соңгра* (барганның сонгра) формасы *-гач/-гәч* формалы хәл фигыль мәгънәсенә туры килә: *Килен төшкәннең сонгра килен мича йагалар; Сөлге алма килгәннең соңра ол йактан кийем китерәләр; Бер ай ашатканның соңра қаз кукай салма йабыша; Кийәү күрешмә кереп чыкканның соңгра, кайнана керә килен аwызландырмага; Килен салмасын йәйеп бетергәннең соңра бер сабый баладан йырттыралар.*

Нократ сөйләшендә хәл фигыльләрнең *-мастан/-мәстән, -мастан алда/-мәстән алда, -мастан элек/-мәстән* элек формалары да еш кулланыла: *Бай қатын қанатны үзе қулы белән бирми, кеше күрмәҫтән бәреп қалдыра қанатны* (ырым); *Ат белән барганда кийәү аттан төшә қапқага йитмистән алда; Пешеп йитмәстән алда йийып кайткаладылар кор бороны.*

*~ыш/~еш* кушымчалы фигыльләр. Нократ сөйләшендә *-ыш/-еш* кушымчасы, еш кына, фигыльнең тамырына ялганып килә һәм бернинди мәгънә төсмере өстәми: *Йуwышмага* (кер чайкарга); *Сагыз чәйнәшмәгә йарамай; Тегешмә* (тегү тегә) *беләм; Эзән* (идән) *йуwышам; Сайрашма* (сөйләшергә) *керделәр; Ул йәшләргә әйтәсин, көлешәләр, йукка әйтәсин, дилир, тыннашмайлар; Бейем иртүк тора да йамашып утыра, бәйләшеп утыра; Кучак астында* (тәрәзә астында) *тыннашып йөрибез чибитйада* (яңа елда); *Әни андай тегешүче булгалаган; Йәш киленга су өчен барасы, пичләр йагышасы була; Каз йуwышалар чишмә күздә.*

**Теркәгечләр.** Нократ сөйләшендә кушма җөмләләрдә дә, гади җөмләләрдә дә *ки* теркәгече актив кулланыла һәм сөйләмгә төрле мәгънә төсмерләре өсти.

Кушма җөмләләрдә *ки* теркәгече иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чара буларак килә һәм әдәби телдәге *әгәр* теркәгечен алыштыра. Шулай ук *-са/-сә* формалы шарт фигыль мәгънәсен дә өсти: *Китап ки бар* (булса); *Искерсә ки* (әгәр), *таш та тишекләнә*

*икән; Казан йаққа барсаң ки, безне аңламаслар; Қайтмаса ки, бармаса ки, түwенчеген түнеп куйсын; Кийәү кергәндә алдан коз эндәшсә ки, козның сүзе өстен була, малай эндәшсә ки, малайның сүзе өстен була; Вирба* (тал ботагы) *белән суккаласа ки, оланның йылагы бетә.*

Гади җөмләләрдә кулланылган *ки* теркәгече шулай ук сөйләмгә төрле мәгънә төсмерләре өсти: а) чамалау, билгесезлек мәгънәсен бирә һәм әдәби телдәге *бугай, шикелле* сүзләренә һәм *-дыр/ -дер* кушымчаларына туры килә: *Қаа* (кая) *китсен йанйаулыгың* (кулъяулыгың), *кучаг* (тәрәзә) *асқа төште ки; Кем ки әби йырлап бездә; Нәселтамыр ни ки булса да китерә әйбер, тапийын кытлап; Кем ки бийи, сөлге айыралар* (бүләк итәләр); *Анда кем ки әулийә үлгән инде.*

б) сорау алмашлыклары белән килгәндә сөйләмгә билгесезлек төсмере өстәлә: *Қаа ки барасыңмы беген? Қаа ки киткән булыр чебиләр; Ни ки йазма таптыгыз шәй; Қа ки аулаги булса кирә идек.* – Кайда да булса аулак өй булса кирә идек.

в) шарт фигыльләр янәшәсендә килә һәм шарт мәгънәсен көчәйтә: *Бала йыласа ки, артыш йандырып төснилэр; Ыҗҗан* (эч авыртуы) *булса ки, йылама йабыша ол-кыз; Үлсәң ки, йумаға кирәк; Раштуwада қарт таwық тотса ки, қартқа китә; Кем булса да үлсә ки, койаш туганчы йумаға су китерәләр; Катыннар үлсә ки, өчесендә катыннар була үлек ашында; Йаңгыр йаумаса ки, тәкбәр төшерәләр; Бәбәй йыласа ки, таңсу* (таң суы) *алдыралар.*

Нократ сөйләшендә, әдәби телдән аермалы буларак, *исә* теркәгече дә бик еш кулланыла: *Салқын су кирәк исә кертмә булдырырыңмы? Йаңгыр йауды исә, әйберләрне өйгә керт.* – Яңгыр яуса, әйберләрне өйгә керт; *Сабан туй исә күрше аwыллар килә ийылып.* – Сабан туе булса күрше авыллар җыелып килә; *Иртә тырдым исә, сине уйатам. Хатны биг усал йаздым, танырсыңмы исә?* – Хатны бик начар яздым, танырсыңмы икән? *Эр кешеләребез кәбен кийем бирә инде, күлмәг исә, йаулыг исә, читекләр исә.* – Ир ягы кәбен киеме бирә, күлмәкме, яулыкмы, читекләрме; *Каршыға кем килә исә, йомырқа бирмә қушқаладылар қайwан қуганда.* – Каршыга кем дә булса килсә, хайваннарны көтүгә куганда йомырка бирергә кушалар; *Йыл килешмәде исә, айак алыштырабыз, алыштырырга булса.*

*Исә* теркәгече еш кына *ки* теркәгече белән янәшә килә ала: *Ол* (малай, ул) *йактан кийем китерәләр исә ки, коз йактан да кийем*

*китергән; Коз йактан ун кеше бара исә ки, ун чепчеги* (чәкчәк) *йасап илтәләр; Дүрт кеше йуwалар исә ки, дастар башы тоталар; Кем туй итә исә ки, ул бүләк айыра* (өләшә); *Менә мин туй итәм исә ки, илле кеше килә исә ки, илле кешегә бүләк айыралар; Суга йақын кэлдик исә ки, киленне суга кертә идек тартып; Эче аwырта исә ки, йаман йылай ол-қыз.*

*Шай* (< рус. чай) модаль сүзе фараз итүне белдерү өчен кулланыла: *Унны шай бетергән* (бетергәндер) *ул; Мында күршегә генә чыққаладым, ызак тырдым шай; Уйлаганга шай йокыга кырмыйсын* (талмыйсың); *Шай акыл'тылатып* (алҗытып) *бетердем тәтәне; Кем ки килә шай, карылдым* (тончыктым); *Нухрат сөлге, дип әйтәләр, нухратлар шай аны сукканнар; Гыби* (гөмбә) *белән кукыли* (бөккән) *пешерәсин шай; Бәлеш қабық ашаганга шай, чәй күп эчтем йаман.*

Максат мәгънәсе, әдәби телдән аермалы буларак, *өчен/ычын* бәйлеге белән белдерелә: *Коз алучылар коз эчен баралар чиңгелеләр* (кыңгыраулар) *тагып; Бикәчәме су йулын күрсәтә, бидыра-күwәндә белән су эчен бара йәш килен; Килен иртә белән су ычын барса, ыланнарга садап айырыр иды; Лафкага икмәк эчен барасы; Салам эчен барганнар; Артыш өчөн без қырга барайық.*

## Нократ сөйләшендәге урынчылыкларга хас үзенчәлекләр

Тарихи сәбәпләр аркасында, татар халкының төп өлешеннән территориаль яктан аерымланып, удмуртлар һәм руслар арасында яшәп калганлыктан, нократ татарлары сөйләшендә (шулай ук аларның гореф-гадәтләрендә дә) җирле халыклар белән уртаклыклар барлыкка килгән.

Тел үзенчәлекләрен лингвистик география методы белән өйрәнү процессында, нократ сөйләшенә хас дүрт урынчылык булуы ачыкланды:

1) Нократ урынчылыгы. Ул Киров өлкәсе Слободской районындагы татар авылларын үз эченә ала;

2) Кистем урынчылыгы. Ул Чыпца елгасының югары агымындагы Кистем, Паюра (Падера), Биктәш, Әхмәди авылларын (Балезино районы) һәм Татар Парҗысы, Пүчинкә авылларын (Глазов районы) берләштерә.

3) Юкамен урынчылыгы. Ул Глазов (элеккеге Юкамен) районы татар-бисермән авылларыннан Дасис (Засеково), Тегермән авыл

(Тат. Ключ), Атабай (Богошур), Иманай (Иманаево), Шәфидә (Шафеево) яшәүчеләргә хас.

4) Бисермән-керәшеннәр урынчылыгы, ул Бурча районы Яр (Ярово), Глазов районының Тегермән авыл (Тат. Ключ) һ. б. кайбер авылларда яшәүче бисермән-христианнар сөйләшенә карый.

Нократ һәм кистем урынчылыклары арасында аермалар зур түгел. Алар, берникадәр, фонетикада, морфологиядә, лексикада күзәтелә.

Сүз башында тел уртасы *й* авазы өстәлү нократ урынчылыгында аеруча актив: *йертә* – әд. иртә, *йере* – эре, *йез* – эз, *йезгәләй* – өзгәли, *йертейпейе* – иртәнге аш. Кистем урынчылыгында мондый әйтелеш сирәгрәк очрый.

Нократ урынчылыгында иркәләү кушымчасы әдәби телдәге кебек -*кай/-кәй* итеп түгел, ә *ку°й* формасында әйтелә һәм сүзнең соңгы иҗегендә кушыла: *Камку°й* – Камилкәй, *Шамку°й* – Шамилкәй, *әтку°й* – эткәй, *әнку°й* – әнкәй, *җанку°й* – җаныкай, *Бибку°й* – Бибкәй.

Нократ урынчылыгында, кистем урынчылыгы белән чагыштырганда, тел арты *ҳ/х* авазы системалы төстә кулланыла: *ҳат, ҳәл, бәҳет, нуҳрат*. Ә кистем урынчылыгында *ҳ/х – ķ/к* күренеше активрак: *ķалыķ* – әд. халык, *ķөрмәт* – хөрмәт, *ķәзер* – хәзер, *Шәйķулла* – Шәйхулла, *Рәķимҗан* – Рәхимҗан.

-*мастан* формасындагы хәл фигыльләрнең актив кулланылуы ягыннан да нократ урынчылыгы берникадәр аерылып тора. Нократ урынчылыгында -*мастан* формасы: а) эш яки хәлнең сәбәбен, максатын белдерә ала: *Баш аwыртмастан* (авыртмаска) *чәй эчәбез; Серен* (сөрем, ис) *тимәçтән мырйаны ачтым; Сыйырларны суга җибәрмәстән* (җибәрмәс өчен), *көтүчеләр алга киттеләр*.

б) *элек, алдан* сүзләре белән килгәндә эш яки хәлнең вакытын белдерә, ягъни -*ганчы* формалы хәл фигыль урынында кулланыла: *Ыныtмастан элек* (онытканчы) *мынсын йаз. Коз алма баралар йертә таңнан, халык, урамга таралмаçтан элек* (таралганчы). *Кәбен булмаçтан алда* (никах укытканчы, укытыр алдыннан) *кыз ийендә тенге туй була. Казлар төшмәçтән элек* (төшкәнче) *ташыйбыз суны. Коз йактан кийаш байымаç элек* (кояш баеганчы) *чыгалар, кийаш байыгачын чыгармыйлар. Чәчүгә төшмәçтән элек* (төшкәнче) *сабан туй булгалады*.

*Зиратķа ķырыķ адым йитмис элек* (җиткәнче) *ойалып узайыķ. Печин чапма чыķмастан элекеләрдә* (чыкканчы) *әүлийә ķабергә*

*ҡорбан чалгаладылар. Күммәҫтән алда* (күмгәнче) *үлек булган өйгә илтеп баралар ризыҡлар, андай гадәт.*

«Татар теленең диалектологик атласы»нда чагылдырылган лексик материаллар буенча да нократ һәм кистем урынчылыклары берникадәр аерылалар.

| **нократ урынчылыгы** | **Кистем урынчылыгы** | **Әдәби** |
|---|---|---|
| *морйа* | *пич* | мич |
| *мәләкәй* | *бәләкәй* | *мендәр* |
| *әржҫә* | *сондок/сандык* | *сандык* |
| *атланмай* | *аталамай* | *атланмай* |
| *алчүпрәк* | *алйапкыч* | *алъяпкыч* |
| *ачҡыч бау* | *ҡәсипә* | *чабата киндерәсе* |
| *бабача* | *бабач* | *әтидән олы ир кешегә эндәшү сүзе* |
| *аба/абый* | *апыч* | *олы ир туганына эндәшү сүзе* |
| *утлыҡ* | *сызгыч* | *шырпы* |

**Юкамен урынчылыгы** түбәндәге үзенчәлекләре белән берникадәр аерымлана:

*ә, э* сузыклары нократ сөйләше өчен характерлы булса да, бу урынчылыкта алар чагыштырмача сирәгрәк кулланылалар (мәсәлән, Бурча, Палагай, Уръякала авылларында): *бикәчәй* – әд. каен сеңел; *бикәм* – иренең апасы, *бэләм/бэлим* – беләм, *бэш кешеләр* – биш кеше.

Тирән тел арты (увуляр) *ҡ, ғ, ҳ* тартыклары бу сөйләштә кулланылмыйлар. Алар урынына, мишәр диалекты сөйләшләрендәге кебек, тел арты *к, г, х* тартыклары әйтелә: *кар* – ҡар, *колончак* – ҡолончак (граф. колынчак), *сағат* – сәгәт (граф. сәгать), *хат/ҡат* – хат, *Гали* – Ғәли (граф. Гали). Кайбер авылларда (мәсәлән, Палагай, Уръякала һ. б.) *ҡ/к, ғ/г, ҳ/х* күренеше күзәтелә: *ҡыз/кыз, Ғариф/Гариф, боғо/бого* – чиләк тоткасы.

Алгы рәт сузыкларын арткы рәт сузыклары белән алмаштырып сөйләү бу урынчылыкта системалы төстә күзәтелә:

***а – ә:*** *там* – әд. тәм, *айбыр* – әйбер, *мактап* – мәктәп, *тараз* – тәрәзә, *наста* – нәстә (әд. нәрсә), *айлана* – әйләнә, *байрам* – бәйрәм;

***ы – э(е):*** *кым* – әд. кем, *ыл'ык* – элек, *тышым йук* – тешем юк, *кычкына* – кечкенә, *ындаш* – эндәш, *быркым* – беркем, *ычым йана* – эчем яна, *читын* – читен, *кыра* – керә;

***о – ө:*** *йогормо оч* – әд. йегерме өч (граф. егерме өч), *котоп тор* – көтеп тор, *кон* – көн, *тон* – төн, *корпа* – көрпә, *комош* – көмөш (граф. көмеш), *сот* – сөт;

***у – ү:*** *кур* – әд. күр, *тубан* – түбән, *угыз* – үгез, *кукай* – күкәй, *курсата* – күрсәтә, *кумыр* – күмер, *куз* – күз.

*л* һәм *т* тартыкларының нечкәрүе (палатальләшүе) башка урынчылыкларга караганда ешрак күзәтелә: *Л'амига* – Ләмига, *ал'а кайда* – әллә кайда, *ыл'ык* – элек, *каз т'уту* – каз бәбкәсе, *интернат* – интернат.

Сирәк очракта: *сыз'ык/соз'ок* – сызык.

Аңкау гармониясенең бозылуы, ягъни сүзләрнең калынлы-нечкәле булып кулланылуы, шулай ук, башка урынчылыклар белән чагыштырганда, активрак: *китыр* – әд. китер, *бишенче кын* – бишенче көн, *алерак кына* – әлерәк кенә, *ышым* – эшем, *тәмны* – тәмне (әд. тәмле), *мескенкайым* – меңкенкәйем, *пескайым* – пескәйем (граф. пескәем).

Сүз башында *й/җ* икесе параллель кулланылырга мөмкин: *йылы/җылы, йил/җил, йерәк/җөрәк/җорак* – әд. йөрәк, *йанагай/җанагай* (иренең энесе).

Сүз һәм иҗек ахырында *н–ң* күренеше актив: *тыннаш* – тыңна (әд. тыңла), *тунам* – туңам, *монно* – моңно (әд. моңлы), *ун йак* – уң як, *безнен* – безнең; *Алтын алкаларым сынды, алырсын* (әд. алырсың) *микән алка. Булырсын микән үземә, калырсың микән йатка* [җыр].

Хәл фигыльнең *-мача/-манчы* формалары кулланыла: *кайткаламачы йергән* – кайтмыйча йөргән, *кинаманчы илтәм* – кыйнамыйча илтәм.

*-ып/-еп/-п* формалы нәтиҗәле үткән заман бу урынчылыкның Палагай, Бурча, Уръякала авылларында гына очрый: *Сүткәләпсин түwенне* – әд. сүткәнсең икән төенне; *Онотопмин ипине пистә* – Онытканмын икән ипине пичтә; *Усал масырупка алыпсыз.* – Начар иттарткыч алгансыз.

Зат һәм күрсәтү алмашлыклары янында *кебек, өчен, белән, төсле, шикелле* бәйлекләре килгәндә иялек килеше кушымчасы ялганмый: *без өчен* – әд. безнең өчен, *сез шикелле* – сезнең

шикелле, *мин кебек* – минем кебек, *бу кебек* – моның кебек, *бу белән* – моның белән, *мин кебек силәшүчән* – минем кебек сөйләшүчән.

Зат алмашлыклары исемнәр белән янәшә килеп ясалган сүзтезмәләрдә дә алмашлыкларга иялек килеше кушымчасы ялганмый: *без аwыл* – безнең авыл, *сез йак* – сезнең як, *без ул белән киттек; сез без йаннан уздыгыз* – сез безнең яннан уздыгыз, *үзебез йак киләре* (көйләре).

Инкарь итүне, кире кагуны белдергән *түгел* сүзе урынына юкамен урынчылыгында *йук* (юк) сүзе кулланыла: *эссе йу'мы?* – әд. эссе түгелме? *Бер кым да тыныч йук* – Бер кем дә тыныч түгел; *Кибет ачы' йу'мы?* – Кибет ачык түгелме? *Толос аwыл Пүчинкәдән йырак йук, мындантын киткән.* – Тылыс авылы Пүчинкәдән йырак түгел, моннан күченеп киткәннәр; *Казан кышылар мында күп йук.* – Казан кешеләре монда күп түгел.

Чыгыш килешендә -*дан/-дән* + -*тын/-тен* кушымчалары ялгану юкамен урынчылыгының характерлы үзенчәлеге: *кечкенәдәнтен* (кечкенәдән) *арча ирәндек. Йырактантын* (ерактан) *айбат курам, йакындантын* (якыннан) *курмим инды. Казандантын* (Казаннан) *килгәннәр. Мәскәүдәнтен* (Мәскәүдән) *армийага китты малайым. Каладантын* (каладан) *кайтып киласинмы? Монантын* (моннан) *ничә чықырым була Палагайга. Аннантын* (аннан) *йырак була кайтма. Мичадантын* (мунчадан) *йалан айак кайткан. Монантын* (моннан кадәр) *коткузы* (удм. чабата киндерәсе) *була чабатаның.*

Юкамен урынчылыгының лексикада да берникадәр үзенчәлекләре бар. Мәсәлән, «Татар теленең диалектологик атласы» материаллары буенча әлеге урынчылыкка түбәндәге диалекталь сүзләр хас: *бәкәй* – әд. бәрән, *саулык* – ана бәрән, *кукай/күкәй* – йомырка, *киндрә* – киндер, *шылан агач* – гөлҗимеш, *тезкапкач* – тез башы. Чыпца төбәгендәге башка урынчылыкларга исә боларга түбәндәге сүзләр туры килә: *сарык бала, мие, йымырка/йоморка, шыган агач, тезтәбәч* (Кистем), *тез т'аша. (Нократ)*

**Бисермән-керәшеннәр урынчылыгы** күп яктан юкамен урынчылыгына якын. Бисермән-керәшеннәр урынчылыгында, *и* сузыгыннан кала алгы рәт сузыклары (ягъни нечкә сузыклар) юк: *йта* – әд. әйтә, *айбыр* – әйбер, *корпа* – көрпә, *бутан* – бүтән, *токорма* – төкермә, *йорак* – йөрәк.

Сүзләрдә авазлар гармониясе бозыла, ягъни сүзләр калынлы-нечкәле булып әйтеләләр: *икы* – әд. ике, *җиды* – җиде, *балиш* – бәлеш, *сийына* – сәйенә (граф. сөенә), *абилар* – әбиләр.

Нечкәртелгән *л'* тартыгы еш кулланыла: *кыл'* – әд. көл, *ыл'ык* – элек, *был'а* – белән, *кул'мак* – күлмәк, *ул'ык* – үлек, *кил'ап* – киләп, *ыл'ган* – элгән, *мил'л'ык* – миллек (әд. мунча себеркесе), *ышл'ама-га* – эшләргә, *ал'апкыч* – алйапкыч (граф. алъяпкыч), *ыл'ыш* – өлеш.

*-йым/-йем* кушымчасы белән тартымлы сүзләр ясалу күбрәк күзәтелә: *кызыйым* – әд. кызым; *барангыйым* – бәрәңгем; *мичайым* – мунчам; *акчийын кайа* – акчаң кая; *барангы пичийымда* (пичемдә) *пыша; Фанийайымны кытам* (көтәм).

Теләкне *кыла/кела, телә, -ма кыла* формалары белән белдерү: *Бызныкы малай Ундри салма кылады исымны* (Безнең малай исемне Андрей дип куштырырга теләде); *Синга йебарымын дип клаган идым* (Сиңа җибәрергә теләгән идем); *Шанги пышырма кыладыкилыным* (Киленем шәңгә пешерергә теләде).

**Нократ сөйләшенең лексик үзенчәлекләре**

Нократ сөйләшендә әдәби телдә булмаган бик күп сүзләр табыла. Аларның күпчелеге төрки-татар сүзләре, шулай ук башка теллəрдән кергән алынма сүзләр дә байтак:

а) әдәби телдә булмаган сүзләр: *беме* – әд. өмә, *быйыра* – җилен: *Кәзәләрнең быйыралары бызылган; Чипча йуwачта* (*теге ягында*) *безнең былымнар*; *Йәwерләре* (нәсел, токым, нәсел-ыруглары) *белән кулбашлы* (кул эшенә оста) *алар; Қарчыҡ қолаҡай* (саңгырау), *қолагы эшитми; йанйаулыҡ* – кульяулык: *Йанйаулыгыңны* (кульяулыгыңны) *алмапсын* бит; *Бездә сезгә йабыгыч* (күңелсез) *түгелме; Таш башбаталар* (каберташлар) *бар безнеке зиратта; йулашаулыҡ* – кеч-кенә, юлга алып йөрү өчен әзерләнгән ашъяулык; *аш айыручы* – аш бүлүче; *бишек астылыҡ* – бишеккә салу өчен әзерләнгән кечкенә матрац; *чәй табаҡ* – чәй тәлинкәсе; *йорт ысла* – өй сырасы һ. б.;

б) әдәби телдә булып та, мәгънәсе ягыннан аерыла торган сүзләр: *тепле* – әд. бикле: *Чумаданың тепләгәнме* (бикләгәнме)*? Йалгыз тормага бик усал* (читен)*; йабыгу – Сәгәте ай тик, айы йыл тик, ул қәдәрле синдин йабыктым* (сагындым); *Былай усал ашагачын, Нухраттан йалыгып* (ябыгып) *кетәрсин әле; Туктамайчы заман* (бик тиз) *барса, хәзер барып җитә.*

Алынма сүзләр. Рус теленнән кергән сүзләр, татар теленең башка сөйләшләрендәге кебек, фонетик яктан үзгәртелеп кабул ителгәннәр: *ыстанча* – рус. станция, *ычтина* – рус. стена, *ылча* – рус. улица, *гүчнич* – рус. гостинец, *кузнич* – рус. кузнец, *путулук* – рус. потолок, *убит* – рус. обед – төшке аш, *кумбай* – рус. комбайн, *кучак* – рус. косяк – тәрәзә, *даступ* – рус. заступ (тимер көрәк), *бугур* – рус. бугор, *пубрик* – рус. погреб.

Күп гасырлар буе удмуртлар белән аралашып яшәү нәтиҗәсендә бу сөйләштә удмурт теленнән кергән сүзләр дә күп.

Өй һәм хуҗалык әйберләре: *пәтери* – удм. патра, диал. петра (чорма); *чиду°н* – удм. пудо сюдон (утлык), *кургит* – удм. куреггид (җылы абзар), удм. пуйы – лампа куыгы, *гөлбәч* – удм. гүлбеч (идән асты), удм. *мажес* (кул тырмасы).

Үсемлек атамалары: *пугриҗ* – удм. огреч (кыяр), *пу°т* – удм. пот (алабута), *гомо* – удм. гумы (үлән), *быры* – удм. боры (җир җиләге), *геби* – удм. губи (гөмбә), *нанай* – удм. печин (эт эчәгесе), *шырбыҙ* (удм.) *йафрак* (бака яфрагы), *кыйбуды* (шайтан таягы).

Хайван һәм бөҗәк атамалары: удм. *папа* (күбәләк), *кошо* – удм. кочо (саескан), *кара зәлкә* – удм. зиллекей (сыерчык), *чунәри/чурәни* – удм. чонари (үрмәкүч), *куҗылы* – удм. кузъыли (кырмыска).

Биредәге авылларның топонимикасында татар һәм удмурт сүзләре белән ясалган күпсанлы географик атамалар таралган. Мәсәлән, кыр исемнәре: *ачкон'ук, кат'кыз, суганбыр;* чокырлар: *гундырлут чокор, гондыр аджон, лепетешур, сорот, кондор* һ. б.; урманнар: *карйол урман, душко урман, йыбык урман* һ. б.

Туганлык терминнарыннан гаиләдә эндәшү сүзләре: *Бийем* (кайнанам), *самрау куйдым, чәй әзер.*

*Бикәчәм* – иренең сеңлесе. *Абыз бикәм* – иренең апасы. *Мулла бийагам* – иренең абыйсы, *мулла җанагай* – иренең энесе. *Бабач* – абзый, әтисенең абзыйсы. *Амма* – бертуган апасы яки үзеннән олы хатын-кыз. *Амыкуй* – бертуган апасына эндәшү сүзе. *Зур килен, урта килен, йәш килен* – кайнана булган кеше киленнәренә шулай эндәшә.

Аш-сулар: *җабарчы* – йомыркага камыр басып, май эчендә пешерелгән күзикмәк. *Җолаҗ җабарчы* – кош теле формасындагы камыр ашы. *Тәбәгый* – төче камырдан пешерелгән баллы ашамлык.

*Йоморка сытасин, йемеш саласин, май саласин, писүк саласин, он саласин. Тәбәгый кабарып пешә инде. Бабай котлайлар безнен тәбәгый белән. Кабарып пешә, күзләреннән майлар чыгып тора. Минем бикәмем* (иремнең апасы) *белән бикәчәм* (*иренең сеңлесе*) *гомбагаш май, чима май йараталар тәбәгый пешермә. Чепчәги, чепчәк* – чәкчәк. *Туй өстәлгә кыз китерә инде чепчәги. Шанги* (рус.) – бәрәңге пәрәмәче, *т'ап-т'ап шанги* – әче камырдан пешерелгән бәрәңге пәрәмәче, *йумал шанги* – төче камырдан пешерелгән бәрәңге пәрәмәче. *Йилләткән каз* – каклаган каз.

Йола терминнары: *атбақчы* – ат багучы, ягъни туйда атларны карап саклап тору өчен куелган кеше, кучер: *Атбақчыга зур селте бирилир, қайнананың энесе була атбақчы. Атбақчы атлар йанында торма тийеш була; Қызйәмшик* – кыз + рус. ямщик – туйда кыз утырган көймәле атны тотып баручы: *Қызйәмшик кыз алма барганда ат багып бара; Қызалдычы* – кызны кияү йортына озата баручы: *Алып китәләр кызны йырлашып кызалдычылар; Кийәүсақчы* – кияү егете: *Кийәүсақчы белән кийәү йәнәшә утырып боргаладылар; Кизүче* – туйда аш-су әзерләүче, өстәл янында хезмәт күрсәтүче: *Кизүчеләр күп булган туйда.*

*Акашка* – язгы чәчү алдыннан кырга чыгып үткәрелә торган йола. *Сабан чабучылар* – сабан туенда катнашучылар.

## ГАИЛӘ ЙОЛАЛАРЫ ҺӘМ ЙОЛА СҮЗЛӘРЕ

### Туй итү, өйләнешү

Нократ татарларында өйләнешүләр күпчелек очракта, яучы җибәреп, ике гаилә арасында сөйләшеп, килешеп хәл ителгән. Шул ук вакытта, аерым очракларда, кызны көчләп кияүгә бирүләр дә, ата-ана ризалыгыннан башка гына урлап алулар яки ябыштырып чыгарулар да булгалаган. Бу соңгысы бигрәк тә бисерманнәр белән катнаш булган авыллар өчен хас күренеш санала.

### *Яучы килү, кыз ярәшү*

### Йаучы

Йаучы итеп егетнең берәр туган тиешле кешесен, яки авылда яучы булып танылган, шул эшне башкарып чыгардай тел остасын җибәрәләр. Яучы булып килгән кешегә, гаилә абруен саклау йөзеннән, беренче кат килүдә үк ризалык биреп бетермиләр.

– Йаучы килә, йаучылай. «Туқтале, бикэмнәрем[1] белән киңәш итийем», – ди әнийем. Бер сорау гына йитмәй, бэш қат, алты қат йөрделәр. «Йук, бирмамбыз али пычтик[2]», – дилир.

Яучы дагы килә. Қозның эти-әнисе сорай: «Тормошлары ару-мы[3]», «Йарар, андай булгач бирәбез, нигә бирмимбез, биребез», – диләр. *(Кистем)*

– «Коз сорамага кэлдем. Тана кереп калган», – ди. «Безнең олыбыз бар, синең козың бар. Алар бергә танышканнар булыр», – ди. *(Палагай)*

– Сорама килеп алгалаганнар кызны. «Без кызыгызны сорама килдек». Кыз үзе йаратмаса да барасы була инде ата-ана биргәчен.

– Утыргач, сүләшкэч әйтәләр:

«Безнеке үгезебез бар, сезнеке танагыз бар. Аларны бергэлэштерэсе», – дигәннәр. *(Атабай)*

## Кыз биру, туй иту көннәре

– Май айында биргаламаганнар қозны. «Майатса итеп[4] торор», – дигәннәр. Апырилдә, мартта актык айлар, начар айлар, дип биргаламаганнар. Ике қоз булса, бер йорттан икесен берйулы бирмэгэ йарами, дигәннәр.

– Кече атнада туй йасама йарамай, шишәмбе йарамай.

**Сәфәр ай** – хәтәр ай, туй йасама йарамай.

Туйны йомгада, шәршәмбедә йасагаладылэр. *(Биктәш)*

## Көн утырту

Көн утырту – туйның көнен билгеләү.

«Йә, көн утыртмага килербез әле ат белән». Көн утыртма киләләр. Ул көнгә туй дип. Килешеп китәләр. Бороңгылар селге бирде, намазлык. Рәхмәт әйтеп китәләр. Алдан көн утыртып китәләр, ул көнгә килерсез, белерсез үзегез, дип. *(Нократ)*

## Сүзгә салу

Сүзгә салу – ике гаилә арасында сөйләшү-килешүләрне башлап җибәрү.

---

[1] Бикэм – иренең апасы.
[2] Пычтик – әзрәк.
[3] Ару – әйбәт, яхшы.
[4] Майатса (< рус.) иту – азаплану.

– Сүзгә салдылар, бирделәр. Туйы булды. Данлыклы қыз иде. Кем ки қәрендәш-ырулуы, алар килә сүзгә салма. Үзенең тигән кешеләрен китерә. Сүзгә салып киткәннәр дә соңра туйга килешкәннәр.

– Сүзгә салгачын, сөлге биргэчен, қызаш[1] дип, ашқа йермә йабыша. *(Нократ)*

– Сүзгә салгачын элек тәбәгый[2] илтәләр иде коз йакка. Аны инде йегет йагы, кызлар илтеп баралар. Йул ашаулыкка[3] түнәп илтәләр. *(Татар Парҗысы)*

**Сүз куймага килү**

Сүз куймага килү – вәгъдәләшергә килү.

– Сүз куймага килерсез, ди. Сөлге биргэлэгэннәр сүз куйганда. *(Палагай)*

**Киңәш**

Киңәш – туй алды мәҗлесе. Анда ике якның да туганнары, ата-анасы була.

– Туйга дүрт-биш көн қалганда чақыралар қоз йаққа киңәшкә. Қачанга туй итәргә, ничә кызу[4] алырга туйга. Нәкәс[5] күп кызулар, йә ун кызу, йә унике кызу қунақлар була. *(Нократ)*

**Кыз килешү**

– Коз килышабыз дип, насылы-тамырын[6] чакырып, козны килышып киталар, чай куйалар, аш. *(Атабай)*

– Килешмәгә килгәч эткуйга күлмәк, энкуйга күлмәк бирәсе була. Бүләкләр бирәсе була аларга. Қозныкы урын эйләнәләрен[7] биреп йибэрэсе була. *(Нократ)*

– Козны килештерәләр. «Сезнең танагыз бар, безнең үгез бар. Килештерик», – диләр. Кат-кат йөргәннәр кайсы. Коз килешәбез дип, нәселе-тамырын чакырып, козны килышып кайталар. *(Уръякала)*

[1] Қызаш – туй алдыннан уздырыла, кызлар мәҗлесе.
[2] Тәбәгый – баллы пирог, кекс.
[3] Йул ашаулык – кечкенә ашъяулык.
[4] Кызу (удм.) – пар.
[5] Нәкәс (гар.) – бик.
[6] Насылы-тамыры – нәсел-нәсәбе.
[7] Урын эйләнә – урын-җир әйберләре.

Тегермән авылы бисерманнәре сөйли: – Ыл'ык сырап йырайлар. Сонгра туй йасайлар. Ничек торорга, алдагысын кым был'а. Кулмаклар бирәләр. Абига да, бабамга да. Кызга пударык тутырасын инды. Ол'ык пударык бик йуг ич. Узы да был'майчы бара, ал'л'а тыра, ал'л'а йок. Ыл'ык туйда йаш килыннар утырмады. Кайа ки. Ана почмакта. Йанаша утыргаламадылар. Йа бытты шай. Туйда бутка, итләр, ашау, эчкы куп. Ыл'ык чай китыралар, чай ычыралар. Сонгра ашау. Кабарчы, пирамач, ит был'и быкканнар да куп.

## Сөлге бирү

Сөлге бирү – кызны ярәшкәч, вәгъдә билгесе итеп, яучыга кызыл башлы сөлге биреп җибәрәләр. Сөлге бирү өчен иң уңышлы көн дип җомга көнне исәплиләр. Сөлге бирү – кызның язмышы хәл ителде, соңгы сүз әйтелде, дигән мәгънәне белдергән:

– «Йеңел көн – йомага[1] көн. Йомага көнне сөлге алырга килерләр», – диләр. Ул туй башлау инде сөлге алу. Асалы[2] қызыл башлы сөлге бирәләр. Нухрат сөлге[3] дилир. Қыз белми дә қала, сөлге биреп йибэрэлэр. Қыз сорама килгән кешегә алай матурлап суққан сөлге биргәләделәр.

– Әнийем әйтә: «Бар, – ди, – абыстаңны[4] чақырып китер, сөлге бирәм, йаучы килде», ди. Бардым абыстамны чақырма. Абыстам мулла өйендә кизүлэй[5], қорбан бәйрәмдә бу. «Әнийем сине чақырма йибэрде. Сөлге бирә әнийем», – димин, – «сине бирәләр», – димин. «Кемгә бирәләр, аның хатыны бар ич», – ди абыстам. «Бармаймин, утқа салсагыз да бармаймин, қайтмаймин да өйгә», – ди абыстам. Абыстам бармаймин, қайтмаймин, дип әйтте.

«Ай, – ди әни, – менә хәзер қайтсын. Қайтмаса ки, бармаса ки, түwенчеген[6] түнәсен[7] дә чыгып китсен». Қызтерлеген[8] инде түнәсен. Элек түwенчек дигән сүздән қурқалар иде қызлар. *(Нократ)*

– Әби әйтте: «Син сөлгеңне бир, барыр. Бармай чарасы булмас. Арқан белән дә өстерәп илтербез», – ди.

---

[1] Й о м а г а – җомга.

[2] А с а л ы – бизәкле.

[3] Н у х р а т с ө л г е – Нократ сөлгесе.

[4] А б ы с т а – апа.

[5] К и з ү л э й – өй эшләре эшли.

[6] Т ү w г е н ч е к – төенчек.

[7] Т ү н ә ү – төйнәү.

[8] Қ ы з т е р л е к – кыз әйберсе.

Таки сөлге бирәләр. Аның хәдәре күз йәше түгә абыстам. Әни көн дә бакма[1] барды. «Тышым җәймә булса да, эчем бекмә берә», – ди.

– Дагы қызданмы сорармин, ди әнийем. Үзем бирермин сөлге, ди. Барыр, ди. Бармаса, делбигә белән бирермин, ди. Йаучы сөлгене селкетеп китә, қызны бирделәр, дип.

– Йегетнең анасы сөлге алма килгәндә падарыклар белән бара, кәнфитләр, қоймақлар белән бара, бер секере икмәк белән бара. Арыш ондан пешерә. Секере икмәкне[2] қызның анасына бирә. *(Нократ)*

– Дүрт кешеме, алты кешеме килә сөлге алмага. Қоймақлар белән киләләр. Қабарчы утырта, сыйлайлар. Табаққа салып сөлге бирәләр. Қызыл башлы озон сөлге бирәләр, қыз үзе суққан була. Аны китереп бирәләр табаққа салып. Аңар ақча салалар.

– Сөлгене табаққа салып қозның әнисе бирә. Сөлгене берне генә бирмиләр. Әрбер килгән кешегә сөлге бирәләр, алар қызга тәңкә бирәләр. Қыз тәңкәне дастымал белән тотып ала, буш кул белән алмый. *(Кистем)*

***Ярәшелмичә кияүгә бару***

Кызны яучыламыйча гына, ата-ана рөхсәтеннән башка гына өйләнешү очраклары түбәндәге сүзләр белән белдерелә:

## Йөгереп китү

Йөгереп китү – ябышып, качып кияүгә чыгу.

– Кайсы қозлар сорамыйча да йөгереп киткәләделәр. Андай йөгергән козлар йаман күп булгалады. *(Паюра)*

Йегертү, йөгертеп алу – ябыштырып чыгару.

Урынтын чыгу – качып чыгу.

## Ырланып китү

Орлау, қоз орлау, ырланып китү – кыз урлау, урланып китү.

– Мин ырланып киткән, миңа йаучы килмәде, сөлге бирмәдэм. Аналтладым[3] мин ул әрни, йаратмас башладым. *(Шәмәрдән)*

– Чишмә күзгә[4] төшкән җирдә орлагалаганнар козны. Эшчән қоз, дип, эшләмэгэ кеше кирәк, дип. *(Пүчинкә)*

[1] Б а қ м а – карарга.
[2] С е к е р е  и к м ә к – түгәрәк икмәк.
[3] А н а л т л а у (< удм.) – калдыру, ташлау.
[4] Ч и ш м ә  к ү з – чишмә.

– Урынтын чыгучылар[1] да булган, ата-анага әйтмичә дә. *(Кистем)*

**Кыз алу**

– Қоз алма баралар йэртэ таңнан, қалық урамга таралмастан элек. Йэшләр қоз алма баралар.

– Җанагам[2] қоз алмаган йегет, бийагамдан[3] кечесе. Кизүче[4] йуқ, даwай қыз ал, дигән этиләр. *(Кистем)*

– Зурсы улым катын алды, катын усал табылды[5]. *(Атабай)*

**Пыртуска керү**

Пыртуска керү (< *удм.* пыртос) – йортка керү, кыз өенә килү.

– Пыртуска керүне элек тә мактамаганнар, әле дә мактамыйлар. Пыртуска керү кыз өйенә керү була. Кеше әйтә инде: «Йүнне булса, пыртуска кермәс иде», – диләр. *(Биктәш)*

– Пыртуска кергән ийе бер бичырман Кул'лубер аwылда. Пыртус кертте бу катын, икенче ирне. Беренче бабачы[6] сугышта йугалган да. *(Татар Парҗысы)*

**Әйтмә бару**

Әйтмә бару, әйтмәгә бару – уллары кызның ата-аналары белән сөйләшмичә, алар рөхсәтеннән башка гына кыз алып кайтса, егетнең ата-аналары кыз өенә сөйләшергә, килешергә баралар.

– Әйтмә баралар қозно йогортып[7] алсалар. «Қозогызны без керттек», – дип. Аларга сөлге биреп йибәрәләр әйтмә барган кешегә кем булса да. Без гумердә йогырып китү булды. Менә бийагамның кызы бу, чапмаган кыз[8] йогортып алма келиләр. *(Биктәш)*

***Никахлашу, дини йоланы үтәү***

Өйләнешүне дини йола буенча никах укытып беркетәләр. Ул кәбен, кәбен салу дип әйтелә. Кәбен – фарсы теленнән кергән сүз. Татар халкының башка төркемнәрендә, мәсәлән, Пермь крае, Мари

---

[1] Урынтын чыгу – качып чыгу.
[2] Җанага – кияүнең энесе.
[3] Бийага – кияүнең абыйсы.
[4] Кизүче – эшләүче.
[5] Усал табылды – начар булды.
[6] Бабачы – ире.
[7] Йогортып алу – кызны рөхсәтсез алу.
[8] Чапмаган кыз – кияүгә бармаган кыз.

Республикасындагы Бәрәңге районы татарлары, керәшен татарлары сөйләшләрендә дә кәбен сүзе кулланыла.

## Кәбен салу, кабын салу

Кәбен бу очракта, дини йола буенча никах укыту, дигәнне белдерә.

– Қозны сүзгә салгачын кәбен салып биргәләгәннәр. Кәбен салма тырышалар туйда. Кәбен салган тошка кеше йокалайлар[1]. Сездә алай йу'ми? *(Палагай)*

– Кабын салганда бийым-бийатага[2] кулмак бирә. Кабын салма картларны чакырасин, муллаларны чакырасин кабын салма.

– Кабын салганда, кабын салмас ыл'ык, йаулык йабалар абилар, айбат йаулык.

– Кызны орлап ала. Кыз йарата, ата-ана йаратмай. Чәттә кәбен салалар, абзи-йеңгәләрне китереп кәбен салма тырышалар. Кәбен салганын кийәү белән кыз ана ийенә киләләр. *(Пүчинкә)*

– Кәбен саласы көнне йезнэйне[3] күрдем. Бүрәнә өстенә утыра, қулына тайақ тотқан, башына малахай бүрек[4] кигән. Моно ничек йезнэй дип әйтмә кирәк. Қычқырып йылап қайтам. Қайтқач әйтәмин, абыстай, кийәweңне күрдем, қулына тайақ тотқан, димин. Абыстай дагы йылама йабыша. Кәбен салдылар, туй булды. Хакимйан абам[5] кәбен салды, тумарак[6] кеше ул безги. *(Нократ)*

Кәбенле булу – кияүле булу.

– Кош кон кәбенле булдым, йеде бала китердем. *(Палагай)*

## Никах, никах салу

Никах – гарәп теленнән кергән сүз, дини йола буенча никах укытып өйләнешү.

– Никах укыганда пич арасыннан гына килеп қараштым. Минеке кийәү қайсы була икән, дип. Әбекуй[7], әтекуй[8] алай әрләделәр үземне. *(Нократ)*

---

[1] Й о к а л а й (< удм.) – җыя.

[2] Б и й ы м - б и й а т а – кайнана-кайната.

[3] Й е з н э й – җизни.

[4] М а л а х а й б ү р е к – мех кырпулы бүрек.

[5] А б а – якын туганы, ир кешегә әйтелә.

[6] Т у м а р а к – туганрак.

[7] Ә б е к у й – әбкәй.

[8] Ә т е к у й – әткәй.

– Малай арны алса, никах салдырмага була. Қоз арга барса, никах салдырмага йарамый. *(Биктәш)*

### Туй мунчасы

Никах көне алдыннан кыз ягында да, егет ягында да мунча кереп аруланалар.

### Кәбен мича

Кәбен мича – кәбен укытыр алдыннан ягып әзерләнгән мунча.

– Кәбен мичаны тегел-тигез[1] кеше йага, аталы-аналы кеше йага. Кәбен мичада кызның чәчләрен тарап үрәләр. Тегел-тигез кеше тарап үрә. *(Шәмәрдән)*

– Йэшлэр-қызлар ийылып[2] қызның ақтық көнен уйнайлар. Ул көнне йегет тә, қыз да үз ийлэрендә кәбен мичага керәләр. *(Нократ)*

– Танда туй дигәндә мичага кергэлэдек дустымым[3] белән. Серен[4] тиде, айындым[5] сәйәт[6] эчтә. Эссе су арындыра[7] башны, кирэг эссе су серен тигәндә. Эссе су түгәсе башына, бармак чыдай торган эссе су. Кара мича тетем чыгып йана ич, төннеген, ишеген ачасы ич.

– Козны бүген илтилир ич инде, сонгра анда кәбен салдыралар. Төнлә үк мича йагалар. Кеше күргәләгәнче кийәү белән кыз мича кереп чыгалар. *(Шәмәрдән)*

### Кэлин мича

Кэлин мича – кияү йортына килен төшкән көнне ягыла, анда егет белән кыз бергә юыналар.

– Кыз белән кийэүне уйатып йибэрэлэр иртүк мичага. Кэлин мича йагалар. Менә үземнең мучайым[8] бар, башуwарлык[9] йасап куйдым кэлин мичага. Ат корйок[10] чаклы чәче. *(Тегермән ав.)*

---

[1] Тегел-тигез – тигез, бәхетле булып гомер итүче.
[2] Ийылып – җыелып.
[3] Дустымым – ахирәт дусым.
[4] Серен – сөрем.
[5] Айыну – айну.
[6] Сәйәт – сәгать.
[7] Арындыра – савыгайта.
[8] Мучайым – мунчам.
[9] Башуwарлык – баш югыч.
[10] Корйок – койрык.

– Кәлин кертүче кеше кәлин керткән көнне мича йага, кәлин мича дип, кич йиткәч. Мучадан чыгучыларга йумал белен[1] тәбик[2] түккелэйбез. *(Татар Парҗысы)*

## Кийәү мунча

Кийәү мунча – кияү хөрмәтенә ягылган мунча.

– Кийәү кермә килгәндә кийәү мунча йагалар иде. Ак киндер җәйәләр иде мунча сарайга, мунча киндер дип әйткәләделәр. Кийәү мунча йаккан өчен сабын йә ойок булгалады мунча йагучыга. Мунча кучак төпкә салып, калдырырлар ыйы.

## Мича йагучы

Мича йагучы – яшь килен мунчасын ягу өчен махсус билгеләнеп куелган кеше. Кияү булган кеше мунча ягучыга дип бүләк калдырырга тиеш була.

– Мича йагучыга селге саласын. Килен белән кийәү мичага барса, сөлге белән сабын салып калдыра мича йагучыга мича сарайда[3] калдыра. *(Падера)*

– Кабын салгач, килын былан малай киталар кабын мича кырмага. Сакы астына салып калдыралар ойок йә сабын. Алар, мича йаккан ычын, дип салалар. *(Дасис)*

– Кызлар мича йаккалаганнар кийәү белән киленгә. Мича йагучыга бүләк салып калдыргалаганнар мичасына, сабынмы, сөлгеме. Ни ки әзерәк бүләк.

Мунчага барганда ырымлау:

– Мичага иң элек үзең барма, кийәwең барсын. Кийәү өстенә син барып керәсе була. Син кийәү өстенә барып керсәң, гумерең буйы кийәүне йиңеп торасың, дигән сүз була. *(Атабай)*

## *Туйда катнашучылар*

Туйларда кызның һәм егетнең әти-әниләре, ягъни кода-кодагыйлар төп игътибар үзәгендә булалар. Болардан башка, туйларда һәртөрле хезмәт күрсәтүчеләр һәм туй кунаклары да күп була. Аларның һәркайсының үз вазифалары һәм атамалары бар.

---

[1] Йумал белен – төче коймак.
[2] Тәбик – тәбикмәк.
[3] Мича сарай – мунча өйалды.

## Кода, оло кода

Кода, оло кода – кызның һәм кияүнең аталары. Кодагый – кызның һәм кияүнең әниләре. Кодача – кияү һәм килен ягындагы яшь кыз туганнары.

– Аты була инде кайсысының бэш, кайсысының ун була. Чаналарында эчәр-дүртәр кеше була. Кодагыйларны, кодачаларны алдан кертәләр каршы алып. Кечкенә йа’лар арттан керәләр. Кеше күп җыйылган була. Кодачалар-кодалар эч эстэл булалар. Ашагач-эчкәч җырлый башлыйлар, бии башлыйлар, герли башлыйлар. Кыз-катын[1] кайсысы бийешмэгэ чыга. Икенче ийдә була бийешүләр *(Бурча)*

– Менә йералма[2] утыртып беткәчтен дә туй буласы бар. Кем ки эби йырлап бездә:

Ишегалдымда миләшем, Бисмилласыз капмагыз. Кызыбыз сезнең кулларда, Кодачалар, какмагыз. *(Уръякала)*

## Атбакчы

Атбакчы – ат багучы, туйда атларны карап, саклап тору өчен куелган кеше, кучер.

– Кийэүгэ пар ат йигэлэр дә пар селте элэлэр атларга. Қапқа テптә туқтай. Кейэүне қаршы алма чыгалар. Эшиктэн керәләр. Атбақчы атлар йанында торма тийеш була, күми[3] йанында тора. Чәй эчмэ дә кергезмилэр атбақчыны. Атбақчыға зур селте бирилэр. Атның башына элеп йибирилир. Қайнананың энесе була атбақчы. Атларның арабаларын[4] аналтлап[5] қайтты қайсы туйдан, атбақчы қарамады, дилир. *(Нократ)*

## Козйәмшик

Қозйәмшик, қызйәмшик, йәмшик – туйда яшь килен утырган көймәле атны тотып баручы, кучер.

– Қызйәмшик қыз алма барганда ат багып бара. Аңар зур селге бирилир.

– Қозйәмшик қозны китыра, ангар быр сыл'гы биралар.

– Йақын кешесен йәмшиг итеп элти, эки қызйәмшик була. «Атбашқа[6] дип экисини ди сөлге сала.

[1] Кыз-катын – хатын-кыз.
[2] Йералма – бәрәңге.
[3] Күми – көймә.
[4] Араба – арба.
[5] Аналтлап (< удм.) – калдырып.
[6] Атбаш – ат карауч ы.

«Ай, йақшы селге салган ич атбашқа», – дилир. Атны йәмшик тота, қоз утырган атны. Элек wахытта қошлоқта[1] туй итилир ийе, эш беткәч кенә. *(Нократ)*

## Күми птич

Күми птич – яшь килен алырга барганда көймәгә кечкенә кыз белән малайны утырталар. Аларны «күми птич» дип әйтәләр.

– Күми птич дип ыл йақтан қызны алып китмә килгәндә кечкенә балаларны утыртып килилэр күмигэ. Бер ыл[2], бер қызны утырталар. Аларга бирнә[3] айыралар[4] йанйаулықлар[5] айыралар.

– Ол[6] йақтан китерә бер ол, бер қыз. «Күми птич булдың», – дип аларны чеметкәлиләр. Алай йоласы. *(Нократ)*

## Кимә төп, күми төп

Кимә төп – кыз ягыннан туйга килгән яшь кыз яки малай.

– Кимә төп итеп җибәргәләделәр мине Кул'л'убергә, Әхмәди аwылга бардык. Баргачтын ук тасма бирделәр чәч үрмә. Йаман күп кийәү йегетләр җыйылдылар. Апама камыр басырга биргәләделәр. Ыклаwык китереп бирделәр камыр җәймәгә. Токмач басмага остайы апам. Зур итеп җәйде, ул камырны бикәчәйе килеп йыртып куйды. Анга сөлгө бирәсе була икән.

Кул'л'убер йегетләр әйттерәләр дә сиптерәләр генә.

Минем башымда ак челтәр шәл ийе. Бер йегет алай йырлагалады:

Берәү-икәү-өчәү-дүртәү
Бишәү-алтау-унике.
Ак челтәр шәлле кодача
Синеке түгел, минеке.

Алай ойалып, йатсынып утырдым туйда. *(Кистем)*

Күми төп – кызны кияү йортына озатып, аның белән бергә туй көймәсенә утырып килүчеләр.

– Ат белән килгәндә қоз йанында затып килә инде ике қоз. Аларны «күми төп» диләр. Қайсы берне китерә, қайсы икене. Күми төпләр қозның ашаулық-сөлгелэрен эләләр, эстинэгэ тәршу[7] эләләр. *(Нократ)*

[1] Қ о ш л о қ т а – кыш көне.
[2] Ы л – ул.
[3] Б и р н ә – бүләк.
[4] А й ы р а – өләшә.
[5] Й а н й а у л ы к – кульяулык.
[6] О л – ул.
[7] Т ә р ш у – чаршау.

Күмә артчылар, күмә артычылар, күмигә йабышып килүчеләр – кызны кияү йортына озатып баручы туганнары, дуслары. Алар үзләре бер атка утырып, кыз утырган туй көймәсе артыннан киләләр.

– Күмигә қыз йанга ике мәләкәй[1] куйалар, икенче атқа қызның әрҗә[2]-таз салган була. Ул атқа утырып барганнарны күмә артычылар диләр. Күмә ишегалдына кергәчен күмә артчылар дә килеп йетә. *(Нократ)*

– Күмә артычылар булгалады. Күмә артыннан бара қыз йақтағылар ол йаққа. Күмә артычыларны, күмигә йабышып килүчеләрне табақлыққа кертеп утырталар. Монда дагын хөрмәтлиләр аларны. *(Нократ)*

## Қыз озатучылар

Қыз озатучылар – кызны озатып башка авылга туйга килүчеләр.

– Қызны алып китилир. Қызны озатып тагын ул аwылга барасы була артыннан. Иптәшләре озатып бара. Қыз озатучылар була инде.

– Қызны затып килүчеләр йегетләрне белемгә чақыралар. Белем бетерәләр дә белемгә чақыралар. *(Кистем)*

## Урын җәйүче

– Урын җәйүчегә әйбер бири, селге. Нәстәгә кәле йитә. Тегелтигез кешегә урын йәйдерәләр.

– Кызлар талашалар урын җаймага. «Мин җайам, йук, мин», – дигэлэделэр. Пирбуй кич йоклагач, кил'ын урын астына йаулыкмы, сабынмы салып калдыра. *(Шәмәрдән)*

## Қызалдычы

Қызалдычы, қыз алдыннан баручы – кызны кияү йортына алып киткәндә, кыз утырган көймә алдындагы атка утырып, кызны озата баручы иптәш кызлары, туганнары.

– Алып китәләр қызны йырлашып қызалдычылар, йақын кешеләре, сеңелләре, абысталары. Қызалдычыларга өй сайын бидыра[3] белән ысла[4] чыгаралар, йорт ысла. Қызалдычының өйе сайын йорт ысла белән сыйлай.

---

[1] М ә л ә к ә й – мендәр.

[2] Ә р җ ә – агач сандык.

[3] Б и д ы р а – чиләк.

[4] Ы с л а – сыра.

– Қызның йақыннары, қардәш-қабиләләреннән[1] йәwереннэн[2] қызалдычылар булып бара күмәдә. Алар белемгә[3] чақыра қызларны. *(Нократ)*

– Күми әстени чаршауны йабаләр. Қоз йанына утыра йақын туганнары. Қоз алдычылар дилир аларны. Қоз алдычылар парлы булсыннар. Қоз белән сәгиз була. *(Нократ)*

## Кийәү йегетләр

– Кийәү йегетләрне бийетеп сөлге айыралар ыйы туйда.

Мин кийәүгә чыгам исә, кийәү йегетләр килә. Аларга муйыннарына сөлге элдереп, унмы анда, унбишме була, бийештереп бирилир. Алай иде без кийәүгә баргалаганда. Аннан соңра калган кешеләргә айыралар сөлге.

Муйыннарына элдереп, бийештереп бирилир йегетләргә. Кийәү йегетләр, ул сөлгене муйыннарына элеп, кереп-чыгып йөриләр туйда. *(Татар Паржҫысы)*

## Кийәүсакчы, йансакчы

Кийэүсакчы, йансакчы – кияү егете.

– Кийэүсакчы белән кийәү йәнәшә утырып баргаладылар. Ат капка төптә туктый. Кийэүне каршы алма чыгалар. Кийэүсакчы рөхсәт сорый, кермә буламы, дип.

– Йансакчы дип тә әйтәләр аны, кийэүсакчыны. Йансакчы саклап тора, кийәүнең кыз белән сөйләшеп чыкканын саклап тора. Келәт тептэ тора йансакчы инде, кийәүсакчы тора. *(Шәмәрдән)*

– Кийәүсакчыга бирәләр комган, сөлге, күлмәг-ыштан. Аны ырлайлар[4] туйда. Ырласалар ки йолыб ала[5] кийәүсакчы. Йегетен дә саклый, комганын да саклый. (*Бурча*)

## Сандык сакчы

Сандык сакчы, әрҗә сакчы – кияү йортына килен төшкәндә, кызның сандыгын илтә баручы кеше.

– Қыз артыннан сандық салалар. Аның өстенә утыралар йәш йегетләр. Аларны «сандық сақчы» диләр. Дүрт йегет булса, сандықны бирмәйләр, ақча бирмэйенче. Сандықта килөннең қоймагы, бал-майы, кийемнәре була. Андай әйберләре була. *(Нократ)*

[1] Қардәш-қабилә – туган-тумача.
[2] Йәwер – нәсел.
[3] Белем – белен.
[4] Ырлай – урлый.
[5] Йолыб ала – түләп ала.

– Кызның сандыгы була. Сандыкны йәмшик саклап алып килә. Сандык өстенә утырып килгән кеше саклай. Акча бирмийенче сандыкны бирмей.

– Күмә артыннан дагын бер ат белән әрҗәне илтәләр малайлар. Кыз тәршу астында утыра келәттә. Киленнең айаг астысына әрҗәсен салалар. Әрҗәне келәткә кертеп салалар әрҗә сакчылардан алып. Алар әрҗәне бирмәйенче торалар малайлар. Йанйаулыклар[1] бирәләр әрҗә сакчыларга. *(Шәмәрдән)*

**Кэзүче**

Кэзүче – туйда аш-су әзерләүче, өстәл янында хезмәт күрсәтүче, өй эшләрен башкаручы.

– Кэзүчеләр күп булган туйда. Кешенең алдысына куйма кэрэк. *(Иманай)*

– Тawык тутыралар иде йоморка белән. Тawыклар зур-зур булалар иде тутыргачын, пешергэчен. Аны кискели. Пычагын сала тawык йанга. Кэзүче кеше кискели тавыкны. Чепчеги[2] сала иде, кабарчы[3] коймак. Аг ашау[4] инде. Калганы кара он белән бешерэ иде. Эт[5] белән бәлиш бешерәләр иде табада. Бөккәне ике була.

– Туй беткэчен кэзүче йуwа эзэн. Ком кертә, шатыр-шотыр ышкып йуwа. Алдан пакач[6] су белән ышкып йуwа да, сонгра ару су белән йуwа эзэнен. Йаман сары, мутур була иде. Өй сирәктә[7] үрмәкәчләр[8], чүрэнилэр[9] калмасын дип, путулукларны дә йуwа кул йетсә. Эзэн сарай[10] йуwа да кизүче, дагын кайтып китә. *(Паюра)*

**Туй йегетләр, туй кызлар**

Туй йегетләр, туй қызлар – туйда катнашучы егетләр һәм кызлар.

– Туй йегетләр, туй қызлар булгалады туйда. Алар қызны йәрәшкәчен, селге биргәчен дә туйны хәстәрләмә[11] йабышалар. Туй

---

[1] Йанйаулык – кулъяулык.
[2] Чепчеги – чәкчәк.
[3] Кабарчы – күзикмәк.
[4] Аг ашау – ак оннан пешерелгән ашамлыклар.
[5] Эт – ит.
[6] Пакач – пычрак.
[7] Сирәк (< удм.) – почмак.
[8] Үрмәкәч – үрмәкүч.
[9] Чүрэни – үрмәкүч.
[10] Сарай – өйалды.
[11] Хәстәрләмә – әзерләргә.

йегетләр туй алашаны[1] кийендермэ йабыша. Туй қызлар қызашқа йөрмә йабыша. *(Нократ)*

### Туй багышма баручылар

Туй багышма баручылар – туй булган йортка карарга килүчеләр, күршеләр, авыл халкы.

– Туй багышма баручылар өй тулы, сарай тулы була, урам тулы халык була. Беген туй, ди, багышма барабыз, ди.

Туй багышма андай куп халык ийыла. Йәйге кенне ишегалдына килә халык.

– Зур шәлен йабына, камзул кийэ. Туй багышма барырсың иде йаман күп. Туй багышмага дип әллә кайларга баралар. *(Дасис)*

### Туй кунаклары

– Кәрендәш-ыруигын[2] йәwер-тамырын[3], күрше-карасын, катын алмаган[4] йәшләрне, йәмәгәтсезләрне чакыра. Йәш-үлэн[5] керә. Йырлашма-бийешмә йабыша. *(Уръякала)*

### Туй сыйлаучылар

Туй сыйлаучылар – туйда кунакларны хөрмәтләп, карап, сыйлап йөрүчеләр.

– Туй сыйлаучылар йырлайлар:

Кайан килдегез сез безгә
Батмайынчы диңгезгә.
Кадерле кунак сез безгә
Ни хөрмәт итик сезгә.
Бийек тауларның башында
Угол'ни колашалар.
Уйнагыз да, йырлагыз да
Кадерле кодачалар, –

дип сыйлыйбыз кодачаларны. Алар йырлай:

И илдек без, илдек без
Идел кичеп килдек без.
Идел кичеп, сулар эчеп,
Күрешер өчен килдек без. *(Әхмәди)*

---

[1] Туй алаша – туй аты.
[2] Кәрендәш-ыру – туган-тумача.
[3] Йәwер-тамыр – нәсел-ыру.
[4] Катын алмаган – өйләнмәгән.
[5] Йәш-үлэн – яшь җилкенчәк.

## *Кызны кияү йортына алып китү. Туй атлары, туй көймәсе*

Кызны кияү йортына өсте ябулы арбага, көймәгә утыртып алып китә торган булганнар. Нократ сөйләшендә аны күми, күмә дип әйтәләр.

### Күми, күмә

Күми, күмә – көймә, өсте ябулы арба, чана.

– Кәбен салгачын кызны алма киләләр ыл йактан, күми белән киләләр. Тәршу[1] коралар күмигә, кызны кертеп утырталар, икенче атта әрҗәсе була.

– Уналты йәштән кийәүгә биргэлэделэр. Әнийемне биргәннәр, уналты йәштән. Дастымалдан[2] мын'улар[3] йасап уйнагаладык. Күмидэн башын тыккан да әнийем: «Мынуларымны китерегез», – дигән. «Кукука[4] китер» дигән. Күмидэн кычкырган алай, балайа-йым[5] йәш булгалаган алай.

– Күмигэ менгәндә эки мәләкәй[6] куйалар. Анда басып күмигэ кересин. *(Шәмәрдән)*

### Туй алаша, туй атлары

– Туй алашага туй йегетләр селгеләр элгелэгэндэ.

– Туй атларын парлап йиккэлэделәр. Туры ат, қара атларны икесен пара[7] йиккэлэделәр. Йанйаулықлар асып. Атлар күп булгалады. Атың йуқ – қанатың йук, дигәләделәр.

Атларны бизәү:

– Бер арбага, бер чанага ике ат җигәләр, чиккән йаулыклар элгән дә була. Зур туй булса, биш-ун ат була. Чиңгелелэр[8] салып киләләр атларга. Пара атлар йигэлэр. Ике йәмшик була. Атның эшлийәлэре йалтырап тора. Селге куйа дуга башына. Қоңгыраулар тагалар. Атлар сикереп кенә тора қоңгырау талкышына.

---

[1] Тәршу – чаршау.
[2] Дастымал – тастымал.
[3] Мыну – курчак.
[4] Кукука – курчак.
[5] Балайайым – балакаем.
[6] Мәләкәй – мендәр.
[7] Пара – парлап.
[8] Чиңгеле – кыңгырау.

– Күбрәк парлы атлар йигэлэр, жыңгырлар[1] салып. Дуга җиңгеле[2] белән киләләр. Дугаларны матурлаганда алай җиңгелеләр салып. *(Иманай)*

– Қозны алучылар қоз эчен баралар инде, чиңгелелэр салып баралар. Аты була қайсысының биш, қайсысының ун була. Қасим бабача, Дәүләт бабача ат җигеп биргәләделәр. Безнең Нухратта ике ылча[3] Қасимовлар, теге ылча Арслановлар, бу йагында Абашевлар, йугары аwыл Деветьяровлар. Атлар урамнарны кутыртлап[4] чабалар, қоз алучылар күми белән киләләр. *(Нократ)*

## Қоз алмага килү

– Қоз йақтан қойаш байымас элек чыгалар, қойаш байыгач чыгармилар. Ол йақтан қойаш байыгач қына китәләр, қунып кайталар.

– Қоз алмага бара қош көн атлар белән. Элек wақытта қошлоқта туй итәләр ийе. Эш беткәч кенә. Атларны кийендереп күми белән қоз алма баралар йертә таңнан. Халық урамга таралмастан элек.

– Қәрендәш-ырулары ийылышып кmasлилир қызны алмага. Музиканнар, гармуннар белән йаман күп атлар белән кmasлилир, кода итилир.

– Ике ат йанаша, берсе алда, алай йигеп барырлар ыйы атларны. Җиңгелеләр белән, сөлгеләр салып. Йаман йәмле булгалады.

Чанага матур бәләкәйләр салып, матур йурганнар йабынып баргаладылар туйларга қош көн. *(Атабай)*

– Пара ат җигеп, пара җиңгелеләр элеп туйлар килә. Қапка төбенә чыгып қаршы алайык, багыша йық.

Йабу[5] өстөнә менеп басқалап туй багышалар.

– Җиңгелеләр тагып пар атлар белән баралар. Барып қапқа төбенә туқтайлар да жырлап торалар.

– Қодачалар, қодагиларны алдан кертәләр. Қоз әзерләнә, кийенә. Ничек сын булыр жырлары:

Қара сирның мөгезен
Қайрыб алма без килдек.
Энекәсенең бәбәкәсен
Айырыб алма без килдек.

Кәкре қайын ботагын
Қайрып алма без килдек.
Энекәсенең қоз баласын
Айырыб алма без килдек.

---

[1] Ж ы ң г ы р – телдер.
[2] Җ и ң г е л е – кыңгырау.
[3] Ы л ч а (< рус.) – урам.
[4] К у т ы р т л а п (< удм.) – әйләнеп.
[5] Й а б у – түбә.

Тартма-тартма бала-игыз
Бал эчәргә без килдек.
Қара шәлне йалтыратып
Қоз алмага без килдек.
И килдек без, килдек без,
Идел буйлап килдек без.
Идел буйлап сулар эчеп
Қоз алмага килдек без. *(Әхмәди)*

## ***Килен төшергәндә ырымнар, йолалар***

### **Атны койаш йагына әйләндерәләр**

– Күми ишегалдыннан чыкканда атны өч қат туқтаттыргаладылар. Атны қойаш йаққа таба әйләндереп, қойаш ничек әйләнә, алай әйләндереп алып киткәләделәр қойаш йаққа. *(Нократ)*

– Кил'ынны кийашка каршы кыртасы дип силашалар иды. Атны бик матурлаганда булган туйга барганда. Шелийә чуклы-чуклы булыр иды, чыбарлаганда. Кыңгыраулар булыр иды дугада. Гармушка былан барганнар коз китырмага. *(Дасис)*

– Алып китилир кызны. Күми белин китилир. Койаш чыгышка әйләндереп кертәләр атларны.

### **Арба, чана wатылмасын**

– Араба[1] wатылса, араба чүләре[2] чыкса әйтәләр:

«Ай, тормошлары тормош булмас», – дилир. Атны эч қат тарттыргаладылар қозны алып киткинди. Туры барсын ат, чыгымламасын. Қапқадан чыққанда уқ эч қат тарттыргаладылар. Сыразы алып китмиләр. *(Нократ)*

## ***Яшь киленне көймәдән төшерү***

### **Мәләкәй[3] өстенә төшерәләр**

– Атны керткәндә күми белән қайтып керәләр ол йаққа. Әрҗәне[4] алалар. Әрҗә эстенэ эки мәләкәй куйалар. Мәләкәй эстенэ басып тешә килен. *(Нократ)*

**Уң йаққа төшә.**

– Қыз утырган күмә ол йақ ишегалдына кергәчен әрҗәне алып куйалар. Әрҗә эстенэ қызның эке мәләкәйен қуйалар, аның эстенэ буйалмасын эчен печин салалар. Қыз уң йаққа тешә. *(Нократ)*

---

[1] Араба – арба.
[2] Чү – чөй
[3] Мәләкәй – мендәр.
[4] Әрҗә – агач сандык.

## *Киленне кияү йортына кертү*

### Печин сибү

Печин сиби – печән сибеп бара.

– Кәлин кергәндә бер кеше кәлин алдыннан печин сиби:

«Хайчуанлы, туwарлы[1] йорт-җирле, бай торсоннар», – дип.

Экинчи кеше комган белән су сибеп йөри. Алдыннан печин сиби, артыннан су сиби. Кергич инде бәләкәйгә утырталар киленне, агач сәкегә түргә. Дога кылалар. *(Пүчинкә)*

– Киленне печин сибеп керттеләр, ишек алдыннан йабышып өйгә кадәр печән сибеп керттеләр киленнәрне элек. Килен алдыннан сибеп баралар печән.

– Кылуптантын мине алып керде кийәwем. Тәтәйе чыккан капка төбөнә печән җәйеп. Кермим мин әйтәм капкадан. Тәтәйе әйтә: «Бәхытенне киметәсин, бәхытенне киметәсин». Алай керттеләр, печән сибеп.

– Печин чәчеп керәләр килennең айак эзенә. Әллә нигә печән сибеп керәләр ийе. Кертәләр дә бәләкәйгә утырталар киленне. *(Уръякала)*

### Килennең битен йудыру

– Каршы чыгалар. Капкадан кергәч, сарай[2] ишек төбендә битен йуwарга комган алып чыгалар.

– Битен йуган суны баскыч астына түгәләр:

«Бу йортта гумер итсен», – дип. Мин йудым битне дә сарай тепкә түктем суны.

Комган белә бит йумага чыгаралар. Суwын әллә кая түгәләр, алдашмага белмәйем.

– Чанадан төшү белән бийем[3] каршы чыкты комган белән, сөлге белән. Битне-кулны йуwып, битне сөртеп кердем.

«Битеңне кулдастымалга[4] сертмә, җантартымсыз[5] буласың кешегә», – дидиләр. (*Тегермән авылы*)

– Табак тоталар. Комган алып чыгалар. Битен йуwып кертәләр.

«Уң айагың белән атлап кер», – диләр.

«Йылаган күз йәше белән кермәсен», – дилир.

---

[1] Т у w а р – хайван.
[2] С а р а й – өйалды.
[3] Б и й е м – каенана.
[4] К у л д а с т ы м а л – кул сөрткеч тастымал.
[5] Җ а н т а р т ы м с ы з – сөйкемсез.

– Кергәч тә бит йуган суын гөлбәчкә[1] кертеп түктеләр:

«Бу йортта хуҗа булып торсон» – дип.

– Битен йудырталар, суwын куйкы астына түгәләр. Битен йудырта. Агач шәйкә[2], битен йумага:

«Урында булсын, китмәсен», – ди. Кем каршы алма чыга, алай киленнең битен йудыртып кертә. *(Пүчинкә)*

**Араларына кеше кермәсен**

– Киленне кертә, килен артыннан малай керә. Араларына кеше кермәсен.

**Киленне бәләкәйгә (мендәргә) утырту**

– Киленне кертәләр дә сәке өстөнә бәләкәйгә утырталар. Киленне зурлап бәләкәй өстөге утырталар иде йәш киленне. *(Шәмәрдән)*

**Бийем (каенана) йаулык йаба**

– Киленне кече йаққа кертәләр, мәләкәй өстенә утырталар. Ул мендәр анарга була. Бийеме киленгә йаулық йаба. «Йақшы торыйқ, тынычлап торыйқ», – дип. *(Кистем)*

**Киленнең урын-җирләрен кертү**

– Кызның ике мендәр, бер йастык, йурганы, комганы, тубалын салалар. Урын әйләнәсен кертеп салалар келәткә, келәте булмаса каршы ийгә. Тегел-тигез кешегә урын йәйдерәләр, ул аннан соңра уйата да, аларны мичага йибәрәләр. *(Палагай)*

**Киленне келәткә кертү**

– Кәлинне қош көн булса да келәткә кертә. Әрҗәсен кертәләр кәлиннең. Ул әрҗә йанында басып торма тийеш була айаққа.

– Келәттә йилән[3] йабынып тора кәлин. Әрҗә йанында тора. Эки көн туй булса, эки кен әрҗә йанында тора. Мәләкәйләре, йурганнары тора анда. Ни сартын[4] алай тора йәш килен? Бабалардан қалган.

– Без балалар идек әле дә. Кәлин келәттә йабынып тора йиләнен. Әрҗәсе йанына китереп салдылар кәлинне. Без сорайбыз қоймақ. Кәлин үзе белән китерә. Бер йиңгәсе алчүперәген бәйли, қоймақны сала. Балаларга қоймақ айыргалый. *(Нократ)*

[1] Гөлбәч – өй асты базы.
[2] Шәйкә – лакан.
[3] Йилән – җилән.
[4] Ни сартын – ни өчен.

## Кийәүне келәткә кертү

– Кийәүсақчы кертә инде кийәүне келәткә. Қайсы алдан эндәшә: «Исәнмесез, нихәл?» – дип, сүзе өстен була. Қоз эндәшсә ки, қозның сүзе өстен була. Малай эндәшсә ки, малайның сүзе өстен була.

– Келәткә керткэлэделәр киленнәрне. Абыстай келәттә тора. Көндәше үлә туй көнне. Кийәү кергән инде. «Тәкмилә, Зари үлде ич», – ди. «Үзең дә җәһәннәмгә олақ», – дип әйткән абыстам. «Тәкмилә, алай дип әйтмә, мин сине гөлләр кебек тотармын», – ди икән кийәү. Туй көнендә, ди абыстам, әллә бақчадан гына китим микин өйгә, ди икән. Әни микән қыйнар инде, ди икән абыстам. Алай итеп абыстам қалды. Таки тордо ич. Йеде йылдан бер қыз тапты абыстам. Оланны[1] йаратқалады қарты. *(Нократ)*

### ***Яшь киленне аwызландыру***

### Кыз аwызландыру

Қыз авызландыру, аwызлықландыру – кияү йортына аяк басып кергәч, яшь киленгә баллы су яки бал каптыру.

– Қайнанасы келәткә тешә қабарчы[2], ширбәт[3] белән қыз аwызландырмага. Кэлин аwызландырма керә қайнанасы. Қабарчы чәй табаққа[4] сала, чәйнүктә шәрбәт, йумал[5] су.

«Йортлы-җирле, ыризықлы бул», – дип кабарчыны сындырып қаптыра. Ширбәт су, йумал суны қаптыра эч мәртәбә.

Йумал суның қалдыгын инде йәшлэргэ бирә. Йәшлэр эчэ калганын.

«Безгә дә йоқсын, без дэ йақшы торыйқ, тынычлап торыйқ», – дип.

Бийем булучысы киленгә йемеш суwы эчерә килен кергәчен, ашызландыра.

«Тәүфиқле, бәхетле булып гомер итегез, озын гомерле булыгыз», – дип, тәүфиқ теләрләр иде. *(Кистем)*

**Тел ачтыру** – яшь киленне сөйләштерү йоласы. Шул йола башкарылганнан соң, килен кеше үзенең кайнанасы белән ачылып сөйләшеп китә, ә кайнатасы, бийагасы (иренең агасы) белән сөйләшми, тел яшерә.

---

[1] О л а н – бала.
[2] К а б а р ч ы – кош теле.
[3] Ш и р б ә т – баллы су.
[4] Ч ә й т а б а к – чәй тәлинкәсе.
[5] Й у м а л (< удм.) – төче.

– Кэлин төшкәннең икенче көнендә кэлинне тел ачтыру була. Бийанай тәбәгый пешерә дә «кабарганмы?» – дип сорый. Кэлин «кабарган», – дип әйтсә, анда сүләшеп китә.

– Кэлин тешкәйнең сонгра кэлин мича йагалар. Мичага кердег инде кэч, тәбәгый салган пичкә. Бийем мине пич алдына илтте, пичне ачты ди:

«Кэлин, тәбәгый кабарганмы?» – диде. «Кабарган», – дидем. Башыма йаулык салды. «Кэлин сүләш», – дип башына шал' сала кэлиннең.

– Мине дә бийем кеше ачтырды. «Менә алйапкыч булыр», – диде. Алйапкычлык ситсы булды. Мин аңа тел ачтым, табакимак пешердем, чәй эчтек. *(Татар Парҗысы)*

## ***Яшь киленнең кияү өендә үзен тотышы***

## **Ойалу**

Ойалу – яшь килен кайнатасы һәм киявенең ир туганнары белән әдәп саклау йөзеннән сөйләшми, алар алдында аяк өсте тора.

– Бийагадан, бийатадан ойала, сөйләшми. Бийата сөйли, кэлин тыңлашып тора. Җанагасы белән сөйләшә. Бийатасы, бийагасы кергәчен айакка тора. Ылчага[1] чыкса, зур кәшәмбир[2] шал' йабына.

– Килен бийатай белән сөйләшмәгән, ашашмаган, кийенеп йөргән. *(Әхмәди)*

– Бийаталы-киленле алай печингэ йердек. Бит йапқанда, сүләшмэдек.

– Әрҗәне келәткә кертеп салалар кэлин йанына. Әрҗә йанында торасин инде ойалып. Ойалган көйө торасин, беркемгә дә күренмәйсин. Йилән йабынып бөркәнеп торасин. Чәй эчмә генә кертеп чыгаралар өйгә. Әрҗә йанында кэлин эки кен тора, кен озон. Тәршу[3] артында тора. Қошкон булса да тора. Өйгә кермә йарамай, ойалып торма тийеш була. *(Нократ)*

– Кэлин битен күрсәтмәде бийана-бийатага. Картлар йулда очраса, арты белән боролып ойалышып кала торган ыйы картлардан. Элек йаман әдәпле ийе калык.

---

[1] Ылча (< рус.) – урам.

[2] Кәшәмбир – кашемир.

[3] Тәршу – чаршау.

– Бийем белән сөйләшә, бийәтәй[1] белән – йук. Бийагай белән сөйләшми, җанагай белән сөйләшә. «Ата – беләк, ана – йөрәк», – дигәннәр әwәле. Бийем белән сүләшә, бабам кышылар[2] белин сүләшмәделәр, ашйакта аша, дилар. *(Атабай)*

– Зурларга эндәшмиләр. Әбиләр белән сөйләшәләр, бабам кешеләрдән качып йөриләр киленнәр.

«Бабам керә икән», – дип әйтеп, айакка тороп баса икән киленнәр. Бийата кешегә телен ачмады, аның алдында кычырып сөйләшү булмады без белдектә. *(Атабай)*

– Битләрен күрсәтмәделәр. Бабаларны, ололарны зурлатып, ойалып йөргәләделәр, качып йөрделәр.

– Башны, битне йабып ойалып йөрдөм. Ирдән зур ир-атларга йөзне күрсәтү йуг ыйы.

И су буйына төшеп йырлай торган ыйым. Байым[3] төшкән артымнан. «Иртәгә үк битеңне ач, кемнән ойаласин, кычырып йырларсин», – дигәләде.

– Йалангач айак идәнгә баскаламадылар, айакларын, балтырларын күрсәткәләмәделәр. «Риза булырсинмы, ойогымны саласы идем», – дип рөхсәт сорап салдым, бикәмдән рөхсәт сорадым. «Сал, сал, ни ки салмассин», – ди. Кәзерге калык аны тыннашмай.

Шал' бәйләп битен күрсәтмәй йөрделәр киленнәр. Күршекарада йәш йегетләр булса, килен сөйләшмәде, бийага белән сөйләшмәде. *(Уръякала)*

– Ойалып, качып йөрдем кийәү йактан тийә торган кешеләрдән. Бөтенесеннән ойалып, качып йөрдем үземнән зур кешеләрдән. Озак йөрдек ойалып. Элек тәртипле булгалады киленнәр. Хәзер карт йаклар да йуг ич инде.

– Почмакка барып ашай иделәр киленнәр. Шал' йабынып. Бийата белән, бийага белән сөйләшкәләмәделәр киленнәр. Җанага белән сөйләшкәләдек. Почмакта ашагаладык.

Бийагайым белән сөйләшкәләмәдем. Бийемем белән шанги бетерешә, бөккән бетерешә идек.

– Бийагадан ойалма кушкан. Ойалма кушкач, ойаласы була. *(Татар Парҗысы)*

[1] Б и й ә т ә й – кайната.

[2] Б а б а м  к ы ш ы л а р – ир кешеләр.

[3] Б а й – ир, хуҗа.

### *Туйдан соң яшь киленнең үз әти-әнисе йортына кунакка баруы*

### Айкасына бару

Айкасына[4] бару, кече атнага бару – яшь киленнең, үз әти-әнисе чакыргач кына, үзенең туган йортына кунакка килүен шулай әйтәләр. Яшь килен янына аның иптәш кызларын, туганнарын да чакыралар.

– Қода узгачын қыз белән кийәүне қунаққа чақыралар. Айкасына қунаққа бара кийәү белән қыз. Ат белән барганда кийәү аттан тешә қапқага йитмистән алда. Атны туқтаталар ылча башына. Қыз үзе генә ойалып керә. Арттан кийәү керә.

«Рөхсәт бармы мыңа кермэгэ?» Кийәү инде рөхсәт сорап қына керә қапқадан.

– Кече атнага барганда тәбәгый алып бара кэлин үзенең айкасына. Тәбәгый алып бара, бәлеш белән қайта. Ул бәлешне ашама қунақлар чақыра. *(Нократ)*

**Кече атна затма** – кызны ата-ана йортыннан озатып җибәрү мәҗлесе.

– Кече атнага бикәчәләре белән бара қыз. Кече атна затма дагын қунақлар чақыралар. Қоз инде йабыгып[5] қайта анасындан, атасындан. Барсындан да йабыгам ди, әнийемдэн дә, этийемдэн дә, ди. Электән үк дустымнар[6] иде, сырларыңны[7] бергә сүлисең, сүтәсең сырларыңны. *(Нократ)*

### Яшь киленгә су юлы күрсәтү

Су йулын **бикәчәме**[8] – кияүнең сеңлесе күрсәтә.

– Бикәчәме су йулын күрсәтә. Бидыра, күwәндә белән су эчен бара йәш килен. Сабын айыра, йанйаулык айыра бикәчәме. Йәш килен сәдәп өләшә балаларга. Су китерттергәннәр, кийәнтә эстени әйбер салгалаганнар. *(Шәмәрдән)*

– Мин унийеде йәштә чыктым кийеүгә. Су эчен тештем. Чиккән бычма'лы бурдушай шал' йабынып. Буш бидыра, кийәнтә төшерә суга да кайткан чакта алып кайта кэлин кеше. Чишмә бар ыйы

---

[4] Айка – үз ягы.
[5] Йабыгып – сагынып.
[6] Дустым – дус, ахирәт.
[7] Сыр – сер.
[8] Бикәчә – иренең сеңлесе.

безнең йаман[1] шәп. Ани[2] тешкэн, бабачның[3] катны, берсе күрше катны. «Кем йибэрде сине су эчен?»

Берсе су тутырып бирде, берсе йилкэмэ салды. Чишмә күзләр күп бездә, аллыл йак чишмәгә баргаладык.

Су буйлары, су буйлары
Су буйлары гел нарат.
Суга барсам йылап кайтам
Су агымына карап.

Сулар ага, сулар ага,
Сулар ага болганып.
Шул суларда битем йудым
Йалгыз башым моңланып.

Ынылды[4] инде җырулар. Без Ыҗбык суwы[5] дибез, чишмә күз йегрә. Шумпыл-шумпыл су ага. Йәйәүле йермегә л'аба[6] йасайлар энишкэ. Мына бидыраларымны йудым, шабалкам[7] калган, шабалкам эчен кайтам ийгә. *(Әхмәди)*

### Көйәнтә өстенә бүләк салу

– Йәш килен су өчен бара иртә белән. Йәш киленгә көйәнтә өстөгә бүләк салалар.

– Су өчен барма чыктым да мин качма келим инде. И, килен кача, дип минем арттан йүгереп чыктылар инде.

– Киленне су өчен йибәрәләр чишмә күзгә. Аның суын котлап, су китергән өчөн дип, көйәнтә өстөгә йаулык салалар. Ситсылай да салалар кайсы кешеләр. Су көйәнтә өстөгә салалар иде алай. Су өчөн баргач, йәш киленнең айагын чылатырлар ыйы.

– Барып төшкән көнне кунак итәләр киленне, су өчен генә барып кайта, суын гына китереп куйа. Бүтән эш кушкаламадылар. Күп эшләтсәң, имеш, аның йыл буйына да эше бетми. *(Кистем)*

### Садап айыру

Садап айыру – сәдәп өләшү.

– Кил'ын ирта былан су эчен баргач, ыланнарга садап[8] айырыр[9] иды. Кыз баласы су йулын курсата. Капка тыбына чыккач та, балаларга садап айырып бирып йибарды килын, садап биргалады.

[1] Йаман – бик.
[2] Ани – абыйсының хатынын шулай әйтәләр.
[3] Бабач – абый, абзый.
[4] Ынылды – онытылды.
[5] Ыҗбык суwы – елга исеме.
[6] Л'аба (удм.) – басма.
[7] Шабалка – чүмеч.
[8] Садап – сәдәп.
[9] Айыра – өләшә.

– Садап бирмаса, айагына су тугалар иды.

«Тукма, тукма, садап бирәм», – диләр.

– Килын су ычын тыша дип, артыннан йугырып тышалар иды. Чишмабыз зур, айбат иды. *(Атабай)*

## *Килен хезмәте*

### Кизүләмә чыгу

Кизүләмә чыгу – өй эшләрен эшли башлау.

– Кизүләмә йабыша икенче көнне. Алчүперәкләр[1] бәйләп кизүлей. Эки кат йабына башына. Безнең утыз ике баш чимийәбез ийе.

«Әйдә, килен, үрәнәсе», – ди бийеме. Ашамага[2] аныклана, сыйыр саума, кашыг-айаклар йума йабыша. «Беребез карый[3], беребез сабый», – ди, – «үрәнәсе», – ди. «Йергән этнең йоно шыма», – дигәннәр усал бийемнәр.

– Кизү кизүлэсе кэлингэ. Ипи пешерә дә камыры кала. Аны әwәли чепчеги кебек. Чумар аш, ди. Борчак белән пешерә.

– Кәлиннән чай парлаттыралар, ашаулар өстәлгә салдыралар. Ашамалар әзерли. Кызыл ашаулык кертеп җәйә килен, кызыл селтеләр элеп куйа. Ойалып йөри инде кэлин. Түбән ийдә, аш ийдә торгалады кэлин, йугар ийгә самрау мендереп бирә.

– Туй беткәч, кэлин кизүлэмэ чыга тешкән ийендә. Кизүлэмэ чыкканда бер селге элэ, ашаулык, дастымал куйа, чәй сала, сетестесе җыйа, эзэн себерә. Пирбуй ук чәй салдыралар чәйнеккә. Чәй парлайсин. Кизүигенең башы андай була. Койаш тугачка калсаң, бейемнэр сине бешерэ. Эртэ тора идек. Менә Гөлсемкуйыма[4] кушар идем сүләмә, ул кизүләмәгә оста йәштән үк. *(Шәмәрдән)*

### Кизү салу

Кизү салу, алмаш кизү кизүләү – бер йортта берничә килен булганда, үзара килешеп, өй эшләрен чиратлап башкару.

– Алмаш кизү кизүлэсе киленнәргә. Икмиген бешерэсе, шангийын[5] бешерэсе, кизүкгеңә кили икән, тәбикмәк бешерэсе.

---

[1] Алчүперәк – алъяпкыч.

[2] Ашама – ашау.

[3] Карый – карт.

[4] Гөлсемкуй – Гөлсемкәй.

[5] Шанги – шәңгә – бәрәңге пәрәмәче.

– Кизүнең танда икмикки, шангига дип оннар илип куйган йәш килен. Экинчи көнендә казан асты, аш йеткерде, ак бодай ононнан кабарчы пешерде.

– Ике кеше йал итә, берсе кизүләй. Алмаш кизү кизүләй. Өч килен, икесе йегерләп утыргалаганнар, берсе кизүләде.

– Алмаш кизү кизүләйләр. Алдан зур кэлин кизүләй. Танда[1] икенче кэлин, өченче көнне өченче кэлин. Мичасын да алмаш йага кэлиннэр, й'мә'не дә алмаш пешерәләр. *(Иманай)*

## Камыр басу, токмач җәйү

– Камыр басарга кушалар. «Ипиле торсон» – дип, токмач җәйәргә кушалар. Токмачны сакласы була. Йыртмага булдырса, бер селге бирәсе була, кәрикә токмач[2] кистем мин.

– Кизүләмәгән киленне йаратмайлар. «Йаман йалкау минем киленем», – дип сүләмә йабышалар. *(Паюра)*

Пич йагу:

– Пички киптермә бәрәләр иде итекләрен дә, чабаталарын да. Ирти торосин килен кеше, пичтин итеген, чабатасин аласин. Кем йоклай, аның итеген урнысына илтеп куйасин. Алай илтеп саласы була. Килеңнәр алай эшләгәләделәр.

Бийагайның катынын йиңги дип әйтәйем. Алданрак мин торайым, йәш килен. Битләремне йукгып, пич йагайым. Чәй кайнагач торалар ыйы.

Ипи басу:

– Сәкеләре бийек, кашн'асы бийек, ипи пешермә булдырмаймин. Ипи басмага бийемем өйрәтте. Су сала иде, он сала иде. Болай күтәр дә куас читендән тагы бас, дип әйтә иде. Ипи бешермә өйрәтте бийемем.

– Ипи чылата торган кашн'а булгалады.

Ипи калак белән камыр чылатасин да йабасин. *(Уръякала)*

## Пичкә ипи салу

– Пич йагып, күмерен тәртешкә белән тартып, пумулу[3] белән пумулулайсин иде. Пудка салып пешергәләдек ипине. Ипи секерене пуд[4] өстөгә салып пешергәләдек. Ипине әшәләйбез дә ашаулыкка салабыз. Анда сунгра ипи көрәккә салып, пуд өстөгә салып

---

[1] Т а н д а – икенче көнне.

[2] К ә р и к ә  т о к м а ч – шакмаклы токмач.

[3] П у м у л у (рус.) – пумала.

[4] П у д (рус.) – под, пич төбе.

пешерәбез ипи секерене. Пички салган wакытта ашаулыктан күтә-реп ипи көрәккә салгаладык. Сигезәр ипи секере пудка тутыргаладык. *(Уръякала)*

**Көлчә пешерү**

– Таба белән көлчә пешергәләдек ипи камырдан. Пич каршында пешереп, катыкка манып ашайлар да китәләр. *(Атабай)*

**Тәбик пешерү**

Тәбик пешерү – коймак пешерү.

– Зур пич йаккачтын пич каршында тәбик пешермәгә кушалар ыйы йәш киленнәргә. Ул табагач өстөгә тәбик пешергән өчен йә бер кийем ойок, йә бер йаулык салалар иде килен котлап. Бийем кеше сала иде. Бийемем биргән йаулык дип әйткәләделәр киленнәр. *(Кистем)*

**Эзән себерү**

Эзән себерү – идән себерү.

– Даwай эзәнне себер, диләр. Эзәнне себермә йабыштым, бар да тетәләр[1] генә чүбемне. Дагын себеремин, дагын тетәләр чүбемне. Аларга дагын йанйаулыҡлар[2] бирэсин, аҡчалай бирэсин.

Бездә идән сыбыртмаганнар. «Сыбырышып торор» – ди. *(Нократ)*

**Айакта тору**

Айакта тору – аяк өсте торып хезмәт күрсәтү, олыларны ихтирам итү.

– Унсигез йыл айакта тордом кайната-кайнана алдында. Утырып ашасы тегел, айактантын[3] тордолар киленнәр. Чәй сала чәйнеккә, суга бара, ашама кертә. Кәзәңкеле[4] өй була иде. Кәзәңкә йакта ашай-эчэ идең.

– Йәш киленнәр камзул кийеп, шәл йабып йөргән печин чапканда. Суга барасы, пичләр йагышасы, идэн-йалдысын себерәсе була. Хайwаннарын эчерэсе-ашатасы була. Бийеме булса, бийемен йаман бага. Ту'та, утын кертеп пичне йагайым да керәйем, аги[5] пичне йагасы, аши[6] пичне йагасы. Без ундүрт җан булыпбыз бер идә.

---

[1] Т е т ә л ә р – тараталар.
[2] Й а н й а у л ы ҡ – кулъяулык.
[3] А й а к т а н – аяк өсте.
[4] К ә з ә ң к ә – өйнең аш-су әзерли торган ягы, кече як.
[5] А г и – ак өй.
[6] А ш и – аш өе.

– Мин дүрт ирләр эстенэ бардым. Бийатай, бийагай бар. Миңа сөйлэшмэгә өрөхсәт йук. Бийем-бийатайның урынын йәйгәләделәр, йигаладылар. Асалаган[1] селгеләр булгалады, андайларны элгэлэде.

– Йугарылы-түбәнтеле өй иде. Кэлин йугары өйгә самавырны мендереп бирә. Кэлин кашык-айаклар йуwа, камыр баса. Чимийә күп булгачтын казанда пешерәсе була ашны, агач аштабакта аш булган, ашамасы утырта.

– Түбән өйдә аш пешерәләр, чәй кайнаталар. Ашама утыргачтын бийем белән бийатага ашама мендерәләр йугаргы өйгә. Киленнәр алай ашама пешергәләделәр кизүләп.

– Йугарылы-түбәнтеле өйләр булгалады. Бийемнәр йугаргы өйдә булса ки, киленнәр мендереп бирәләр самаwырны. Урыннарын йәйеп бирә, урыннарын иштыра килен бийем-бийатаның.

Шәңгә йасайлар, шоморттан бөккән, балан бәлеше, ит бәлеше, кабак бәлеше салалар. Йәш-үлән аны йасама булдырмый инде.

– Кайнатам-кайнанам белән тордок. Җанагаларым бар иде. Берсе унбер йәшәр иде. Бикэчэй бар иде. Бик туwар[2] күп иде. Бик йырактан су ташыгаладык ич бидыра[3] белән. Менә кер уамин да, ашимин да йатамин. Көлсу[4] белән кер уwасин, энишкә төшеп китәсин.

– Пул кэндэрлэр[5] йәйгэлэмэдек эзэнгэ, эзэнне көн дэ йугаладык. Йәш киленгә суга барасы, пичләр йагышасы, идән-йалдысын себерәсе була, хайwаннарны эчерэсе-ашатасы. Мына идән йуwып алырмын, дип калган ийым иртән ук тороп. Йомага белән шишәмбе кен йарамый кер йуwарга. Йул чыкмага йарый. Пигамбәр йулга чыккан кен ул. *(Биктәш)*

## Яшь киленнәрнең гаиләдә эндәшү сүзләре

Гаиләдә тынычлык, татулык саклау йөзеннән, килен булып төшкәннең беренче көннәреннән үк, яшь килен үзен тыйнак, түбәнчелекле итеп тота һәм һәркемгә борынгыдан килгән эндәшү сүзләре белән мөрәҗәгать итә. Нократ татарларында төрки халыкларга хас булган **бикә, абыз** кебек олылау, титул сүзләре туганлык мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр булып киткәннәр.

---

[1] Асалаган – бизәкләп суккан.
[2] Туwар – хайван.
[3] Бидыра – чиләк.
[4] Көлсу – көл суы, селте.
[5] Пул кэндэр – идәнгә җәелә торган палас.

**Бийем** – килен кеше үзенең кайнанасына шулай эндәшә: Бийем, самрау куйдым, чәй әзер. **Абыз бикәм** – иренең апасы. **Бикәчәм, туганым** – иренең сеңлесе. **Мулла бийагам** – иренең абыйсы. **Мулла җанагай** – иренең энесе. **Абыз йинги, туганым йинги** – иренең өлкән абыйсының хатыны. **Абыстай, абыз тутай** – бертуган апасы. **Бабач** – абзый, әтисенең абзыйсы, зур яшьтәге кешеләр. **Ани** – абзыйсының хатыны. **Амма** – бертуган апасы яки үзеннән олы хатын-кызга эндәшү сүзе. **Амыкуй,** диләр бик йараткан абыстасына. **Апыч** – абый. **Тәтә, түтәй** – апа. **Аппак** – апа. Кәмлә аппак килә. **Зур анам** – бер кеше ике катын алса, элке катынны зур ана дип әйттеләр. **Кэлин-кэлиндэш** (Кэлин-кэлиндэшнең башы сыймай, ә көндәшләр сыйалар, диб әйтәләр иде). **Зур килен, урта килен, йәш килен** – кайнана булган кеше киленнәренә шулай эндәшә.

### Мәгълүмат бирүчеләр исемлеге

***Удмуртия Республикасы, Балезино районы, Кистем:*** Касыймов Бәдертдин, Касыймов Зәйдулла, Касыймова Әдия, Касыймова Әкълимә, Касыймова Әсмабикә, Касыймова Гайшә, Касыймова Гарифә, Касыймова Мәликә, Касыймова Мәхмүзә, Касыймова Мөнәвәрә, Касыймова Мөхтәрәмә, Касыймова Наилә, Касыймова Рәбига, Касыймова Рәсимә, Касыймова Шәмсиямал;

***Татар Парҗысы:*** Балтачев Исмәгыйл, Бекмансуров Ибраһим, Бузикова Мәүҗидә, Касыймов Гайса, Касыймов Нәҗип, Касыймов Нургаян, Касыймова Бибинур, Касыймова Зәйтүнә, Касыймова Майбәр, Касыймова Мәгърифә, Касыймова Мәрьям, Касыймова Мәүҗидә, Касыймова Миңниса, Касыймова Мөршидә, Касыймова Орхия, Касыймова Рәшидә, Касыймов Сафуан, Касыймова Таифә, Касыймова Фәйрүзә, Рәхимова Ясминә.

***Уръякала:*** Исмәгыйлева Әминә; Тютина Асылбикә, Тютина Әсмабикә, Тютина Җофарбикә, Тютина Зәгыйфә, Тютина Миңсылу, Тютина Нәгыймә.

***Глазов районы, Дасис (Засеково):*** Абашева Закирә, Әмирова Һаҗәр, Балтачев Нәкыйп, Балтачев Рәхимҗан, Балтачева Гайния, Балтачева Галия, Балтачева Гөлҗиһан, Балтачева Илһамия, Балтачева Мәдинә, Балтачева Миңзифа, Балтачева Өммиҗиһан, Балтачева Рафилә, Балтачева Сания, Балтачева Сәлимә, Балтачева Фатыйма, Балтачева Фәния, Бикмансурова Миңсылу, Бузанакова Маһитап, Бузанакова Мәргубә, Сабрекова Фәхерниса;

***Иманай:*** Сабрекова Гөлҗиһан, Сабрекова Гөлчирə, Сабрекова Мəдинə, Сабрекова Мəликə, Сабрекова Миңзифа, Сабрекова Сания, Сабрекова Хəтимə;

***Паюра (Падера):*** Касыймов Газимҗан, Касыймов Радик, Касыймова Гөлниса, Касыймова Мəгъмүрə, Касыймова Миңнебикə, Касыймова Наилə, Касыймова Нəсимə, Касыймова Сания, Касыймова Сатыйга, Касыймова Тəнзилə, Касыймова Фатиха, Касыймова Фəрвиза, Касыймова Хəмидə.

***Юкамен районы, Әхмəди:*** Бикмансурова Галия, Дюкина Гөлниса, Дюкина Рəхимьян, Дюкина Сəрбиямал, Дюкина Фəрхениса, Касыймова Наилə, Касыймова Сабура, Сабрекова Асылбикə, Тютина Хөббиниса;

***Палагай:*** Абашев Габделхəй, Абашев Гайнетдин, Абашева Асылбикə, Абашева Гөлбикə, Абашева Заһирə, Абашева Маһинур, Абашева Маһирə, Абашева Миңзифа, Абашева Сания, Абашева Фагыйлə;

***Пүчинкə:*** Абашева Фəүзия, Байкузина Мəгълүфə, Бикмансурова Әдия, Бикмансурова Рабига, Бикмансурова Рəйсə, Бикмансурова Халидə, Бузакова Рабига, Бузанакова Фəүзия, Бузикова Гөлсем, Бузикова Зөбəрҗəт, Есенеева Рахилə, Есенеева Рəшидə, Нурəлеева Ләүзия, Сабрекова Хəтимə, Табышева Мəүҗидə, Шəнтова Наилə.

***Яр районы, Бурча:*** Бикмəмəтова Аксинья, Дюкин Гафият, Дюкина Фəрхинур, Зянкина Настя һ. б.

# ТӘГӘРИ КИТТЕ ЙОМГАГЫМ

*Илсөяр Закирова*

Бу «йомгак» быел да безне яңа юлларга, яңа сәфәргә алып китте. Без дигәнем – Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре – фольклорчылар, диалектологлар, гамәли сәнгать һәм музыка белгечләре, археографлар. Экспедициягә чыккан фольклорчылар халык авыз иҗаты материалларын – риваять-легенда, әкиятләрне, мәкаль-әйтемнәр, мөнәҗәт-бәетләрне, җыр текстларын, йола фольклорына караган үрнәкләрне, мифологик хикәятләр һәм ышануларны язып ала; музыка белгечләре халкыбызның җыр-моңын, мөнәҗәт-бәетләрнең көен, Коръән сүрәләренең мәкамен яздыра, музыка коралларын өйрәнә, халык талантларын барлый; диалектологлар аерым бер төбәктә яшәүче халыкның тел үзенчәлекләрен өйрәнә. Археографлар борынгы һәм кульязма китапларны барлый, каберташ язмаларын укый. Халкыбызның милли киемнәрен, ювелир сәнгатен, кул эшләре үрнәкләрен, тимерче, балта осталарының эшләрен гамәли сәнгать белгечләре өйрәнә. Галимнәр халыкның үткәнен, бүгенгесен барлый, һәрбер табылган материал фото- һәм видеоязмаларга, диктофон язмаларына теркәлә, белгечләр тарафыннан өйрәнелә, анализлана. Ахыргы максат – аларны китап рәвешендә яңадан халыкка кайтару.

Удмуртиядә татар авыллары шактый. Ижевскиның (Ижауның) үзендә дә татарлар тупланып яшиләр.

Эшебезне биредәге иң зур татар авылы Кистемдә башлап җибәрдек. Кистем авылында хәзерге вакытта 300 дән артык хуҗалык бар, аларда 805 кеше яши. Ул элек-электән бу якта яшәүче татарларны берләштереп торган рухи мәркәз ролен уйнаган. Мәсәлән, инкыйлабка кадәр Глазов байлары үзләренең рухи ватаннары дип

Кистемне санаганнар. Үзләрен бары Кистемдә җирләргә васыять иткәннәр. Халык хәтере Кистем зиратында җирләнгән беренче кешенең – Сандугач абыстайның да исемен онытмый.

Авылның, дөресрәге урамнарның урнашуы да шактый үзенчәлекле. Урамнар төркемләнеп урнашкан 2 шәр, 3 әр йорттан гыйбарәт. Бу аерым бер нәсел-ыруның бергәләшеп урнашуы белән аңлатыла икән.

Кистем халкы үзләренең килеп чыгышын Нократ ягы белән бәйли. «Безнең бабаларыбыз Нократтан килгәннәр», – дип сөйлиләр. Беренче килеп утыручылар Баяз Пинекеләр булган. «Пи» ыру яки токымны аңлата, үзе аерым нәселләргә бүленә. Кистем халкы ике «Пи»дән башланган. Икесенең дә фамилияләре – Касыймовлар. Информантлардан материал туплый башлагач, бөтен кешенең Касыймов фамилияле булуын үзебез дә күрдек. Башка авылларда да әлеге фамилия еш очрый. Ул теге яки бу кешенең, еш кына тулаем авылның да Кистемнән килеп урнашуына бер дәлил булып чыкты. Кистемдә мәгълүматлы информантлар, кызыклы шәхесләр белән таныштык. Безне авылның мулласы Илмир Касыймов каршы алды. Төбәк тарихын яхшы белү өстенә, ул безгә авыл халкы белән аралашырга да ярдәм итте.

Кистемнең икенче бер күркәм гаиләсе – Ринат абый һәм Светлана апа белән аларның кызлары Мирия таныштырды. Мирия дә тарихчы. Беренче соравыбыз исеме турында. Бу матур яңгырашлы, әмма бер дә ишетелмәгән исемне кем тапкан, дип сорыйбыз. Әбисе кушкан исем икән. Яңгырашлы гына түгел, мәгънәле дә булсын, дип, кызга Миһрия исеме биргән. Миһрия исеме – миһер дигән фарсы сүзеннән. Берничә мәгънәсе бар – шәфкать, дуслык, мәхәббәт һәм кояш. Миһрияне телгә җайлырак яңгырашлы Мирия алыштырган.

Мириянең туган як тарихын өйрәнүе очраклы түгел. Авыл музееен аның әбисе Касыймова Хания Ибраһим кызы ачып җибәргән булган. Мирия Удмуртия татарларына XX йөз башларына кадәр үк килеп җиткән суфыйчылык юнәлешен өйрәнә. Фәнни конференцияләрдә-симпозиумнарда чыгыш ясый. Кыз спортның да тарих белән бәйле төрен сайлаган, ул – укчы.

Мириянең әтисе Ринат абый белән әнисе Светлана апа сәнгать кешеләре, авылның Мәдәният сараенда эшлиләр. Икенче кызлары Сәрия дә музыка өлкәсен сайлаган, Глазов педагогика институтының музыка факультетында белем ала.

Авылның кунак каршылау йолалары белән шушы ике гаиләнең йортында «таныштык». Илмирның әти-әнисе, хатыны Зөһрә, Светлана апа белән Ринат абый безне иң кадерле кунаклары итеп каршы алды. Кистем авылының гасырлар дәвамында формалашкан кунак каршылау, кунак сыйлау традициясе бар. Озын өстәл тирәли, ирләр – бер якка, хатын-кызлар икенче якка тезелеп утыралар. Табынга башта кабарчы, табиг, чәкчәк кебек камыр ашлары, җиләк-җимеш кайнатмалары, конфет, бал кебек татлы ризыклар белән чәй чыгаралар. Балан, ирга бәлеше куела. (Һәрбер йортның бакчасында балан үсә. Балан бәлеше еш пешерелә биредә). Һәм, шуны да әйтеп китәсе килә, эчлеге арыш оны белән баланны мичтә пешереп әзерләнгән «дөрес» балан бәлеше бу. Чәйдән соң табынга аш чыга. Олы табак белән чыгарылган ашны табынчы бүлә. Аштан соң куелган ит янына өстәлгә бәлеш китерәләр.

Бу якларда авыллар арасында кунакка йөрү, кунаклашу вакытлары бар. Кардәш-ыруны мал суйган көнне кунакка «ит ашарга» чакыралар.

Кистем халкының теле әдәби телдән шактый үзенчәлекле. Иң беренче аерма изафә бәйләнешләрдә күренә. Мәсәлән: каз өмәсе түгел, *каз өмә*, каен агачы – *каен агач*. Лексикада да аермалыклар бар: Су иясе – *Су әси*. Удмурт теленнән кергән сүзләр дә очрый: күбәләк – *җан папа* (*папа* – удмуртларда, *бөҗәк* дигән сүз).

Экспедициябезне Паюра (Падера) авылында дәвам иттек. Паюра Кистемнән күчкән авыл икән. Авылның табигате бик матур, бормаланып аккан елгасы бар. Тәрәзәдән урманнары, таулары, болыннары күренеп тора. Урамнар киң, чиста, йортлар зур, төзек. Авыл халкы матур яши. Паюраның бер бизәге – «Очрашу» ансамбле. Өлкән апа-әбиләр ансамбльгә берләшеп, халыкның җыр-моңнарын саклап калу, киләчәк буыннарга җиткерү өчен зур эш башкаралар. Алар татар халык җырлары, үз төбәкләренең җырлы биюләре белән, тамашачыларның мәхәббәтен яулаганнар. Тормыштан ямь табып, күңелле итеп яши белә ансамбльдә катнашучылар. Конкурсларда призлы урыннар да алып кайталар икән.

Балезино районында урнашкан өченче авыл – Гордино. Авылның татарча исеме Уръякала (Гурья Кала дип тә атыйлар, ә арлар Гурья Кар диләр). Удмурт телендә кар сүзе крепость, кальга, каланы аңлата. Ә авыл исеменә кала сүзе килеп керү аның борынгылыгын исбатлаучы бер дәлил. Тарихчылар да әлеге авылда борынгы

кала эзләре саклануын язалар. Авылның тирә-ягында берничә иске зират бар. Авыл эчендә урнашкан каберне, Уръякала халкы гына түгел, бөтен тирә-як авыллар «Әүлия кабере» дип саный. Әлеге кабер янында дога укыйлар, сәдака бирәләр, корбан аенда корбан чалалар. Аның болгар чорына каравы, болгар кешесенеке булуы турында легендалар сөйли. Тарихи китапларда да әлеге кабер турында мәгълүмат бар икән. 1323 елда вафат булган болгар кызы Йәхәм истәлегенә куелган кабер ташы шулай ук күп риваятьләргә кергән. Хәзерге вакытта ул Ижау шәһәрендәге музейда ябык фондта саклана, диделәр. Бу таш әлеге җирләрдә яшәүче халыкның Болгар дәүләтенә мөнәсәбәтле булуы белән дә изгелеккә дәгъва кыла ала кебек.

Уръякала авылында татарлар белән арлар аралашып яши, катнаш гаиләләр күп. Авыл кешеләре ике телне дә туган теле дип саный, икесен дә яхшы белә. Халык нигездә ислам динендә булса да, кайбер христиан бәйрәмнәре дә билгеләп үтелә. Мәсәлән, Рошпода (Рождествода) Уръякалага якын-тирә авыллардан кунаклар җыела икән. Әхмәди, Паюра, Биктәш халкы Уръякалага кунакка җыелу вакытын нәкъ шушы бәйрәмгә көйли.

Уръякала табигатьнең иң гүзәл почмагында урнашкан. Халык та табигатьтән аерылмаган. Әмма бу да авылны саклап кала алмаган. Буш-ятим өйләр бик күп. Анда, нигездә, өлкәннәр гомер кичерә. Буш йортларның тәрәзәләрендә челтәрләре әле дә эленеп тора, тәрәзә төпләренә ясалма гөлләр утыртканнар, өстәлләрендәге чәйнек-чынаякларына кадәр күренә. Хуҗасы бер-ике сәгатькә, йомыш белән генә чыккан диярсең...

Әхмәди авылына бирегә беренчеләрдән булып күчеп килгән Әхмәди бабайның исемен биргәннәр. Авыл XIX йөз башында Кистемнән күчеп килгән. Хәзергә кадәр бу ике авыл арасында туганлык мөнәсәбәтләре саклана, дус-туганнар кунакка йөрешә. Кунакка баручыларны «Шулпа ашатсалар – өч көн, ботка ашатсалар – җиде көн кунарсың», – дип озатканнар. Әхмәди авылы мулласы Раиф әфәнде бу гыйбарәнең мәгънәсен түбәндәгечә аңлата. Халык элек-электән мал асрап яшәгән. Ит гаиләнең көндәлек төп ризыгы саналган. Ә ярма, бигрәк тә дөге ярмасы, тансык ризык, кунак ризыгы булган. Читтән китерелгән бу ярманы һәр кеше ала да алмаган. Шуңа күрә ботканы, затлы сый びуларак, кадерле кунаклар өчен генә пешергәннәр.

10 июньдә Әхмәди авылында Сабан туе бәйрәме булды. Көне буе килеп-килеп коеп яуган яңгыр да куркытмады Сабан туе кунакларын. Яңгыр яуганда ышыкланып торган халык, кояш чыгуга мәйданга ашыкты. Сабан туе матур, оешкан төстә узды. Ул чын халык бәйрәме иде. Һәр кеше бәйрәмнең үзәгендә кайнады: җырлады, биеде, аркан тартышты. Сабан туе ат ярышы, ягъни «Сабан чабу» белән башланды. Ул арада мәйдан сәхнәсендә авылның һәм районның талантлы яшьләре, балалар концерт башлады. Аларны өлкәннәр алыштырды. Атлар килгәннән соң, биек колгага менү ярышы башланды. Капчык белән сугышу, аркан тарту кебек ярышларда да авыл халкы да, килгән кунаклар да теләп катнашты. Һәр ярышны балалар башлап җибәрә, аларны үсмерләр, үсмерләрне хатын-кызлар алыштыра. Иң соңыннан ир-егетләр көч сынаша. Шул рәвешле бер кеше дә читтә калмый. Һәр ярыш җиңүчеләрнең дәртле биюе белән тәмамлана. Аларга җиңелүчеләр кушыла. Мәйдан эчендәге халык дәррәү кубып биеп ала. Яңа ярыш башланып китә. Сабан чабу, дип, ат чабышын да, Сабан туенда йөгерүне дә атыйлар икән. Балалар, хатын-кызлар, ир-егетләр төркемләшеп йөгерәләр. Йөгереп килеп җиткән бер төркемне икенчесе алыштыра. Ямь-яшел болын өстеннән элдерткән балаларга әти-әниләре көч өсти. Затлы туфлиларын салып калдырып йөгергән чибәр хатын-кызларны мәйдан аеруча алкышлый.

Көрәшне 4–5 яшьлек «егетләр» башлап җибәрә. Иншаллаһ, 15–20 елдан алар менә дигән көрәшчеләр дә булырлар әле.

Сабан туеның тагын бер үзенчәлеге – «Сабан боткасы» пешереп бөтен кешене сыйлау иде. Сабан туена бөтен халыкка җитәрлек ботка пешерү – Әхмәди авылының электән килгән йоласы икән. Урман буенда унлап казан асып, ир-егетләр сабан боткасы пешерә. Шунда ук күмер самавырларында чәй кайный.

Сабан боткасы белән сыйланган халык яңа көч-дәрман белән мәйданга ашыкты. Кичкә кадәр дәвам иткән Сабан туе кешеләрнең рухын сафландыра, көч-дәрт бирә, ел буена җыелган тискәре уйларын тарата, күңелләрен пакьләндерә. Халык уңай энергия ала.

14 июньдә тагын бер зур бәйрәм – Ижау шәһәрендә яңа мәчет ачу тантанасы булды. Шәһәрдә яшәүче татарлар белән аралашу да милләттәшләребезнең рухи дөньясын, тормыш-көнкүрешен, яшәү рәвешләрен яхшырак белергә ярдәм итте. Халык бердәм яши. Мал, байлык артыннан куып, рухи ихтыяҗларын онытмыйлар. Булга-

ныннан ямь табып, шөкерана кылып көн итә биредәге милләттәшләребез.

Удмуртия Республикасында яшәүче милләттәшләребезнең фольклор үрнәкләре дә кызыклы һәм гыйбрәтле.

### I. МИФОЛОГИК ОБРАЗЛАР ТУРЫНДАГЫ ЫШАНУЛАР

## Хозыр Ильяс

«Юлга чыкканда, Хозыр Ильяс, мине исән-сау йөртеп китер, дип сорыйлар».

*Касыймова Нәҗибә Госман кызы (1930 елгы). Кистем*

«Бер заман Әсма апайның сарыклары югалган. Бу урам буенча эзләп йөри икән. Бер заман артыннан ак киемле бер карт килеп чыккан. “Ни өчен елыйсың, кызым?” – дип сораган. Бу әйтә. “Кызым, елама”, – ди карт. – “Бар, – ди, – урамга кер. Шул урамда, абзарда синең сарыкларың”, – ди. Бу шул сүзләрне әйтә дә югала. Хозыр Ильяс ак киемле, ак чапанлы була. Ул ярдәм сораган кешегә, Аллаһыга ышанган кешегә күренә. Гайбәтчеләрне, начар кешеләрне яратмый».

* * *

«Яхшы атлар, кошевкалар белән чабышып йөри икән ул. Төнлә атларда чабыша. Төнге 12 дә. Бар аны күргән кешеләр».

*Касыймова Хәят Ибраһим кызы (1924 елгы). Балезино*

## Акшам бабай

«Кояш батканнан алып, кояш чыкканчы вакыт – Акшам бабай вакыты. Бу вакыт – вакыт арасы. Кояш баегач тәрәзәдән карарга ярамый. Акшам бабай күзне алырга, куркытырга мөмкин. Акшам бабай удмуртларда да бар. Ул да Акшам дип атала. Удмуртлар аны үтә күренмәле итеп күз алдына китерә. Ул аларда “ак” образ».

* * *

«Кистемнең фермалар артында Кара күл һәм Әүлия чишмәсе булган. Анда бер ия булган. Бу ияне Акшам бабай дип тә уйлыйлар.

Ул кешеләрне адаштыра яки кулыннан тотып Кара күлгә өстери, ди, батырыр өчен».

*Касыймова Мирия Ринат кызы (1990 елгы).*
*Кистем*

«Кич балаларны Акшам бабай белән куркыталар. Акшам бабай алып китә, дип. Кич суга барырга ярамый. Су керергә, межага керергә ярамый. Вакыт араларының тыюлары күп».

*Касыймова Светлана Казбек кызы (1963 елгы).*
*Кистем*

«Эңгер-меңгердә тәрәзәдән карамагыз, урамга чыкмагыз, куркырсыз, диләр иде әбиләр».

*Митякова Мәдинә Габдулла кызы (1950 елгы).*
*Иманай*

**Зәнки бабай**

«Сәдака китергәндә Зәнки бабай, Су газизләре, йер (җир) газизләрен искә алып дога кылалар. Элек алар күренеп йөргәннәр. Хайваннарны көтүгә чыгаргач, Зәнки бабайга атап дога кылыр өчен, сәдака бирәләр. Хайваннар әйбәт йөрсен өчен».

*Касыймова Нәҗибә Госман кызы (1930 елгы).*
*Кистем*

«Һәрбер хайван исән-имин йөрсен өчен сәдака бирәләр:

Ат өчен – Елкы бабайга,
Сыер – Зәнки бабайга,
Сарык – Чупа бабайга,
Каз – Сөләйман бабайга».

*Бузикова Фәйрүзә Гайнан кызы (1936 елгы).*
*Татар Парҗысы*

**Су иясе**

«Суәси – ягъни су анасы бар, дип сөйлиләр. Ул кешене суга тарта. Обедта – сәгать 12 дә коенырга ярамый. Бу вакытта су коенсаң, суәси тарта, дип әйтәләр. Суәси чишмәгә бассаң да тота. Тотса, укыйлар, карчыклар укый, ташла052налар».

*Касыймова Камилә Галиулла кызы (1924 елгы).*
*Кистем*

«Чуан чыкса, су газизләренә сәдака кирәк».

* * *

«Төш түрдә – көндезге 12 дә суга төшәргә ярамый, коенырга да, кер юарга да, су алырга да ярамый. Суәси алып китәр, диләр».

*Касыймова Светлана Казбек кызы (1963 елгы).*
*Кистем*

«Суны болгатма, ярамый. Суны болгатсаң, суәсинең йорты бозыла».

*Касыймова Алсу Муса кызы (1981 елгы).*
*Кистем*

Су бай. «Бер күренде миңа. Яман зур балык булып сикерде. Чумгач су өстенә яман кара сачы чәчелде, чәче су өстенә җәелде дә, су караңгыланды».

*Тютина Нәкыя Нотфулла кызы (1935 елгы).*
*Уръякала*

«Су әби бар ул. Суга тартып төшерә кешеләрне».

*Митякова Мәдинә Габдулла кызы (1950 елгы).*
*Иманай*

## Урман иясе

«Элек анда урман булган. Хәзер юк. Әбиләр, урман иясе яшәгән, дип сөйлиләр. Ул адаштыра. Кеше урманда йөргәндә бик тиз караңгылана. Юл юкка чыга. Бөтен якта агачлар үсә. Кеше кая барырга белми. Андый вакытта аңа мөрәҗәгать итәргә кирәк: “Мине адаштырма”, – дип. Киемнең эчен тышка алмаштырып кияләр. Урман иясен үзен күрмиләр. Ул атналар буе йөртә. Кеше аңсыз кайтырга мөмкин».

*Касыймова Мирия Ринат кызы (1990 елгы).*
*Кистем*

«Урман бабай адаштыра ул. Якты җирдә дә адаштыра, хайваннарны да тота, җибәрми. Укытасы була. Кеше адашса, абызлар тыныштыра, чыгаралар».

*Тютина Раида Леонидовна (1961 елгы).*
*Уръякала*

## Өй иясе. Йорт иясе

«Яңа өй салгач, әбине күчерәләр. Мич тарта торган помело белән күчерәләр. Яки, яңа өйгә аерылып чыкканда, үзләре белән песи алып чыгалар. "Песи белән бергә торсак, тату тораек, син дә безнең белән бергә тор", – диләр».

* * *

«Иске йортларны, ташландык йортларны җимерәләр. Аларда Өй әбиләре кала. Бу әбиләрне балчык-җир белән күмәләр, урнаштыралар. Әгәр әбине урнаштырмаган җирдән берәр әйбер алсаң, яныңдагы кешегә "әйдә, киттек!" – дип әйтсәң, Өй әби үзен чакыралар дип белеп, арттан килә икән. Әби кайткач, өйдәгеләр йоклый алмый. Савыт-саба чылтырый, ишекләр ачыла-ябыла, аяк тавышлары, сөйләшкән тавышлар ишетелә. Андый вакытта яңа килгән Өй әбине: "Әйдә барабыз, торган урыныңа", – дип, илтеп урнаштыралар. Бер өйдә ике Өй әбие сыешмый, ызгышалар».

*Касыймова Сания Габдулхак кызы (1959 елгы).*
*Кистем*

«Йорт салгач, тартмага утыртып идән астына кертеп салалар Өй әбисен. Бер йортны сүтеп, аның урынына икенчесен салса, Өй әбине китерергә кирәкми. Ике Өй әбие кыйнашалар, ди».

* * *

«Бала еласа, Өй әби алыштырган, диләр. Догалар укыйлар».

*Касыймова Алсу Муса кызы (1981 елгы).*
*Кистем*

## Азбар иясе (Абзар иясе)

«Азбар иясен бабамның этисе күргән. Азбар иясе ат өстендә утырган, ди. Ак киемле, ак сакаллы, ак мыеклы, кечкенә буйлы. Атның ялын үреп утырган. Атны Азбар иясе яратмаса, ат тирләп чыга, ябыга. Яратса, чәчен үрә икән».

*Касыймова Фәнзилә Нурулла кызы (1962 елгы).*
*Кистем*

Азбар бай. «Хайваннарны беренче азбарга керткәндә әйтәләр: "Син дә яратып тот, мин дә яратып китердем", – дип».

*Балтачева Өммегөлсем Габделбәр кызы (1922 елгы).*
*Дасис (Засеково)*

## II. ИМ-ТОМ, МАГИЯ, БАЛА БАГУ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЫШАНУЛАР

«Балаларны артыш яндырып, аның төтене белән төсниләр (төтәслиләр):

Ай да кайта,
Көн дә кайта,
Кояш та кайта,
Балам ... да кайт».

* * *

«Артыш агачын яндырып, өйне чистарталар. Төтене белән өйне әйләндереп чыгасың».

* * *

«Тәнгә чуан чыкса, су газизләренә сәдака бирергә кирәк».

* * *

«Курыкканнан кургаш коялар. Курыккан кешене матча астына яки бусагага утырталар. Нәрсәдән авырганы чыга».

*Касыймова Светлана Казбек кызы (1963 елгы).*
*Кистем*

* * *

Күз тиюне түбәндәгечә имлиләр: «Бу балага яман күз төшкән. Ул күз төшүләре, яман күзләре, авырулары бетсен.

Ай да кайта,
Көн дә кайта,
Төн дә кайта,
Бу да кайта».

*Касыймова Нажия Фәтхулла кызы (1930 елгы).*
*Кистем*

«Кара кашлы,
Кара күзле,
Көрән күзле,
Чурай күзле (*серый*),
Зәңгәр күзле,
Ак чырайлы,
Кара чырайлы,
Кызыл чырайлы кешеләрнең күзләре
Бетсен-китсен,
Хруч мәлген шифара.
Бетсен-китсен, (3 тапкыр)
Тьфү-тьфү-тьфү».

«Тота, диләр, ул вакытта да әйтәләр: кырык агачның тамыры ничек корыган, бу авырту да шулай корысын, диләр».

*Касыймова Сания Габдулхак кызы (1959 елгы).*
*Кистем*

«Өй әби балаларны алыштырмасын, дип, бала янына пычак салалар. Бала бик еласа, Өй әби алыштырган, диләр. Догалар укыйлар. Мунчада баланың киемен дә калдырырга ярамый».

*Касыймова Фәнзилә Нурулла кызы (1962 елгы).*
*Кистем*

«Баланы алыштырып китмәсен, дип, аның исеме алдыннан “миң” сүзе кушалар. Мәсәлән: Миңлеайгөл, Миңлеилдар».

* * *

«Яңа туган баланы мунчага әби йөртә. Балага исеме белән дәшәргә ярамый. Балага: “Аю балам, куян балам”, – дип дәшәләр».

«Яшен яшьнәгәндә култык асларын, тез асларын сыпырырга кирәк. “Бисмилла” укырга».

*Касыймова Светлана Казбек кызы (1963 елгы).*
*Кистем*

«Яшен бәргән урынны кара сыерның сөте белән сүндерәләр. Кара сыер сөте белән әйләндереп алырга кирәк».

* * *

«Адаштыра торган җирдә киемнең, яулыкның тискәре ягын кияргә кирәк. Аннары чыгара».

* * *

«Боз яуса, мичтән ипи ала торган көрәкне чыгарып бәрәләр».

*Касыймова Хәят Ибраһим кызы (1924 елгы).*
*Балезино*

**«Чүп эни» йоласы**

«Бу йола Уръякалада бар. Бала бик елак булса, алдан күрше белән сөйләшеп куялар. Ишек төбенә чүп өеп куялар. Бала-

ны шул чүп өстенә чыгарып салалар. Алдан сөйләшеп куйган күрше хатын шул вакытта килеп керә дә: “И, бу кемнең баласы икән? Исеме ничек икән? Исеме фәлән булсын”, – дип, үзе исем бирә. Кире шул өйгә кертеп бирә. Бу хатын Чүп әни була. Әнисе кебек була».

* * *

«Бала еласа, белгән кешеләр баланың чүпрәген (пеленкасын) алган, аны идән астына, мич астына куеп калдырган. Әгәр бала чүпрәге икенче көнгә кузгалган булса, балага җен тигән, диләр. Кузгалмаса, тимәгән була. Алмаштырган булса, баланы идән астына алып төшеп, җен баласын биреп, үз баласын алып менә».

* * *

«Тота торган җирләр була. Андый җиргә тоз, акча илтеп ташлыйлар. Бу “ташлану” дип атала. Болай дип әйтәләр:

Име-томы шул булсын,
Бүтән миннән көтмәгез,
Шуңа риза булыгыз».

* * *

«“Чобан” дисәң – “чыгам” дип тора, “сыткыч” дисәң – бетә».

* * *

«Бәби еласа, мәче койрыгын суырырга биргәннәр».

*Касыймов Илмир Харис улы (1979 елгы).*
*Кистем*

«Великий четверг капкаларга артыш агач тутырабыз. Дошман, авырулар кермәсен, дип».

*Тютина Раида Леонидовна (1961 елгы).*
*Уръякала*

«Артыш – шайтан кертми өйгә. Аны ишек өстенә кыстырасың».

*Балтачева Өммегөлсем Габделбәр кызы (1922 елгы).*
*Дасис (Засеково)*

## III. РИВАЯТЬ-ЛЕГЕНДАЛАР, СӨЙЛӘКЛӘР

### Кистем тарихы

«Безнең бабалар Нократтан килгәннәр. Беренче килгән Корбангали бабам булган. Улы – Сәфиулла бабам булган. Башта Ужҗага килгәннәр. Анда базар булган. Базарлы-чиркәүле зур авыл булган. Ужҗа – Балезино авылы ул. Соңыннан су эзләп килгәннәр дә, монда килеп урнашканнар. Урман чабып урнашканнар».

*Касыймова Нәҗибә Госман кызы (1930 елгы).*
*Кистем*

«Кистем» исеменең килеп чыгуын берничә төрле аңлаталар.

«Берничә ир-ат агач чапканда бер ар кешесе сораган: “Авылыгызның исеме ничек?” Берсе агач чапканда, агач кискәнен әйтеп: “Кистем”, дип кычкырган. Теге ар кешесе авылның исемен Кистем дип аңлаган.

Икенче мәгънәсен удмурт теле белән бәйләп аңлаталар. Удмуртча ул куяннар яши торган җирне аңлата.

Кистем – чик дигән сүз. Болгар җиренең чиге дип аңларга була.

Авылда Иске Казан юлы дигән урын бар. Анда 1870 елларда зур хәзинә дә табылган.

Кистем аша Сибирский тракт та узган. Бу юлдан Екатерина II үткән, дип тә сөйлиләр. Бу юл хәзер юк. Әмма анда бик адаштыра».

*Касыймова Мирия Ринат кызы (1990 елгы).*
*Кистем*

### Ат караклары

«Бу якта бик хәйләкәр ат караклары яшәгән. Бабайлар атны алып киткәннәр. Арттан полиция килгән. Полиция караклар артыннан килеп керсә, ат беркайда да юк. Бөтен җирне тентеп эзләгәннәр. Өйдә ирләр чәй эчеп утыра. Атны бәйләп полатька (*сәндерәгә*) менгереп салганнар. Полиция анда дип уйлый да алмаган. Атны, алып кайтканда, чабата киертеп кайтканнар. Юкә чабата булгач эт тә ат исен сизми. Бабам шулай сөйли иде».

### Зур адәмнәр – алыплар турында

«Минем Шәмсия әби бар иде. Ул безгә сөйли иде. Элекке заманда Уръякала артындамы, Гординодамы шунда, озын-озын адәмнәр

булган. Великаннар ягъни. Зур-зур ташларны Чепца (*елга*) аркылы ыргытканнар. Аларны «зур адәмнәр» дип атаганнар. Алардан халык бик курыккан. Газиз бабай да сөйләгән иде. Акбур ташыганда, казыганда сөякләр тапканнар. Берцовый сөяк үзе 2 метр булган. Бригадир күмдергән. Каргышы, җене тияр, дигән. Күмгәннәр инде. Бер кешегә дә сүләмәгез, дигән. Үләр алдыннан сөйләгәннәр. Ул сөякләрне тапкан кешеләр бөтенесе авырган».

* * *

«Уръякала-тауда зур адәмнәр яшәгән. 2,5–3 метрлы булганнар. Алар икесе Чепцаның ике ягында торып, бер-берсенә туп белән бәрешеп уйнаганнар».

*Касыймова Хәят Ибраһим кызы (1924 елгы).*
*Балезино*

## Җеннәр турында

«Берәү Уръякалада Рошпо (Рождество) вакытта туры килгән. Машина белән бара икән. Бер заман машина туктый. Бер нәрсә эшләп тә булмый. Бармый машина. Бер заман атлар килә. Тройкалар җигелгән. Җырлашып, кыңгыраулар белән киләләр. Җил-давыл булып үтеп китәләр дә юкка чыгалар. Алар киткәч, җил дә бетә. Машина да кузгалып китә».

*Касыймов Ренат Габдулла улы (1964 елгы).*
*Кистем*

* * *

«Кара күл булган. Хәзер ул кипте инде. Элек Чепца аккан түбәнгә. Кара күл белән җир астыннан кушылган булганнар. Ул күл зур түгел. 2–3 метр диаметрлы булган. Куаклык эчендә, кырыенда чирәм селкенеп торган. Анда керергә кушмыйлар. Әти әйтә иде, кич алтыда ул күлдә прилив була, дип. Суы күтәреләторган булган.

Әти бервакыт судан озын муенлы бер баш чыкканын күргән. Кәлтә башына охшаган бу баш бер яктан икенче якка караган да, кире чумган. Бу 30 нчы елларда була. Соңрак күрмәгәннәр».

«Ферма ягында элек зур сугыш булган. Анда хәзер дә уклар табалар. Ул җирдән юлдан үткәндә, Кистем ягына үткәч тә, кире якка үткәч тә, туктап пычак белән юлны кискәннәр (пычак белән юлга

аркылы сызганнар), арттан килмәсеннәр, дип. Граница билгеләгәннәр. Ул 7 нче кулон дигән җир, 7 нче күпер».

*Касыймова Илсөя Хәкимҗан кызы (1938 елгы).*
*Кистем*

«Авылга керә торган юл буенда наратлар үсә. Ул наратларны авылның яшь егетләре утырткан. 1941 елны сугышка киткәндә әйткәннәр: “Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз, бу наратларны саклагыз”, – дигәннәр. Ничә егет икәнен дә хәтерләмиләр. Ул вакытта нарат утырткан егетләрнең берсе дә кайтмаган. Наратлар егерме өч, берсе аерымрак үсә».

*Касыймов Илмир Харис улы (1979 елгы).*
*Кистем*

«Иманай авылына кергәндә юл буенда кабер кала. Бер бабай булган. Аның бер кешесе дә булмаган. Бик салкында үлсәм, якын гына җирләгез, еракка зиратка илтмәгез, дигән. Юл буена җирләгәннәр. Ул, мине зиратта бер кем дә искә алмас, монда юлдан үтүчеләр дога кылып үтәрләр, дигән. Исеме Аслый бабай булган диләр. Аны юлчы дип тә сөйлиләр».

*Митякова Мәдинә Габдулла кызы (1950).*
*Иманай*

# ҖЫРЛЫ ТӨБӘК

***Удмуртия татарларының халык иҗаты***

---

*Ленар Җамалетдинов*

Без, әлбәттә, «халык телендә элек әкиятләр күп булган» дибез. Әмма халык авыз иҗатындагы бу әсәрләр һәр җирдә дә булмаган шул. Әнә бит, Удмуртия Республикасында 1956 елда эшләгән экспедициядә 11 авылда булып, нибары бер әкият алып кайткан! Бу бит моннан 56 ел элек! Әйе, әкият дигән хәзинә ул – төбәге-төбәге белән генә. Әйтик, Татарстанда әкиятле як дип Теләче, Апас, Буа төбәкләре санала. Шул ук вакытта әкиятсез төбәкләр дә бар.

Әмма шулай да узган гасырның 60 нчы еллар азагында Удмуртиянең Воткинск шәһәреннән Рәйханә Назарова дигән ханым Татарстан Язучылар союзына «Алтын кош» дип исемләнгән озын гына бер әкият язып җибәрә...

Әлеге әкият шагыйрь Рәшит Гәрәй кулына килеп кергән. Чөнки текстның азагында карандаш белән «Укыдым. Р. Гәрәй» дигән тамга бар, күрәсең, әкият язылган дәфтәр авторга кире кайтарылган.

Рәйханә ханым бу юлы үзенең әкиятен ул вакыттагы Тел, әдәбият һәм тарих институтына җибәрә. Аның хатында мондый юллар бар: «Бу әкиятне кечкенә чагымда тыңласам да, бик яратып искә аламын. Мин бик күп китаплар укыдым, төрле милләтләрнең әкиятләрен. Бу әкиятемне бер китапта да очратмадым. Мин аны башкаларның да белүен телим. Әгәр яраклы дип тапсагыз, китапка кертүегезне үтенәм».

Хатның язылу датасы күрсәтелмәгән, әмма бу язышу 1968 елда булгандыр мөгаен, чөнки дәфтәр төрелгән соры кәгазьдә, ул чорда Институтның гыйльми сәркәтибе булып эшләгән И. Надировның «4.01.69» диелгән култамгасы бар.

Әкияткә бәйле тагын ике сорау туа. Бу сорауларга инде Рәйханә ханым хатларыннан җавап таба алмабыз. Институттан әкият язылган дәфтәрен алу турында хәбәр ителгәч, Рәйханә ханым рухланып, тагын бер әкият язып җибәргән. Монысын ул «Бер тәпәч» дип атаган. Ихтимал, аңарда әкиятләр әле тагын да булгандыр. Әмма информант әлеге әкиятләрнең кайда, кайчан һәм нинди шартларда кем тарафыннан сөйләнгәнен хәбәр итмәгән. Шуның өстенә Рәйханә ханым үзенең җирле кешеме, булмаса, кайсы төбәктән икәнен дә әйтмәгән, бары тик «Воткинск шәһәрендә 1939 елдан башлап яшим» дигән җөмләсе генә бар. Әкият Удмуртиядән килгән икән, без аны бу җыентыкка кертергә булдык. Исемен исә үзгәртергә туры килде. Сәбәбе – «Алтын кош» исемле әкиятнең булуында түгел, бәлки бу исемнең информант бәян иткән эчтәлекне иңләмәвендә. Шуңа күрә аңа «Сабыр сеңел» дигән исем куелды.

## Сабыр сеңел

Берничә йөз еллар элек бер кечкенә шәһәрдә өч улы һәм кече кызы белән бер карт яши. Кече кыз була шулкадәр чибәр: йөзе кояш кебек нурлы, алтын кашлы һәм алтын чәчле була. Бу бабайның тагы була бер яраткан алтын кошы һәм алмачуар айгыры. Бабайның хәле көннән-көн авырая, куллары хәлсезләнә, сөйләше загыйфьләнә. Көн дә көтә алсу таңнарның атканын һәм гомеренең актык минутлары җиткәнен.

Көннәрнең берендә бабай өч улын да янына чакыра.

– Улларым, – ди, – минем сезнең белән саубуллашу көннәрем килеп җитте. Сау булыгыз, рәхәт яшәгез, әмма минем васыятемне үтәгез, – ди. – Улларым, васыятем шул: сеңлегезне һәм алтын кошны, алмачуар айгырымны күзегезнең карасы күк саклагыз. Кешеләрдән сеңлегезне көлдертмәгез һәм алтын кошны, алмачуар айгырымны ерткыч куллардан саклагыз, – ди.

Уллары аталарының васыятен үтәргә вәгъдә бирәләр.

Кояш алсу чаткыларын җир йөзенә сибеп, әкрен генә батканда, кошларның да моңлы сайрау тавышлары тынганда, бабайның гомере өзелә.

Аталары үлгәч, өч улы күз яше түгәләр. Иркәләнеп кенә үсә торган чагында кече кызына бу кайгы бигрәк тә авыр була. Алтын кош та сайрамый, алмачуар айгыр да хуҗасын көтеп кешнәми. Алар да сизә кайгылы көннең килгәнен.

Аталарын күмгәч, бик авыр була. Хуҗалык белән эш итү кече сеңелләренә тапшырыла.

Өч туган, өч ир бала аучылык белән шөгыльләнәләр һәм шуның файдасы белән көн күрәләр. Ауга чыкканда өч абыйсы да күбрәк ау тотсалар, кече сеңелләренә күбрәк бүләк алырга вәгъдә бирәләр. Аларның көннәре шулай итеп үтә. Көннән-көн аулары арта, сеңелләренең бәхетле булуына шатланалар. Сеңелләренә алар нинди генә бүләкләр алмыйлар. Күлмәкләре дисәң, күлмәкләре шундый, патша-падиша кызлары гына кия торган күлмәкләр, аягында төрле матур башмаклар, муенында җем-җем иткән йолдызлар күк төймәләр… Һәммәсенең чуты-чамасы булмый. Кошның да азрак кайгысы басыла төшә, сайрый башлый. Ул да шатлана. Абыйлары сеңелләрен бик хөрмәтлиләр, шулкадәр яраталар. Алмачуар айгыр да көчле тавышы белән кешни башлый.

Бөтен йорт эшләрен башкару сеңелләренә авыр икәнен исләреннән чыгармадылар. Сеңелләренең эшен җиңеләйтү өчен, өчесе дә өйләнергә уйладылар. Көннәрнең берендә өчесе дә бер көнне өйләренә өч килен алып кайталар.

Өч киленнең дә каен сеңелләренең шулкадәр чибәр булуына исләре китеп, һәммәсенең дә күңелендә көнчеллек туа. Өйләнсәләр дә, абыйлары сеңелләрен һичкайчан онытмыйлар, элекке шикелле бүләкләр вәгъдә итеп, аның белән исәпләшеп, юлга, ауга чыгалар. Сеңелләре исә һәрвакыт юл кирәкләрен хәзерләп, абыйларын озатып кала.

Аудан кайткач, яхшы бүләкләрне аңа, сеңлесенә бирәләр.

Кызның җиңгәләре күңелендә көнчелек көннән-көн көчәя. Әмма берсе дә иренә бу уйны әйтергә курка, әйтмичә әрниләр.

Ел тулганда, өч килен бер көнне өчесе өч ир бала таба. Балалары аталары шикелле чибәр булалар. Шулай да, каенсеңелләре кебек булырга ерак инде.

Балалары булса да, сеңелләрен ярату кимеми, элеккечә зурлыйлар, шәфкать итәләр абыйлары.

Көннәрдән бер көнне өч хатын бергә җыйналып киңәш итәләр: ничек итеп ирләрен сеңелләреннән читләштерергә. Үзләрен яратырга мәҗбүр итәргә. Күп уйлаганнан соң, бер фикергә киләләр: алтын кошны үтерергә дә «сеңелегез үтерде» дип әйтергә.

Бу көнне аучыларга ау бер дә бәхет китерми. Сеңелләренә биргән вәгъдә дә үтәлми.

Ирләренең каршысына өч хатын да елап чыгалар:

– Менә сезнең сеңелегезнең яхшылыгы бүген башланды. Алтын кошны үтерде ул, – диләр.

Абыйларының: «Нигә үтердең?» – дигән сорауларына «Мин үтермәдем, абыйларым», – дип әйтергә булдыра алмый. Шулай итеп, сеңелләре абыйлары алдында хыянәтче, кош үтерүче булып кала. Абыйларын, элеккечә, юлга барын да әзерләп озата, шат күңел белән каршы ала. Күңелендә авыр тойгы булса да, абыйларына әйтми, күңелендә яшереп тота. Абыйлары элеккечә бүләкләр алып кайталар, алтын кошны үтерүче булса да, сеңелләрен элеккечә яраталар.

Кызның җиңгәләре тагы нык көнләшәләр. Алтын кошны үтереп тә, абыйларының кызга ачуланмауларына бик ачулары кilә.

Көннәрнең берендә кызның абыйлары атсыз гына ауга чыгалар. Алмачуар айгыр, нидер буласын сизгән кебек, хуҗалары артыннан шулкадәр барырга теләсә дә, бикләп, утарда калдыралар. Хатыннар атның өйдә калуына шатланалар һәм, бүген үк атны үтереп, сеңелләреннән котылырга телиләр.

Ирләре күпме юл үткәндер, хатыннары уйлаган начар уйларын башкара башлыйлар. Атка ашарга биргәндә агу салып ашаталар да, бик нык итеп, утарны бикләп куялар.

Ат агулы ашамлыкны ашаганнан соң никадәр ярдәмгә чакырса да, ярдәмгә беркем дә килә алмый. Шулай итеп, ат үлә.

Хуҗалары көн буе күпме тырышсалар да, бер җәнлек тә аулый алмыйлар.

Кояш байый, төн җитә. Шулай итеп, болар урманда кунарга мәҗбүр булалар. Бик кәефсезләнәләр бүген, ни өчендер, сеңелләренең бәхете юклыгына. Бер бүләксез ничек кайтып керергә өйгә.

Авыр булса да иртән үк өйгә кайталар. Каршыларына өчесенең дә хатыны елап чыга.

– Менә сезнең сөйкемле, чибәр сеңлегез нәрсәдер эшләтеп айгырны үтерде, – диләр.

Абыйларына «мин үтермәдем, кадерле абыйларым», дип тагы әйтә алмый кыз. Үз кулы белән эшләмәгән гаепне үз өстенә ала.

Абыйлары бу хәлгә дә ачуланып сүз әйтергә булдыра алмыйлар. Әтиләренең васыятен онытмыйлар. Алтын кошсыз да, алмачуар айгырсыз да яшәргә булалар. Сеңелләреннән башка, бәхетле булып яши алмауларына ышаналар.

Абыйлары сеңелләренә бер авыр сүз дә әйтмәүләренә кызның җиңгәләре елан шикелле зәһәрле агуларын чәчәләр. Ни генә эшләтеп булса да, бу каенсеңелләреннән котылу юлын уйлыйлар.

Кошның үлеме дә, атның үлеме дә, күп вакытлар үткәч, онытыла төшә. Көзге көннәр җитә. Җәнлеккә аучылык өчен иң бай вакыт бу. Бер көн үтә, ике көн үтә, өченче көндә бер табышсыз кайтырга мәҗбүр булалар. Үзләренең йөрәкләре әрни. Нәрсәгә әрнегәнен белмиләр. Өч көн йөреп тә, бер җәнлек тә аулый алмый кайтуларына дип уйлыйлар.

Ерактан ук күрәләр, өчесенең дә хатыны капка алдында басып торганын. Ничек тә кызны бу йорттан юк итү өчен күп планнар корганнан соң, үзләренең газиз булган балаларын үтереп, капка алдында, кулларына үле балаларын тотып ирләрен каршы алалар. Бу хәл кызның өч абыйсының да ачуын кабарта. Һәркайсы үз улын шулкадәр ярата иде, өйдә вакытта улын иркәләп, сөеп вакытын үткәрә иде.

Олы абыйсы энеләренә әйтә:

– Туганнар, бу хәлне минем йөрәгем кичерә алмый, – ди. Алтын кошны да үтерде, алмачуар атны да үтерде, сөекле улларыбызны да үтерде. Сеңлебез сөекле һәм чибәр булса да, әткәбезнең васыяте булса да, без аңа җәза бирергә хаклыбыз, – ди.

Кызның җиңгәләре дә елый-елый җәза бирүләрен сорыйлар:

– Без сезнең сеңлегез белән бергә яши алмыйбыз, кая булса да куегыз, – диләр. – Кадерле улларыбызны үтерде, алтын кошны да, атны да. Ул, озакламый безнең өчебезне дә үтерер. – диләр.

Олы абыйсы сеңлесен чакырып ала да:

– Кадерле сеңлем, нигә син андый җинаять эшләдең? – дип сорау бирә. – Нинди гаепләре бар иде безнең кечкенә улларыбызның, нигә син аларны үтердең? – дип сораса да, бер җавап та ишетә алмады. – Шулай булгач, кадерле сеңлем, мин, синең олы абыең буларак, сиңа үзем җәза бирәм, – диде.

Сеңлесе һаман да эндәшмәде, башын гына иде.

Абыйсы атка утыртып алып чыгып китә сеңлесен зур урманга. Күп юллар үткәч, түгәрәк кенә күл буенда бер алма агачы үсеп утыра. Алмалары пешеп, җиргә төшәрдәй булып торалар. Атны туктатып, сеңлесенең арбадан төшүен сорый. Аннары сеңлесенә кычкыра:

– Үрел дә әнә шул алманы ал, – ди.

Сеңлесе алмага үрелгәч, абыйсы тиз генә кылычын ала да ике кулын чабып өзә. Сеңлесе һушсыз булып егыла. Агач яфраклары белән сеңлесен каплый да өенә кайтып китә бу.

Кыз күпме вакытлар яткандыр, белми. Мылтык тавышына сискәнеп, сикереп торырга уйлый. Ә куллары торырга ярдәм итми. Нәрсәләр булганын: этисен, алтын кошны, алмачуар айгырны, балаларның үлемен, барысын да күңеленнән күз алдына китерә. Бер гаепсезгә абыйсы аның ике кулын да чабып өзде ич, үксеп-үксеп ачы кайнар күз яше белән елый. Көмештәй яшь тамчылары чәчәкләрне чылата.

Ерак түгел бер каен янында аучы басып тора. Кызга күзе төшә. Кызның нурлы йөзе бөтен күл буен балкытып, яктыртып тора, нәкъ иртәнге кояшның алсу нурыдай. Аучы әкрен генә атлап, кызның каршысына килеп баса, һәм, кулларының юклыгын күргәч, йөрәге әрнеп куя. Аучы сорый, аның нигә шулай кулсыз калганын, кемнәр ерткычларча кулын чабып өзгәнен. Кыз барын да сөйләп бирә, бер гаепсезгә абыйсы кулып чабып өзгәнен. Өч җиңгәсенең бөтен гаепләрен үз өстенә алып, алар күрәсе җәзаны үзе алганын.

Аучы егет сорый:

– Син миңа гомерлек иптәш булырга телисеңме? – ди.

Кыз нәрсә дип җавап бирергә дә белми.

– Мин бит сиңа иптәш булырлык тиң түгел. Мин бит, кулларым булмагач, бер нәрсә белән дә ярдәм итә алмаячакмын. – ди.

– Синең миңа бер эш белән дә ярдәм итүең кирәкми, бары синең нурлы йөзең белән үзең генә кирәк, – ди.

Бик үтенгәч аучы егет, кыз каршы килә алмый. Шулай итеп, егет кызны алып кайта өенә.

Аучы егетнең анасы гына була, башка беркеме дә булмый, туганнары да. Анасына бар хәлне яхшылап сөйләп бирә бу. Куллары булмаган кызны алып кайтуына хәтере калса да, дөньяда бу кыз кебек чибәр кыз булмавына ышана һәм риза була гомерлеккә килен итәргә.

Бу кыз аучы егет белән яши башлагач та, тормышлары яхшыра башлый. Егетнең авы көннән-көн бик күп файда китерә. Егет тә, кыз да, аналары да шулкадәр шатланалар…

Шулай матур гына яшәгәндә, егетне хөкүмәт аучылыгына алып, ерак юлга озаталар. Вакытын тутырып кайтырга өч ай кала, кыз үзе шикелле, алтын чәчле, алтын кашлы, зәңгәр күктән аерып алмаслык зәңгәр күзле, ап-ак йөзле бер ир бала таба.

Аучы егетнең анасы шулкадәр шатлана. Ничек итеп бу шатлыкны улына хәбәр итүне кайгырта башлый. Ул вакытта хатлар хәзерге шикелле тимер юлларда поезд белән йөрми. Егетнең анасы, бер картны яллап, хат язып, улына шатлыклы хәбәрне җибәрә, ат белән.

Көн кичегә, караңгылана төшә. Бу карт кечкенә генә шәһәрдә кунарга була. Бер иске генә ярым җимерек йорт янына туктап хуҗа хатыннардан, төн кундырып чыгаруларын сорый. Хуҗалар риза була.

Ашагач-эчкәч сорыйлар моңардан кая барганын. Бабай барын да сөйләп бирә. Аучы егетнең урманнан ике кулы киселгән, алтын чәчле, алтын кашлы, якты кояш кебек нурлы йөзле бер кызны өенә алып кайтуын. Әнисенең рөхсәте белән бу кызга өйләнүен. «Егет еракта ауда булу сәбәпле, менә мин аңа хат илтәм, – ди. – Чибәр кызның үзе кебек чибәр улы туды», – ди.

Бабай йокыга киткәч тә, хуҗа хатыннар киңәш итәргә җыйналалар. «Бабайның сүзе буенча, бу кызның каенсеңлебез булуына һич шик юк» – диләр.

Болар бабайның кесәсеннән хатны алып укыйлар. Егетнең анасы яза: «Улым, безнең өйгә икенче нурлы кояш туды: анасыннан да чибәр ир бала. Улым, тизрәк кайт», – дигән.

Бу хатны ертып ташлыйлар да, икенче хат язалар: «Улым! Ир бала туды, урмандагы ерткыч хайван шикелле, олы күзләре баканыкы кебек, карарга да куркыныч, ни эшләтим инде».

Бабай бу хатны илтеп тапшыра. Аучы егет укый да:

– Бу хатны кем язды? – дип сорый.

– Әниең язды, тизрәк сиңа тапшырырга җибәрде, – ди бабай.

Хатка язган сүзләрнең дөресме-түгелме икәнен сорамый, «анаң язды» дигәч, ышана.

Каршы хат яза улы: «Әни, ничек булса да, ни туса да, түз инде, кайткач мин үзем хәл итәрмен, кызны да, баланы да бер нәрсә дә эшләтмә, яшәсеннәр», – дип.

Бабай кайтканда тагы кызның шул ук җиңгәләренә кереп, төнне аларда йоклап уздыра.

Кызның җиңгәләре, бабай йоклагач, тиз генә хатны алып укыйлар да тагы җавап язалар: «Әни, миңа кулсыз хатын кирәк түгел, бу хатны алу белән, аны баласы белән бергә чыгарып җибәр», – дип язалар да, кире конвертына салып, ябыштырып куялар.

Кыз белән анасы, түземсезлек белән яхшы хәбәр көткәндә, бабай шушы хатны алып кайтып тоттыра. Анасы ачып укый башлый,

кычкырып. Улының һәрбер сүзе, үткен пычак булып йөрәгенә кадала. Кыз, абыйларына сүз әйтә алмаган күк, моңа каршы бер сүз әйтә алмый.

– Әни, ярый, мин китәм чыгып, рәхәт яшәгез, – ди, – булмаган бәхетемне якты дөньяның күпме юлларын таптап эзләсәм дә таба алмамын. Әйе, әнием, минем кулларым юк, мин беркемгә дә кирәкле һәм яраклы кеше түгелмен. Яшәгән көннәрем өчен һәм күрсәткән хөрмәтләреңә зур рәхмәт. Әнием, бәгърем, баланы гына яхшылап төреп бир инде, – ди.

Анасы бик матур итеп төреп бирә дә, икесенең дә алма кебек алсу битләреннән үбеп, озатып кала. Кыз беләкләре белән баласын кочаклап, авылдан-авылга, урманнан-урманга йөреп, нәрсә туры килсә шуның белән тукланып, кайда төн җитсә шунда йоклап, гомерен үткәрә. Бала, шулай яшәүгә карамастан, көн үсә, төн үсә, ныгый.

Кызу көннәрнең берендә моның баласы су эчәргә сорый. Су тирән була, тирә-якта беркем күренми, елганың ярлары биек, кыяланып тора. Бик интегеп төшсә дә су буена, балага ничек су эчерүнең чарасын таба алмый. Бик күп азаплангач, беләкләре белән тотып, баланың башын суга ия. Баланы кире күтәрим дигәндә, кулларының көче җитми, баланы суга төшереп җибәрә. Ярдәм сорагандай, як-ягына карый. Караса, биек ярның башында бер карчык басып тора. Кычкыра: «Ике кулыңны да суга тыгып, тартып ал баланы», – ди.

Ике кулының юклыгын да уйлап тормастан, балага кулын суза. Судан баласын тартып ала да, кулының бармаклары беләкләренә ялганганын күреп, шатлыгыннан, һушын югалта яза. Азрак вакыт үткәч, аңына килеп, бармаклары белән баланың чәчләрен сыйпап сөя, кысып кочаклый. «Улым, син минем кадерлем, син суга төшеп, мине ике куллы иттең ич, – ди. – Үзең дә котылдың, гомер буе интегергә калган әниеңне куллы, бармаклы иттердең».

Карчыкның сүзе, колак эчендә яңгырагандай була яңадан. Әмма тау башында инде карчык күренми, рәхмәт әйтергә кеше дә юк. Карчык күренде дә, юк та булды.

Күп вакыт та үтмәстән, аучы егет, чибәр хатыны һәм әнисен сагынып, өенә кайта. Ашыга-ашыга өенә керсә, өйдә бер әнисе елап утыра.

– Улым! Нигә син шундый начарлык ясадың? Нигә хатыныңны, балаң белән куарга куштың? – дип, үксеп елый.

Аучы егет аңламый тора.

– Әни! – ди. – Мин бит сиңа «ерткыч хайван кебек булып туса да, мин кайтканчы тот, бер нәрсә дә эшләмә, бер кая да чыгарма! – дип яздым, – ди.

Анасы бу сүзләрне ишеткәч, артына егылып китә язды.

– Улым! Мин бит сиңа яздым: «Анасыннан да чибәр, якты кояштай йөзле, алтын чәчле, алтын кашлы, зәңгәр күктән дә зәңгәррәк күзле улың туды. Улым, тизрәк күрергә кайт», – дип язган идем. Бу нинди намуссызлык, хат илтүче үзе укый-яза белми. Бу хат безнең дошманыбыз кулына кергәндер. Мескен кадерле киленемне, кече улымны шулай куып чыгарырга мәҗбүр итүче дошман кем икән ул, улым? – диде.

Аучы егет, күп уйлап тормый, мылтыгын иңсәсенә аса да, эзләргә һәм табарга ант биреп, әнисе белән саубуллашып, юлга чыга.

Көн артыннан көннәр үтә, төн артыннан төннәр үтә, айлар үтә. Һаман да табу ышанычын югалтмый бу, эзләвен дәвам итә. Очраган һәрбер юлчыдан сорый. Беркем дә күрмәгән ике кулы булмаган ананы. «Куллы ананы күргәнебез бар, кулсыз ананы күргәнебез юк», – диләр.

Менә яланга туктый бу. Су эчәсе килә моның, сусый. Якында чишмә юк микән, дип, эзләп китә.

Ерак түгел чылтырап аккан бәләкәй генә чишмәгә килеп җитә бу. Ятып учы белән су эчә дә шушы чишмә буенда ял итеп, йоклап алмакчы була. Күзен йомып өлгерми, әкрен генә чыбыкларның сынганын ишетә. Күзен ачса, чишмәгә баласын кулына тоткан ана якынлашып килә. Телсез кала бу, бер сүз әйтә алмый. Күзен бер йома, бер ача, күңеле ышанмый да: каршында, улын күтәреп, хатыны басып тора. Уйлый: минем хатынымның бит куллары юк иде, моның ике кулы да бар.

Шул вакытта уе белән башы чуалганда, ана аучы егетнең муенына ташлана.

– Син ничек монда? Безне эзләсәң, без – синең каршыңда. Мин – синең хатының, менә синең улың, – дип, улын атасының кулына тоттыра.

Атасы улын ничек кенә иркәләргә дә белми, коча, үбә.

Улы инде үскән була. Кулына карый хатынының, ике кулы да, бармаклары да чын, табигый бармаклар. Шатлыгы йөрәгенә сыймый, ничек сорарга белми.

Хатын иренең бу уен аңлап ала да үзе сөйли башлый:

– Син минем кулларым, бармакларым ялганганга көенәсеңме, әллә шатланасыңмы? – ди. – Курыкма, кулларым да, бармакларым да үземнекеләр. Бәлки син бу кулларымны кисмәссең һәм бер кемгә дә кисәргә рөхсәт итмәссең бит?

– Син сөйлә миңа ачыктан-ачык, ничек куллы булганыңны? Бәлки мин бу хәлне, сезне төшемдә генә күрәмдер, – ди.

– Юк, төшең түгел, чын дөреслектә, без синең белән бергәбез. Тыңла, сөйлим барын да ничек булганын, – дип, барын да сөйләп бирә.

Шулай утырганда алтын кояш, нурлы чаткыларын соңгы тапкыр җир йөзенә сибеп, байый. Кояшка тиң булган, кояш кебек көләч йөзле ана баласы белән кечкенә болында кала. Караңгы төшә, җем-җем итеп, йолдызлар һәм якты ай калка.

Чылтырап аккан чишмә буенда өчесе төн уздыралар. Таң пәрдәсе ачылгач, яктыра башлагач, йокыларыннан уяныл кошлар сайрый башлагач, өйләренә кайтырга чыгалар.

Өйләренә кайтып кергәч, аналарының шатлыгын каләм белән язып, тел белән сөйләп аңлатырлык булмый.

Шатланып матур гына гомер иткәндә, хатын сорый иренең абыйларына алып баруын. Әйтә: «Мин аларны бик сагындым, бик күрәсем килә», – ди.

Сеңлесенең кулып чабып өзгән көннән үк абыйларының тормышлары авырая башлый. Аучылыклары бер дә бәхет китерми, көннән-көн фәкыйрьлеккә, юклыкка чумалар. Аучылыктан башка бер һөнәр дә белмиләр. Атасыннан калган йортның да почмаклары җимерелә башлый.

Көннәрдән бер көнне, көн кичеккәч, юлчылар кунарга сорыйлар киленнәрдән. Киленнәр өчесе дә риза булалар. Ирләре өйдә булмый, ауда була. Юлчылар өйгә кергәч, киленнәр бу яшь, чибәр анага һәм аның баласына сокланып карыйлар. Алар берничек тә ышанмыйлар каенсеңелләре булуына, төсе шулкадәр ошаса да. Үлгән сеңелләре терелергә тиеш түгел, ике кулын да кисеп өзгәч, ул ничек яшәсен, ди. Ә бу апаның ике кулы да бар. Дөньяда була инде охшаш кешеләр, дип, күңелләрен юаталар.

Озак та үтми кызның абыйлары кайта. Ябыкканнар шулкадәр, күлмәкләре ерткаланган, хәлсезләр. Әгәр юлда очрасалар, кыз үзенең абыйларын берничек тә танымас иде, үтеп киткән булыр

иде. Өйләренә кайтып кергәч, таныды инде. «Абыйларым сез минем», – дип кычкырып, кочаклыйсы килсә дә, тавышы чыкмый, тамак төбендә тукталып кала. Йөрәге ярсый, елыйсы килә, шулай да сиздерми, түзә.

Абыйлары: «Кунаклар бар икән, исәнмесез», – дип, исәнләшәләр. Күзләре бу апа белән балага текәлә, сеңелләренә шулкадәр охшаталар. Сеңлебез дип әйтергә кыймыйлар, чөнки бу апаның куллары исән. Шулай да шикләнәләр, сеңлебез түгелме икән, дип, күңелләреннән һәркайсы үз-үзенә сорау бирә. Кичке аш әзер була. Кунакларны да ашарга утырталар. Аш артыннан чәй әзерлиләр.

Чәй эчеп, өстәл җыйналгач, сүзгә күчәләр. Кызның иң олы абыйсы әйтә:

– Сөйләгез, – ди, – тормышыгызданиләр булганын. Көннәрегезнең ничек үткәнен.

Кыз әйтә:

– Мин сөйлим, әмма мин сөйләгәндә, минем сүзләремне «дөрес түгел» дип әйтүче булса, шуның өчен аңа үлем җәзасы бирергә риза булсагыз гына сөйлим, – ди.

Бар да риза булалар. Кыз сөйли башлый:

– Булган, ди, бер шәһәрдә өч ир туган һәм аларның бер сеңелләре. Абыйлары өйләнә. Бу кызның җиңгәләре абыйларының үз сеңелләрен яратуына бик көнләшәләр. Көннәрдән бер көнне абыйлары сеңелләреннән үч алсын өчен, өч җиңгәсе бер булып, алтын кошларын үтерергә булалар һәм үтерәләр.

«Үтерәләр» сүзен ишетү белән, өч килен дә бер тавыштан кычкыралар, «дөрес түгел, ялган» дип.

– Ярый, монысы ялган булсын сезнеңчә, дәвам итәм, – ди, – аларның бер алмачуар айгырлары да була. Абыйлары, сеңелләренә алтын кошны үтереп тә сүз әйтмәгәч, өч җиңгәсе, тагын бер булып, агу эчереп, айгырны үтерәләр.

Сеңелләре әйтеп өлгерми, өч җиңгәсе, беравыздан, тагын кычкыралар, «дөрес түгел», дип. Абыйлары бер сүз дә дәшмиләр, нәрсә әйтергә дә белмиләр.

– Туганнар нигә алай тавышланасыз, сүзне бетерергә рөхсәт итегез, – дип, сүзен дәвам итә сеңелләре. – Җиңгәләре алтын кошны үтереп тә, атны үтереп тә, абыйлары сеңлесенә бер сүз дә әйтмәгәнгә, бер җәза да бирмәгәнгә йөрәкләре ярсый. Актык чиктә, үзләреннән туган балаларын үтереп булса да, каенсеңелләреннән

котылырга телиләр. Һәм өчесе дә, балаларын үтереп, каенсеңелләреннән котылу дәрәҗәсенә җитәләр.

– Бу сүзләрең синең бар да ялган! Ялган! – дип кычкыралар.

– Абыйларым, мин сезнең сеңлегез, мин исән. Абыем-бәгърем, син минем кулларымны чабып өздең, боларның зәһәрле-ачулы сүзләренә ышанып. Табигать миңа куллар бирде, мине кызганды. Абыем, мин сине кичерәм, гафу итәм. Мин сезнең каршыгызда гаепле түгел, һәм беркайчан да гаепле булмадым һәм булмам да. Сез гаепле түгелсез, сезнең дә йөрәгегез саф. Җиңгәләрем генә, ни өчендер, яратмадылар, күрә алмадылар.

Өч абыйсы да сеңлесен кочаклап үбәләр, тормышка чыгуы, баласының тууы һәм шулкадәр матур булып үсүе белән тәбриклиләр.

Кызның җиңгәләренә үз җинаятьләре өчен җәза алыр көн җитә.

Аучы егет аптырашта кала, ни уйларга да белми. Хатыны булса да, башыннан үткән бу хәлләрне ул аңа сөйләмәде. Йөрәгендә яшереп саклады.

Инде менә алтын кошны, алмачуар айгырны, үзләренең сөекле балаларын кызганмыйча, якты дөньядан җир астына озатырга намусы җиткән аналарга һәммәсе белән дә саубуллашу сәгате җитте. Алар ирләреннән һәм каенсеңелләреннән гафу итүләрен күпме генә үтенсәләр дә, берсе дә риза булмый.

Өч туган ир һәм сеңелләре үзенең ире – аучы егет белән, шулай ук сөекле уллары белән бәхетле булып яши башлыйлар.

*Удмуртия Республикасының Воткинск шәһәреннән*
*Рәйханә Назарова язып җибәргән, 1968 ел.*

Удмуртия татарларында фольклорыбызның башка жанрларын үз иткән кешеләр шактый булган. Мәсәлән, алда телгә алынган экспедиция вакытында Балезино районының Кистем авылында яшәүче Маһинур Касыймова (40 яшь) 181 кыска җыр яздырган, шул ук авыл кызы Мәдинә Касыймова (20 яшь) 114 җыр тәкъдим иткән. Шушы ук нәселдән Саимә (23 яшь), Фатыйма (18 яшь) һәркайсы 80 шәр җыр яздырган. Гомумән алганда, галимнәр Кистем авылыннан 594 дүртьюллык җыр алып китә. Паюра (Падера) һәм Әхмәди авылларында тупланган җырларны да кушсаң, бер Балезино районында гына да 1260 дүртьюллык җыр тупланган, ә Удмуртия буенча бу жанр әсәрләре, алдарак әйткәнебезчә, 3634 данә тәшкил итә.

Халык лирикасының тагын бер популяр төре – уен җырлары, аларның бер өлешен бию такмаклары дип атарга да мөмкин. Бу җырлар яшьләрнең кичке уеннары вакытында язып алынганнар. Алар шактый – 88 данә тупланган. Биредә шуларның берничәсе белән танышып узыйк.

**Бииләр, бииләр**

Сатин күлмәк киң кирәк,
Сөйгән ярың тиң кирәк;
Сөйгән ярларың тиң булгач,
Бу дөньяда ни кирәк?

К у ш ы м т а :
Бииләр, бииләр,
Бию көен белмиләр.

Егет булса шундый булсын –
Ике күзе ут булсын.
Ике күзе ут булмаса,
Бар булганчы юк булсын.

К у ш ы м т а .

Алмагачы утыртканнар
Карурман читләренә;
Алсу алма суы тамган,
Җаныем, битләреңә.

К у ш ы м т а .

*Юкамен районы Пүчинкә авылында*
*Х. Гатина язып алган. 1956 ел*

**Бас эзенә генә**

Килсен болыт, яусын яңгыр,
Китсен болын буйлата.
Сезнең белән дус булулар
Китсен гомер буйлата.

К у ш ы м т а :
Бас эзенә генә,
Кара күзенә генә,
Карасаң күзенә генә –
Булыр үземә генә.

Карлыганнар алыр идем –
Тия ул тешләремә.
Сары сандугачлар булып,
Керәсең төшләремә.

К у ш ы м т а .

Беләзекләрем бөгелми,
Беләгем бөгелсә дә.
Аерылырга туры килде,
Үзәгем өзелсә дә.

К у ш ы м т а .

*Юкамен районы Максут*
*(М. Венеж) авылында*
*Маһинур Абашевадан (22 яшь)*
*Х. Мәхмүтов һәм М. Зәбиров*
*язып алган. 1956 ел*

**Басар, басар...**

Аклы ситса күлмәгемнең
Тар булган ич кисүе.
Әллә шушы микән инде
Яшь гомернең үтүе.

К у ш ы м т а :
Басар, басар,
Басар өчен килгән ул.
Уйнап-көлеп, күңелләрен
Ачар өчен килгән ул.

Су буена төшкәнем юк –
Үсә микән гөлләрем.
Үссә дә үсә гөлләрем,
Үтә яшь гомерләрем.

Кушымта.

Сәгать суга унбергә
Телефон белән бергә.
Син дә телә, мин дә телим
Икәү булуны бергә.

Кушымта.

*Юкамен районы Максут (М. Венеж) авылында*
*Мәһинур Абашевадан (22 яшь)*
*Х. Мәхмүтов һәм М. Зәбиров язып алган. 1956 ел*

Алдарак әйткәнебезчә, Удмуртиядә эшләгән экспедиция материаллары арасында сан ягыннан иң күләмлесе – кыска җырлар. Гадәттә, «Агыйделнең аръягында...», «Аклы ситса күлмәгемне...», «Иртән торып, тышка чыксам...» һ. б. шундый трафарет фразалар белән башлана торган дүртьюллыклар аеруча күп була. Биредә дә бу үзенчәлек саклана.

Без, әлеге кыска җырларда кеше исемнәре кулланылышын күрсәтү йөзеннән, «Кулымдагы йөзегемнең исемнәре...» дип башланган җырларны сайлап алдык. Язып алучылар: Х. Ярми, Х. Гатина, Х. Мәхмүтов, М. Зәбиров.

Удмуртиядә тупланган кыска җырларның бу төркемендә кеше исемнәренең кайсылары кулланылган соң? Кызыксынучылар өчен аларны бер урында тезеп күрсәтү артык булмастыр кебек. Алар түбәндәгеләр (берничә җырда кулланылган исемнәр курсив белән бирелә): ир-ат исемнәре – Азат, Барый, *Габделхак*, Габделхәй, Габдулла, *Газизулла*, Газыймҗан, Гайнан, Гафур, Гыйльми, Зиннәт, *Ибрай*, Идрис, *Илгизәр*, Имани, *Исмәгыйль*, Йолсым, Кабул, Кәбир, *Мансур*, Миннехан, Миркасыйм, Мөбарәк, Мөхәммәт, Мөхәррәм, *Нургали, Нургата*, Нургаян, *Нурислам*, Нуркадыйр, Нурулла, *Пигамбәр*[1], Рәҗәп, Рәсим, *Сабирҗан, Сафуан*, Сәет, Такташ, Тәлгат, Хаҗи, Харис, Хисами, Шәйхелислам, Шәйхенур, Шәйхулла, Ярулла, Яхъя; хатын-кыз исемнәре – Асия, Асыл, Балдыз, Бибисара, Вәкилә, Газия, Гөлбаян, Гөлҗамал, *Гөлзадә*, Гөлзәйнәп, Гөлкәй, *Гөлсем*, Гөлсинә, Гөлтуташ, Зәйнәп, *Зөбәйдә*, Кадерле, Мәһинур, Мәдинә, Мәрфуга, *Мәрьям*, Мәүдүдә, Мәүзүдә, Мәүлидә, Минниса, Минхәят, Мөнәвәрә,

[1] Әдәби телдә бу сүз *пәйгамбәр* рәвешендә кабул ителгән, әмма халык телендә ул *пигамбәр* формасында йөри. Н. Исәнбәт тә бу сүзне шул шәкелдә кулланган, чөнки гарәп телендә дә ул нәкъ шулай (پيغمبر). Әлбәттә, бу сүз – кеше исеме түгел. Әмма халык аны, «кулымдагы йөзегем»ә бәйләп, исем вазифасында файдаланган, шуңа күрә ул да исемнәр янәшәсендә бирелә.

*Мөршидә*, Наҗия, Нурзадә, *Нәсимә*, Нәфисә. Өммегөлсем, Рауза, *Рәисә, Рәкыя*, Рәмзия, Рәшидә, Рузалия, *Сандугач*, Саҗидә, Сәлимә, Тәскирә, Фариза, Фатыйма, Фәйрүзә, Фәтанәт, Хәдичә, Хәлимә.

Кеше исемнәре кулланылган җырлар тупланмасы белән махсус эш итмәсәң, беренче карашка җырларда хатын-кыз исемнәре ир-ат исемнәренә караганда күпкә артык булып тоела. Әмма чынбарлыкта алай түгел икән. Удмуртия Республикасында яшәүче милләттәшләребез даирәсендә тупланган материаллар күрсәткәнчә, «кулымдагы йөзегемнең исемнәре» дип башланган җырларда файдаланылган кеше исемнәре фондында ир-ат һәм хатын-кыз исемнәре тигез. Түбәндә урнаштырылган 126 кыска җырда ир-ат исемнәре 47 данә булса, хатын-кыз исемнәре («балдыз»ны исәпкә алмаганда) 48 данә.

Кайбер исемнәр берничә җырда кулланылган. Биредә китерелгән әлеге кыска җырлар арасында бер үк исем (кеше исеме) кулланылган берничә текст очрый икән (мәсәлән, Мәрьям, Нәфисә һ. б.), димәк, алар (ошбу текстлар) – төрле җырлар. Төрле булганга күрә, бу исемнәр кулланылган җырларның барысы да бирегә кертелде. Ә сүзгә-сүз тәңгәл килгән текстлар, гәрчә алар төрле авылларда язып алынган булсалар да, биредә бары бер урында гына (бер данәдә генә) күрсәтелде.

Бер үк исем кулланылган җырларның эчтәлеге исә төрле булырга да мөмкин: әйтик, берсе мәхәббәт җыры булса, икенчесе тормыш-көнкүреш темасына багышланган булуы ихтимал (мәсәлән, Нургата). Алай гына да түгел, төрле авыл материалында бер үк исем ярдәмендә, хәтта бер үк мәсьәләгә карата, капма-каршы фикер дә белдерелергә мөмкин (мәсәлән, Пигамбәр). Менә шундый очракларда инде, бер үк исем кабатлануга карамастан, әлеге җырлар бу тупламга икесе дә урнаштырылды. Кызыксынган укучылар, аларны эзләп табып, таныша алалар.

Халык үзенең шатлык-куанычларын, кайгы-хәсрәтләрен, шулай ук әрнүле хәлләрен җыры аша да белдерә. Җырда әйтеләсе фикернең соңгы сүзенә рифма итеп кеше исемен файдалану үзе бер традициягә әверелгән. Ә бу исемнәр исә җырчының йөзегенә «язылган». «Кулымдагы йөзегемнең исемнәре...» дип башланган җырлар кешенең нинди генә рухи халәтен чагылдырмый: анда аның тормыш тәҗрибәсе, киләчәккә өмет-хыяллары, якын кешесенә изге теләкләре, сөеклесен сагынуы, аны мактавы, аңа соклануы, аерылышу сагышы, урынлы киңәшләре, үтенече, таләбе, ә кайвакыт

кайгы-хәсрәте, ачынуы, хәтта өметсезлеккә бирелүе, әмма кыенлыкларны җиңәргә омтылуы, сабыр итүе һ. б., һ. б. сурәтләнә.

«Кулымдагы йөзегем»ә исем куйганда исә 8–7 үлчәмендәге җыр өчен кешенең исеме өч иҗекле булырга тиеш. Бу очракта ул үз урынына бик җайлы «кереп утыра». Ә тиешле исем ике иҗекле генә булса, нишләргә? Моның да юлын тапкан халык. Әгәр исем сузык авазга башланса, җырлаганда ул аны өч иҗекле итә: Яхъя = «Исемнәре Я-хы-я», яисә Ибрай = «Исемнәре И-бы-рай».

Әгәр ике иҗекле исем тартык авазга тәмамланса? Бу очракта җырчы ритм мәнфәгатендә кеше исеменә тартым кушымчасын өсти. Мәсәлән: «Исемнәре Тәлгатем».

Кыенлыктан чыгуның тагын бер кулай ысулы барлыгы ачыкланды: «Исеме матур – Кәбир», – дип тә җырлый икән халык. Бу очракта хәтта җырның мантыйк ягы да «рәтләнә» (йөзек берәү генә ич, ә «исемнәре» сүзе күплек санда), ягъни җөмлә грамматик яктан да төзекләнә.

Хәер, ике иҗекле исемнәр белән бәйле «ритм кризисыннан» чыгуның башка ысулларына да тап булдык без. Халык кыенлыктан котылуның башка юлларын да белә икән. Менә алар: «Исеме Рәҗәп түгел», «Исеме Хаҗи иде», «Исеме Гөлсем дисең», «Исемен Сәет куштым» (һ. б. дип куярга да мөмкиндер).

Әйдәгез, кыска җырларның шушы үзенчәлекле төркеме белән якыннан танышыйк әле.

## Кыска җырлар

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Тәскирә.
Хат язганда маркасыз яз –
Маркасыз хат тиз килә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Сәлимә.
Кеше сүзләренә кермә,
Керсәң – чыгармын, димә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Саҗидә.
Суларда агып барыр идем –
Туктармын, дип, сай җирдә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Вәкилә.
Сезне күреп, куллар биреп,
Бер сөйләшәсем килә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Хәдичә.
Сез куштыгыз, мин җырладым –
Менә булды сезнеңчә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Хәлимә икән.
Ул да, мескен, минем кебек –
Сагыну хәлендә икән.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлтуташ.
Гөл булсак, аерылмас идек –
Гөл тамырлары тоташ.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нәфисә.
Гөлләр бездән бәхетлерәк –
Бергә бәйләнеп үсә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Газыя.
Гөлләр – маяк, сандугачлар
Юлдаш булсыннар сиңа.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мөршидә.
Бик сагынган вакытларда
Булса иде күрешергә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Тәлгатем.
Синнән башка берәүне дә
Теләми табигатем.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Мәрьям.
Гыйшык тотып, утларында
Янарлык булсаң, бәйлән.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Фаризамы?
Син йөрисең ике белән,
Мин йөрсәм, син ризамы?

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Шәйхулла.
Сине өзелеп сөяргә
Үзе кушкандыр Алла.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Рәисә.
Әллә кемнәргә калырсың,
Әгәр мин үлдем исә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Зәйнәп.
Ничә жалованье алдың,
Минем гайбәтне чәйнәп?

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нәсимә.
Исеңдә тот, васыятем шул:
Миннән башка яр сөймә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Рәҗәп түгел.
Сөям дисәң, гаҗәп түгел,
Сөймәсәң, хаҗәт түгел.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Шәйхенур.
Әллә сиңа ай-кояшлар
Подарить иттеме нур?

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нажия.
«Быел кияүгә чыгам» дип,
Базардан мендәр җыя.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Габделхәй.
Буең – көзге, тешең – энҗе,
Күзең – йолдыз, кашың – ай.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Муса.
Йөрер дә бер кайтыр әле,
Үземә язган булса.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлҗамал.
Гөлҗамал янына барсаң,
Онытыла дөньялар.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Рәисә.
Сезнең яктан җилләр иссә,
Йөрәк-бәгъремне кисә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Гыйльми.
Сөяменме, сөймименме –
Сезгә әйтәсем килми.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нургата.
Хәзер инде дусларым да
Дошман булып болгата.

*Балезино районы Кистем авылында*
*төрле кешеләрдән язып алынды.*
*18 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Әсма.
Хәзер инде аерылдык –
Мин баскан эзгә басма.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Бибисара.
Алдыңда – дус, артта – дошман
Булган ул, йөзе кара.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Рәшидә.
Өзелеп сөйгән ярым хәзер
Дәшми дә, сөйләшми дә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Барый ла.
Гыйшык тоттым, утын йоттым –
Үземә булса ярый ла.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәдинә.
Чәнечкеле сүзләр белән
Кадама йөрәгемә.

*Балезино районы Кистем авылында*
*Мәһинур Касыймовадан (40 яшь)*
*язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Илгизәр.
Өзелеп сөйгән ярыңнан
Ничек җаннарың бизәр?

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Идрис.
Җаным-тәнем, табигатем
Белән сөйгән идем ич.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Имани.
Үпкән-кочкан җилгә очкан –
Уйламыйм да мин аны.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Хаҗи иде.
Бераз переживать иттем –
Яраткан ярым иде.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Газизулла.
Һәркемнең дә үз сөйгәне
Үзенә газиз була.

*Балезино районы Кистем авылында*
*Рәйсә Касыймовадан (22 яшь)*
*язып алынды. 20 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Фатыйма.
Бирсәнә, кош, канатыңны –
Бер әйләнеп кайтыйм ла.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Хисамый.
Яратмаган агачына
Кош та оя ясамый.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Газыймҗан.
Их, бәгърем, синнән генә
Бизәлмәде газиз җан.

*Балезино районы Кистем авылында*
*Гөлҗиһан Касыймовадан (46 яшь)*
*язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемен Сәет куштым.
Икебезгә бер яр җитәр –
Татулык кирәк, дустым.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлзада.
Кавышырга карыйк, бәгърем,
Еллар авыр булса да.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлзада.
Урман якын, сайрый кошлар,
Түзәм, шулай булса да.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Асылдыр.
Яшь күңелемне син аздырдың –
Теләсәң ничек басылдыр.

*Балезино районы Кистем авылында*
*Зөләйха Касыймовадан*
*(20 яшь) язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Зөбәйдә.
Бер генә кеше аерылмый,
Бер аерылгач, түз әйдә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Азат.
Сөюләрем нигә булды –
Тыныч башыма газап?

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлсемем.
Гөлләр кебек саргаерга
Калдың инде, мескенем.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нурислам.
Сөйгәнеңне ятлар алган,
Бирмәс идем, мин булсам.

*Балезино районы Кистем авылында*
*Мәдинә Касыймовадан (21 яшь)*
*язып алынды. 20 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нурулла.
Рапорт бирергә килмәдем
Сөю-сөймәү турында.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нәсимә.
Сознательный яр икәнсең –
Дустыңның ярын сөймә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Мансур.
Мәхәббәтләре булмагач,
Пожалуй, булсын матур.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Раузамы?
Син йөрисең ятлар белән,
Мин дә йөрсәм, ризамы?

*Балезино районы Кистем авылында*
*Галия Садыйковадан (32 яшь)*
*язып алынды. 20 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Өммегөлсем.
Онытмам, дустым, онытмам,
Онытылырлык түгелсең.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Шәйхелислам.
Бәлки, иркәм, кавышырбыз,
Син – ай, мин кояш булсам.

*Балезино районы Кистем авылында*
*Саимә Касыймовадан (23 яшь)*
*язып алынды. 22 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әгъзам.
Дошманнар суга салса да,
Мин тотармын, агызмам.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Кабул.
Булмады инде, булмас инде
Теләккәйләрем кабул.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нургали.
Таулар, ташлар аерылса да,
Без аерылмабыз әле.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Миркасыйм.
Аерганчы сал суларга,
Су төпләрендә ятыйм.

*Балезино районы Кистем авылында*
*Рауза Мусинадан (23 яшь)*
*язып алынды. 26 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Маһинур.
Ике битең – пешкән алма,
Иреннәрең – помидор.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Кәбир.
Сөясеңме, сөймисеңме –
Чын дөресен әйт тә бир.

*Балезино районы Кистем авылында*
*Асыл Касыймовадан (24 яшь)*
*язып алынды. 22 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлкәем.
Ташласам – җәл, сөйсәм – авыр,
Нишләем, бәгырькәем?

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Бибисара.
Әгәр, иркәм, бизгән булсаң,
Ятларны сөеп кара.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Габделхак.
Синең сөюләрең ничек?
Минем сөюләрем – хак.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әгъзам.
Бик сагынган көннәремдә
Тәрәз төбеңнән узам.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Габделхактыр.
Минем сөюләрем хактыр –
Багучылардан бактыр.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нургата.
Авторитетың төшкән ич,
Безнең турыда ята.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Такташев.
Кай илләрдә йөри икән
Бәгырькәем, адашып.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Исмәгыйль.
Төнлә йокымнан уята
Сезнең яктан искән җил.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мөхәррәм.
Мине ташлап, ятны сөйсәң,
Ашаган ашың – хәрәм.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлбаян.
Бик сагынган көннәреңдә
Хатымны укып юан.

*Балезино районы Паюра авылында*
*Наилә Ляпинадан (23 яшь)*
*язып алынды. 24 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Габдулла.
Матур ярларны сайлама –
Матур тәкәббер була.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мөхәммәт.
Гармунчыда биш мәртәбә
Артык була мәхәббәт.

*Балезино районы Паюра авылында*
*Фатыйма Касыймовадан (18 яшь)*
*язып алынды. 24 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Ибрай.
Кашың кара, буең зифа,
Кайдин тудың син болай?

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Газизулла.
Һәркемнең дә газиз яры
Үзенә газиз була.

*Балезино районы Паюра авылында*
*Зәйтүнә Касыймовадан (17 яшь) язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Саттар.
Әллә хәтерең калдымы –
Нигә язмыйсың хатлар?

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Минхәят.
Үз сөйгәнем син булмагач,
Кеше яры ни хаҗәт?

*Балезино районы Әхмәди авылында*
*Асия Касыймовадан (25 яшь) язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлзәйнәп.
Сандугачлар арасыннан
Алдым мин сине, сайлап.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Фәтанәт.
Кош аерылса да, кавыша –
Аларда ике канат.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәүлидә.
Күп яр сөйдем, тиз оныттым,
Сине онытмам мәңге дә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Рәмзия.
Кеше ярларына тимә,
Тап үзеңә дә ия.

*Балезино районы Әхмәди авылында*
*Мәүлидә Шакир кызы Тютинадан (28 яшь) язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәүзүдә.
И бәгърем, ак шарфың
На память тора чөйдә.

*Балезино районы Әхмәди авылында*
*Мәүзүдә Касыймовадан (28 яшь)*
*язып алынды. 27 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Йолсымдыр.
Януларым, көюләрем –
Бар да синең тылсымдыр.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Рәсим.
Былбыл булып, талга кунып,
Төшләремә керәсең.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нургаян.
Минем генә бәхетем юк,
Шуңа күрә моңаям.

*Балезино районы Әхмәди авылында*
*Нәвал Касыймовадан (56 яшь) язып алынды.*
*26–27 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мулланур.
Ай туганда тугандыр ул,
Шуңа нурлы булган ул.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Сабирҗан.
Мине ташлап, ятны сөйсәң,
Тәмуг утларында ян.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Мәрьям.
Мин югалсам, эзләмәгез –
Суларда булыр гәүдәм.

*Балезино районы Әхмәди авылында*
*Ләмига Касыймовадан (22 яшь)*
*язып алынды. 26–27 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Пигамбәр.
«Бик яратып сөйгән ярлар
Үзеңә булмый», – дигәннәр.

*Балезино районы Әхмәди авылында*
*Хөббениса Тютинадан (37 яшь)*
*язып алынды. 27 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Фәйрүзә.
Кемнәрең бар? Кемне уйлыйсың?
Кем үзәгеңне өзә?

*Юкамен районы*
*Дасис (Засеково) авылында*
*Зәйтүнә Бикмансуровадан (22 яшь)*
*язып алынды. 31 июль, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Исмәгыйль.
Быел кайгылы елларым –
Сайрама кош, исмә җил.

*Юкамен районы*
*Дасис (Засеково) авылында*
*Хәлимә Әмировадан (18 яшь)*
*язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мөршидә.
Сиңа охшатып сөяр идем,
Сиңа охшамый берсе дә.

*Юкамен районы*
*Дасис (Засеково) авылында*
*Людмила Кутявинадан*
*язып алынды. 31 июль, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мөбарәк.
Сиңа хатлар язган чакта
Яшем төшә тәгәрәп.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Миңнехан.
Бу дөньяда иң бәхетсез
Әллә мин генә микән?

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Зөбәйдә.
Мин – авылдан, син – шәһәрдән,
Рәхәтләнеп йөр әйдә.

*Юкамен районы Палагай авылында*
*Рәшидә Абашевадан (26 яшь)*
*язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Миңниса.
Берне түгел, икене сөй,
Куеннарыңа сыйса.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Рокыя.
Аерылганга уфтанмагыз –
Гөл дә чәчәген коя.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гафур бит.
Төрле вакытларым булды –
Зинһар, дустым, гафу ит.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Асия.
Гөлләр – маяк, сандугачлар
Юлдаш булсыннар сиңа.

*Юкамен районы Палагай авылында*
*Мәдинә Касыймовадан (24 яшь)*
*язып алынды. 6 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Кадерлем.
Югары алма тиз коела –
Шулай булма, бәгырем.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нуркадыйр.
Җиде ятып, бер төшемә
Кермисең инде хәзер.

*Юкамен районы Пүчинкә авылында*
*Рәшидә Есенеевадан (18 яшь) язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Рокыя.
Аерылганга үкенмимен –
Гөл дә чәчәген коя.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Сафуан.
Сине сагынган чакларда
Сачәк җыям басудан.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Гөлсем, дисең,
Янсын, дисең, көйсен, дисең,
Саргаеп үлсен, дисең.

*Юкамен районы Тегермән авылында*
*Фәүзия Арслановадан (22 яшь)*
*язып алынды. 12 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәрфуга.
Синең утларында янам –
Уттан ал да сал суга.

*Юкамен районы Тегермән авылында*
*Мәрьям Арслановадан (19 яшь)*
*язып алынды. 13 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Яхыя.
Бик сагынган чакларында
Кырлардан чәчәк җыя.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нурзадә.
Кояш нуры диеп торам –
Син икәнсең уртада.

*Юкамен районы Тегермән авылында*
*Мәүлия Арслановадан (23 яшь)*
*язып алынды. 13 август, 1956 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әлләкем.
Әлләкемнәр дә кавыша,
Без дә кавышырбыз, бәлкем.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Балдызым.
Гөлләр кебек саргаерга
Калдым инде ялгызым.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлсемем.
Яндым, көйдем, өзелеп сөйдем –
Ятка калдың, мескенем.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Ярулла.
Күтәрелеп карый алмыйм
Йөзеңдәге нурыңа.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәдинә.
Кермә кеше телләренә,
Керсәң, чыгармын димә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Хәсәнә.
Сөйсәң, сөй, сөймәсәң, сөймә,
Сөймәсәң, сөймәсәнә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нургата.
Әллә яратып сөйгәнгә
Истән чыкмый, уйлата.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мансурдыр.
Икебез ике илләрдә,
Шуңа бик ямансудыр.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нәсимә.
Салган чәемне эчә алмыйм –
Син төшәсең исемә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нургали.
Ничек кенә күрим, дигән
Көннәр күбрәк булгалый.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Харисым.
Әллә, бәгърем, сагындыңмы –
Йөземә еш карыйсың?

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлсинә.
Исләремдә гел син генә –
Бәгърем, белмисең генә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әкрәм.
Син төшеңдә күрәсеңме?
Мин төшләремдә күрәм.

*Глазов шәһәрендә яшәүче*
*Галия Касыймовадан (59 яшь) язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Рузалия.
Синең кебек гөлләр үсә
Средний Азиядә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Гайнан.
Яңа ярлар – язгы бозлар,
Искесен табыйм кайдан?

*Глазов районы Татар Парҗысы авылында*
*Хәтимә Касыймовадан (24 яшь) язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме матур – Зиннәт.
Дошман сүзләре күп булыр –
Сахрага чыгып җилләт.

*Глазов районы Татар Парҗысы авылында Җәмилә*
*Касыймовадан (21 яшь) язып алынды. 16 август, 1956 ел*

# ПЕСНИ ЖИВУТ ДОЛЬШЕ ВЕКА

***Народное музыкально-поэтическое творчество чепецких татар***

*Эльмира Каюмова*

Чепецкие (нукратские, каринские) татары – одна из этнографических групп казанских татар. Они расселены в бассейне р. Чепцы (притока Вятки) на территории современной Удмуртии и Кировской области. Татары, проживающие в Удмуртской Республике, образуют две подгруппы: 1) верхнечепецкую, или кестымскую (Балезинский, Глазовский районы) и 2) среднечепецкую, или юкаменскую (Юкаменский район)[1].

Можно с полной уверенностью сказать, что народная музыка татар Удмуртии является «белым пятном» в этномузыковедении (опубликовано всего два напева)[2]. В этой связи предлагаемые материалы представляют несомненный научный интерес.

В ходе экспедиции, состоявшейся в июне 2012 г., автором обследовано 8 деревень. Из них в Балезинском районе – 3: Кестым (Кистем), Падера (Паюра), Ахмади (Әхмәди); в Глазовском районе – 2: Тат. Парзи (Татар Парҗы), Гордино (Гүрья кала, Үрә кала); в Юкаменском районе – 3: Иманай, Засеково (Дасис), Палагай. Удалось побывать на сабантуях в д. Кестым и д. Ахмади, а также посетить города Ижевск и Глазов, где состоялись встречи с татарской общественностью.

Большую помощь в собирательской работе оказали местные жители, предоставившие нам компакт-диски и кассеты с записями прошлых лет, за что мы выражаем им искреннюю признательность.

[1] *Касимова Д. Г.* Семейная обрядность чепецких татар (середина XIX–XX вв.). – Ижевск, 2003. – С. 6.

[2] *Нигмедзянов М.* Татарские народные песни. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – № 149 («Ай, чиясе»), 213 («Туй такмаклары»).

В результате был зафиксирован разнообразный и чрезвычайно оригинальный материал (в том числе есть несколько примеров удмуртских и бесермянских народных песен).

Пожалуй, первое, на что обращают внимание приезжие исследователи, это то, что почти все жители одной и даже нескольких деревень носят одинаковую фамилию. В Кестыме, Ахмади, Тат. Парзи – Касимовы, в Падере – в основном Касимовы, реже – Интинтеевы, в Иманае – Сабрековы, Митюковы, в Засеково – Балтачевы, в Палагае – Абашевы, в Гордино – Тютины (причем эту фамилию носят и татары-мусульмане, и бесермяне-христиане).

Кестымцы и падеровцы о себе говорят: *«Без – арлы татарлар, телебез – ни татарча, ни удмуртча»* («Мы – обудмурченные татары, наш язык – и не татарский, и не удмуртский»). Информанты всегда спрашивали: «Как с вами общаться? По-кестымски или по-казански?», имея в виду различия в говорах. Однако любопытно, что специфика местного наречия мало проявляется в текстах фольклорных произведений: они приближены к среднему диалекту, который, как известно, лег в основу общенационального литературного языка.

Вместе с тем, имеющиеся отличия в лексике и фонетике верхнечепецкого и среднечепецкого говоров осознаются самим населением. Так, татары Юкаменского района отмечали, что они говорят по-татарски гораздо чище, чем их соседи из Балезинского и Глазовского районов, т. к. в языке последних много удмуртских и русских заимствований: *бидра* – чиләк (ведро), *косяк* – тәрәзә (окно) и др. Кроме того, представители кестымской подгруппы произносят слова мягче и на этой почве иногда возникает недопонимание. Рассказывали курьезные случаи, когда житель Кестыма говорил: *«Элек керек иде»*, а засековцы не могли понять, что ему нужно, оказалось – просил сито (*«Иләк кирәк иде»*); или, наоборот, если в Тат. Парзи говорили: *«Илек саталар»*, то жители Засеково думали, что речь идет о сите, но на самом деле подразумевались ягоды (*«Җиләк саталар»*).

В деревнях Юкаменского района были выявлены интересные свидетельства того, что еще в недавнем прошлом старики в семейном кругу общались на удмуртском языке.

Совместное проживание народов способствовало усвоению языка, песенного репертуара соседей. Некоторые татары знают удмуртский, бесермянский, могут исполнить удмуртские песни.

В смешанных браках, где невестка – удмуртка или бесермянка, она становилась членом татарского социума: разговаривала по-татарски, пела татарские песни, и хоронили ее с мужем на одном кладбище. Респонденты вспоминали, что в 1940-е годы все предметы в школе шли на татарском, а преподавали их удмуртские учителя (Юкаменский район).

В настоящее время наблюдается общий процесс обрусения. Молодое поколение не желает изучать родной язык (д. Падера). В д. Тат. Парзи Глазовского района даже пожилые люди говорят на полутатарском-полурусском. В татарско-удмуртских семьях общение происходит все больше на русском языке (д. Гордино). Потеря языка автоматически отрезает человека от фольклорного наследия предков.

В наши дни механизм естественной передачи народных знаний нарушен. Приобщение детей и молодежи к национальной культуре происходит через вторичные формы: соответствующие мероприятия в учебных заведениях, в клубе и др. Многое из того, что мы фиксируем в момент записи, уже существует в пассивном виде (вышло из употребления и хранится в памяти исполнителей). Активное бытование характерно для религиозных песнопений, актуализуемых благодаря проведению мусульманских ритуалов и праздников. Но и востребованные современным обществом явления, адаптируясь к новым условиям, претерпевают значительные изменения (трансформируются). При этом степень сохранности традиционного музыкально-поэтического искусства везде разная. По сравнению с остальными лучше обстоят дела в д. Кестым Балезинского района.

## Песенное творчество

При знакомстве с певческой культурой самое яркое и сильное впечатление производит обилие и необычность огласовок в протяжно интонируемых песнях. Помимо типичных *ы, е,* добавляемых к согласным, широко используются распевы гласных. Как правило, дополнительные слоги образуются путем повторения самого гласного вместе со звуком *й.* Наряду с частицами *шул, ди, да/дә, ла/лә, ай* применяются *соң, ич.*

Саубу(йу)лы(йы)гыз(ы), туган(ы)ла(йа)рым(ы),
Са(йа)бул(ы), ка(йа)ра(йа) кош(ы)ла(йа)рым(ы), да.

(«Солдат озату көе», д. Ахмади)

Борылы(у)п(ы) кит(е)кән, ич(е), бо(йы)дай(ы)ның(ы) ми(йе)жа(йа)сы,
Ай, авыр, ук, икен, ич, дөн(ны)ьяның(ы) нуж(а)на(йа)сы.
(«Шушма көе», д. Кестым)

Вследствие интенсивного насыщения поэтический текст буквально растворяется в распевах, и его смысл становится едва уловимым, особенно – для неподготовленных слушателей. Причем носители традиции ясно ощущают эту специфику и считают, что так и должно быть. Пока трудно определить генезис данного феномена, но аналогичный способ распевания (зашифровки текста) в других ареалах нам не встречался.

В описанной манере исполняются тексты-прощания, соединяемые с долгими, тягучими мелодиями («Шушма көе», «Шахта», «Солдат озату көе»). Вообще, тема расставания, когда человек вынужден покидать родные края и отправляться на чужбину (чаще перед уходом в армию), является центральной в народном творчестве татар Удмуртии. Не случайно на просьбу спеть что-нибудь прежде всего поют песни проводов солдат. Они бытуют как с «длинными» напевами (см. выше), так и с «короткими» («Алмагачлары», «Баламишкин»).

Выделяются две мелодии, связанные с солдатской тематикой. Первая, обозначаемая исполнителями как *солдат көе, солдат озату көе, авыл көе, урам көе,* бытует в двух версиях. Записанные в дд. Ахмади, Палагай образцы по стилю представляют собой типичный «деревенский напев». Сходный вариант помещен в нотном собрании А. Ключарева[1]. В дд. Кестым и Падера поют иначе: в музыкальную ткань вплетают малосекундовые интонации (см. *Приложение* I, № 2). Гемитонная ладовая основа прорисовывается и в другой мелодии – «Солдат бәете» (см. *Приложение* I, № 3). Сфера ее действия локализуется деревней Кестым. По тексту и напеву это, скорее, песня. В частности, кадансовый оборот (трихорд в квинте) вызывает ассоциации с обрядовыми напевами татар-кряшен. Жанровое определение *бәет* (баит) оправдано нисходящей направленностью интонационного развертывания, арузным метром *мутакариб-и мусамман-и махзуф* (1:2:2 1:2:2). Кстати, подобная слогоритмическая схема употребляется весьма редко (наиболее популярны у татар разновидности рамаля и хазаджа).

---

[1] *Ключарев А. С.* Татар халык җырлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 88 ( № 62 «Кара күл»).

Важно подчеркнуть, что одна из строф «Солдат бәете» совпадает с четверостишием старинной песни «Мазар тавы», записанной филологом Н. Бургановой в 1951 году в с. Карино (Нократ) Слободского района Кировской области, т.е. от нижнечепецких татар:

Сандугач бала, ла, муены кара(у),
Ав(ай)аларга, ла, очып, ла(й), югала,
Һав(ай)аларга, ла, очып, ла(й), югала.

Бәхетле балалар илләрдә кала(у),
Бер бә(йә)хет(е)сез(е) китеп, лә(й), югала,
Бер бә(йә)хет(е)сез(е) китеп, лә(й), югала.
(«Солдат бәете», д. Кестым)

Сандугачтай ала муйынысы кара,
Һаваларга менгәч йугала.
Бәхетле балалар ийенә кайта,
Бәхетсезе китеп йугала[1].
(«Мазар тавы», с.Карино)

Согласно устным преданиям и сведениям историков, татарские поселения в Удмуртии были основаны выходцами из Карино. Как видим, это подтверждается и фольклорными материалами.

Особое место в рассматриваемой традиции занимает самобытная мелодия «Шушма көе». Она была записана в 1966 году Н. Бургановой в д. Кестым от Касимовой Ханифы (1896 г. р.) и увидела свет в 1984 году в сборнике М. Нигмедзянова с названием «Ай, чиясе»[2]. В комментариях указано, что «здесь принято все традиционные деревенские напевы называть *шушма көе*». Составитель далее отмечает, что из-за многочисленности распевных вставок вынужден был их сократить, а недостающие слоги заменить повторами последних фраз[3]. Словесный текст песни «Шушма көе», опубликованный Ф. Юсуповым в журнале «Мирас»[4], также приводится без огласовок. На наш взгляд, при таком подходе, действительно, обнажается содержание произведения, но он не дает адекватного представления о реальном звучании. Более того, вне поля зрения остается сама

[1] Материалы по татарской диалектологии. – Вып. 2. – Казань, 1962. – С. 306. В нашей статье текст приводится без дополнительных знаков, используемых языковедами.

[2] *Нигмедзянов М.* Татарские народные песни. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – С. – 148 (№ 149).

[3] Там же. – С. 219–220.

[4] *Йосыпов Ф.* Нократ-Кистем (Чепца буе) татарлары // Мирас. – 2003. – № 4. –Б. 21.

суть, все своеобразие местного музицирования. По этой причине мы сочли необходимым давать оба варианта (см. *Приложение* II).

Экспедиция 2012 года показала, что наименование «Шушма көе» закреплено за конкретной мелодией (*Приложение* I, № 1), той самой, что была нотирована М. Нигмедзяновым. Зона ее распространения ограничивается кестымской подгруппой (Балезинским и Глазовским районами). Исполнители, родившиеся в 20–30-е годы XX в., сообщали, что она не имела хождения в их кругу, а была достоянием предыдущих поколений (*«картлар җырлыйлар иде»*). В интонационном плане обраруживается общность с архаичными песнями крещеных татар. По роли в песенной системе это *авыл көе*, т. е. полифункциональный напев, предназначенный для совместного пения. В годы войны женщины затягивали «Шушма көе», когда собирались в одном из домов на посиделки: сюда брали ручную работу, готовили угощение, вели разговоры и пели (д. Падера). В 1940–50-е годы запевали эту мелодию, отправляясь на лошадях или машинах на луга на сенокос и возвращаясь с работы, заполняя окрестности звонкими голосами (д. Кестым). Поэтому иногда определяют ее как *болын көе* (луговой напев). Сейчас воспроизвести «Шушма көе» могут только певцы преклонного возраста, да и то единицы (не всем он оказался под силу). Музыканты помоложе признавались, что им не удается перенять напев от старших из-за его трудности.

С данной мелодией часто поется следующий текст:

А) Утыр(ы)дым көймә(йә)ләрнең түренә,
Кара(йа)мадым сулар(ы)ның йөзенә.
Су төпләрендә һич(е) каралар юк,
Алланың язган эшләргә чара юк.

Б) У(йу)тыр(ы)ды(йы)м, ич(е), ди, көймәләр(е) түренә,
Карадым, ич(е), су(йу)ларның(ы) йөзе(йе)ни.
Сулар(ы)ның(ы) йөзен(е)ди һич(е) кара юк,
Ал(ы)ла яз(ы)ган эш(е)лирги ча(йа)ра(йа) юк,
Ал(ы)ла яз(ы)ганын эш(е)лирги ча(йа)ра юк.
(д. Кестым, запись 2012 г.)

В варианте Н. Бургановой и Ф. Юсупова имеются такие строки:

Шушма буйларының, ай, чиясе,
Асылынса җирләргә тиясе.
Кат белән кәлләрен, ай, беләсе,
Зифа ла буен кайлардан күрәсе.

Утырдым көймәләрнең түренә,
Карадым Шушманың төбенә.
Шушманың төбендә һич кара юк,
Тәкъдир язган эшләргә чара юк.
(д. Кестым, запись 1966 г.)

Шушма (Шошма) – название реки, верхнего притока Вятки. Она берет начало в Марий Эл, основное течение – на территории Татарстана (в Арском, Балтасинском и других районах), устье – возле г. Малмыж Кировской области. Чем объясняется появление этого гидронима в творчестве верхнечепецких татар? Очевидно, он остался как воспоминание о прежней родине, как отголосок далеких эпох. Местные жители выдвинули гипотезу, что их предки (арские князья) в поисках новых мест обитания сплавлялись по реке.

Большинство игровых песен принадлежит к общенациональному фонду: «Суда, суда», «Талы, талы», «Көймә килә», «Чума үрдәк, чума каз» и др. В Юкаменском районе были зафиксированы интересные образцы. Так, мелодической основой одного из них послужила русская песня «Златые горы».

Татары, проживающие в бассейне реки Чепца предпочитают петь коллективно – ансамблем по 2–3 и более человек. Естественно, в этом случае возникает гетерофония. Усиленная звукоподача, свойственная некоторым пожилым исполнителям, напоминает манеру пения кряшен и мордовских мишарей.

### Исламские жанры

Состояние исламских музыкальных традиций в Балезинском, Глазовском и Юкаменском районах разное, что обусловлено целым комплексом факторов (историей заселения края, социально-экономическими причинами, ролью отдельных личностей и т. д.).

В прошлом мусульманские музыкально-поэтические традиции были достаточно развиты в д. Кестым. Они сильны до сих пор, чему в немалой степени способствует подвижническая деятельность нынешнего имама Ильмира Касимова (1979 г. р.), который одновременно является руководителем краеведческого музея и вообще большим знатоком местных обычаев и фольклора. Здесь ранее было 3 мечети, начальная школа *мектеб*. В настоящий момент действует одна мечеть, рядом строится новая.

В Кестыме записаны весьма примечательные образцы мунаджатов, баитов («Юач мулла бәете», «Шәех баба бәете», «Нәзирә

бәете»), «книжных напевов» («Ахырзаман көе», «Мөхәммәдия»), религиозных песнопений (суры Корана, *азан, тәравих, әлвидаг, салават*). Многое из перечисленного сообщила Гульфира абыстай (1946 г. р.) – истинная хранительница народных традиций. Встреча с такими исполнителями всегда огромная удача для исследователя.

Специфику функционирования жанров *көйләп уку* (баитов, мунаджатов, «книжных напевов») составляет включение их в похоронно-поминальную обрядность. Существующий обычай ночных бдений (*төн утыру*) до недавнего времени проводился следующим образом: в течение 3–7 ночей (примерно с 19 ч. до 2 ч.) в доме покойного собирались односельчане, 3–4 женщины из числа знающих читали нараспев религиозные тексты. Чтение продолжалось несколько часов. Полевые материалы показывают, что посиделки имели значение общинного моления. Дом был заполнен людьми. Слушательская аудитория, знакомая с традиционным репертуаром, принимала непосредственное участие в процессе, заказывая исполнителям те или иные произведения. В наши дни ритуал заметно сократился (длится всего 1 вечер, приходят лишь родственники и т. д.) и почти утратил свой сакральный смысл. Сокращенный вид *төн утыру* еще бытует в дд. Кестым, Падера и Палагай. В качестве близкой параллели необходимо указать на традицию мелодизированного произнесения мунаджатов о смерти над телом усопшего у мишарей Нижегородской области (экспедиция 2010 г.).

Выявлены уникальные факты музыкальной практики суфийских орденов (д. Кестым). Участники мистического действа (*«ишанга тапшырылган кешеләр»*), по обыкновению женщины, садились в круг и распевали традиционные «книжные» тексты, интенсивно топая в такт ногой, до тех пор, пока не теряли сознание. В другом варианте входили в транс путем быстрого бегания по кругу.

В д. Тат. Парзи Глазовского района сложились неблагоприятные условия для сохранения этнической культуры. С упразднением колхоза население вынуждено искать работу в городе, школу и клуб закрыли, с каждым годом увеличивается количество межнациональных браков, татарский язык вытесняется из повседневной жизни, посещать мечеть практически некому. Тем не менее богослужения ведутся: для совершения пятничных молитв и по мусульманским праздникам из Глазова приезжают мулла и так называемые *мәчет картлары* (уроженцы этой деревни). Удивительно, но именно здесь

от Салим-хазрата (1951 г. р.) были записаны «Таравих», «Альвидаг», «Такбир», бытовавшие в Тат. Парзи еще в 1960-е годы и ранее.

В нашей коллекции имеются также макамы азанов (дд. Тат. Парзи, Ахмади, Падера), баит «Сак-Сок» (д. Палагай).

В микролокальных традициях деревень Гордино Глазовского района, Засеково и Иманай Юкаменского района удельный вес исламских музыкально-поэтических жанров крайне мал. Полученные результаты можно интерпретировать с позиции слабого воздействия мусульманского фактора. Данная тенденция в отношении средне-чепецкой подгруппы была отмечена Д. Касимовой. По ее мнению, этому способствовало несколько причин: ликвидация мечетей в Юкаменском районе (в 1940–1960-х гг.), наличие бесермянского компонента, влияние христианской культуры соседних народов[1].

В ходе собирательской работы пристальное внимание уделялось выяснению источников усвоения текстов и напевов. По сути, каждый фольклорный факт, фиксируемый в XXI столетии, – это сплав традиций и инноваций, местных элементов и привнесенных извне. Следует помнить, что аутентичные исполнители – такие же современные люди, как и мы, они открыты для восприятия нового. Тем более, что уровень технического прогресса дает широкие возможности для получения необходимой информации. Творческая задача, стоящая перед сельскими религиозными деятелями, всякий раз решается индивидуально. Одни отдают предпочтение местным образцам, другие ориентируются на внешние источники, третьи сочетают и то, и другое. Сказанное касается как вербальной, так и музыкальной стороны произведений.

Поэтические тексты баитов, освещающих трагические события из жизни конкретного человека («Юач мулла бәете») или сочиняемых по случаю смерти («Нәзирә бәете»), имеют местное происхождение. Текст общеизвестного баита «Сак-Сок» Абашева Танзиля (родилась в 1955 г. в д. Верх. Дасос[2], живет в Палагае) слышала в детстве от бабушки, а позже дополнила публикацией из журнала «Азат хатын». В арсенале Касимовой Гульфиры Сафиулловны (Гульфиры абыстай) несколько тетрадей с переписанными кириллицей

[1] *Касимова Д. Г.* Семейная обрядность чепецких татар (середина XIX–XX вв.). – Ижевск, 2003. – С. 205–206.

[2] Татарское наименование – Мөрсәлим, удмуртское – Норык (означает «родник»). Деревня расположена в Юкаменском районе, в 3 км от Засеково и в 1 км от Иманая. Относится к числу умирающих.

текстами, предназначенными для сказывания с напевами (мунаджаты, фрагменты книг и т. д. ), а также казанские издания («Бакырган китабы» – 2000 г., сборник К. Хуснуллина и др.). Если в традиции тексты каких-либо жанров забылись (например, «Салават»), их заимствуют из доступных книжных публикаций.

Напевы перенимают либо у односельчан (носителей исламских традиций старшего возраста), либо заимствуют с пластинок, из радио-, телепередач, интернета и др. Но даже в случае преемственности мелодия не является точной копией выученного оригинала. Мулла, муэдзин или абыстай вносят что-то свое, исходя из собственного вкуса, художественного чутья, звукового багажа. Достаточно сравнить, к примеру, варианты напева «Альвидаг» в исполнении Салим-хазрата, 1951 г. р. (запись 2012 г.), и его отца – Касимова Гильфана, 1901 г. р. (запись 1965 г.)[1].

С точки зрения музыкальных особенностей чепецкие образцы в целом вписываются в общетатарский стиль. Ладомелодическое, метроритмическое строение баитов, мунаджатов и «книжных напевов» является жанрово характерным. В звуковысотном аспекте в религиозных напевах (*азан, тәкбир, тәравих, әлвидаг, Әлхәм* и др.) наблюдается взаимодействие ангемитонных (пентатонных) и гемитонных (диатонических) образований с преобладанием первых, что также нормативно.

Респонденты отмечали, что традиционные мусульманские песнопения соседних деревень отличались друг от друга (например, «Таравих» в Кестыме и Биктеше, «Альвидаг» в д. Тат. Парзи и в уже исчезнувшей д. Малые Парзи), а кестымские варианты не похожи на казанские. Исследование показало, что в дд. Кестым и Тат. Парзи были распространены разные мелодии «Таравих» и «Альвидаг», но напев «Такбир» один и тот же. Кроме того, парзинский вариант «Альвидаг» (*Приложение* I, № 9) интонационно родственен напеву, опубликованному в популярном издании «Хан кызы» (Казань, 1994 г.). Как сказано во введении, сборник составлен преимущественно из татарстанских записей[2]. Подобного рода пересечения объясняются, во-первых, усилившимися в последнее время контактами, инфор-

---

[1] Аудиокассета любезно предоставлена Касимовым Салимом Гильфановичем. Запись была сделана в д. Тат. Парзи в последние дни месяца Рамазан.

[2] Хан кызы: Мөнәҗәтләр / төз. Җ. Г. Зәйнуллин. – Казан: Мәгариф, 1994. – Б. 4, 33–34.

мационной открытостью общества. Во-вторых, судя по имеющимся в нашем распоряжении материалам, среди священнослужителей в Удмуртии раньше было немало выходцев из Татарстана.

Завершая обзор исламских традиций, необходимо затронуть вопрос о манере исполнения культовой музыки. При распевании арабоязычных текстов (азана, сур Корана и др.) у сельских религиозных деятелей сохраняется типично татарский звукоидеал. В городе же у представителей официального духовенства способ звукоизвлечения совершенно иной – присущий вокальному искусству арабов, в чем мы и смогли убедиться на открытии мечети «Иман нуры» в Устиновском районе г. Ижевска 14 июня 2012 г. Таким образом, музыкальное произношение в народном исламе можно назвать татарским, в официальном – арабским. Хотя арабское влияние сейчас просачивается и в деревенскую среду.

## Инструментальное искусство

Для инструментальной культуры чепецких татар характерно наличие музыкальных династий. Носителям традиции свойственны: а) мультиинструментализм – владение несколькими инструментами, б) совмещение видов деятельности – умение играть и изготавливать инструменты. Несмотря на то, что исполнительство не служит главным источником дохода, вышеперечисленные черты указывают на профессионализацию творчества.

Состав выявленных инструментов достаточно обширен: гармоника, скрипка, мандолина, курай, кубыз, гитара, балалайка, синтезатор. Между тем не все из них распространены в равной степени.

Как и в остальных ареалах проживания татар, самыми популярными являются различные виды гармоники. В современном быту используются двухрядные гармони-хромки («Чайка», «Белорусь», «Ивушка») и баяны («Орфей», «Унисон» и др.). В музыкальной практике прошлого применялись и однорядные тальянки (с 12, 14 и 18 планками). Традиция была преимущественно мужской, хотя иногда играли и женщины (дд. Кестым, Падера). Репертуар – песенные и плясовые мелодии.

По свидетельству информантов, раньше гармонистов было много, а теперь остались единицы. Назовем тех, с кем довелось встретиться в экспедиции. В д. Кестым – Касимов Ринат Габдуллович (1961 г. р.), работает методистом в клубе; Касимов Зуфар

Зиннатуллович (1955 г. р.), работал в клубе, школе, детском саду, организовал ансамбль «Дуслык». В д. Падера – Касимова Раиля Рашидовна (1966 г. р.), участница фольклорного ансамбля «Очрашу». В д. Гордино – Тютин Саубан Накипович (1960 г. р.), бывший сварщик. В д. Засеково – Митюков Касим Исмагилович (родился в 1934 г. в д. Верх. Дасос), был пастухом, шофером. В д. Палагай – Абашев Газимджан (Хыялетдин) Гусманович (1928 г. р.), колхозник, тальянка не сохранилась.

Все исполнители выучились самостоятельно, наблюдая игру старшего поколения. Многие происходят из семей народных музыкантов (играли их отцы и деды), а ныне дело продолжают дети (осваивают инструменты в учебных заведениях).

В предшествующий период было развито скрипичное искусство. Музыканты пользовались фабричными и самодельными инструментами. Сфера функционирования охватывала бытовое и концертное музицирование. Скрипка звучала соло, в дуэте с гармошкой и как сопровождение пения.

Из слов З. З. Касимова (д. Кестым) явствует, что его отец – Зиннатулла Ибрагимович (1927–1971) и дед – Ибрагим были скрипачами. Сначала исполняли на инструменте собственного производства, а затем приобрели маленькую скрипку в Глазове (тоже кустарную), для которой соорудили смычок. В школьные годы Зуфар абый и сам играл на скрипке. Хранимый в сельском музее экспонат (см. фото) принадлежал Зиннатулле Габитовичу (умер в середине 1990-х гг.). Он также сочетал талант музыканта-исполнителя (играл на свадьбах) и мастера-изготовителя.

На самодельном инструменте музицировал и Митюков Исмагил Гайфуллович (1905 г. р.), живший в д. Верх. Дасос (Мөрсәлим). Корпус был сделан из ёлки (*кара чыршы*), пропитывался кипяченым льняным маслом. Струны – стальные, а басовая – пластмассовая. На древко смычка натягивались конские волосы (*ат койрыгыннан*) и, для придания нужной шершавости, смазывались еловой смолой. Сын музыканта, давший это описание, не смог точно вспомнить: изготавливалась ли скрипка его отцом целиком, или он только ремонтировал готовую. Но больше он склоняется ко второй мысли, ибо в Юкаменском районе были в ходу инструменты (скрипки, гармоники) русских умельцев: их привозили из Кировской области, а подновляли уже татарские кустари.

Следует упомянуть еще Абашева Хисаметдина Салахетдиновича (или Низамовича) из д. Палагай. Слепой от рождения музыкант в молодости занимался торговлей, позже стал муллой. Сабреков Хабир Ситдикович (1922 г. р.) – здравствующий ныне скрипач, живет в д. Иманай, однако инструмент отсутствует, о чем он очень сожалеет.

В д. Падера поведали удивительную историю. Касимов Муса Габдуллович (1939–2009) – местная гордость, многогранно одаренная личность (о его талантах речь пойдет чуть дальше), выступал на концертах со скрипкой. И с какой! Рассказывают, что это была настоящая скрипка Амати. Каким путем шедевр выдающихся итальянских мастеров XVI–XVII вв. попал к татарам из сельской глубинки? Это остается загадкой. Предположительно, скрипка досталась от бабушки по материнской линии (на ней занимался ее брат). Семья была родом из Башкирии и переехала сюда в 1931–1933 гг., спасаясь от голода. К великому огорчению, застать скрипку и услышать ее божественный голос так и не посчастливилось. Кто-то из родственников продал ее и на вырученные деньги купил машину. Наше огорчение усугубляется осознанием того, что основная масса людей в культурных ценностях видит лишь материальную сторону и относится к ним как к средству обогащения.

Об укорененности исполнительства на струнных щипковых инструментах говорит бытование в прежние годы мандолины, балалайки и гитары.

Мандолина по большей части была распространена среди учителей, поскольку обучение на ней входило в программы педагогических училищ. Зафиксирована в дд. Кестым, Засеково. Экземпляр, представленный в экспозиции музея д. Засеково, принадлежал Митюковой Фагиле Галяветдиновне (1937 г. р.). В 1957 г. она закончила училище в Можге. По ее сообщению, на уроках музыки преподавали нотную грамоту, разучивали русские песни (учитель был русским). Приступив к работе в школе, она специально покупала татарские издания, разучивала народные и композиторские произведения, чтобы передать их детям.

состояло в том, что не надо было различать правый от левого, также не было разницы в типе мужских и женских лаптей. Таким лаптям были свойственны косоугольная головка и низкие бортики. Лапти, можно сказать, надевали все, т.е. не только крестьяне, но и люди, имеющие более высокое социальное положение. Еще в XVII–XVII вв. у татар появилось понятие «лапотные мурзы» (*чабаталы морзалар*), так называли людей, утверждающих наличие у себя дворянского титула, но не имеющих доказательства. Данное разговорное название появилось, когда некоторая часть татарских дворян бежала от насильственной христианизации. Противники крещения, естественно, лишались не только крепостных православного исповедования, но и всего богатства, прежде всего поместий и вотчин. Вероятно, именно после этих событий среди татар утвердилось выражение «чабаталы морза». Удмуртским татарам это была особо знакомо, так как татары называли себя потомками арских князей и основным делом была у них торговля. Отличие в том, что на данной территории их называли «лапотные князья» (*чабаталы кенәзләр*).

Плели лапти всей семьей. Например, в Кестыме татарские лапти делала только семья Касимова Ихсана. В музее сохранились образцы татарских лаптей, плетенные Касимовой Фагимой Тафиятуловной (1950 г. р.) в 1970 году (длина 28 см). Данные лапти в музей привезены из деревни Засеково (Дасис) Юкаменского района. В самом Кестыме мастером плетения был Касимов Идрис Хатмиярович (?–1946). Такие же лапти делал Бикмухаметов Ситдик (примерно 1925–?). У его внучки, Бикмансуровой Рахилы Хабировны (1950 г. р.), хранятся лапти его работы. По её словам, лаптей было сорок пар, сейчас они розданы родственникам и в большинстве случаев используются как артефакт (декор для дома).

Лапти русского образца сохранились не только в деревне Кестым, но и в музеях деревень Засеково и Палагай, а также во многих частных коллекциях. В Кестыме русские лапти плел Касимов Лутфулла Хафизович (1955–2004). Он плел лапти от всей души, и даже когда лапти перестали носить, он не прекращал свою деятельность.

Для плетения и для подачи формы, размера не только для татарских, но и для русских лаптей использовались деревянные колодки разных размеров. Мастер делал колодки сам и имел несколько вариаций. В деревне Ахмади Глазовского района известно о двух

братьях («чабатачы малайлар», как называли их в семье) – Тютине Нажие Габдулбаровиче (1935 г. р.) и Тютине Асхате Габдулбаровиче (1928 г. р.). По словам Тютиной Нурии Габделбаровны (1938 г. р.), они валили лес и по дороге домой приносили лыко и таким образом обеспечивали семью плетеными вещами.

Хочется сказать, что из бересты изготавливали различную хозяйственную утварь, например бураки, дно которых делалось из древесины. Из прямоугольной бересты скручивая делали форму и сшивали лентой (тоже из бересты) края.

Также традиционной обувью были кожаные ичиги и башмаки с мягкой и жёсткой подошвой, сшитые из цветной кожи. Такие ичиги не делались местными жителями, а закупались в большинстве случаев в Арске или в Казани. Арские ичиги с узорами пользовались особым спросом, так как в этих краях не было мастеров, занимавшихся этим промыслом. Но, по словам И. Х. Касимова, в деревне Балезино жил мастер – сапожник Касимов Маулет, который доставлял сапоги и в соседние деревни. Его сапоги выставлены в музее. Отличие его сапог от арских было в том, что они не имели орнаментального украшения. В музее сохранился один экземпляр его сапог, которые принадлежали мулле д. Кестым Касимову Валиулле Сафиулловичу. Обувь делалась из телячьей, конской, коровьей кожи. Подошва к основе подкреплялась деревянными шпильками. Цветовым разнообразием сапоги мастера не отличались и узора, как обычные татарские ичиги, не имели.

Самым известным и до сих пор актуальным промыслом среди татар Удмуртии остается **изготовление валенок**. Если современные условия позволяют использовать возможности технологии, то бабушки до сих пор занимаются ручным валянием. Этим ремеслом занимается Тютина Мухтарама Таиповна (1938 г. р.), жительница деревни Ахмади Глазовского района. По ее словам, промыслу валяния её научила мать, Касимова Фариха Набиевна (1910–?). Из молодых же валянием занимаются Касимов Ильфат Тагирович (1974 г. р.) и Касимов Хайдар Мукминович (1961 г. р.), жители д. Падера Балезинского района.

Валяют валенки так же, как и в старину. Основным материалом является овечья шерсть. Процесс производства валенок начинается с получения и подготовки необходимого сырья, то есть овечьей шерсти. По словам Мухтарамы Таиповны, используется шерсть

двух типов – летняя и зимняя, получаемая в зависимости от времени стрижки овец. Мы узнали, что летняя шерсть в основном берется во время осенней стрижки. Для нее характерна большая легкость и меньшее количество пуховых волокон. А вот зимняя шерсть стрижется весной, имеет более длинные волокна и большую подпушку.

Мухтарама Таиповна частично показала нам, как валяет валенок. Первым делом она чистит шерсть, расчесывает её с помощью чесалок. Потом накладывает на стол, намачивает мыльной водой и скалкой прессует, наматывая как тесто, пока она не уплотнится и ворсинки не сцепятся друг с другом. Следующий этап – придание формы, инструментом для этого является деревянная колодка. Потом ошпаривают горячей водой и сушат.

Еще одно ремесло, которое привлекло наше внимание, – это **кладка печки**. Печь в доме в первую очередь служила для обогрева. В печи готовили пищу, выпекали хлеб. Непременным элементом каждой печки была широкая лежанка (*мич башы*). Печи тщательно обмазывали глиной, белили. Изготавливали их из кирпичей, или же они были глинобитные. У татар Удмуртии распространено два вида печек: со встроенным казаном сбоку, где варили еду, и без казана. Преобладает первый вариант, так как отличается удобством. Почти у каждой деревни был свой печник. В деревне Кестым этим делом занимались Касимов Рафис Ибрагимович, Касимов Галиулла Садыкович, Касимов Ильхам Братиславович (1964–2004). В д. Падера до сих пор есть свой печник – Касимов Алмас Таирович (1981 г. р.).

Деревня Парзи до недавних времен славилась печником – Касимовым Сафуаном Ахметгалиевичем (1931–2008). По словам жителей данной деревни, его печи находятся во всех домах, также он делал на заказ и за пределами своей деревни. О нем до сих пор ходят притчи. Его печи особо славились среди родных и соседей. «До сих пор скучаем. Его не хватает» (*«Һаман да сагынабыз, җитми»*), – говорят жители Парзи. Его учителем был другой печник этой же деревни – Бузиков Фатхрахман Ханнанович.

Татары были и остаются верующим народом. Они, «кучкуясь» и основывая свои деревни среди удмуртов, бережно хранят свою религию и остаются ей верны. Такие религиозные аксессуары, как шамаиль и четки (*тәсбих*), хранятся не только в мечетях и в музеях, но и в домах. Если шамаили в основном привозились из Татарста-

на, то четки делали своими руками из косточек фиников, разноцветных бусинок и «позвонков резьбы» (бугорки на древесине).

По словам И. Х. Касимова, на данной территории, возможно, татары промышляли ювелирным делом, так как сохранилось много ювелирных изделий. Также известно, что татары занимались резьбой по камню. Писали в основном на мельничных жерновах (*тегермән ташы*) и на погребальных камнях.

Подводя итоги, можно сказать, что татары, проживающие на территории Удмуртской Республики, в основном занимались животноводством, земледелием и валили лес, все это давало им основной доход. Также татарам была хорошо знакома торговля, и они взяли в свои руки торговое дело, славясь искусными торговцами.

Все это привело к развитию отдельных ремесел, промыслов, как ткачество, кожевенное дело, обувное ремесло и т. д. Заметим, что удмурты особо не отличались от татар. Ни ткачество, ни деревянное дело не имеют особых различий. Отличаются лишь орнаментом и цветовыми сочетаниями: татарские изделия более красочны, используется раскраска. Но наблюдаются и следы взаимовлияния. Так, во многих работах удмуртских мастеров заметно присутствие татарской орнаментики, а у татар – удмуртской. Нужно сказать, что техника исполнения схожа.

Итак, среди ремесел у татар значительную роль играли деревообработка, развито были ткацкое ремесло. Деревянных дел мастера не только строили дома и украшали экстерьер, но и были искусными мебельщиками и делали утварь, возможно, и не только для своего хозяйства. Большинство кустарей занималось промыслом для дополнительного заработка, но для многих промыслы являлись основным занятием.

Встает вопрос: что же повлияло на некий «симбиоз» двух разных народов не только по вероисповеданию, но и по образу жизни?

Первоочередное, определенное влияние на формирование общей культуры оказывают характерные особенности географической среды (климата, почвы, рельефа, флоры, фауны и т. д.), что выражается в формирующихся стереотипах поведения, привычках, обычаях, обрядах, в которых проявляются черты быта народов. Много веков подряд климатические, территориальные и социально-экономические условия воздействуют на преобразование. Расширяются географические особенности – расширяются и ремесла.

Географическая (природная) среда повлияла на развитие таких видов. Татары, переехав в Удмуртию, поменяли равнины на лесные массивы, адаптировались к новым условиям, усвоили местные традиции, приняли своеобразие материальной и духовной культуры коренных жителей. Это выражается в развитии таких промыслов, как плетение из бересты, использование неких элементов обряда в резьбе (изготовление тотемов).

Естественно, со временем два народа обрели единые черты поведения, что также повлияло на ремесло и кустарные промыслы. Но при этом ни в отношении татар, ни в отношении удмуртов не чувствуются особых изменений.

Желание показать свое национальное своеобразие привело к сохранению таких традиций, обрядов, праздников (*сабантуй*), что, в свою очередь, способствовало дальнейшему развитию основных видов народных ремесел (вышивка, ковроплетение, резьба по дереву).

### Список информаторов

*Балезинский район, д. Кестым:*

Касимов Илмир Харисович, 1978 г. р.
Касимова Файма Валиуловна, 1928 г. р.
Касимова Люция Ибрагимовна
Касимов Нурислам Зайдуллович, 1950 г. р.
Касимова Светлана Казбековна, 1963 г. р.
Касимова Фардана Бадретдиновна, 1937 г. р.
Касимова Расима Лотфуловна, 1940 г. р.
Касимова Назия Байдулловна, 1931 г. р.

*Балезинский район, д. Падера:*

Касимова Аклима Миннуловна, 1934 г. р.
Касимова Асия Габдулбаровна, 1954 г. р.
Касимов Басир Шамилович, 1972 г. р.
Касимов Рафис Валиуллович, 1943 г. р.
Касимова Марзия Фатыховна, 1938 г. р.
Касимова Мадина Габделхаевна, 1957 г. р.
Касимова Нахия Галаутдиновна, 1938 г. р.

*Глазовский район, д. Парзи:*

Касимова Ламига Равиловна
Касимова Салиха Нахибовна, 1956 г. р.

*Глазовский район, д. Гордино:*
Тютина Зуфарбика Ибрагимовна, 1928 г. р.

*Глазовский район, д. Ахмади:*
Касимов Раиф хазрат
Тютина Нурия Габделбаровна, 1938 г. р.
Тютина Мухтарама Таиповна, 1938 г. р.

*Юкаменский район, д. Иманай:*
Бикмансурова Рахила Хабировна, 1950 г. р.

*Юкаменский район, д. Засеково:*
Балтачева Зухра Гыйлемдаровна, 1950 г. р.
Балтачева Марина Николаевна, 1962 г. р.

*Юкаменский район, д. Палагай:*
Гусева Маргарита Романовна, 1944 г. р.
Абашева Тахира Хайретдиновна, 1949 г. р.

*г. Ижевск:*
Габбасова Рамзия Илдусовна.

# ҮТКӘННӘРГӘ КАЙТУ

***1956 елгы экспедиция көндәлегеннән***

*Хуҗиәхмәт Мәхмүтов*



27-июль, 1956 ел.
Бүген 0 сг. 40 мин. Казан-Киров поезды белән юлга чыктык. Экспедиция составында 4 кеше: Х. Ярми, Х. Гатина, Ш. Зәбиров һәм мин.
Быел экспедиция Киров өлкәсе һәм Удмурт АССРда яшәүче татарларның халык авыз иҗатын өйрәнәчәк. Без 2 отрядка бүләндек: Хәмит абый белән Хамидә апа кичә пароход белән Киров өлкәсенә киттеләр. Шәех һәм мин Удмурт АССРга – Глазов, Юкаменск, Балезино районнарына барабыз.

Без 7 нче вагонда, 33, 34 нче урыннар. Вагондашлар бар да йоклый. Ара-тирә Шәехнең йокы аралаш канәгать мырлавы ишетелә. Кичә бик нык арылган, минем дә йокы килә. Ләкин йокламыйм.

---

Текстта аталган затларның шәхси мәгълүматлары һәм башка кайбер атамалар шул елларда кулланылганча, русчалатып бирелә.

Миншәех (Шәех) Харис улы Зәбиров (1932–2010) – ул чакта университет студенты, соңыннан күренекле журналист.

Җай гына селкенә вагон,
Тәгәрмәчләр бара шаулап.
Йомылалар арган күзләр,
Йомылалар йокы даулап.
Ләкин күңел риза түгел
Күзләрнең бу таләбенә.
Валлаһи, бу юл йөргәндә
Йокы килү бәла генә.

Яктыра. Шәмәрдән, Кукмара, Вятские Поляны станцияләрен үтәбез. Ниһаять, Вятка елгасы күренде. Аның аша салынган озын тимер күпердән чыгабыз. Вятка суы, ничектер, соры, болганчык шикелле. Ахры, яңгыр яугангадыр, юкса, безнең Мамадыш янында ул зәп-зәңгәр булып ялтырап тора.

Хәзер йокларга да була. Әле генә Шәех йоклап төшкән, хәтта суынырга да өлгермәгән урынга менеп ятам...

...Йокы туйды. Тамакны да туйдырдык. Әгерҗе дә артта калды. Менә Ижевск. Вокзалы бик иркен һәм матур. Дөрес, вокзал тирәсендә бер катлы агач өйләр генә күренә. Ләкин Ижевск бик зур, матур шәһәр икән. Без аны, поезд кузгалып киткәч, вагон тәрәзәсеннән карап бардык.

Кичен сәг. 10 яртылар тирәсендә Глазовка килеп җиттек. Гостиница вокзал янында гына икән. Кундык...

***28 июль, 1956 ел.*** Без Глазовта. Бик зур һәм матур шәһәр. Бертуктаусыз автобуслар йөреп тора. Күп кенә яңа йортлар төзелә. Дөресен әйтергә кирәк, минем мондый зур район үзәге күргәнем юк иде.

Райисполкомда булдык. Документларны рәтләдек, Хәмит абыйларга хат калдырдык. Эш бетте.

Такси белән Юкаменск район үзәгенә килдек. Райисполком председателе урынбасары ип. Сабриков белән таныштык. Ул бик ачык абый, татар, Ижевскида туып үскән. Аның белән бергәләп, якынча гына үзебез йөрисе маршрутны билгеләдек. Ул берсекөнгә Засековога бара икән, безне дә үзе белән алырга булды...

Юкаменск районында татар авыллары 19–20, аларда райондагы барлык халыкның 29%ы яши. Юкаменскиның үзендә татар мәктәбе юк.

Китап кибетенә кереп чыктык. Кибетче апа татар китапларына сорау аз булудан зарлана. Башлыча, дәреслекләр һәм балалар өчен язылган китаплар сатыла икән.

***30 июль, 1956 ел.*** Райисполком машинасы белән Дасиска (Засековога) барырга чыккан идек, ләкин, юл пычрак булу сәбәпле, Иманай авылы аша үтәргә туры килде. Хәзер шуннан ат белән Засековога китәбез.

Дасис (Засеково), Иманай, Норык (Верх. Дасис) – өчесе бергә «Үрнәк» колхозына берләшәләр. Авыл советы председателе – Ибраһимова Таифә Ибраһимовна, секретарь – Сабриков Хәбир Ситдыйкович, колхоз председателе – Абашев Зиннәт Зәйнуллович, библиотека мөдире – Балтачева Антонина Афанасьевна.

Авылда җидееллык мәктәп. Директоры – Сусаева Ольга Григорьевна. Клуб юк. Хәзерге вакытта өйдә: укытучы Абашева Заһирә Мифтаховна.

Кирәкле кешеләр:

1. Балтачев Маннаф Сәгыйтович, 1872 елгы. Правлениедән сул якта, 4-йорт.

2. Балтачев Ханнан Галләмович, 1888 елгы. Вундыр урамы.

3. Әмиров Шәкүр Идрисович, 1899 елгы, правление артындагы тыкрыктан өченче йорт, сулда. Бәет булырга мөмкин.

Авыл электрлаштырылган һәм радиолаштырылган.

***31 июль, 1956 ел.*** Дасис (Засеково). Кичә авыл активы белән танышкач, Маннаф бабайларга квартирга урнаштырдылар. Семьяда өчәү: бабай (күзләре күрми), аның килене Гаҗилә апа (начар ишетә) һәм малае Таһир.

Бабай үзе бик боевой егет күренә. Көр күңелле, күп сөйләшә, азгын анекдотлар сөйләргә әвәслеге зур. Апа да бик ачык хатын. Бередә халык, ничектер, сузып сөйләшә. «Контургамы бара-сың-ң-ң?» һ. б.

«Ырга-ергә» кушымчасына беткән фигыль формасы «мага-мәгә» белән йөртелә. «Т» авазы күп вакыт «к»гә күчә. «Бик» рәвеше «яман» сүзе белән алышынган; «яман усал», «укымага keләми», «яман озын» һ. б.

Кичә кичтән радиоузелга кызларны җыеп, алар белән сөйләштек. Җыр дәфтәрләре һәм үзләре белгән җырларны язып китерергә вәгъдә биргәннәр иде, бүген иртән без торганчы 3–4 истәлек дәфтәре калдырып чыкканнар.

Бүген, иң элек, Галия апаларга төштек. Ул 1895 елда Казан губернасының Күкчә[1] авылында туган. 1921 елгы ачлык вакытында

[1] Күкчә – бу исемдәге авыл Казан ханлыгы чорында ук билгеле булган. Хәзер Теләче районына керә.

тегүче абыйсына ияреп бу якларга килгән һәм тормышка чыгып калган. Туган якларын бик сагына. Үзе ачык, үткен, сүзгә оста хатын. 80 ләп җыр һәм берничә әйтем яздырды.

Төштән соң Ханнан исемле картка кереп чыктык. Авыл тарихы турында кайбер нәрсәләр сөйләде. Мондагы картлар арасында әкият ише әйберләр сөйләү хас түгел ахры.

Кич белән кызларның истәлек дәфтәреннән шактый җыр яздык. Почтада эшләүче Хәйретдин абый керде, аның белән районндагы татар авыллары турында гәпләшеп утырдык.

Биредә күңелсез түгел. Халык ачык. Казанга бик хөрмәт белән карыйлар. Казаннан радиотапшыруларны тыңларга «яман» яраталар.

Без хәзер Шәех, мин һәм Заһирә апа (укытучы) авыл советында утырабыз. Җирле вакыт белән 22 сәгать (Мәскәү вакытыннан бер сәгатькә алда йөри). Инде караңгы төште. Бүген көн матур гына иде. Җилле булса да, һава аяз торды. Хәзер салкынайтты. Урамнарда бер кеше дә күренми. Бүген кич кызлар җырлар язып китерергә булганнар иде, әлегә тавыш-тыннары юк.

Безне кичә Иманайдан ат белән китергән егет – Басыйр, удмурт теле турында сүз чыккач, мондый вакыйга сөйләде. Бер удмурт базарга он сатырга бара икән. Басыйр юл буенда гына печән чаба. Моңа он кирәк. Удмурт белән сатулаша башлый бу. Соңыннан ниндидер бәягә килешәләр. Удмуртча чалгы «литовка» икән, Басыйр ялгыш удмуртка печән арасыннан «литовка»ны алып чыгыйм, диясе урында, «винтовка»ны дип ычкындырган. Шуннан ул печән арасына кереп кенә киткән, давай удмурт атын кыйный-кыйный чаптырырга!

Галия апа кызык кына бер җыр әйтеп куйды. Имештер, бер бай уракчыларына аш ашаткач, чәй эчермәгән. Уракчылар эшкә киткәндә тәрәзә турыннан болай җырлап үткәннәр:

Безнең авыл зур авыл,
Капка саен каравыл,
Аш артыннан чәй эчмәгәч,
Нигә кирәк самавыр.

Ярый. Язуны шушында туктатып торам. Кызлар җыела башлады.

Кызлар (Мәдинә, Людмила, Сания) берничә уен җырлары язганнар. Алар хәзер үзләре бер өстәл янына утырып җырлар язалар.

***1 август, 1956 ел.***

Бездә биек таулар бар,
Тау астында таллар бар.

Талда яфрак, бездә сагыну,
Сездә нинди хәлләр бар?

Бу җырны Мәдинә исемле кыз яздырды. Без бүген җәяүләп кенә Иманай авылына килдек. Әлегә укытучылар күренми. Закир бабай калага киткән.

Биктаева Мәдинә Габделгазизовна, 1940 елда туган, 9 кл. белемле, комсомолка.

Рәхимә (укытучы) берничә җыр дәфтәре китерде. Алардан сайлап бераз җырлар күчердек.

Дасиска кайттык. Документларны оформить иттек. Ат белештек. Иртәгә Максутка (М.Венежга) китәбез.

Кайткач Маннаф бабай белән сөйләшеп утырдым. Бабай бик горур, көнче. Ханнан бабай авыл тарихын синнән күбрәк белә, дигәч, тиресеннән чыгардай булды. «Врет он, вот и вче», яисә «ул миннән ишеткәнне генә сөйли» дип, Ханнанның «дәрәҗәсен» төшерергә тырыша. Элек Маннаф бабайны «Ата каз» дип йөрткәннәр.

Бу авылда өйләр бик зур итеп салынган. Урманлык булу тәэсиредер.

Сарыкларның, кәҗәләрнең муенына кечкенә кыңгыраулар тагалар. Кичә кич көтү кайтканда шаккаттым. Кәҗәләр кычкыра, сарыклар кычкыра, көтүчеләр кычкыра, бала-чагалар кычкыра, өстәвенә берьюлы 100 дән артык кыңгырау шалтырый, тузан. Чын пәри туе иде.



Юкамен районы, Дасис (Засеково) авылы. Х. Мәхмүтов Балтачева Гаҗиләдән җырлар яза

Маннаф бабай кыңгырау тагуны болай аңлата: «Имеш, элек пастух булмаган. Мал урман эченә кереп киткәч, кыңгырау авазы белән барып тапканнар».

***Дасис (Засеково) авылы,*** картларның (Ханнан бабай, Маннаф бабай һ. б.) сөйләве буенча, читтән күчеп утырган. Бу хәл Екатерина II заманында булса кирәк. Татарларны көчләп чукындыра башлагач, Малмыж өязенең Балтач авылы кешеләре башта Вятка губернасының Слободской өязенә, Дунды дигән авылга, аннан бирегә

күчеп утырганнар. Бу тирәләрдә кап-кара урман булган. Имештер, элек бу якларга 4 өй генә күчеп килгән... «Безнең бабам әйткәләде, монда 15 өй вакытын беләм, дип», – ди Ханнан бабай.

Маннаф бабай әйтүенчә, Балтачтан килүчеләргә Дундыда җир килешмәгән. Күчеп килүчеләрнең берсе – Маннаф бабайның бабасының бабасы Мисял булган. Җир бүлеп йөрүче межовой урыс, бу күчеп килгән кешеләр белән бергә, чишмә-күзгә килеп чыккан. Кулында балтасы икән, чапкан бу агачка: «Менә сезгә межа, я засек здесь», – дип. Шуннан Засеково киткән, ди.

Авылдагы бөтен кеше диярлек Балтачев фамилияле. Бу Балтач дигән авылдан күчкәнгә икән.

Элекке вакытларда ук бу якларга Казаннан тегүчеләр, башка һөнәрчеләр килеп йөргәннәр. Аларның кайберләре монда торып ук калганнар. Тимер юл Глазовка 55 еллар элек килеп җиткән, ә аңа кадәр болар Казанга бару өчен Каравыл дигән җиргә чыга торган булганнар. Аннан Казанский тракт үткән, тракт буенча подводалар белән Казанга йөргәннәр.

Хәзерге вакытта Иманайдан ерак та түгел Җуам исемле керәшен авылы бар. Ул авылда элек татарлар булган. Екатерина II аларны көчләп чукындырган. Шул чакта бу авылдан Иманай атлы берәү качып киткән. Ул вакытта монда бик куе урманлык булган. «Инде 10 чакырым киттем, хәзер 10 ат белән кусалар да тота алмаслар, котылдым, денемне ташламадым», – дигән Иманай. Ул урман эчендә үзе генә 3 ел качып яткан. Шуннан бу урынга башкалар да күчеп утырган. Авылга Иманай исеме бирелгән.

Дасис (Засеково) авылында язылды:

402 җыр, халык уеннары – 7, бәет – 1, мәкаль-табышмак – 15, әкият – 1.

Иманай авылы – 50 җыр, 1 халык уены.

***2 август, 1956 ел.*** Иртән көчле яңгыр ява башлады. Сәгать 9 ларда, яңгыр туктала төшкәч, ат белән Максут (Малый Венеж) авылына киттек. Юлда бик күңелле булды: урман арасыннан, Убыть елгасы буеннан бардык. Килеп җитәрәк яңгыр ява башлады. Чыландык. Правлениедә кеше күп иде, ләкин председатель Юкаменга киткән.

Газимҗан абыйларга урнаштык. Ике улы бар (Мөдәррис һәм Мөкаддис). Бик ачык кешеләр.

Бер-ике сәгать ял иттек. Хәзер правление тирәсенә чыгабыз.

Максут (М. Венеж) Бадера авыл советына керә. 60 хуҗалык. «Красная звезда» колхозы.

Колхоз председателе – Гобәев Галибай Дәүләтбаевич.

Парторг – Васильев Виталий Николаевич.

Авыл советы председателе – Абашев Габдулла Ахметзянович.

Завклуб – Арсланов Наил Габделбариевич.

Абашева Һәҗәр Шәймулловна – бухгалтер.

Авылда башлангыч мәктәп.

Әмиров Гата Габделхакович – укытучы, хәзер авылда.

Яшьләр арасыннан җырга оста кешеләр:

1. Абашева Маһинур Габдулхаковна.
2. Абашева Рауза.
3. Абашева Хөсния Каюмовна.
4. Имаметдинова Зәкия Габдрәшитовна.

Олылардан:

1. Абашев Камали Голдышин (җырлар, клуб янындарак).
2. Абашев Сәхәветдин Гыймаевич.
3. Абашев Шәйдулла Хисамович, гармонист, үткәнне белә.
4. Абашев Хөрмәт.
5. Абашев Каюм.

Шәйдулла бабай янында булдык. Максут авылы Палагай авылыннан күчеп утырган. Беренче күчеп килүчеләр Максут һәм Кыйлмит исемле кешеләр булган. Хәзер авылның бер өлешен Максут нәселе, бер өлешен Кыйлмит нәселе дип йөртәләр. Палагай үзе Нократтан күчкән булса кирәк.

***3 август, 1956 ел.*** Максут. Ак дәфтәргә 85 җыр күчердем. Камалетдин бабайдан 16 җыр язып алдым.

Аннан чыккач урам буйлап төшеп барганда, бер өйнең тәрәзәсеннән берничә хатын-кыз күренде. Миңа күрсәтеп нидер сөйләшәләр. Тәрәзәгә барам. «Нәрсә дисез?» – дип сорыйм. Ниндидер җыр турында әйтәләр. «Аллага тапшырып» кереп киттем. «Үзегез чакырып керттегез, җыр җырламасагыз, чыкмыйм», – дим. Көлешәләр. Өй түрендә сәке. Сәке янында өстәл. Өстәл артында 45–50 яшьләр тирәсендәге 3 апа һәм 1 абый утыра. «Ерактан колагым ишетми», – дигән булып араларына ук кереп утырдым. Үзебезнең эшне әйттем, «Татар халык иҗаты» китабын чыгарып күрсәттем, Камалетдин бабайның бер-ике «хикмәтле» җырын укып җибәрдем. Арадан Хәят исемле бер апа, артык назландырмыйча гына, җырлар




әйтеп торырга кереште. Сөйләшәбез, көлешәбез, шулай итә-итә 32 җыр булды.

Квартирга кайттым, күңел күтәренке генә иде, өстәвенә, бабайның олы улы Мөдәрриснең яшь ярымлык малае Рәсим көлдереп үтерә язды. Күз алдына китерегез: яшел чирәм үскән киң ишегалды. Ишегалды уртасындарак ике бүрәнә. Бүрәнә өстендә тормыштан һәм үзләреннән бик канәгать ике егет утыра. Алары – Шәех белән мин. Көннең кояшлы, җылы, җиләс булуын да өстәргә кирәк.

Бездән ерак та түгел, кулына ипи сыныгы тотып, башына яулык бәйләсә дә, малайлар сафына керүче кечкенә генә бер бала басып тора. Нәни генә аякларын як-якка җәйгән, ипи тоткан уң кулы бераз арткарак киткән, сул кулын «ау бул» дип безгә селки, дөресрәге

без «ау бул», «ау бул» дип утырабыз, ул кулын селки. Елмаюлы йөзе, борын тирәсе бик үк чиста булмауга да карамастан, айның ундүртенче кичәсе кебек балкый.

Бу күренеш озакка барыр идеме, белмим, әмма якында гына чирәм чүпләп йөрүче, түшеннән җоннары йолкынган бер ак тавыкка малай кулындагы ипи сыныгы шактый кызыктыргыч тоелды бугай, ул башта сак, аннан шактый кыю адымнар белән малайга якынлаша башлады. Кара аксак тавык та аңа иярде һәм, «аксак күп йөрер» дигән мәкальнең дөреслеген тагын бер кат раслап, малай кулындагы ипигә беренче булып килеп җитте. Аның чукуы көчсезрәк булдымы, малай ныграк тоткан идеме – ипи кисәге ычкынмады. Кара тавыкның икенче һөҗүменә ак тавык та өлгерде. Ике тавыкның берьюлы чукуыннан малай артка егыла язды. Ипи кара тавыкка эләкте. Муенын алга сузып, канатларын җәеп йөгереп караса да, аксак аяклар сынаттылар, башка тавыклар аны куып җитеп, зур батырлык күрсәтеп алган табышын талап алдылар. Бу минутта малайчыкның йөзендә елмаю урынына курку, гаҗәпләнү, ачыну билгеләре чыккан иде. Мин бер генә кино, цирк яки театрда болай көлүемне хәтерләмим. Шәех турында әйтеп тә торасы юк. Ул, гомумән, көләргә бик сәләт егет. Бу минутларда аның бүрәнә өстенә ятып, бөтен зур гәүдәсе белән селкенә-селкенә, куллары белән әле башын тотып, әле йөзен каплап һәм шул ук вакытта «их-их», «кых-кых» кебегрәк авазлар чыгарып көлүен күргән кеше, һичшиксез, бу егет нормаль ук түгел, дип уйлаган булыр иде. Мин, билгеле, алай уйламадым...

Кич белән клубка бардык. Шәех күп кенә уен җырлары язды.

***4 август, 1956 ел.*** Колхоз идарәсенә барып документларны рәтләдек. Хәмит абыйларга хат яздым.

Төштән соң урманга бардык. Андагы кура җиләге – исәпсез-сансыз, тамып-тамып торалар. Шәех башта утырган җирдән ашарга дип йөри иде, соңыннан ятып ашарга кереште. Урманда адаштык. И, йөрибез, йөрибез – юк. Мин бик биек агачка да менеп карадым. Җирдән бер 3–4 м күтәрелдем – берни күренми. Менүем бушка китмәсен дип, Шәехтән фотога төшерергә сорадым. Ләкин рәтле чыгачагына бер генә тамчы да ышанмыйм, бик теләр-теләмәс кенә төшерде. Хәер, аны гаепләп булмый. Урман уртасында адашып калган кеше, һәрхәлдә, фото турында уйламый. Җитмәсә, кайтып җитәргә вакыт. Кич белән кантурга керәсе бар.

Менә бервакыт урман эчендә шылтыр-шылтыр, челтер-челтер кыңгырау авазлары ишетелә башлады. Көтү! Шәехнең йөзе яктырды. Аяклары тибеш-тибеш атлый башладылар. Аның артыннан җитү өчен миңа ул әйләнеп үткән чокырларны сикереп кенә чыгарга туры килә. Бер сикергәндә расческам төшеп калган. Әйбәт иде, эх!..

Көтүчеләр удмурт малайлары булып чыкты. Сиздермәскә тырышып, юлны сораштык. Ләкин Шәех һаман тыныч түгел. Фотога төшер, дигәч, үз күзем белән авылны күрим әле элек, ди.

Кайтып җиттек. Все в порядке!

***5 август, 1956 ел.*** Палагайга килдек. Зур Палагай авылы, «Трактор» колхозы, 91 хуҗалык, җидееллык мәктәп, сельпо, детдом (50–60 бала).

Авыл советы председателе – Абашев Нәкыйп Зиннәтович.

Колхоз председателе – Абашев Малик Мөхәмммәтясәвиевич.

Сельпо председателе – Абашев Гыйлаҗетдин Сәлахетдинович.

Детдом директоры – Шнякина Надежда Макаровна.

Мәктәп директоры – Кутуева Разия Нәҗиповна.

Абашев Габделхәй Хуҗиәхмәтович, татар теле һәм әдәбият укыта.

1. Абашев Хисаметдин Низаметдинович, скрипач, бездән 3 өй аша.

2. Абашев Солтангәрәй Мөхәммәдиевич, үткәнне сорарга.

3. Абашев Лотфулла Әхмәтшевич. Юкамен башында.

Авылда радиоузел һәм электричество бар. Радист – Абашев Талип Дамиевич.

Мәхмүдә апаларга квартирга кердек. Аннан Хисаметдин абыйга бардык. 56 яшьтә, яшь ярымнан сукыр калган, скрипкада оста уйный. Аңардан 46 җыр язып алдым. Иртәгә тагын кереп чыгарга, фотога төшерергә кирәк булыр.

Хәзер кичке сәгать 9 (Казанда – 8). Мин өйдә, ачык тәрәзә янында утырам. Шундый рәхәт җил исә... Кәеф яхшы. Ак дәфтәргә 50 гә якын җыр күчердем. Шәех журналлар караштырып утыра. Йөзе болытлырак. Нигә икән? Ә-ә! Өстәлдә кәҗә сөте бар, безгә дигән. Ул кәҗә сөте яратмый. «Апа, бу сөтеңнең берәр чокырын сыер сөте белән алыштырып кайт әле», – дим. Апа риза була. «Кирәкмәс, юк» кебек сүзләр әйтсә дә, Шәех тә бу тәкъдимгә бик риза. Ул хәзер күңелле сызгыргалый.

Сөт эчкәч, клубка, яшьләр янына чыгабыз.



6-август, 1956 ел.

Бүген иртән мәктәпкә барып утырдык. Габделхәй абый 17 җыр, 18 әйтем, 4 табышмак китерде. Мәктәптән чыккач, Хисаметдин абыйга кердек. Скрипка уйнаттык. Чын романтик картина. Сипкелләр белән чуарланган күркәм, сабыр йөз. Сукыр күзләрдән дә ниндидер бер тирән уй сизелерлек карый. Башта татарча түбәтәй. Уң аягын сул аяк өстенә куйган да, сул аягы белән ара-тирә әкрен генә идәнгә баскалап утыра. Иске скрипкадан үзәк өзгеч сагыш, тирән моң авазлары чыгып, күңелне тетрәтә.

Хисаметдин абый вакыт-вакыт үз уенына үзе кушылып җырлап җибәрә. Аның тавышы әллә ни матур түгел, әмма чиста:

«Кара гына урман, караңгы төн...»

...Бүген тагын Лотфулла абыйларга барып утырдым. 10 лап җыр яздым. Бик кунакчыл кешеләр булып чыктылар. Чәй эчеп, иркенләп сөйләшеп утырдык. Ул авыл тарихын әллә ни әйтә алмады алуын.

Зур Палагай авылы Нократ ягыннан күчеп утырган булса кирәк. Сәбәп һаман шул – Екатерина II көчләп руслаштыра башлагач. Авылдан ерак түгел «Иске йорт» дип аталган урын бар. Имештер, шунда, иң элек, өч улы белән Янбулат исемле кеше килеп утырган. Иске йорт янында кечкенәрәк кенә тау бар, ул Янбулат тавы дип йөртелә. Янбулатның бер улы Абаш исемле икән. Шуннан Абашев дигән фамилия киткән. Максуттагы кебек үк, бу авылда да күпчелек кешеләр Абашевлар.

...Зур Палагай авылы янында ук, су аша гына, Кече Палагай авылы бар. Бу авылга башта, Лотфулла абый әйтүенчә, Палаг дигән кеше килгән. Кече Палагайдан кешеләр Зур Палагайга күчкәннәр.

Кичә кичтән, көтмәгәндә генә, безгә бер абый килеп керде. Ул район юл бүлегендә эшләүче Нәкыйп исемле кеше булып чыкты. Бераз «кәккән» иде, шуңа һәрбер сүзен чистая монета итеп кабул итәргә ярамый. Гәрчә изге ният белән сөйләсә дә!..

Имештер, «Иске йорт»тан, чукындыра башлагач, бөтен кеше качып беткән. Бары бер генә хатын чукынырга риза булган. Аңа чукындырганда Пелагея дип исем биргәннәр. Пелагеядән Палагай килеп чыккан.

Бу якларда һәр кеше бер сүзне әйтә: «Без кара халык». Элек, 1917 нче елга кадәр монда, имештер, русча грамоталы бердәнбер шәкерт булган. 19 нчы гасырларда гына, имештер, бирегә беренче самовар килеп чыккан. Аны Мәкәрҗәдән бер бай алып кайткан. Кайткач, башта авыл кешеләре самоварның утлыгына су, су саласы җиренә ут салып азапланганнар икән. Биредә озак вакытлар чыра яндыру булган. Беренче керосин лампасы кайткач, аны карарга бөтен авыл җыелган.

Нәкыйп абый бу нәрсәләрне бик бутап, ләкин ялкынланып сөйләде. Әйтерсең, ул аларның барысын да үз күзе белән күргән. Аннан «әйдә, клубка чыгабыз» дип йөдәтә башлады. Анда менгәндә дә әллә нинди хыял-фантазияләр белән тәңкәгә тиде. Имештер, ул, клубка менгәч, яшьләргә үзе аңлата, һәркем үзе белгән җырны яза да почта ящигына (!) сала. Почтальонны алдан кисәтеп куябыз. Почта ящигында бер кочак җыр була! Аны бергәләп разбирать итәбез! У-у-у, эшләр гөрләячәк! Иртәгә председательдән ат алып, «Иске йорт»ка, Янбулат тауларына барабыз!.. И «кәккән баш», нәрсәләр эшләргә генә сәләтле түгел ул! Клубка менгәч 42 яшьлек абыебыз 22 яшьлек егеткә әйләндемени! Бик үк хуш булмаган тавыш белән җырлый, бии...

Кичә кич авыл советына берничә кызны җыеп сөйләшкән идем, Шәех бүген аларны фотога төшерде.

***7 август, 1956 ел.*** Бүген, колхозның «Маяк» исемле айгырын җигеп, Пүчинкәгә китерделәр. Колхоз председателе ип. Касыймов бик боевой, эшлекле кеше. Молодец! Хотя аның бер кулы юк.

Сабира апаларга квартирга кердек. Карты Ибәтулла исемле. Бу юлларны аларга кергәч яздым.

***8 август, 1956 ел.*** Пүчинкә, Юкамен районы. «Большевик» колхозы; Ежово авыл советына карый. Авылда 7–8 елдан бирле радио һәм электричество бар. Җидееллык мәктәп. Зур гына медпункт. Уку өе. Клуб.

Колхоз председателе – Касыймов Насыйх Вәлиевич. Авыл советы председателе – Есинеев Әхмәдулла Нигъмәтуллович. Клуб мөдире – Арсланова Мәрзия Гатаулловна.

Мәктәп директоры – Гатауллин Мирзаян, Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаган.

Кичә кич мунча кергән идек, бик яхшылап йокладык. Иртән коедан су алып юынып йөргәндә өйдән Ибәтулла бабайның тавышы ишетелә:

– Айдагез, ашамага керегез, ашамага-эчмагә...

– Апа, сабын алып кайтыгыз әле. Ике кисәк алсагыз да ярый.

– Икенеме алыйм?..

Биредә «китте» диясе урынга «барды» дип сөйләшәләр:

– Апа, бабай кая китте?

– Казларны кумага алып барды.

...Мехәматхан абый өйдә юк. Калага барган.

Иртә белән өйдә утыра идем, тышта Шәехнең көлгәне ишетелә. Көлүнең көчле яңгыравына карап, гәүдәсенең селкенү дәрәҗәсен билгеләгәч (ә Шәехнең гәүдәсен селкетмичә көлгәнен һичкайчан күрмәссез!), ниндидер бер кызык вакыйга булганын төшендем. Гәүдә баштан алып билгә кадәр селкенә иде.

– Менә җүләр, кых-ких-ках-ха, – бу Шәех. Ул өйгә керә.

– Нәрсә булды?

– Мине этәч талады. Кых-ких-ках-ха-хах! Менә җүләр! Кых...

Ибәтулла бабай да эшнең нәрсәдә икәнен аңлап ала һәм картларча көчсез, ләкин шул ук вакытта бу яктагыча калын итеп «Хы-ха-хе» кебегрәк авазлар ярдәмендә көлеп туйгач, үзенең һәр минут ярым саен әйтә торган «ый, Аллам»ын әйтә дә, этәчнең балаларны чүкергә бик әвәс булуын куанып сөйли.

Әтәч Шәех өйгә керергә теләгәндә башта ишек төбенә килеп биеп торган да, аннан чукымага ябышкан икән. Ый, Аллам!

***9 август, 1956 ел.*** Бүген көн бик күңелсез, җил, салкын, вак кына яңгыр сибәли. Иртә белән Рәисә Таушова дигән кыз җырлар дәфтәре һәм, үзе язып, җырлар китерде.

Без ашап утырганда, бик ачуланып, бабай кайтып керде. Ничек ачуланмасын: апа казларны әле өйдән чыгармаган да, ә бабай инде сазга (болынга) төшеп, казлар ничек йөри икән дип, аларны эзләп азапланган!..

– Кафыр, бөтен казларыңны бәреп үтерермен!

– Бәреп үтерсәң, итен үзең үк ашамага киләрсең ич!

Мондый «тимер логика» каршында гаҗиз калган бабай казларга әле генә чыгарган «үлем җәзасын» саз буена «сөрген» белән алыштырды һәм бераздан, каурый канатларны куа-куа, шул тарафка юл алды.

...Канцеляриягә барып, райисполкомга хәбәр иттек – үзебезнең кайдалыкны. Тиздән Хәмит абыйлар Глазовка килеп җитәргә тиеш.

Мәктәпкә кердек. Хәтимә Касыймова исемле укытучы кыз белән таныштык. Ул хәзер безгә җырлар язып утыра. Әти-әнисе Глазов районының Татар Парҗысы авылында яши. Безнең ул авылда буласыбызны белгәч, «квартирга безгә керерсез» дип, вәгъдә алып куйды. «Әтием Галәветдин мәкальгә оста» дип тә «кызыктырды».

Авыл кызлары:

1. Әкълимә Шәетовна Есинеева.
2. Рәисә Әгъләмовна Таушева.
3. Рәшидә Әхәтовна Есинеева һ. б.

Кызлар барысы да җырлар язып китерделәр. Молодцы!

Иртәгә Тегермән авылына китәргә исәп. Бу районда, күп дигәндә, 3–4 көнлек эш калды.

Юкамен районындагы татар авыллары:

1. Дасис (Засеково) – булдык.
2. Мөрсәлим (Норык, В. Дасис).
3. Иманайда булдык.
4. Максут (Малый Венеж) – булдык.
5. Кишур.
6. Яңа юл (Тутаево).

7–8. Зур Палагай – булдык. Кече Палагай. Икесе бер авыл диярлек.

9. Пүчинкә – булдык.
10. Тегермән (Тат. Ключи) – булдык.
11. Байгазы (Мамлей) – 10–15 йорт.
12. Мостай – кечкенә, татар һәм бисермән.
13. Атабай (Рахматово).

14. Мулла авыл (Муллино) – кечкенә.
15. Шафи авылы.
16. В. Пажма
17. Н. Пажма } – татарлар берничә генә йорт.
18. Югары Кушупи
19. Түбән Кушупи } – кечкенә авыллар.

Районда ике җидееллык мәктәптә (Зур Палагай һәм Пүчинкә) татар теле һәм әдәбияты укытыла. Татар язучыларының портретлары, татар теле буенча таблицалар юк. Татарча дәреслекләр соңга калып кайта (Зур Палагай укытучысы Абашев Габделхай Хуҗиәхмәт улы сөйләвеннән).

***10 август, 1956 ел.*** Бүген иртән Тегермән авылына килдек (русча – Тат. Ключи).

Дәрәҗә бар! – Колхоз председателе үзе тарантас башына кучерга утырып алып кайтты.

Квартирга Галиулла исемле кешеләргә урнаштык. Арсланов Галиулла, 55 яшьтә. Искечә укымышлы. Бик күп китаплары, үзе язып алган җырлары бар.

Галиулла абыйдагы «Җир байлыгы» исемле китапта табышмак, мәкальләр күп.

Пүчинкә белән Тегермән икесе дә бер колхоз составында. «Большевик» колхозы. Ежово авыл советына карый. Начальство Пүчинкәдәге кебек үк.

Авылда 82 хуҗалык, башлангыч мәктәп, радиоузел, электростанция.

Халыкның 8–10 проценты бисерманнәр.

Колхоз идарәсендә утырабыз. Җирле вакыт – 6 сәг. 45 мин. Беркем дә юк. Җыен кирәк кешеләр районга китеп беткән.

Тегермән бу районда соңгы авыл. 10–12 августта эшләсәк, 13 ендә Глазовка китәргә була. Ләкин Хәмит абыйлар соңлады. 15 көннән сезнең янга җитәрбез, дигәннәр иде – бүген аерылышканга нәкъ 15 көн тулды. Әле алар Глазовка да килмәгәннәр. Алда 18 эш көне. Әгәр хәбәр килмәсә, 14 августта Глазовка китәбез. Хәзер берәр көннән мондагы һәр көн – бушка узган көн булачак.

***11 август, 1956 ел.*** Тегермән авылы, иртән канцеляриягә килеп, завклуб Нафыйк абый белән сөйләштем. Җырга оста кызлар:

1. Арсланова Әсма Ногмановна.
2. Арсланова Фәүзия Бәдретдиновна.

3. Арсланова Мәрьям Йосыповна.
4. Арсланова Таифә Гыйләҗевна.
5. Арсланова Фәүзия Габделбәровна.
6. Таушева Лима Нәфыйковна.

Иртәгә Глазовка китәбез. Тегермәндә телефон эшләми.

Юкамен районында эш бетте.

**Халык сүзләре**

1. Суйган да куйган; бер тамчы су төсле.
2. Тукмак тисә, тик торыр.
3. Авызына йөзек яшергән.
4. Уклау йоткан.
5. Ялан-ялан майлы бутка булмый.
6. Капкан саен калҗа булмый.
7. Карама көленә утыртты.
8. Гүр тишегенә кергән.
9. Майламыйча тәгәрмәч әйләнми.
10. Башы-аягы бер казан.
11. Пычагы майда йөзә.
12. Койрыгы пешкән мәче төсле.
13. Җил уңаена кабык сөямә.
14. Аның әтәче кубыз уйный.
15. Дуга белән печән чаба.
16. Кыйланышы кырга сыймый.
17. Кысыр хатыннан бала таптырма.
18. Ияк биетү (ашау).
19. Аның мәчесе дә куян тота.
20. Тере саескан очыра.

Биредә килеш кушымчаларын төшереп тә сөйләшәләр. Кичә безгә бер апа кергән иде. Абыйга «**Без өчен** булса, самавыр куеп йөрмә», – ди.

Яшьләр арасында мондый түгәрәк уены да бар:

Әйдә, әйдә **мин белән,**
Әйдә, әйдә мин белән,
Әйдә, әйдә мин белән дә,
Яхшы сүзләрең белән.

«Түгел» ярдәмче сүзе урынына «юк» кулланыла. Мәсәлән, «Биредә суык түгел» диясе урынга «Биредә суык юк» диләр.

Бүген Шәех, Пүчинкәгә барып, документларны рәтләп кайтты. Мин әле генә правлениедән ат белешеп төштем.

Иртәгә юлга! Хуш, Тегермән! Хуш, Юкамен!

Мондый решение өчен Хәмит абый мине асармы-кисәрме, әллә рәхмәт әйтерме – бар да булуы мөмкин. Ләкин мин үземчә дөрес эшлим.

Хәзер настроение чемоданное. Әйберләр әзерләнгән. Эш беткән. Кич белән клубка чыгып керәсе булыр. Кичә Шәех үзе генә чыккан иде, кызларны бик мактап кайтты. Берәрсенә күзе төшкән ахры. «Бүген мин дә чыгам әле» дигәч, «чыкмасаң да ярый» дип тора.

Язуны шушы төштә туктатып торырга кирәк. Кызыклар булса, соңыннан искә төшерермен әле.

СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы оештырган фольклор экспедициясенең икенче отряды 29 июльдән алып 13 августка кадәр Юкамен районында булды. Барысы 15 көн.

Отряд түбәндәге маршрут буенча хәрәкәт итте:

1. Казан – Глазов (УАССР).
2. Глазов – Юкамен (43 км, 2 кич).
3. Юкамен – Дасис (Засеково) (15 км, с. 30/VII – по 1/ VIII).
4. Дасис (Засеково) – Иманай (3 км, с 1/ VIII – по 2/ VIII).
5. Иманай – Максут (М. Венеж) (9 км, с 2/ VIII – по 5/ VIII).
6. Максут (М. Венеж) – Олы Палагай (12 км, с 5/ VIII – по 7/ VIII).
7. Олы Палагай – Пүчинкә (5 км, с 7/ VIII – по 10/ VIII).
8. Пүчинкә – Тегермән (Тат.Ключи) (3 км, с 10/ VIII – по 3/ VIII).
9. Тегермән (Тат.Ключи) – Олы Палагай – Глазов.

Барысы 6 авыл, 14 эш көне.

Юкамен районында җыелган материаллар:

1. Җырлар – 1115.
2. Халык уеннары – 54.
3. Әкият – 1.
4. Бәет – 3.
5. Табышмак, мәкаль – 139.
6. Авыл тарихы – 6.

Биредәге бисермәннәр (удмурт керәшеннәре) кайчандыр татарлардан килеп чыкканнар, дигән караш бар. Аларда хәзер христиан һәм мөселман диннәрен бергә тотуны очратырга була.

Юкамен районында Пүчинкә дигән татар авылы һәм Сидоровка дигән рус-бисермән авылы бар. Һәр ике авылда Есинеев дигән фамилия күп.

Пүчинкә авыл советы председателе Әхмәдулла Есинеевка 1938 елда 110 яшьлек бер бисермән карчыгы сөйләгән. Бу карчык әле 3 яшьлек сабый вакытта аның бабасының атасы Пүчинкә авылында мөәзин булган. Фамилиясе Есинеев. «Ул вакытта чукынырга теләмәгән татарларга тоз сатмаганнар. Шуннан соң бу мөәзин авылдан 12 мужикны ияртеп Учалыга киткән, 12 подвода белән. Ярар, болар тоз төяп кайтып барганда, бер поселокта камап ала боларны жандармерия. – "Сез татарлар бит?!" – "Ие!" – "Контрабанда белән заниматься итәсез, хәзер акт төзибез!" Мужиклар бик куркуга төшәләр. Мөәзинне сөйләшергә җибәрәләр. Мөәзин жандармнарга ялына башлый. "А вот что, милый человек, принимайте христианскую религию, – диләр аңа, – акт та төземәбез, тоз да үзегезгә булыр". Мөәзин хитриться итергә кели. Мужикларга бара да әйтә: менә шулай-шулай дип әйтәләр, алдалыйк боларны. Тыштан риза булган кебек торыгыз, ә эчтән һәрвакыт "Алла, Алла" диегез. Чукынган булырбыз да, бетәр. Авыл ерак, берәү дә белмәс. Чукыналар поп янына барып. И кайталар болар, шатлана-шатлана. Алдаладык урысларны, дип. Ул арада алар кайтып җиткәнче әллә кайчан хәбәр итеп куйганнар икән: "Менә андый-андый авылның могометаннары рус религиясен кабул иттеләр, чиркәүгә йөрергә заставить итегез", – дип. Боларны урядниклар, полицейскилар көтеп тора икән. Халыкка да беленә бит инде. Халык күтәрелеп килә боларга: кем сәнәк тоткан, кем гер тоткан. Мужиклар безгә "мөәзин кушты" диләр. Шуннан мөәзинне яндырмага килиләр, урядниклар гына аерып кала. Бу әлеге мужиклар Пүчинкәдә калырга куркалар, 3 чакрымдагы Сидоровка исемле рус авылына күчәләр. Сидоровкада хәзер руслар белән бергә Есинеев фамилияле бисермәннәр, ә Пүчинкәдә Есинеев фамилияле татарлар бар».

***13 август, 1956 ел.*** Тегермән авылы, Юкамен районы. Бүген иртүк Глазовка китәргә тиеш идек, ләкин көн бик ямьсез, яңгыр ява. Һава ачылу белән немедленно юлга! Хәзергә, тик утырганчы, ак дәфтәргә җырлар күчерә торырга кирәк. Яңгыр түгел, таш яуса да, өйләдән соң китәбез.

Обедтан соң ат белән Олы Палагай авылына килдек. Юл шундый пычрак. Алгы ике тәгәрмәч балчыкны пулемет күк сиптереп кенә тора. Авылга килеп җиткәнче сап-сары саз булып беттек. Ярый әле плащлар яхшы!

Палагайда Юкаменск – Глазов маршрутында йөрүче таксига утырып Глазовка киттек. Ул таксидагы халык – энә төртер урын

юк. Бераз баргач, машинаның бензины бетте. Юл тау астына иде, бер-ике егет, төшеп, таксины бераз этеп бардык. Шул ходка ул 200–300 метрлар барды. Аннан соң бер мотоциклисттан ике банка бензин алып, юлны дәвам иттек. Ул бензин бетүгә бер машина очрады. Инде эшләр рәтләнде, дип кенә торганда, машина тагын туктады. Алда күпер, ә күпернең бер башы җимерелеп төшкән икән. Ул җимерелгән урынга такталар тезеп, мең бәла белән машинаны чыгардык.

Ниһаять, без Глазовта, гостиницада. Ишек төбендә бер абый белән бер апа тора. Тукта, тукта! Ир кешенең өстендә безнең академия плащы бит!.. Әйе, болар Хәмит абый белән  Халидә апа булып чыкты. Алар әле яңа гына Нократтан килеп төшкәннәр.

Гостиницада урнаштык. Хәмит абый обстановканы бераз аңлый башлады. Ул башта безне күргәч, бик аптырап, ризасызланып киткән иде.

Кич белән соң гына шәһәрне карап йөрдек. Ресторанга кереп чыктык... һәм кайтып йокладык.

***14 август, 1956 ел.*** Глазов. Иртән торгач парикмахерская һәм ашханәдә булдык. Аннан Халидә апа белән Шәех бер җырчы апага, без Хәмит абый белән райисполкомга киттек.

Райисполком председателе – Ворончихин.

Секретарь – Миронов Василий Петрович.

Райисполкомда секретарь белән озак кына сөйләшеп утырдык. Глазов аша тимер юл өчен, как будто, Глазов һәм Малмыж купецлары арасында бәхәс булган: тимер юл кайдан үтәргә тиеш? Глазов ашамы, әллә Малмыж ашамы? Глазов купецлары җиңеп чыккан.

Маршрутный листка печать бастырдым. Ләкин бүген Тат. Парҗыга китеп булмас.

Без хәзер гостиницада, үзебезнең бүлмәдә (№ 8). Хәмит абый һәм Шәех йоклый. Әле генә магнитофон эзләп радиоузелга звонить иттем. Хәзер шул ук мәсьәлә буенча Дворец культуры белән сөйләшәм.

Кич белән Зәки Дәүләт дигән кешеләргә барып кайттык.

***15 август, 1956 ел.*** Глазов. Гостиница. Кичә райисполком секретаре Миронов машина вәгъдә иткән иде, нигәдер, килми әле. Көтәкөтә ялыгып беттек. Хәмит абый мондый бер такмак та чыгарып куйды:

«Әнә килә автомобиль,  
Төягәннәр ак каеш.

Бу Миронның машинасы
Килми бит, понимаешь».

Бу машина, чыннан да, килмәде, дөресрәге ул килергә тиеш иде, без көтеп тормадык. Таксига утырып, Татар Парҗысы авылына килдек. Район үзәгеннән 18 км. Авыл матур гына. Квартирга Хәтимәләргә кердек. «Первомай» колхозы Татар Парҗысы, Кече Парҗы һәм Удмурт Парҗысы авылларын берләштерә.

Авыл советы председателе – Касыймов Муллаҗан Ибраһимович.

Колхоз председателе – Касыймов Фәттәхетдин Сәлахетдинович.

Библиотека мөдире – Лошкина Люд-мила.

Җидееллык мәктәп директоры – Ушаков Анатолий Петрович.

Рәхимов Нургаяз Харисович – татар теле-әдәбияты укыта.

Завклуб – Касыймов Зәки Сафа улы.

Авылда 65 йорт. Медпунктта 2 кеше эшли.

Кече Парҗы авылы; 46 йорт.

Касыймов Сәгыйть Хисмәтович – истәлекләр.

Касыймов Кәлимулла Гобаевич – авыл тарихы.

Касыймова Әдия Әхмәтовна, бәет.



*«Балык, кап, кап! Яр башында ялтырап ят!»*
*Уңнан:* Х. Мәхмүтов, Х. Ярми, Х. Гатина. Балезино районы, Татар Парҗысы авылы тирәсе

***16 август, 1956 ел.*** Татар Парҗысы авылы. Бүген иртән торгач, күрше авылга – Кече Парҗыга бардык. Сәгыйть абый да, Кәлимулла абый да калага «барган». Кәлимулла абыйның кызлары өйдә иде. Наҗия һәм Нәсимә – игезәк кызлар. 1929 елда туганнар. Наҗия Глазовта, кияүгә чыккан.

Алардан 15 ләп җыр яздым.

***17 август, 1956 ел.*** Татар Парҗысы. Бүген иртәрәк тордык. Автомашина белән Глазовка кайттык. Райисполкомга кереп чыктык һәм такси белән Балезино районының Кистем авылына килдек.

Кистем авылы, Киров исемендәге миллионер колхоз, Балезинодан 7 км.

Колхозда 4 кырчылык һәм 1 терлекчелек бригадасы бар.

230 хуҗалык, җидееллык мәктәп, балалар йорты, больница (медпункт), клуб, библиотека.

Җитәкчелек: авыл советы председателе – Касыймов Шәрәфетдин, колхоз председателе – Касыймов Вәлиулла. Мәктәп директоры – Касыймов Насыйбулла.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы – Тимербулатова Суфия.

Библиотекага кергәч, күңелгә рәхәт булып китте: Стенада М. Гафури, Ш. Камал, Г. Камал, К. Насыйри, Һ. Такташ портретлары эленеп тора.

Библиотекада 812 татарча китап бар.

Без керү белән клубка яшьләр кереп тулды. Чиста киенгән чибәр-чибәр егетләр, кызлар. Бик ачык, үткен күренәләр.

Клуб мөдире Әминә Касыймовага үзебезнең максатны аңлатам. Яшьләр «Ялантау кешеләре»нең икенче китабын бик көтәләр. Берсе Хәмит абыйдан сорап та куйды:

– Ә шулай да белмисезме, Камил җиңеп кайтамы анда?

Библиотекага «Совет Татарстаны», «Татарстан яшьләре», «Совет әдәбияты», «Чаян» һәм «Агитатор блокноты» килә. Яшьләр татар китапларын бик яратып укыйлар. Мин Әминәгә библиотека укучыларыннан берәрсенең карточкасын бирүен сорадым. Ул сайламыйча гына 2 карточканы (формулярны. – *Ред.*) алып бирде:

1) **Касыймова** Мәрзия Газыймовна, 7 кл. белемле. Менә аның быел укыган китаплары:

1. К. Нәҗми – «Весенние ветры».
2. Ш. Камал – «Сайланма әсәрләр».
3. Г. Камал – «Сайланма әсәрләр».
4. «Үсү юлы» – 8 нче китап.
5. Г. Гобәй – «Замана балалары».
6. М. Әмир – «Ялантау кешеләре».
7. Р. Саттаров – «Яшьлек дәрте».
8. М. Әмир – «Сайланма әсәрләр».
9. К. Нәҗми – «Якты сукмак».
10. М. Гафури – «Кара йөзләр».
11. Н. Исәнбәт – «Хуҗа Насретдин».

2) **Касыймов** Нурулла Мәүлүтович, VII класста укый. Ул укып чыккан китаплар:

1. К. Нәҗми – «Язгы җилләр».

2. П. Неруда – «Уянсын икән урман кисүче».
3. «Кызым, сиңа әйтәм» (*«“Чаян” көтепханәсе»*).
4. М. Бубеннов – «Ак каен».
5. М. Әмир – «Ялантау кешеләре».
6. Г. Хуҗи – «Идел хикәясе».
7. Г. Бәширов – «Безнең заман».

Кич белән клубка чыктык. Күп кенә кызлар җыелган иде, аларны изба-читальняга чакырып бик күп җырлар яздык. Биредә кызлар (Зөләйха, Мәдинә, Фатыйма һ. б.) бик акыллы, культуралы күренә. Зөләйхадан бер дигән артистка чыгар иде.

***18 август, 1956 ел.*** Бүген председатель, «Победа»сы белән, Балезинога алып барды. Райисполкомга һәм райкомга кереп чыктык. Тиз генә кибетләргә барып килдем. Аннан авылга кайттык. Авыл советы председателе белән таныштык. Хәзер сәгать 12 тула. Библиотекага барып, бераз эшләп кайтырга кирәк.

1. Касыймов Равил Лотфуллович, 1931 елгы (җырлый да, гармунчы да).
2. Касыймов Муллаҗан Мөхәммәтҗанович (оста уйнаса кирәк).
3. Касыймов Азат Зәйнуллович, гармунчы.
1. Ситдыйкова Галия Зиннәтулловна, җырчы, детдомда тәрбияче.
2. Касыймов Нотфулла Хафизович, 1929 елгы, скрипач.
3. Касыймов Газимҗан.

Бүген кич клубта булдык. Зур якта – танец, уку залында репетиция бара. Авыл яшьләре А. Фәттәхованың «Далада» исемле пьесасын куярга әзерләнә. Китап артыннан барганда сөйләшүләрендә бернинди кытыршылык сизелми. Димәк, әдәбият күбрәк укыганда яшьләр чиста гына сөйләшә алалар.

Көндез кайбер «маҗаралар» булып алды. Өйдә кандала күп, йоклап булмый. Монда әле иске нәрсәләр куелган тагын бер бүлмә бар. Квартир апасы Гөлҗиһаннан бу бүлмәне юдырттык. Ул моңа риза ук түгел, әйберләрен кымшатасы килмичә «мыжлап» (Хәмит абый термины) йөрмәсенме! Бүлмәнең уртасында ук Нух пәйгамбәр заманыннан калган тәрәзәләр тора. Мин, Хәмит абый һәм Шәех шул тәрәзәләрне почмакка күчереп азапланганда Шәех аягы белән ялгыш бер шешәне аударды. Моны кухня ягында йокымсырап ятучы Гөлҗиһан ишеткән. Менә ул килеп керде бервакыт. Керде дә, Хәмит абый белән Шәехне эткәли, тәрәзәләрне үзе күчерә башлады. «Кергән чакта «борчымабыз» дигән идегез, аптыратып бетердегез

инде», – дип «мыжлый». Аннан кызып китте Хәмит абый... Шул чакта, ярый әле, ат белән салам китерделәр. Аны бүлмәгә ташыдык. Урыннарны бик әйбәтләп җәйдек. Кандалалар безнең бу «бөек күченеш»не сизми калдылар. Төнлә тыныч йокладык.

***19 август, 1956 ел.*** Бүген иртә белән мәктәпкә барып утырдык. 45 җыр күчердем. Бөтен көн җыр язу белән үтте, беркая да бармадым. Бертуктаусыз яңгыр ява. Кич белән клубка да чыгып булмады.

Бу көннәрдә колакка чалынган тел үзенчәлекләре:

– Яшь-үлән халык – яшьләр.

– Шелеп – йомычка.

– Тавыш итәсез – тавышланасыз.

– Алла, күп әйттем шәй?

– Ярар эчкә – ярый, ярар.

– Оныткаладым – онытгым.

«Өй» дифтонгы урынына «и» килә (*силәгән идем*).

– И куйдык – өй күтәрдек.

– Пьеса салдык – пьеса куйдык, уйнадык.

– Беттеге – бөтенесе.

– Мин дә мәкән әллә берне яздырып калдырыйм? (*җыр турында*)

– Ничек үрәндек, алай булды.

***20 август, 1956 ел.*** Кистем. Бүген көн бераз матурланырга исәпләп тора. Күк йөзен, тоташтан дип әйтерлек, болыт капласа да, атналар буе җир йөзен күрә алмыйча тилмергән кояш болытлар арасындагы ертыклыктан җиргә карап елмая. Дөрес, аяк асты бик пычрак. Без Шәех белән урам аша үткәндә сазга чумып беттек. Хәзер мәктәпкә килдек. Укытучылар бар да җыелган иде, инде алар таралыштылар дияргә була. «Учительская»да утырып бераз эшләп алырга кирәк.

Байтак җырлар күчердем. Исәп-хисапларны бераз тәртипкә китердем.

Хәмит абый берсекөнгә Молотовка[1] китәргә тиеш, ә без Падера, Биктәш, Әхмәди авылларында булачакбыз. Алда 7 эш көне бар әле. 28 августта Казанга кайтырга чыгабыз.

Быел экспедиция артык күңелле булмады. Сәбәбе – көннәр ямьсез, материал аз очрый. Казанга кайтасы килә.

[1] Молотов – Пермь шәһәренең ул вакыттагы исеме.

Өйләдән соң фатир хуҗасы Гөлҗиһан ападан җырлар яздым. Бу хатын үзе, беркатлырак күренсә дә, бик күп җырлар белә икән. Арада гаҗәп яхшылары бар.

***21 август, 1956 ел.*** Бүген, иртән торгач, правлениега барып Хәмит абыйның лекция укыячагы турында белдерү яздырдым һәм сельпо председателеннән шикәргә язу алып кайттым.

Аннан Шәех белән Уръякала (Гордино) авылына барып кайттык.

Чыпца елгасы бик матур. Киңлеге 15–20 метрлар. Ә тирәнлеге – 3–5 метр чамасы, диләр. Безне агач аяклы паромщик көймә белән икенче якка чыгарып куйды. Көн матур гына булуга да карамастан, аяк асты бик былчырак. Мең бәла белән конторага (үзләре «теплушка» диләр) килеп җиттек.



*Ямьле Чыпца буйлары.*
Шәех Зәбиров *(уңда)* һәм Х. Мәхмүтов

Уръякала авылы «Коммунар» колхозына керә икән. Правление 3 чакрымдагы Подгорная дигән авылда. Председателе – Русских Веньямин Анисимович. Бу авылда колхоз председателе урынбасары – Тютин Габдулла Камалетдинович.

Авылда 96 йорт. 60 лабында – татарлар, калганында – удмурт һәм бисерманнәр яши. Башлангыч мәктәп (татар телендә) эшли.

Безгә кирәкле кешеләр юк бугай. Ике картны әйттеләр әйтүен:

1. Тютин Гыйльметдин Галләмович, 70 яшендә .

2. Гафуров Сафиулла. Хәмит абыйның Мулла пи (малае) Сапи дип исе китә торган кешесе. Ул кеше Мулла пи генә түгел, элек үзе дә мулла булган ахры.

Авыл халкы бар да эштә. Без Гыйльметдин бабайларга килгән идек, ул өйдә юк. Хәзер бакча башындагы чирәмлектә аны көтеп ятабыз. Мин көндәлек язам, Шәех йоклый.

Бабайга тагын бер кереп чыгабыз да, өйдә булмаса, юл өстендә теге мулла пигә сугылып, Кистемгә кайтып китәбез. Тор, Шәех!

Кистемгә кайттык. Кич белән Хәмит абый «Герой-шагыйрь Муса Җәлил» дигән темага лекция укыды.

***22 август, 1956 ел.*** Бүген иртән сәг. 5 тә торып конторага бардым. Документларны рәтләдем, ат белештем. Бүген Хәмит абый Молотовка китә. Халидә апа минем отрядка күчә.

Шәех белән бергә (икебез генә) 238 км юл үттек.

Көндез сәг. 12 дә ат белән юлга чыгып киттек. Балезинога барып җиткәнче көн бик матур торды. Берничә мәртәбә туктап фотога төштек.

Хәмит абый Балезинода төшеп калды. Станцияне чыгып кына җиткән идек, яңгыр яварга тотынды. Без барабыз, безнең өстән болыт бара. Коя гына инде; сәгать ярымнар шул яңгыр астында бардык.

Падера авылына килдек. Колхоз идарәсенә тукталдык.

Кистемнән безне бик яхшы айгыр җигеп китерделәр, бөтен халыкның күзе шунда.

– Бу үзегезнең атмы? – дип сорыйлар. Бер-икесенә «үзебезнеке» дип тә ычкындырдым.

«О-о-о!», – диләр.

Квартирга контора янына гына урнаштык. Семья составы: Фариза апа, кызы Фатыйма, киленнәре Фәридә, Фәридәнең кызчыгы Әлфия. Квартир чиста, иркен, җылы.

Без урнашып бераз торгач, Халидә апа кайтып җитте. Ул Балезинода Хәмит абыйны озата калган иде.

Фатыйма бик җитез кыз булып чыкты. Әллә кай арада әллә кемнәрдән җыр дәфтәрләре табып кайткан. Очып йөри диярсең. Үз исеме кергән җырдагы шикелле:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Фатыйма;
Бир сәнә, кош, канатыңны,
Бер әйләнеп кайтыйм ла!

Фатыйманың мондый ихласлыгына күңеле булган Шәех аны һәм иптәш кызын татарча киемнәрдән фотога да төшерде.

Кичтән яңгыр яуды. Клубка чыгып йөрмәдек, бераз җырлар күчереп утырдык та, йокладык.

***23 август, 1956 ел.*** Иртән торгач, җырлар күчердек. Төштән соң мәктәпкә



Фатыйма *(уңда)* иптәш кызы белән

барып эшләдек. Нигәдер, бу арада көндәлек язасы килмәде.

***25 август, 1956 ел.*** Кичә кичтән ятканга, бик иртә уяндым. Правлениегә кергән идем, әле председатель килмәгән. Анда бераз утырдым да өйгә чыктым. Председатель килгәч, мине чакыртырга булдылар.

Падера авылы, «Первое мая» колхозы.

120 хуҗалык.



Чигү чигә, челтәр бәйли Падера гүзәлләре,
Тиздән алар егетләрнең үзеген өзәр әле

Җидееллык мәктәп. Директор – Касыймов Ибраһим Лотфулла улы. Завклуб – Насыйпов Габделбәр Ишморат улы.

Файзуллин Лотфулла Исмәгыйлович, карт.

Инсентеев Ахунҗан – колхозда бухгалтер.

Касыймов Зиннәтулла – колхоз председателе.

Әхмәди авылына килдек. Ат белән Локман абый китерде. «Йолдыз» колхозы, 64 хуҗалык. Башлангыч мәктәп.

Травмпункт. Клуб (Касыймов Абдрахман).

Колхоз председателе – Фәйзуллина Нәҗибә Лотфулловна.

Бухгалтер (партоешма секретаре) – Касыймов Ахунҗан Шаһбанович.

Сөйләшәсе кешеләр:

1. Касыймов Ярулла
2. Касыймов Габдулла
3. Тютин Нәҗметдин.

***27 август, 1956.*** Бүген Әхмәдидә соңгы көн. Юлга әзерләнәбез. Бөтен киемнәрне юып-чистартып, рюкзакларны тәртипкә китереп куйдык. Колхоз белән исәп-хисапларны рәтләдем.

***28 август, 1956 ел.*** Бүген колхоз машинасы икмәк төяп Балезинога бара икән – аның белән сәгать 8 гә район үзәгенә килдек.

Без хәзер станциядә – вокзалның көтү бүлмәсендә утырабыз. Шәех белән яңа гына ашханәгә барып килдек. Ул, әнә, диванда чырайларын сытып бик кәефсез генә утыра. Поезд килергә әле 7 сәгать вакыт бар шул! Әгәр билетлар ала алсам, минем, отряд җитәкчесе буларак, вазыйфаларым бетә.

Мең бәла белән плацкарт вагонга 3 билет алдым! Халык бик күп иде – командировкада йөрүчеләре дә байтак. Милиционер: «Командировочные, в живую очередь!» – дип, безнең халыкны кыса башлагач, начальник станции янына кердем. Ул удостоверение читенә резолюция салды. Аннан инде милиционер белән исәпләшеп тормадым. Бик күп энергия салып булса да, кассага үттем һәм билетлар алдым.

Вагонда чып-чыннан да кыямәт иде. Ике урынны безгә кадәр кереп өлгергән кешеләрдән бушаттырдык, әмма Шәех урынына бик усал хатын менеп яткан. Баласы бар каһәрнең! Төшми – и шабаш. Шуннан Шәехне үз урыныма яткырдым да, рус әйтмешли, бодрствовать итә башладым. Утырырга урын юк, аяк өсте барам...

Бер өч сәгать шулай азаплангач, Шәехне уятам: Давай, – мин әйтәм, – тор. Берәр сәгатьтән берничә плацкарт бушый, үзеңә урын алып кал, – дим. Аннан урынга менеп ятам һәм йоклыйм.

Иртә белән вагон бераз бушаган иде. Шәех тә урнашкан. Алар Халидә апа белән әле йоклыйлар. Кайтабыз. Казан һаман якынлаша.

Җай гына селкенә вагон,  
Шаулап бара тәгәрмәчләр.  
Станцаларда сатыла  
Сөт, йомырка, пәрәмәчләр.


Пассажирлар бар да үзләренең төп җимәре белән мәшгульләр: ашыйлар да гайбәт саталар, гайбәт саталар да ашыйлар.
Юлда күргәннәрнең барсын да язып булмый инде. Рәхәтен дә кыенлыгын да күрә-күрә 29-августта, көндезге сәгать 1дә Казанга кайтып җиттебез. 35 көнлек поход тәмам!

## ТАРИХЫН ҮЗЕБЕЗ ЯЗАБЫЗ, КИЛӘЧӘГЕН ҮЗЕБЕЗ ТӨЗИБЕЗ

*Удмуртия Республикасында яшәүче милләттәшләребезнең үткәне һәм бүгенге проблемалары турындагы язмаларны Ижауда чыга торган «Яңарыш» газетасы да даими биреп барырга омтыла. Форсаттан файдаланып, шул газетадан да берничә авторның язмасын тәкъдим итәбез. Аларны Ижау шәһәрендәге Татар иҗтимагый үзәге идарәсе әгъзасы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Вәсилә ханым Хәкимова туплап җибәрде.*

Удмуртия Республикасында яшәүче милләтләр арасында татарлар сан ягыннан өченче урынны тәшкил итә. Бүгенге көндә Республикада 100 меңгә якын татар яши, дип исәпләнсә, шуның 70 меңе Ижауда гомер итә.

Күп гасырлар элек Ижау шәһәре урнашкан жирләр Алтын Урданыкы булган, аннары – Казан ханлыгына кергән. Аннан соң хәзерге Удмуртия җирләре барысы да татар морзасы Яушев кул астында була. 1720 елларда Яушевлар бу җирләрне Россиянең дәүләт эшчесе генерал-майор Тәвкилевка саталар.

1760 елда Ижауда тимер кою заводы, ә 1807 елда корал заводы да төзелә. Татарлар, башка халыклар белән беррәттән, Иж заводына нигез салуда, аның үсешенә, Ижауның шәһәр буларак төзелүенә дә бик зур өлеш керткәннәр. Алар арасында табиблар, корал осталары, сәүдәгәрләр, эшмәкәрләр дә булганы билгеле. Завод эшләренә халыкны, хәрби хезмәткә җибәргән сыман, мәҗбүри алганнар, татарлар иң күбе Әгерҗе, Иж-Бубый, Иж-Бәйки авылларыннан килгәннәр. Иж заводы хәрби гарнизонының иң беренче табибы да Габделкафи исемле татар кешесе булган. Корал заводы эшчеләре арасындагы Габдиковлар нәселе әнә шул исемгә бәйле. Бу нәсел башлануга инде 200 елдан артык.

Ижауда татарларны аек һәм намуслы эшчеләр булганнары өчен хөрмәт иткәннәр. Татар эшчеләре авырлыктан курыкмаганнар, кайда көч, чыдамлылык кирәк – шул эшкә барып тотынганнар, тырышлыклары белән дан тотканнар. Тимер заводының да, корал заводының да төрле цехларында эшләгәннәр, аларның күпләре кафтанчы исеменә лаек булган. Бу исем Иж корал заводында иң югары бәя булып саналган. Бәширов дигән эшче, мәсәлән, революциягә кадәр – кафтанчы, Советлар вакытында шул ук корал заводында Хезмәт Герое исемен яулый. Заводта эшләүче татарлар йодрык сугышларында (*кулачные бои*) иң көчлеләрдән саналганнар. Колчакның Ижау дивизиясендә мөселман батальоны оештырганнар.

XVII гасырда татарларга Ижауның иң начар, бернинди дә уңайлыклары булмаган, язын һәм көзен су баса торган сазлыклы жирләрендә генә яшәргә рөхсәт ителгән. Бик тиз арада татарлар бу сазлы җирләрне экзотик әкияткә әверелдерә торган булганнар. Ижауда татарлар, беренчеләрдән булып, яшелчә үстерә башлыйлар, җиләк-җимеш, татлы ашамлык кибетләре ачалар, ә йортларын агачтан сырлап эшләнгән, буялган бизәкләр белән матурлый беләләр. Тышкы бизәкләрдә европалылар күзенә ят булган яшел һәм зәңгәр төсләргә өстенлек бирәләр, алар арасына аз күләмдә сары, ак һәм кызыл төсләрне кушып җибәргәннәр. Татар мәктәпләре салу, аларны китаплар, дәреслекләр белән тәэмин итү, укытучыларга эш хакын түләүне дә Ижаудагы татар эшмәкәрләре тулысынча үз өсләренә алганнар. Ижауда татар бистәсен, зират урынында тимер кою заводының яңа цехларын төзүдә дә татарлар актив эшлиләр. Мәчет салып куялар, беркадәр вакыттан соң аны сүтеп, икенче урынга күчереп төзиләр.

Халык исәбен алу нәтиҗәсе буенча, Ижауда, 1887 елда 570 татар яшәгән. Туган якны өйрәнүче Гата ага Кутузов (1907–1997) гомере буена Ижау татарларының тарихын өйрәнгән. Аның гаҗәеп зур эше – Иж заводының, татар бистәсенең 1917 елга кадәр булган карта-схемасы. Бу карта-схемада татар бистәсенең бөтен урамнары, һәрбер йорты, һәр йорт хуҗасының исеме, ул йортта яшәгән кешеләрнең нинди эш белән шөгыльләнгәннәрен аңлаткан билге тора: чүкеч билгесе икән – димәк, бу йорт хуҗасы корыч кою заводында эшләгән, бизмән-үлчәү булса – сатучы икәнлеген аңлаткан, икмәк – ипи пешерүче, ат башы рәсеме – ат сатучы, фотоаппарат – фотограф һ. б. Бу карта-схеманы төзү өчен Гата ага хәзерге татар

бистәсен күп еллар дәвамында өйрәнгән, бик күп кешеләр белән очрашып, җентекләп материал туплаган. Моннан тыш, Гата ага революциягә кадәрге Ижауда яшәгән татарларның иң танылганнарының (Габдиков, Бәширов, Гатиятуллин, Фәйзуллин, Кәримов, Ханов кебекләрнең) шәҗәрәләрен (утызга якын) төзегән.

*Резедә Әхмәтвәлиева,*
*УР Кузебай Герд исемендәге*
*Милли музейның фәнни хезмәткәре*

* * *

1970 елларның уртасына кадәр – **Зур һәм Кече Палагай** авыллары булган. Хәзер дә еш кына Зур Палагайда яшәүчеләр кечесен «Аръяк Палагай» диләр. Дөрестән дә, бу ике авыл әле дә булса үз урыннарында утыра, тик документлар буенча алар бер авыл – Палагай, дип язылалар. Палагай авылын һәм Юкәмен төбәгендә урнашкан авылларның күпчелеген нигезләүчеләр, галимнәр язуы буенча, «бисермән» исеме белән аталган төрки яки удмурт телле этник төркем (таифә) булган. XVII–XVIII гасырларда Чүпче (Чыпца) елгасы буенда яшәгән бисермәннәрне, арларны (алар барысы да ул вакытта мәҗүсилектә булганнар) һәм татарларны чукындыру башланган. Чукындырылган бисермәннәр ар теленә күчәргә мәҗбүр булганнар: чукындырылмаганнары үзләрен «татар» дип атаганнар. Соңгыларының авылларында мәчетләр төзелгән. Мәсәлән, архив документлары буенча Палагайда 1797 елда мәчет булганы мәгълүм.

Рус галиме П. Н. Лупповның «Документы по истории Удмуртии XV–XVII вв. – Ижевск. 1958» китабында Чүпче (Чыпца) удмуртлары, татарлары, чувашлары (бисермәннәре) арасында 1615, 1629, 1646, 1662 һәм 1678 елларда үткәрелгән халык исәбен алу мәгълүматлары бирелгән.

Убыть елгасы буена беренче күченүләр 1646 елда булган (док. № 59, 240 бит). Хәзерге Глазов төбәгендә Югары, Урта, Түбән Убыть авыллары булган, Югары һәм Урта Убыть авыллары бүгенге көнгә кадәр сакланып калганнар. Хәзер алар ар телле авыллар. Шул ук документларда «Убыть елгасында ике буш хуҗалык Ивановскаяда, бер буш хуҗалык Кунасевскаяда язылган, һәм шушы хужалар, 17 ел элек, каралтыларын ташлап, Казан өязенә киткәннәр». (Бәлкем, шул авылларда торучы гаиләләр татар телле кешеләр булгандыр, югыйсә алар Казан өязенә китәргә мәҗбүр булмаслар иде).

60 нчы документта («Приставные дворы в Каринской и Верхочепецкой волости у удмуртов и бесермян по переписи ... 1662 г.». Луппов П. Н. 1958. – 251 бит) Убытьтан югарырак яңа пүчинкә күрсәтелгән.

П. Н. Луппов бу документның искәрмәсендә, «өстәп куелган» хуҗалыкларны (приставные дворы), искесеннән аерылып чыгып, шул ук авылда яңа үзләштерелгән җирдә салынган (на выселках, починках) крестьян хуҗалыклары, дип аңлата.

1678 елны (16 елдан соң) күчереп язучылар Михаил Воейков һәм Федор Прокофьев Убыть елгасы буенда Җанбулатко Бекбулат улы Бединов хуҗалыгын күрсәтәләр (док. № 61, 288 бит). Аның оныклары – Абаш балалары (Абашевы дети) «Ешмеметко, Ермеметко өйләнгәннәр, Зямаметкога 20 яшь; Дахтубайко Тубач улына 15, Бегенкога 13, Шахмаметкога 10 яшь», диелгән.

Мөгаен, бу пүчинкә Бединовныкы булган (беренче хисапта Бедаков дип язылган булса да, бу бер үк кеше булырга тиеш, чөнки күчереп язучылар исемнәрне ишетелгәнчә генә язганнар).

Шулай ук Бединов гаиләсенең яшәү урыннары да алышынган булса кирәк. Ике язманы чагыштырганда, 1678 елда Абашко һәм Тюбачко күренмиләр, балалары гына эләккән. Күрәсең, Бединов үз урынын ике мәртәбә алыштыра: бер улы үлгәч – бер мәртәбә, тагын бер мәртәбә икенче улы вафат булгач.

Ә 1678 елны Убыть елгасының 3–4 чакрым югары юнәлешендә Тутаев пүчинкәсе үсеп чыга, андагы 5 хуҗалыкта 22 ир-ат яшәве язылган була.

Өлкәннәр сөйләвенчә, Палагай авылының беренче урыны «Алабаш» аймагында (аймак = урочище) булган. Соңыннан, Нарат чишмәсеннән югарырак урманны чистарткач, Җанбулат үзенең пүчинкәсен шунда күчерә. Аның тегермән буасы әле дә сакланган. Әле 1940 елларның азагында картлар безгә, анда бер пар ташлы тегермән булган, дип сөйлиләр иде. Шуның янындагы нарат урманы үскән тауны бүген дә «Җанбулат тавы» дип йөртәләр.

Каюм Габид улы Абашевның (1865–1949) оныгы Мәлик Садретдин улы, Нарат чишмә белән Җанбулат тау арасында үскән нарат урманының югары башында татар зираты бар, дип сөйләде, ул аймакны аңар Каюм бабае күрсәтеп калдырган. Димәк, ул Бединовның икенче пүчинкә урыны булган. Ләкин Җанбулат үзенең гаиләсе белән, нигәдер, башка урынга күчәргә мәҗбүр булган. Бәлкем, На-

рат чишмә суын борынгы кешеләр «начар су» дип санаганнардыр, чөнки авылдашларым Нарат чишмә суын хәзер дә бик эчмиләр. Бу суны эчсәң, чиргә сабышасың, дип куркалар.

Җанбулатның яңа авыл урыны «Поршай» аймагына якын урнашкан булган.

Риваятьләр буенча, Поршай аймагында чишмә суы азайгач, авылдашлар Убыть елгасының сул ягында бик көчле чишмә янында яңа урын табалар. Бу яңа авылны нигезләүче Палаг (Малаг дип тә әйтәләр) исемле бер чибәр һәм кыю, ай йөзле кыз булган, диләр. Һәм яңа авылны шул кыз исеме белән «Палагай» дип атаганнар имеш...

Палагайның төп халкының күбесе Абашевлар (1811 елгы хисап алулар буенча Палагай булачак урында бер гаилә Касыймовлар да яшәгән булган, авылда аларның токымнары бар). Димәк, Палаг шушы авылга нигез салучы Абашевларның бер баласы булырга тиеш. 1794 елгы архив документында шундый юллар бар: «Губайдулла Касимов из д. Кестымской (по состоянию на 23 июня 1794 года), у него жена Тутья Баязитова, дочь 22 лет, ...из деревни Палагинской». Димәк, 1794 елда ук пүчинкәнең исемен «Палагинская» дип язганнар. (Бу мәгълүматлар Глазов udинституты доценты Д. Г. Касыймовадан алынган).

Удмурт галимнәренең фикере буенча бисерманнәр ар телле төркем булганнар (Атаманов. 1988, с. 17–18). Ә татар галимнәре бисерманнәрне «татар-төрек телле таифә» дип саныйлар. Удмурт галимнәренең фикерен дөрес дип алсак, Палагай авылының исеме (этнотопонимы) менә болай килеп чыккан дип әйтергә була: бу топонимны икегә бүлик: беренче өлеше «Пал» – удмуртча берничә мәгънә аңлата, берсе – «як» (сторона) дигән сүзне яисә нәрсәнең булса да яртысын («палкышно» – тол хатын, «палпиосмурт» – тол ир кеше) белдерә. Икенче яртысы – «агай», «абый = абзый», ягъни өлкән туган мәгънәсендә. Кыска гына бер хикәяткә игътибар итик: Замаметко Абаш улы әле генә ерак юллардан кайтып, Ермеметко абыеннан Тубач улы Дахтубайко абзые турында кызыксына. Зямаметко ар телендә аңардан: «Починкае, пал агае доры мыниз» ... («Пүчинкәгә тол абзые янына ... китте»), дигән җавап ишетә. Вакытлар узгач, бу әңгәмәдә яңгыраган «Пал агай» сүзләре бергә кушылып, яңа пүчинкәнең исеме булып калуы да ихтимал.

Менә инде ике гасырдан артык минем туган авылым Палагай үз исемен (топонимын) югалтмый. Хәзерге заманда Палагайны «саф татар авылы» дип әйтүе кыенрак, чөнки бирегә бисермән, удмурт, рус, украин һәм башка милләтләр дә килеп төпләнеп яшиләр.

*Азат Галиев*

* * *

**Байсар** авылында 12 ел дәвамында «Каз канаты» ансамбле эшләп килгән. Өлкәннәр белән беррәттән, анда яшьләр, балалар да йөргән. Үзешчән артистлар үз чыгышлары белән Татарстан авылларына да чыга торган булганнар. Концертлар гына түгел, спектакльләр дә куйганнар алар. Әмма ул таркалган. Сәбәбе – яшьләрнең, эш эзләп, шәһәргә китүе. «Бүгенге көндә безнең авылда мәктәп яшендәге ике генә бала калды. Шулай да без бирешмибез. Кайчандыр ансамбльгә йөргән үзешчән артистларыбыз белән бәйрәм-кичәләр оештырабыз. Авылда күбрәк өлкән яшьтәгеләр яши. Максатыбыз – булдыра алган кадәр үз сәнгатебезне, мәдәниятебезне саклап калу», – ди Кыяс районының мәдәни үзәге рәисе Мәсхүдә Бәхтиева.

Халкыбыз тарихын барлау максатыннан өч ел элек клуб каршында музей эшли башлаган. Авыл халкы тарихны чагылдыручы төрле экспонатлар алып киләләр. Иң түрдә самавыр, үз заманындагы пластинкалары белән патефон, әбиләребез чорында кулланылган сандык тора. Шулай ук халкыбызның милли киемнәре дә музейга куелган. Мәсхүдә ханым палас туку станогында эшләп тә күрсәтте. Авылга беренче килеп төпләнгән гаилә, басудагы чәчү һәм урыпҗыю вакытларын сурәтләгән фоторәсемнәр тупланган альбом да кадерле бер тарихи эскпонат булып тора.

**Таужамал** – Кыяс районында бердәнбер мәчетле авыл. Изге йорт 2001 елны ачылган. Авылда ике йөзгә якын халык исәпләнә. Клуб мөдире Тәнзилә Илалетдинова: «Халыкબездә тату яши, йолаларыбызга тугры кала. Һәр бәйрәмне татар телендә уздырабыз. Концертларга кеше бик теләп йөри, яраталар, мактыйлар», – ди.

Бирегә шулай ук халкыбызның зур бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре сакланып килә. Байсар һәм Мүшек авыллары белән дә дуслыклары, элемтәләре нык икән. Корбан гаетен, Өлкәннәр көнен дә өч авыл халкы бергәләп уздырган. Мондый дуслыкка, әлбәттә, сокланмый мөмкин түгел.

*Эльвира Хужҗина*



قرداشلاری خدمتینه کلدا چیدور
یغلاق اولوشر مسادا اولدا چیدور
ندامتدا هم پشمان اولدا چیدور
یوسف خندان آنلار کریان اولور ایدی
اول وقت ساعت جبرائیل حاضر کلدی
هم سلام هم احوالی ظاهر قیلدی
یوسف احوال بلوبن شکر قیلدی
قضاسینه رضا داغی اولور ایدی

حضرت یوسف علیه السلام سند آغالاری ایولارینه قایتقانلاری

یوسفنینک قرداشلاری اوه دوندی
برسی بر اوغلاقنی دوتب بوغازلادی
قانن یوسف کوینککا کینه بولاشدوردی
جملالاری آغلاشوبن واردلار ایدی
یول اوزره بر قریه یغاچ اولور ایدی
یعقوب آنینک توبینه تورور ایدی
کوردی انکا کیسه دن براوی کلدی
دونکلادی سبعین دیور ایدی
یعقوب ایتور آه یتمشی کونکولی ایکان
وا ویلتا یوقه یتمشی آیمو ایکان
ای دریغ یوقه یتمشی بلمو ایکان
یوسفم نینک کیچکلاکی دیور ایدی
یعقوب واردی اول مقامندن آواره چک
یوسفنینک قتلنی بغرینه یاقار
یاری یعقوب یول اوستینه مدام بقار
یوسفنی کوررسام دیو بقار ایدی
کونکلی غمکین آغلاب اوه کردی
بایق اوغلانلاری اوزره کمان قیلدی
یوسف قصد قیلدقلارین بایق بلدی
تیمار قیلور نهار ایلچه آغلار ایدی
اوغلانلاری ایکی ایکی آنطلاشدیلار
اوه یقین کلوچک جوغلاشدیلار

Юкамен районы Пүчинкә авылында табылган Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы



Балезино районы Әхмәди авылында табылган фарсы телендәге «Хәмде бихәд» поэмасы

Юкамен районы Палагай авылында табылган Коръән китабы



Юкамен районы Пүчинкә авылында табылган фал ачу китабы



Юкамен районы Иманай авылында табылган Коръән китабы



СССР Фәннәр Академиясе Казан филиалы тел, әдәбият һәм
вакытында язып алган материаллар. Экспедиция җитәк
Отряд членнары: Х. Ярмухаметов, Х. Гарина. Экспедиция 19

| Кайсы пункттан килгән 2 | Кайсы пунктка килгән 3 | Колхоз исеме 4 | транспорт төре 5 | ике пункт арасы 6 | жанрлар: җыр 7 | халык көе 8 | сюжетлы җыр 9 | бәет 10 | табышмак, мәкаль 11 | [illegible] 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Глазов р-ны | Таг. Парҗи | Беренче май | маш. | 50 | – | 20 | – | – | – | – |
| –"– | –"– | –"– | " | | 30 | 7 | 1 | – | – | – |
| –"– | –"– | –"– | " | | 24 | – | 1 | 1 | – | – |
| Таг. Парҗи ав. | Кистем авылы Балезино р-ны | Киров исем. | " | 57 | 263 | – | – | – | – | – |
| –"– | –"– | –"– | " | + | – | – | – | – | 16 | – |
| –"– | –"– | –"– | " | – | 79 | – | – | – | – | – |
| –"– | –"– | –"– | " | – | 181 | – | – | – | – | – |
| –"– | –"– | –"– | " | – | – | – | 1 | – | – | – |
| –"– | –"– | –"– | " | – | 37 | – | – | – | – | – |
| Слободской р-ны ~~[illegible]~~ | Глазов шәһ. | – | поезд | – | 27 | – | – | – | – | – |
| – | Кистем авылы Балезино р-ны | Киров исеменд. | маш. | – | 114 | – | – | – | – | – |
| – | –"– | –"– | " | – | 13 | – | 1 | – | – | – |
| Кистем авылы | Падера авылы юнда а/с Балезино р-ны | „Беренче май" | ат | 17 | 116 | – | – | – | – | – |
| –"– | | " | – | – | 9 | – | – | – | – | – |
| –"– | –"– | " | – | – | 31 | – | – | – | – | – |
| –"– | –"– | " | – | – | 25 | – | – | – | – | – |
| Падера авылы | Эгмәдзи авылы, юнда а/с | „Елдыз" | ат | 15 | 117 | – | – | – | – | – |
| – | –"– | –"– | – | – | 9 | – | – | – | – | – |
| – | –"– | –"– | – | – | 44 | – | – | – | – | – |
| – | –"– | –"– | – | – | 93 | – | – | – | – | – |
| – | –"– | –"– | – | – | 3 | – | – | – | – | – |
| – | –"– | –"– | – | – | 44 | – | – | – | – | – |
| | | | | | 1606 | 27 | 11 | 4 | 27 | |

Экспедиция җитәкчесе
лаборант

...әбият һәм тарих институтының фольклор (татар) экспедициясе
...ның җитәкчесе филология фәннәре кандидаты Х. Ярмухаметов.
...дициясе 1956 елның 26 июленнән 29 августына кадәр булды.
Удмуртиянең Глазов, Балезино районнары

...т языка, литературы и истории ...занского филиала АН СССР ...укописный фонд ...народно-поэтического т-ва 58

| р л а р | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| бәет 10 | табышмак, мәкаль 11 | җыр 12 | авыл тарихы 13 | | Материалны яздырган кешенең фамилиясе, исеме, атасының исеме 14 | туган елы 15 | белеме 16 | партиялелеге 17 | профессиясе 18 | 19 |
| — | — | — | — | | Касимова Флюра | 1938 | 2 курс | ВЛКСМ | студент | |
| — | — | — | — | | Касимова Рәшидә | 1938 | пед. училища | ВЛКСМ | студент | |
| 1 | — | — | — | | Касимова Бибигайшә | 1904 | иске грамотлы | — | колхозчы | |
| — | — | — | — | | Касимова Асылбикә | 1932 | 7 кл. | ВЛКСМ | свинарка | |
| — | 16 | — | — | | Касимов Насибулла Кадырович | 1918 | югары | | мәктәп директоры | |
| — | — | — | — | | Касимова Саимә | 1933 | 7 кл. | ВЛКСМ | свинарка | |
| — | — | — | — | | Касимова Маһинур | 40 яшь | | — | колхозчы | |
| — | — | — | — | | Касимова Гөлҗиһан Шамс. | 1910 | 7 кл. | — | | авыл эшлә[illegible] |
| — | — | — | — | | Касимова Рәисә | 1934 | 7 кл. | ВЛКСМ | колхозда звеновод | |
| — | — | — | — | — | Касимова Мәдинә Лотфулла кызы | 1936 | III курс пед. ин-та | ВЛКСМ | студент | |
| 1 | — | — | — | — | Касимов Галәветдин Сабитович | 1896 | | — | колхозчы | |
| — | — | — | — | — | Касимова Фәрима Лотфулла кызы | 1938 | 7 кл. | ВЛКСМ | колхозчы | |
| — | — | — | — | — | Касимова Сания Габдулхаковна | 1937 | 10 кл. | ВЛКСМ | колхозчы | |
| — | — | — | — | — | төрле кешеләрдән | — | — | — | — | |
| — | — | — | — | — | Касимова Фәзизә | 1902 | н/гр. | — | колхозчы | |
| — | — | — | — | — | Тюрина Мәүлүдә Шакировна | 1928 | 4 кл. | — | колхозчы | |
| — | — | — | — | — | Касимова Мәүлүдә | 1928 | 4 кл. | — | —"— | |
| — | — | — | — | — | Касимова Нәвәл | 1900 | н/гр. | — | —"— | |
| — | — | — | — | — | Касимова Ләмига Сәлимгулловна | 1934 | 7 кл. | — | —"— | |
| — | — | — | — | — | Тюрина Хәтбениса Галимовна | 1919 | 4 кл. | КПСС | —"— | |
| — | — | — | — | — | Касимова Мөхтәрәмә | 1938 | 5 кл. | — | —"— | |
| 11 | 4 | 27 | | | | | | | | |

Ч. Х. Ярмухаметов Ч.

Гарина

①

СССР Фәннәр Академиясе, Казан Филиалының 1956 елгы татар фольклор экспедици
Отряд членнары: Х. Мәхмутов (отряд җитәкчесе), Ш. Зәбиров. Экспедиция әзейт
отряд 1956 елның 26 июленнән 29 августына кадәр Удмурт АССРның Юк

| 2 Кайсы пункттан килгән | 3 кайсы пунктка килгән | 4 колхоз исеме | 5 транспорт төре | 6 ике пункт арасы (км) | Жанрлар: 7 җыр | 8 халык көены | 9 сюжетлы җыр | 10 бәет | 11 табышмак, мәкаль | 12 әкият | 13 авыл … |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Глазов шәһәре | Юкамен районы | | авто маш. | 43 | | | | | | | |
| Юкамен районы | Засек (Дасес) авыл советы | „Урнәк" | —„— | 15 | – | – | – | – | – | 1 | – |
| | | | | | 4 | – | – | – | 4 | – | 1 |
| | | | | | 80 | – | – | 1 | 7 | – | – |
| | | | | | 90 | – | – | – | – | – | – |
| | | | | | – | – | – | – | – | – | 1 |
| | | | | | – | – | – | – | 4 | – | – |
| | | | | | 150 | [illegible] | – | – | – | – | – |
| | | | | | – | 7 | – | – | – | – | – |
| | | | | | 53 | – | – | – | – | – | – |
| | | | | | 25 | – | – | – | – | – | – |
| | Авыл буенча барысы: | | | | 402 | 7 | – | 1 | 15 | 1 | 2 |
| Засек авылы | Иманай авылы, Засек ав. сов. | „Урнәк" | автом. | 3 | 19 | 1 | – | – | – | – | – |
| | | | | | 31 | – | – | – | – | – | |
| | авыл буенча барысы | | | | 50 | 1 | – | – | – | – | |
| Иманай ав. | М. Венеш авылы Бадера ав. советы | „Красная звезда" | ат | 9 | 30 | 14 | – | – | – | – | |
| | | | | | – | | – | – | – | – | |
| | | | | | – | 4 | – | – | 13 | – | |
| | | | | | 16 | – | – | – | 7 | – | |
| | | | | | 31 | – | – | – | – | – | |
| | авыл буенча барлыгы | | | | 77 | 18 | – | – | 20 | – | |
| М. Венеш | Олы Палага Олы Палага | трактор | ат | 12 | 58 | 2 | – | – | – | – | |
| | | | | | – | 2 | – | – | – | – | |
| | | | | | 14 | 2 | – | – | – | – | |
| | | | | | – | 7 | – | – | – | – | |
| | | | | | 69 | – | – | – | – | – | |

...ар экспедициясенең 2-отряды язып алган материаллар отчеты.
...едиция җитәкчесе филология фәннәре кандидаты Х.Х. Ярмухаметов.
...АССРның Юкамен, Глазов, Балезино районнарында эшләде.

| н 10 бәет | р 11 табышмак-мәкаль | л 12 әкият | а 13 р авыл тарихы | 14 Материалны яздырган кешенең фамилиясе, исеме, атасының исеме. | 15 туган елы | 16 белеме | 17 партиялелеге | 18 профессиясе | 19 искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| - | - | 1 | - | Балтачев Хәйретдин Хисаметдин | 1923 | 4кл | - | колхозчы | |
| - | 4 | - | 1 | Балтачев Маннаф Сәгыйть ул. | 1873 | - | - | инвалид | |
| 1 | 7 | - | - | Балтачева Галия Гадельша к. | 1895 | - | - | колхозчы | 1 мәзәк ал... |
| - | - | - | - | Амирова Җәмилә Гыйльфан к | 1938 | 4 | - | —"— | |
| - | - | - | 1 | Балтачев Хәннан Гәләм у. | 1888 | - | - | инвалид | |
| - | 4 | - | - | Абашев Фирдәвес Җиһан ул. | 1945 | 4 | пионер | укучы | |
| - | - | - | - | Кутявина Людмила Алексеевна | 1939 | 6 | - | колхозчы | |
| - | - | - | - | Балтачева Сания Исмәгыйль | 1940 | 7 | - | —"— | |
| - | - | - | - | Бикманеурова Зәйнуп Хәеч | 1934 | 4 | - | —"— | |
| - | - | - | - | Балтачева Мәдинә Гыйльфан | 1933 | 4 | ВЛКСМ | —"— | |
| 1 | 15 | 1 | 2 | | | | | | |
| - | - | - | - | Бикташева Мәдинә Газизовна | 1940 | 9 | ВЛКСМ | укучы | |
| - | - | - | - | Байгузин Салах Заһри ул. | 1938 | 7 | —"— | колхозчы | |
| - | - | - | - | | | | | | |
| - | - | - | - | Абашева Маһинур Гыйльветдин | 1934 | 4 | ВЛКСМ | колхозчы. | фермада |
| - | - | - | - | —"— Рауза Бәдретдин | 1934 | 4 | —"— | —"— | |
| - | 13 | - | - | Арысланов Наиль Габделбари | 1937 | 10 | —"— | завклуб. | |
| - | 7 | - | - | Абашев Хәләм Гадельша улы | 1878 | - | - | - | |
| - | - | - | - | —"— Хаят Гайнетдин к. | 1906 | - | - | колхозчы | |
| - | 20 | - | - | | | | | | |
| - | - | - | - | Абашева Мәрмудә Зиятдин | 1941 | 8 | ВЛКСМ | укучы | |
| - | - | - | - | Абашева Нәфия Габделхак | 1928 | 7 | ВЛКСМ | авыл советы секрет... | |
| - | - | - | - | —"— Фәридә —"— | 1933 | 5 | —"— | колхозчы | |
| - | - | - | - | Авыл җырлары | | | | | |
| - | - | - | - | Абашева Рәшидә Исхак к. | 1933 | 10 | — | колхозчы | |

| 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 87 | - | - | - | - | - |
| | | | | | 17 | - | - | 1 | 4 | - |
| | | | | | 46 | - | 1 | - | - | - |
| | | | | | 10 | - | - | - | - | - |
| | авыл буенча барысы | | | | 301 | 13 | 1 | 1 | 4 | - |
| Олы Палага | Пученкә Ёжово ав. сов. | Большевик | ар. | 6 | 64 | - | - | - | - | - |
| | | | | | 20 | - | - | - | - | - |
| | | | | | 24 | - | - | - | 29 | - |
| | | | | | 8 | - | - | - | - | - |
| | | | | | 28 | - | - | - | - | - |
| | | | | | - | 9 | - | - | - | - |
| | авыл буенча барысы: | | | | 144 | 9 | - | - | 29 | - |
| Пученкә | Тат. Ключи (Тегермән) ав. Ёжово ав. сов | Большевик | ар | 3 | - | - | 1 | - | 56 | - |
| | | | | | 12 | - | - | - | - | - |
| | | | | | 28 | - | - | - | - | - |
| | | | | | - | - | - | - | 15 | - |
| | | | | | 20 | - | - | - | - | - |
| | | | | | 35 | - | - | - | - | - |
| | | | | | 25 | - | - | - | - | - |
| | | | | | 10 | - | - | - | - | - |
| | | | | | 10 | - | - | - | - | - |
| | | | | | - | 9 | - | - | - | - |
| | авыл буенча барысы: | | | | 140 | 9 | 1 | - | 71 | - |
| Юкамен районы буенча барысы: | | | | | 1115 | 56 | 2 | 2 | 139 | 1 |
| Тат. Ключи (Тегермән) | Тат. Парзи авылы Тат. Парзи ав. сов Глазов районы | „1-май" | маш. | 75 | 17 | - | - | - | - | - |
| Тат. Парзи | Кече Парзи Тат. Парзи ав. сов. | „1-май" | ар. | 5 | 13 | - | - | - | - | - |
| | Авыл советы буенча барысы: | | | | 30 | - | - | - | - | - |
| Глазов районы буенча барысы: | | | | | 30 | - | - | - | - | - |

| 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| – | – | – | – | Касимова Мәдинә Әхмәт к. | 1932 | 4 | – | колхозчы | |
| 1 | 4 | – | – | Абашев Габделхай Хушнаклар | 1895 | 10 | – | укытучы | |
| – | – | – | – | —"— Хисаметдин Низам | 1900 | – | – | инвалид | |
| – | – | – | – | —"— Лотфулла Әхмәтҗан | 1895 | – | – | колхозчы | |
| 1 | 4 | – | – | | | | | | |
| – | – | – | – | Таушева Рәйсә Хәлим к. | 1937 | 7 | – | колхозчы | |
| – | – | – | – | Есенеева Рәйсә Ибрагим к. | 1937 | 10 | ВЛКСМ | —"— | |
| – | 29 | – | – | Касимова Хәтимә Галәви к. | 1932 | 10 | —"— | укытучы | |
| – | – | – | – | Есенеева Җәмилә Шәех к. | 1940 | 7 | —"— | колхозчы | |
| – | – | – | – | —"— Рәшидә Әхтәм к. | 1938 | 9 | —"— | укучы | |
| – | – | – | – | Авыл яшьләре | | | | | |
| – | 29 | – | – | | | | | | |
| – | 56 | – | – | Арсланов Гомәрулла Нәсибулла | 1901 | – | – | инвалид. | |
| – | – | – | – | —"— Габделбар Әхмәт | 1893 | – | – | колхозчы | |
| – | – | – | – | —"— Гыйльфан Фәхретдин | 1887 | – | – | —"— | |
| – | 15 | – | – | Таушева Асия Нәсибулла к. | 1932 | 10 | ВЛКСМ | укытучы | |
| – | – | – | – | Арсланова Рәйсә Шәйдулла | 1936 | 10 | —"— | колхозчы | |
| – | – | – | – | —"— Фәузия Габделбәр | 1934 | 4 | – | —"— | |
| – | – | – | – | —"— Мәрзия Дәүләтша | 1933 | 4 | – | —"— | |
| – | – | – | – | —"— Мәрьям Габделбәр | 1937 | 7 | ВЛКСМ | медсестра | |
| – | – | – | – | —"— Нурзия Солтанман | 1940 | 7 | – | колхозчы | |
| – | – | – | – | Авыл яшьләре | | | | | |
| – | 71 | – | – | | | | | | |
| 2 | 139 | 1 | 2 | | | | | | |
| – | – | – | – | Касимова Җәмилә Ризван к. | 1935 | 4 | – | колхозчы | |
| – | – | – | – | Касимова Наҗия Хәмитулла | 1929 | 4 | – | колхозчы | |
| | | | | —"— Нәсимә —"— | 1929 | 4 | – | —"— | |
| – | – | – | – | | | | | | |
| – | – | – | – | | | | | | |



| 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Тат. Парҗи | Кистем ав. | Киров к-з | маш. | 57 | 151 | - | - |
| | Кистем ав. сов. | | | | 45 | - | - |
| | Балезино р-нп. | | | | 23 | - | - |
| | | | | | 58 | - | - |
| | | | | | 70 | - | - |
| | | | | | 84 | - | - |
| | | | | | ~ | - | - |
| | | | | | 30 | - | - |
| | | | | | 10 | - | - |
| | | | | | 30 | - | - |
| | | | | | 75 | - | - |
| | | | | | - | 5 | - |
| | Авыл буенча барысы: | | | | 576 | 5 | - |
| Кистем | Падера авылы „1-май" | | ат. | 17 | 60 | - | - |
| | Юнда ав. сов. | | | | 43 | - | - |
| | | | | | 60 | - | - |
| | | | | | 72 | - | - |
| | Авыл буенча барысы: | | | | 235 | - | - |
| Падера авылы | Эжмуди ав. „Йолдыз" | | ат | 15 | 36 | - | - |
| | Юнда ав. соверл. | | | | 32 | - | - |
| | Авыл буенча барысы: | | | | 68 | - | - |
| Балезино район буенча: | | | | | 876 | 5 | - |
| Удмурт АССРы буенча барысы: | | | | | 2021 | 61 | 2 |

Отряд членнары:

Глазов, Балезино районнарына оештырылган фәнни экспедициянең (1956 ел, 26 июль – 29 август) башкарган эше турында хисап. Экспедиция җитәкчесе – Х. Х. Ярмөхәммәтов

| 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| - | - | - | - | Касимова Фәһимә Даутовна | 1932 | 7 | ВЛКСМ | колхозчы | почтада |
| - | - | - | - | —"— Фатима Вәлиулла к. | 1931 | 7 | – | эшче | |
| - | - | - | - | —"— Сания Шәбгановна | 1932 | 4 | ВЛКСМ | колхозчы | |
| - | - | - | - | Мусина Фауза Габбас к. | 1933 | 7 | —"— | —"— | |
| - | - | - | - | Касимова Мәдинә Ахметҗан к. | 1935 | 7 | —"— | —"— | |
| - | - | - | - | —"— Зөләйха Хафиз к. | 1936 | 5 | —"— | —"— | |
| - | 9 | - | - | Касимов Вәлиулла Шәрәфи улы | 1897 | – | – | колхозчы | |
| - | - | - | - | Садикова Галия | 1924 | укучы | | дәүләттә тәрбиядә | |
| - | - | - | - | Касимова Сания Вәлиулла | 1933 | 7 | ВЛКСМ | колхозчы | |
| - | - | - | - | —"— Асия Дауд кызы | 1932 | 7 | —"— | —"— | |
| - | - | - | - | —"— Гөлҗиһан Шәмсетдин | 1910 | 7 | – | йортхозяйкасы. | |
| - | - | - | - | Авыл яшьләре | | | | | |
| - | 9 | - | - | | | | | | |
| - | - | - | - | Касимов Зариф Гайнулла ул. | 1940 | 7 | – | колхозчы | |
| - | - | - | - | Касимова Асия Габдулла к. | 1940 | 7 | ВЛКСМ | —"— | |
| - | - | - | - | —"— Зәйтүнә Заһретдин | 1939 | 7 | – | —"— | |
| - | - | - | - | Ляхина Нагия Мухаметҗан | 1927 | 10 | – | укучы | |
| - | - | - | - | | | | | | |
| - | - | - | - | Тюкина Минзада Гатауллина | 1941 | 4 | – | колхозчы. | |
| - | - | - | - | Касимова Асия Гариф кызы | 1931 | 4 | – | —"— | |
| - | - | - | - | | | | | | |
| - | 9 | - | - | | | | | | |
| 3 | 148 | 1 | 4 | язып алынды | | | | | |

1) [подпись] /. Махмутов Х. Ш. /.

2) [подпись] /. Забиров М. Х. /.

6/IX – 56 ел.

*385–395 битләрдәге ядкярләр Институтның*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондларында саклана.*
*Басмага Үзәкнең фәнни хезмәткәре Айдар Гайнетдинов әзерләде*

## Авторлар турында кыскача белешмә

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы*** – филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры.

***Шәрипов Ирек Илдус улы*** – Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты директоры.

***Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы**** – филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре.

***Баязитова Флера Сәет кызы*** – филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

***Булатова Миңнира Рәхим кызы*** – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

***Гайнетдинов Айдар Марсель улы**** – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре.

***Җамалетдинов Ленар Шәйхи улы**** – филология фәннәре кандидаты.

***Закирова Илсөяр Гамил кызы*** – филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

---

* Мәгълүматлар китапның беренче басмасы әзерләнгән вакытка бирелде.

***Каюмова Эльмира Ринат кызы**** – сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

***Мәхмүтов Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улы**** – филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

***Нуртдинова Дания Рамил кызы**** – Казан (Идел буе) Федераль универститеты Филология һәм сәнгать институты студенты.

***Рамазанова Дария Бәйрәм кызы*** – филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

***Фаррахова Илүсә Рәсим кызы**** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты.

***Шкляева Людмила Михайловна*** – сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

**ЭЧТӘЛЕК**

КЕРЕШ = ВВЕДЕНИЕ
*Ким Миңнуллин*
6

ҺӘР ТӨБӘКНЕҢ ҮЗ СЕРЕ
*Ирек Шәрипов*
26

ТЕЛ, ГАДӘТ ВӘ ӘХЛАК АЛМАШЫП
*Марсель Әхмәтҗанов*
30

ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНЕҢ РАУШАН КӨЗГЕСЕ
*Айдар Гайнетдинов*
78

ТЕЛ – МИЛЛӘТНЕҢ ҖАНЫ
*Дария Рамазанова, Миңнира Булатова*
98

«ЧИШМӘ КҮЗЛӘР КҮП БЕЗДӘ»
(Татар теле урта диалектының нократ сөйләше)
*Флера Баязитова*
150

ТӘГӘРИ КИТТЕ ЙОМГАГЫМ
*Илсөяр Закирова*
204

ҖЫРЛЫ ТӨБӘК
*Ленар Җамалетдинов*
219

ПЕСНИ ЖИВУТ ДОЛЬШЕ ВЕКА
*Эльмира Каюмова*
243

ОТ КОЛЫБЕЛИ ДО КРЫЛЬЕВ МЕЛЬНИЦЫ
Искусство резьбы по дереву у татар,
проживающих в районе реки Чепца
*Людмила Шкляева*
321

ИЗБА КРАСНА УГЛАМИ
*Илюса Фаррахова*
328

РОДИНА МАСТЕРОВ
*Дания Нуртдинова*
339

ҮТКӘННӘРГӘ КАЙТУ
*Хуҗиәхмәт Мәхмүтов*
352

ТАРИХЫН ҮЗЕБЕЗ ЯЗАБЫЗ,
КИЛӘЧӘГЕН ҮЗЕБЕЗ ТӨЗИБЕЗ
379

Научно-популярное издание

*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

**НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ**

**Татары Удмуртии**

2-е издание

Фәнни-популяр басма

*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

**МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ**

**Удмуртия татарлары**

Редакторлар *Я. М. Абдулкадыйрова, А. В. Әбдриева, Д. Э. Нигъмәтуллина*
Корректор *Л. Г. Шәрифуллина*
Компьютерда биткә салучы *Н. Т. Абдуллина*
Китапта *М. Р. Булатова, Х. Ш. Мәхмүтов, Э. Р. Каюмова, А. М. Гайнетдинов, Л. М. Шкляева, Д. Р. Нуртдинова, И. Р. Фаррахова* фоторәсемнәре файдаланылды

Басарга кул куелды 20.01.2021.
Форматы 60 х 84 $^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 20. Шартлы басма табагы 23,25.
Тиражы 500 д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан, Бауман ур., 20